# казан утлары

3
МАРТ-1974

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**3**

МАРТ
1974

## Бу санда

**Х. КАМАЛОВ.** Һәркемнең гомере бер генә. Роман . . . . . . . . . . . . . . . . 3
**М. ШАБАЕВ.** Ялта аһәңнәре. Шигырьләр . . . 50
**Ә. СИНЕГОЛОВ.** Таулар иле. Шигырьләр . . . . 57
**К. МӘРГӘН.** Солдат хаты. Хикәя . . . . . . . . 59
**Л. ШАКИРҖАНОВА.** Үземә кайтып төштем. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 65
**Ф. ГАЛИЕВА.** Урамнар була бормалы... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . : 66
**М. РУМЯНЦЕВА.** Чал чәчләр турында баллада . 67
**Н. НУРУЛЛИН.** Әгәр син булмасаң... Повесть . . 69

ДӨНЬЯ КЛАССИКЛАРЫННАН ТӘРҖЕМӘЛӘР

Имадетдин Нәсими газәлләре . . . . . . . . 129

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . 134
**И. АЛЕКСЕЕВ.** Олы юлга чыкканда . . . . . . 137

ИСТӘЛЕКЛӘР

**Г. МИНСКИЙ.** Дустым турында . . . . . . . . 142

ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ЛАБОРАТОРИЯСЕННӘН

**Г. ӘПСӘЛӘМОВ.** Кояш тотылганда табылган хәзинә . . . . . . . . . . . . . . . 148

МАТБУГАТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Анкета битләреннән . . . . . . . . . . . 164

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ VIII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

З. НУРИ. Яшьләргә — яшел урам . . . . . . . 169

КИТАП КҮЗӘТҮ

Х. САРЬЯН. Кыскалык — әдәби осталыкның бер шарты . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Т. МИҢНУЛЛИН. Тәнкыйтьчеләр өлгергәнче . . 182

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Ш. ГАЛИЕВ. Бакчада бәхәс . . . . . . . . . 184

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
*Редакциянең адресы: Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-36-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 14/XII-1973 ел. Басарга кул куелды 19/II-1974 ел. ПФ 09004. Кәгазь форматы 70×108$^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 89.000 экз. Заказ Л-226. Бәясе 50 тиен.

Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 12.

© «Казан утлары» 1974

Хисам Камалов

# ҺӘРКЕМНЕҢ ГОМЕРЕ БЕР ГЕНӘ

РОМАН

## I



Батарея командиры блиндаж алдында, планшетын ачып, нәрсәдер карап утыра иде, янына кыскарак буйлы бер лейтенант килеп туктады.

— Сугыш алласына сәлам! — диде ул шаян тавыш белән һәм иелебрәк комбатка кулын сузды, аннары шул уңайдан чирәмгә утырды. Комбат йөзен күтәрде, ике куллап күреште дә:

— Ә, җир наркомы, сәлам! — диде.

Бирелә, солдат фольклорынча, артиллеристларны «сугыш алласы» дип, ә пехотаны «җир нарком»нары дип ирештерәләр иде.

— Сез монда сәхрәдә, чын!..— Лейтенант блиндажны һәм тупларны яшереп торган чакалыкларга күз төшерде.

— Кая инде! Әнә!..— Арырак су белән тулган зур снаряд чокырлары ялтырый иде.

— Безгә фриц тәмәке тартырга да бирми, әз генә төтен күрде исә, кул минометыннан яудыра башлый.— Лейтенант гасабиланып җиргә төкереп куйды. Комбат ике кулын ике якка җәеп җибәрде, аңлыйм, янәсе, әмма берни дә эшләп булмый. Чыннан да биредә алар өчен оборона шартлары гаять авыр иде. Алда — тау тезмәләре, тауларның иң биек маңгаенда немецлар, ә уч төбе кебек күренә торган урта эргәсенә безнең пехота урнашкан. Җитмәсә, немецлар белән безнең беренче траншеялар арасы дүрт йөз метрдан артмас.

— Соң шушындый җиргә оборона кораларммы? — Лейтенант монда үзләреннән элгәре булган частьны тиргәп алды.

— Алар да мәҗбүрдән инде,— диде комбат.— Моннан алтмыш-җитмеш чакрымдагы Великие Луки кышын алынды. Немец бу тауларга оялагач, безнең һөҗүм уңышка ирешмәде.

— Һаман безгә начар оборона көчләп тага, денсез! — Лейтенантның аксыл битендәге вак кына кара нокталар кебек тутлары күз кырыйларына җыелды һәм йөзен караңгылатып җибәрде.

Алар аптыраган кыяфәттә, ни әйтергә белми, уйланып калдылар.

— Разведка белән тылына төшсәң, ә? — диде лейтенант аннары, малайларчарак хыялый бер төс белән.

Комбатның башак шикелле күпереп торган кашлары бергә килеп тоташты. Уйлап әйтәсеңме син моны дигәндәй, гаптәшенә текәлеп торды.

— Һе, каян?! Бөтен җирне бетон белән нygытканнар!

— Тау инеше үзәненнән,— дип, лейтенант, ниһаять, кабынып киткән тәмәкесен тәмләп суырды.— Буа буып, фрицлар су коенып яталар анда! — Ул тешләрен кысты, очлы яңагында бүлтәймәләр чыкты. Немецлар тәмам җелеген киптергәннәр аның. Бигрәк тә менә унҗидеунсигез яшьлек яңа өстәмә килгәч күзгә күренеп чәче агарды. Тиктормас, чытлык малайлар, йөз мәртәбә кисәтәсең, юк, онытылалар да немец снайперына азык булалар. Алар өчен командир башы җавап бирә...

— Ә ничек шәйләдең? — диде комбат, кинәт кузгалган кызыксыну белән.

— Алар да суны шул инештән эчә. Кайчак безнекеләр су алып торучы немец белән очрашалар, ә бер төнне су керүләрен үз күзләре белән күргәннәр.

— Ай-һай, азындылар! — диде комбат, күңелен төнлә залп бирергә дигән уй кымырҗытты, ләкин малайларча уй иде бу, позицияне дошманга сиздерү — баш китә торган эш. Әмма лейтенант һаман да үзенекен каерды, комбатка коткы салырга теләде:

— Әллә алла көчтәнәчләре белән сыйлап карыйсызмы?

— Ымсындыргыч та бит,— диде комбат, туры җавап бирмичә, үзе эчтән: ә бит позицияне алыштырырга була! Ялган позициядән ату иң отышлысы!..— дип уйлады. Лейтенант комбатның икеле сөйләвенә аптыраган сыманрак, җиңелчә елмайган килеш, сораулы карашын аңардан алмады. Ахырда комбат лейтенантны тынычландырырга теләгәндәй өстәп куйды:

— Тиздән сезгә барам! — Бу сүз шактый нәрсә аңлата иде, комбат тәфсилләргә яратмый. Лейтенант, сөйләшү бушка булмаганга куангандай, җавап урынына уң кулын козырегына куеп алды.

Комбат авырткан аягын тез турыннан ике учы белән күтәреп, җайлабрак куйды. Балтыр сөягендәге иске ярасы ачылган, эренләп, сулләнеп тора, шул нәрсә аны борчый, эчен пошыра. Бәйләтергә барырга кирәк, ләкин Семен Израилович ятарга алып калмагае дип шикләнебрәк тора... Әллә лейтенантның күңеленә кызык бер фикер килде инде, йөзе яктырып китте. Ул нindiдер бик мөһим нәрсә әйтмәкче булып, авызын ачкан иде, түбәннән, куаклар артыннан, сары чәчле бер баш күренде. Санбат сестрасы икән. Куаклар ышыгындагы сукмактан ул каядыр бара иде, боларга тап булды.

— Ә-ә, Римма,— диде комбат, кинәт җанланып һәм урыныннан тормакчы булып. Аның йөнтәс кашлары ягымлыланды, күз кырыйларына нур чыкты.

— Инпакетлар китергән идем, сезне искә төшердем,— диде сестра, ике ир-ат күзе текәлүдән бераз кызара төшеп.

— Эх, тагы сезне мәшәкатьләдем! — дип кул селтәде комбат, гафу үтенгән кебек һәм, уңайсызланып, кырынмаган битен учы белән сыпырды. Аның бөтен кыяфәтендә сестрага чиксез рәхмәт чагыла иде. Врач белән сөйләшүдән котылды болай булгач. «Патриот булу яхшы, ә яраны дәваларга кирәк»,— дип, каты төрттереп, аның ниндидер серен сизгән кебек, һәр вакыт көлеп әйтә врач. Ә комбат Алексей Барановның үз исәбе үзендә: зур вакыйгалар булырга тора, шундый чакта сыныкны сылтау итеп читтә каласы килми иде...

Сестра сумкасын актара башлады, комбат ашыга-ашыга күн итеген салды, галифе балагын тезенә кадәр сыдырып куйды. Лейтенант исә алгы сызыкта, ут эскәнҗәсе астында айлар буе ятып барысын оныткан да, хәзер генә үзенең ир-ат җенесеннән икәнен белгән кебек, кызга төбәлгән. Тик кыз бер дә каушап калмый, мондый гына күзләрнең утына күнеккән булса кирәк. Әмма аның тавышы әллә нинди баштан сыйпый торган, йомшак. Бәлки күптән хатын-кыз тавышы ишетмәгәнгә шулай тоелгандыр.

— Аягыгызны туры куегыз, иптәш капитан,— диде кыз һәм сумкасыннан сары риванол шешәсе чыгарды, даруны марляга агызды, пинцет очына спиртлы мамык элеп, яраның үлекләрен сөртеп алды, аннары комбатның аягы янына тезләнеп, зур бинтны сүтәргә кереште. Лейтенант, күзләрен тасрайтып, аның тар юбкасы аша беленеп торган аякларына карашын шудырып узды. Кыз да, бераз читенсенгән шикелле, учы белән итәгеннән чүп себергәндәй алдын сыпырып куйды.

— Капитанның йөрәген дә бәйләп алып китмәсәгез ярый инде,— дигән булды лейтенант, ниһаять, сүзгә кушылып. Аның бик сөйләшәсе килә иде бугай, дөресрәге, кыз белән үзе арасында яшерен сукмак та салып булмасмы, дип өметләнмәде микән?

— Үз йөрәгегезне кайгыртыгыз, иптәш лейтенант,— диде кыз, бер дә исе китмичә. Үзе әкрен генә ярага тампон куеп, бинтны урады.

— Минем йөрәккә дә чират тимәсме дим шул.— Лейтенантның күзләре чаткыланып китте.

— Йөрәген закладка салмакчы! — дип, капитан көлеп җибәрде.

— Нинди йөрәк бит, алдакчымы, әллә чын йөрәкме? — диде кыз, ике төрле уйларга урын калдырып.

Лейтенант әллә арага басма сузыламы дип, кызга карады, юк икән, кыз шаярта гына икән.

— Чын, тугры йөрәк!..— Лейтенант та, беркатлы булмаска теләп, тизрәк шаяртуга күчте.

— Кара, сестрага йөрәген бирмәкче? Еламассыңмы соң? — диде капитан тегеңәргә ымлап. Үзе тавышсыз гына көлеп, кызга карады. Ул да көлә һәм мондый тел яздыруга шат иде бугай.

— Кызлар безнең йөрәкне елатыр өчен алалармыни?

— Кайсы көлдерер өчен, кайсы елатыр өчен, бәхетең кемнән була бит,— дип, капитан бинт очын тотты, кызга булышты.

— Рас үзе теләп аяк астына ташлагач, ул йөрәкне кем санласын? — Кыз кеткелдәп көлеп куйды. Аның тешләре йөзе кебек үк матур түгел иде. Кызның куллары комбатның балтыры тирәли хәрәкәтләнде. Менә ул бәйләп тә бетерде.

— Эчкерсез булса, санларга кирәк! — диде лейтенант һәм кинәт җитдигә күчте:— Хәер, кызлар шуның киресен яраталар!

— Ихласны аңламыйлар димәкчесеңме? — Капитан бинт ураганнан соң юанаеп киткән чалбар балагын төшерде.

Ә кыз аның сүзен ишетмәмешкә салынды. Үзара гәпләшүне бирелдәге ир-ат халкы зурга ала, үзенчә бәяли, танышлыкка нигез итеп саный башлый. Бәлки кыз шуна сагаеп калгандыр.

— Терелегез,— диде кыз. Эшен бетереп, урыныннан торды. Әйберләрен сумкасына тутырды.

— Рәхмәт! — Комбат һаман шул аягы белән булашты.

— Китәсез дәмени? — диде лейтенант, ниһаять, үтенүле, шаярулы тавыш белән.— Әзрәк утырыгыз инде, юкса, без еларбыз.

— Еламагыз,— дип көлеп куйды кыз, сумкасын җилкәсенә элде, бер кулын өскә күтәрде, әзрәк башын ия төшеп саубуллашты да китеп тә барды. Бер минуттан ул куаклар артына китеп күздән югалды.

Болар да кинәт юксынып тынып калдылар. Ләкин тәннәре белән җирнең дерт итеп куюын тойдылар. Немец пушкасы телгә килде, авыр снарядларның чинап очканнары ишетелде. Икесе дә аларның юнәлешләрен шәйләп торды. Юк, моннан үтеп киттеләр. Кайдадыр «дыңк» итеп бәрелгәннәрен җир селкенүеннән сизделәр. Снарядлар сазга туры килде, шартлау тавышы ишетелмәде. Лейтенант яңадан тәмәке төрде, баштагы төпчегеннән аны кабызды да тирән итеп суырып тарта башлады.

— Ай-һай, чибәр, шайтан,— диде ул, төтенен өреп.

Капитан исә, аның бу сүзләрен бик үк өнәп бетермичә, ник булмас нәрсәгә тәмгыйны ымсындырып маташырга, дигән кебек, кулын гына селтәде. Лейтенант та моның белән килеште, маңгайлары җыерылды, кашлары өскә күтәрелде, аны ниндидер бүтән уйлар биләп алганлыгы күренеп тора иде.

— Синең белән «опер» кызыксынган, имеш? — диде ул, бераз кимсенгәнрәк чырай белән. Бу хәбәрне аның үзеннән ишетмәвенә бераз кәефе киткән иде, чөнки шундый серне дә ышана алмаслык булгач, начар дус, ахры, мин, дип уйлаган иде.

— Ә-ә, пустяк! — диде Алексей һәм тагы кулын селтәде.

— Эх, Алеша, сер сандыгы син...— Лейтенант дәгъвачыллыгын йомшарту өчен елмаеп куйды.

Капитан, аңа карагач, кинәт барысын да аңлады: Бикиев аның өчен чын күңелдән дусларча борчыла иде, шулай кайгырырга хакы да бар иде. Алар кыр госпиталендә ятканда таныштылар, дуслаштылар, бер-берсенә эчләрен ачтылар. Менә тагы икесе бер позициягә туры килделәр. Сугышчан тактика тәртибе буенча, лейтенант Бикиев ротасына капитан Баранов батареясы беркетелгән. Айга якын инде бер окоп төбендә дигәндәй ауныйлар.

— Син нәрсә, Бари? Просто минем 41 нче ел белән кызыксыналар.

— Әгәр сер булмаса, ни өчен?

— Теге елларны бергә булган бер шәхесне ачыклыйлар булса кирәк,— диде Алексей һәм бернинди дә хафаланырлык сәбәп юк дигән кыяфәт белән бинтлы аягын сыйпаштырды.

— Шулай да күңелсез.

— Оборонада озак яту галәмәте, чокчыналар.

— Эзләгән җирдән табыла, диләрме?

— Миңа нәрсә? — дип, комбат көлеп куйды.

Лейтенант моны Алексей сер бирергә теләми дип аңлады, ләкин төпченеп, кеше йөрәгенә керергә яхшысынмады. Шул чак комбатны телефонга дәшеп, блиндаж тамбурында элемтәче күренде.

— Мин Сакал янына барып киләм әле,— диде Бикиев кузгалып. Батальон командирын, гәрчә яшь, сакал-мыексыз булса да, искечәрәк фигыле өчен үзара шулай атап йөртәләр иде. Алексей башы белән ым какты да, бер кулына итеген тоткан килеш, ялан аягы белән чирәмнең салкын рәхәтлеген тоя-тоя, блиндажга кереп китте. Лейтенант аның бөкшәебрәк калган киң аркасына, көчле иңбашларына игътибар итте. Аннары Алексейның көлүен искә төшерде: сиздерми генә, нәрсәдер булган инде, «опер» тикмәгә казынмас дигән шөбһәгә килде. Егетне бутамасалар ярар иде. Сизүенчә, Алексей бөгелеп-сыгылып, кискен хәлдән елдырым гына котыла ала торганнардан түгел. Ул түзем табигатьле күренә, ләкин бөгелә-сыгыла белмәгән кеше тиз сынучан була... Бәлки әле пошаманга төшәрлек берни дә юктыр?..

Фронт язмышы туры китергән ул егетне Бикиев яратып өлгергән иде, шуңа күрә аны югалтасы, аңа тап төшерәсе килми, белүенчә, Алексей азагынача дөрес кеше, тик сугыш һич уйламаган хәлләргә дә дучар итүе мөмкин шул.

## 2

Караңгы бер станциядә аларны вагоннардан төшерделәр. Бик шыпырт булырга тырышып, озак кына бардылар. Алда кайдадыр тонык кына шартлау тавышлары ишетелде, офыкта ут ялкыннарының аҗаган кебек ялтырап китүе һәм кинәт сүнүе эчкә шом салды. Фронт сызыгының ерак түгеллеген сизеп, барысының да тынып калуы шомны тагы да арттырды.

Үләннәргә мул булып чык төшкән, шуңадырмы, төн бик яңгырау: юешләнеп авырайган аяклар лаш-лош атлый, табан астында чыбык сынуы, ботинкаларның ташка бәрелүе ишетелеп китә. Барган шәпкә Әнвәр күккә карады: йолдызлар ярмаланып-ярмаланып яналар, шул ук Суслонгердагы йолдызлар. Кинәт ниндидер мотор тавышы колакка бәреп керде. Фараларын яндырмыйча гына машиналар йөри, ахрысы, дип уйлады ул. Аннары гына бу тавышның күктән килгәнлеген искәрде. Ниндидер самолет аларның турыннан гына станция ягына очып үтте. «Самолетлар төнлә оча ала микәнни?» — дип шикләнде Әнвәр, ләкин күктә бер генә самолет түгеллеген шунда ук тавыштан чамалады. Кинәт: «Һава!!» — дигән команда яңгырады, строй җиргә сибелде. Якында гына каты шартлау йөрәкне яргандай итте, бөтен тирә-юньне дер селкетте. Бомбаның ачы сызгырып төшүе җанны телгәләде. Икенче шартлау тагы да якынрак булды, күздә ут чагылды, колак тонды. Өскә зур-зур кантар балчыклар төште. Әнвәр башын беләкләре белән каплады, бик каты куркып, урыныннан торды да бер иптәше янына барып ауды. Теге дә башын җиргә күмәрдәй булып бөрешкән иде. Әнвәр килеп ятуга, капылт кына торды да чапты. Тагы шартлау җирне тетрәтте. Әнвәр касыгына кемдер төрткән кебек сизде. Як-ягына каранды. Ул ялгыз иде, тагы да ныграк куркуга төште. Үзе дә белмәстән, берәр җан иясе эзләп кайдыр йөгерде. Кеше янында аңа куркынычсызрак булыр төсле тоелды. Әнвәр тагы теге егетне шәйләде, тагы аның янына барып ауды. Ул Актаныш малае, бер вагонда килгән иделәр. Әнвәр аның янынарак елышты. Ләкин теге егет Әнвәргә аягы белән тибеп җибәрде.

— Кит моннан! — дип сүгенде ул, теш арасыннан чыккан тавыш белән. Әнвәр күзләрен мелт-мелт итеп аңа карап торды, нигә куганлыгын аңламый иде ул. Тагы шартлау җирне актарды, теге сикереп торды да үләннәр арасында күздән югалды. Әнвәр аның артыннан бер тотам да калмады. Ул моны үзе аңлап эшләми, ә аңардагы ниндидер эчке көч, аның ихтыярыннан тыш, шулай хәрәкәтләнергә мәҗбүр итә иде. Бераздан икесе дә җиргә йөзтүбән капланып төштеләр.

— Ник тагыласың?! — дип еламсырады теге егет һәм тагы яткан килеш бик каты итеп аягы белән типте. Әнвәр аны сизмәгәнгә салышып, башын җиргә сеңдереп, көчкә тын алып ята бирде. Теге егет тагы моның кырыеннан каядыр читкә атылды. Әнвәр күрми дә калды, якында гына бомба шартлап, аны яртылаш балчык белән күмеп ташлады. Шул минут куркынычта укырсың дип әбисе өйрәткән догалар исенә төште һәм Әнвәр шуларны пыш-пыш әйтергә тотынды.

Бераздан шартлау тавышлары тынды, ерагайган мотор гүләүләре генә ишетелде. Төн караңгылыгы шактый сыекланган, офык буйлары яктылыгыннан тирә-якны, аяк астын ачык күрергә була иде инде. Әнвәр күзен ачып, башын калкытты: мин исән әле, дип чиксез сөенеп куйды. Аякларын тиз генә кымшата алмыйча азапланды, яралану ихтималы булганлыгын ул башына да китермәде. Азаплана торгач, ниһаять, бер аягын тартып чыгарды, ләкин обмотка сыерылып балчык эчендә калган иде, икенче аягын чыгару тагы да читенрәк булды. Ботинка кала, ахры, дип, көчәнә-көчәнә аягын тартты. Сеңерләре суырылудан күзеннән яшьләр атылды.

— Тезелергә! — дигән команда яңгырап китте. Бу команда Әнвәргә көч өстәгәндәй итте, ахыр чиктә икенче аягын да тартып чыгара алды һәм аксый-аксый иптәшләре янына килде. Кинәт җанлану, шау-шу купты. Егетләр бер-берсенең балчыкка, сөремгә буялган йөзләреннән көлешә-көлешә җыелдылар. Арада теге дөньядан кайткан кебегрәк өнсез кыяфәтлеләре дә күренгәли иде. Строй басынкы тавыш белән рәт санавы уздырды. Кырыктан артык кешенең һәммәсе дә исән-имин иде.

— Налет вакытында кем «әни!» дип кычкырды? — диде командир, строй уртасына килеп. Аның төк баскан яңак сөякләре кыймылдады, йөзендә ягымлылык шәүләсе чагылгандай булды. Күзләре дә мәрхәмәтле карый. Строй тын калды. Әллә мин кычкырдым микән дип уйлады Әнвәр дә курка-курка. Җавап бирүче булмады, киеренкелек хөкем сөрде, нәрсә булыр икән дип, Әнвәр командирның йөзен күзәтте. Менә-менә ул елмаер да егетләрне газаплаган хәлне җиңеләйтеп җибәрер. Ләкин командир елмаю түгел, һаман кырыслана гына бара шикелле. Ул, аска төбәлгән килеш нидер уйланып, строй алдында йөренде. Аннары ачыла башлаган чәчкә бөресе кебек алсу офыкка карап торды, тик аның соравына җавап кайтаручы булмады. Командир, туңган кебек, җилкәләрен селкетеп алды, йөзе ниндидер билгесез мәгънә белгертте, аннары ул төркем башына барды да стройны үзе артыннан ияртеп алып китте.

Әнвәр үзен типкәләп куган егет яныннан атлады. Аңа сүз кушасы килә иде: баягы кыланышы бик нык ачуын китерде. Дошман атканда бер кучкә өелмәскә дигән кагыйдә бар. Озынча йөзле бу егет шуның белән акланып, куркак җан диярме? Тик гел көтелмәгәнчә килеп чыкты.

— Син нигә миңа типтең? — дип, янаган кебегрәк әйтте Әнвәр, тавышын күтәрә төшеп.

— Якында булгач, газраил мине синең урыныңа алуы бар, тиле! — диде егет, каршы килмәслек каты итеп. Әнвәр авызына суккан кебек хис итте.

— Син үзең шыр юләр! Анаң яламаган! — дип, Әнвәр аның яныннан читкә тайпылды.

Төшкә таба алар зур гына бер урман аланына килеп туктадылар. Командир куе агачлар ышыгына эшләнгән блиндажларга таба китеп барды. Әнвәрнең күңеле меңтөрле билгесез өмет белән тулы иде. Хәер, кайбер өметләре билгесез түгел: менә хәзер көнлек ипине бирәчәкләр, ашатачаклар. Эчтә «оркестр» улый, теш казналары кычыта, авызда ниндидер тимер тәме. Шул исенә төште — сару кайнаган чакта аңа әнисе чалгы пычагы ялата да, кикерүе шунда ук бетә иде. Әнвәр шул пычак тәмен телендә тойды. Менә, әни, улыңның газиз башлары кай тарафларда йөри! Әнвәр үзен әнисеннән бик кызгандырасы килде. Өйгә салган хатларда үзенең газапларын күп арттырып яза ул. Әнисе аның өчен еласа, яшь түксә, аны исеннән чыгармаса, аңа солдатның авыр йөген күтәрү җиңелрәк булыр шикелле тоела иде.

Әллә кайдан командир килеп чыгып, ике солдатны үз янына дәште. Бу, әлбәттә, продукты алырга. Димәк, өмет чынга аша, дип уйлады Әнвәр, эчтәге «оркестры» тагы да ныграк улап куйды. Ул арада ике солдат алларына ипи, консерва төяп кайтып та җиттеләр. Чирәмгә шинель, бушлат җәеп, азыкларны бүлеш китте. Бигрәк тә ипи тәмле күренә, йөзен китереп, кызартып пешерелгән, карау белән авыз суларыңны китерә башлый. Егетләрнең күзләрендә шатлык очкыннары бии, һәркайсының күз алмаларында шул кызыл кирпеч икмәкләрнең шәүләсен күрәсең. Һәркайсының йөзе алдан ук туклык рәхәтен тоеп елмая сыман. Төнге бомбежкадан исенә килә алмыйча бөрешкән егетләргә дә җан керде, әх, ипекәй бар нәрсәгә дә баш шул, бар нәрсәгә дә җан өрә торган тылсымлы әйбер шул! Әнвәр бүленгән ипи кисәкләрен күзәтте,

кибән башы миңа булса иде дип ымсынды. Ләкин аңа ипинең йомшак җире эләкте, ничектер бүтәннәрдән кечкенәрәк сыман күренде. Учында гына сындырып, шунда ук кабып та җибәрде. Икмәк гаҗәп тәмле иде. Бу тоташ арыштан гына түгел, шулай ук тоташ бодайдан да түгел, катнаш булырга тиеш. Икмәк янына тагы өч борынга бер балык консервасы туры килде. Аның белән ипи тагы да әйбәт барды. Ашагач, үзеннән-үзе күз йомыла башлады. Әнвәр бер җиргә чирәмгә түнтәеп йоклап та китте.

— Тезелергә! — командасы колагына бәреп керүгә, ул янә сикереп торды. Тавык йокысы кебек кенә кыска черем дә тәнен җиңеләйтеп, авырткан буыннарын язып җибәргәндәй иткән иде.

Алар тезелгәндә, аланның теге ягыннан да, бу башыннан да болайга таба рота-рота солдатлар килә иде.

— Хәзер хәрби ант бирәчәксез,— дип аңлатты командир.— Сезгә зур җаваплылык йөкләнә, сезнең өчен хәрби законнар көченә керә.

Кайсыдыр шаяны көлеп куйды, командир аңа илтифат итмәде, җитди кыяфәттә моңсу гына карап торды. «Бу бала-чага барысын да аңлап бетерми, ярый, сугыш өйрәтер әле!» — дип уйлаган шикелле иде.

Аланның каршы ягына озын колонна тезелде. Бирге якта да ротарота яшь солдатлар басып тора. Һәммәсе яңа яшел киемнән, яшел чирәмдә тагы да яшь булып күренәләр. Урман эченнән югары чиндагы берничә командир чыкты. Алар мәйдан уртасына кереп бастылар. «Смирно!» дигән юан тавышлы команда, урманны яңгыратып, катлы-катлы булып ишетелде. Теге блиндажлар яныннан алтын укалар белән чигелгән зур кызыл байрак күтәреп, китель кигән солдат килгәне күренде, аның яныннан шундый ук сакчы иңенә автомат кысып атлый. Менә түгәрәк уртасындагы командирлар янына килеп туктадылар. Ә байрак шунда җилфердәп торды. Күзлек кигән бер лейтенант кызыл тышлы китаптан хәрби ант текстын укый башлады. Бер җөмлә укый да, туктап, аның артыннан барча строй кабатлаганны көтеп тора, борын очына төшкән күзлегенә бармагы белән төртеп ала. Аннан тагы укый, солдатлар аның артыннан тонык тавыш белән кабатлыйлар: «Мин Ватан өчен канымны, кирәк булса гомеремне дә кызганмый бирергә ант итәм! Әгәр антыма хыянәт итсәм, Ватан мине иң каты җәзага тартсын!» Иң каты җәзаның ату икәнен Әнвәрнең ишеткәне бар иде, ул бик нык куркып куйды, хыянәт итмәсәм генә ярар иде дип кайгырды.

Кайдадыр болытлар артыннан самолет тавышлары ишетелде. Командир күккә карап алды, тантаналы кыяфәттә антны укып баручыга нәрсәдер әйтмәкче иде. Тик шул вакыт күксел болыт эченнән берничә самолетның килеп чыкканы күренде, алар алан өстенә пике белән килә иде, ә теге баштарак инде балчык фонтаннары күккә чөелде.

— Юнкерслар! — дип кычкырды кемдер. Барча солдатлар, тилгән шәүләсеннән кычыткан арасына качкан чебешләр кебек, төрлесе төрле якка сибелделәр. Кемдер «ложись!» дип кычкырды. Көн караңгыланып, күкне төтен, сөрем, тузан каплады. Әнвәр баягы кебек үк шыр җибәрмәсә дә: «Беттем!» — дип уйлады. Куркынычта аның үзеннән алда йөри торган көчме, әллә шартлау дулкынымы аны бер чокырга очыртып төшерде. Ул башы белән каты гына бәрелүен тойды, миендә исәнмен икән әле, дигән уй чагылды. Якында гына тагы бомба төште, җир чайкалып китте, һавага туфрак баганасы күтәрелде, таш һәм балчык кантарлары, калай түбәгә боз яуган тавыш чыгарып, җиргә, өскә-башка коелды. Бераздан самолет тавышларының тынып калуы колакка суккан кебек тәэсир итте. Тик Әнвәр чокырдан башын калкытуга, ике яралы атның постромкаларын өстерәп җан-фәрманга үзенә

таба чабып килүен күрде. Туп-туры аның өстенә, пошкыра-пошкыра, күзләрен акайтып ыргылалар. Әнвәр нишләргә белмичә аптырап торганда, атларның берсе кинәт лапылдап җиргә ауды һәм икенчесен дә туктатты. Бусы өздереп кешнәп җибәрде. Кайдадыр ярдәм сораган тавышлар, ахылдаулар, әче итеп сүгенүләр, приказлар яңгырады. Урман эченнән ак халатлы сестралар носилкалар белән чабышып чыктылар. Озак та үтмәде, ак марляга чорналган башлар, куллар күренгәләде.

Әнвәр, торып, өстен кагынды, курыкканлыгын белгертмәскә тырышып елмайган булды, аннары иптәшләрен эзләп алан буйлап китте. Ул үзенекеләрдән бөтенләй икенче тарафка авышкан булган. Командирны теге баштарак очратты. Аның йөзе бик чытык, борчулы, карашы да керпеле иде. Әнвәр аның янына килергә куркыбрак торды. Кечкенә буйлы, нигәдер шатланган бер лейтенант үтешли кинәт туктады да командирга дәште:

— Кемне күрәм! Тукташев, синме?

— Мин,— диде командир аны танымаган кебек.

— Җылы пар белән! — дип, кинаяле шаркылдады лейтенант.

Командир, аңа дикъкат итмичә, үз карамагындагыларны барлыйбарлый тиз генә тезелергә боерды. Ә лейтенант нәрсәдер мыгырданды да китеп барды. Көтмәгәндә аланның басу белән тоташкан җирендә ут чүмәләсе күтәрелде. Саламмы, печәнме эскертләре яна булса кирәк. Ниндидер солдатлар шунда таба йөгерделәр. Командир, яралылар юкмы дип, исемлек буенча барлап маташканда, болар рәтеннән бер малай җәһәт кенә борылды да теге утка таба чабып китте, үзе нәрсәдер кычкыра-кычкыра йөгерә иде. Командир: «Стой!» — диде, теге аны ишетмәде дә, һаман чаба бирде. Бер кулына яшел капчыгын тоткан, икенче кулын пропеллер кебек һавада болгый-болгый элдерә. Командир яңадан: «Стой!» — дип кычкырды. Юк, теге һаман чаба. Утка җиткәч туктар дип, бөтен строй күзен шуңа төбәде. Чү, егет утка ук кереп бара. Йөрәкләр дерт итте. Командир, берәр хәвеф сизенепме, бар көченә янгынга таба атылды, артыннан солдатлары иярде. Теге тиле ут кырыеннан чабып йөри, капчыгы белән утка суга, үзе нидер кычкыра. Менә ул көтмәгәндә ут эченә таба талпынды һәм ялкыннар арасында югалды.

Тукташев, кабурасын салып атып, аның артыннан: «Назад! Назад!» — дип ямьсез акырды, кычкыруының нәтиҗәсе булмагач, үзе дә утка керергә мәҗбүр булды. Кемнәрдер сүгенәләр, солдатлар команданы тыңламыйлар, шушы тамашага өеләләр. Менә киемнәре яна башлаган Тукташев ялкын эченнән килеп чыкты, аңа кемдер шинель бирде һәм ул шуны киеп, яңадан ут эченә ыргылды, бер минуттан теге «батыр»ның гәүдәсен өстерәп чыгарды. Төркем «ах!» итте һәм чигенеп куйды. Әнвәр үлгәндер дип уйлаган иде, тере икән. Аяк-куллары белән чапалана бугай. Тукташевка ярдәмгә килгән өч-дүрт интендант гәүдәне тиз-тиз шинельләргә төреп, яшел палаткалар ягына алып йөгерделәр. Әнвәр тегенең төтәп барган ботинкаларын гына күреп калды.

Әнвәрләр төркеме ни уйларга, ни эшләргә белми тораташ булып торганда, ниндидер сержант килеп, сораштыра башлады:

— Әллә бераз «тегеләйрәк» идеме?

— Юк, андый түгел иде,— диде русча әйбәт белүче бер татар малае.

— Син авылдашымы әллә?

— Юк, без бер вагонда килдек.

Сержант тынып калды һәм бераздан иптәшенә:

— Шул, бомбага тотуны күтәрә алмаган! — диде.

— Ихтимал,— диде икенчесе.— Артподготовка вакытында безгә дә шулай ике немец чыккан иде. Карыйбыз, акылдан язганнар...

— Әйе,— диде сержант сузып һәм тирән көрсенеп куйды.
Ә утны саперлар килеп сүндерә башладылар, көрәкләр белән балчык ыргыталар. Тегендәрәкниндидер нечкә команда тавышлары чырылдап китте. «Тезелергә! Смирно!» — дигән боерыклар ишетелде. Әнвәрләр дә командирны көтәләр. Төрле имеш-мимешләр сөйләшәләр. Командирга бик каты эләгә инде моның өчен, диешәләр. Әйбәт иде безнең командир, дип үкенешәләр.
Ниһаять, бер старшина килде, боларны тезеп санатты да каядыр алып китте. Урманга алып барып, һәр взводка агач ботакларыннан шалаш ясарга боерды. Кич белән кайнар аш бирделәр, агачлар ышыгына җайланган ачык клубта «Антоша Рыбкин» дигән кино күрсәттеләр. Икенче көнне, төрлесен төрле частька бүләләп, алгы сызыкка озаттылар.

## 3

Сөенчалин күзәтү пунктына дежурга килде: комбатны тагы җыелышка чакырдылар. Алгы сызыкка беренче баруы булмаса да, уйлана калды: немец моннан биш йөз метрда гына. Җитмәсә, блиндаж да бер генә кат түшәп ясалган. Комбат йомшак, разведчикларны узындырган, түбәгә тагы бер кат агач тездермәгән, дип ачуы килде. Телефон янына утырды да үзенең бирегә килеп җитүе турында батареяга шалтыратты. Чак беленеп торган саргылт кашлары җыерылды, кәефе кырылганлыгы күренеп тора иде. Трубканы элемтәчегә биргәч, күзенә чалынган сержант Шиловка бәйләнеп китте.
— Немец парабеллумын йөртү тиеш түгел! — диде Сөенчалин.
— Дошманны үз коралы белән кыйнарга кирәк.— Шилов лейтенантны шаярта дип уйлады.
— Тиеш түгел, диләр сиңа! Уставны онyттыңмы? — Сөенчалинның тавышы калтыранып китте. Шиловка аның боеручан тавышы ошамады, кинәт үртәшәсе килде.
— Устав буенча бер карыш җирне дә дошманга бирергә тиеш түгел идек! Кая ул устав? — диде Шилов, бик тыныч булырга тырышып.
— Өстенә күпне алсаң, башыңа көч килер, егет! — Лейтенант, сержантның көтмәгәндә кабынып китүен тоеп, тавышын йомшартты, баягы ачуы да кайта төште.
— Һәркем өстенә алмаганга шушы хәл булган да! Һе!..
— Искене искә төшермә, Шилов.— Элемтәче бәйләнешеп китә күрмәсеннәр дип курыкты.
— Фиг иске, барысы да яңа!
— Ә тел өчен бит, Шилов, баш җавап бирә,— диде Сөенчалин, инде тыныч елмаеп. Әмма Шиловның туктарга исәбе юк иде.
— Һу-у,— дип, ачы көлгән тавыш белән әйтте ул.— Монда тыл түгел, ул яктан курыкмаска мөмкин!
Ишектә плащпалатка кыштырдады. Утлары караңгы яна иде, Сөенчалин шырпы сызды.
— Ә-ә, Сережа, сәлам! — диде Шилов керүчене танып аңа таба кузгалды.
Бу полк разведчигы Сергей Айкилдиев иде.
— Ник болай караңгы «тавык күзе»? — дип, ул түргәрәк узды.
Элемтәче сукыр лампаның филтәсендәге күмерне пәке очы белән кыргалап ташлады, шуннан соң блиндаж эче шактый яктырып китте.
— Безнекеләр тегендә Румыния чигенә чыкканнар! — диде Сергей горур тавыш белән. Зур шатлыгы аның эченә сыеша алмыйча тышка түгелә шикелле иде.

— Ә без һаман җир иснәп ятабызмы? — Шилов сорау белән Сөенчалинга карады, гүя һөҗүмнең кайчан башланасын ул төгәл белә дә әйтми тора. Әрепләшүнең аңарда эзе дә калмаган иде.

— Өстә уйлыйлардыр.

— Ә без кушканны үтәүчеләр генә, димәкче була лейтенант! — дип, Сергей шаярткан сыман әйтеп куйды.

Элемтәче исә җинү шатлыгын телефон аша бүтәннәргә ирештерде.

Кинәт безнең пехота җинел кораллар белән немец ягына ата башлады: Мылтык-автомат тавышлары, граната шартлаулары ачык ишетелеп торды. Сөенчалин траншеяга чыкты, бу хәлгә бераз аптырады, әллә немецлар безгә таба үрмәлиләрме, дип шикләнсә дә, янында басып торган Сергейга сүз катмады. Бераздан кинәт атыш тынды, шул арада немец радиорепродукторының ачык тавышы яңгырый башлады. Немецлар безгә каршы оборонада утлы корал белән генә түгел, тел белән дә көрәш алып баралар иде. Көн саен караңгылык иңү белән радио аша кычкырырга тотыналар. Саф русча сөйлиләр. Фрицларның әшәкелекләре бөтен дөньяга фаш булып барганда, шулай сөйләү соң дәрәҗәдә түбәнлек, батып барганда саламга тотыну, дип уйлап куйды Сөенчалин. Шул радионы юкка чыгарасы, изеп ташлыйсы килде. Безнекеләр тагы барлык кораллардан атарга тотындылар. Немец бер дә атмый, ара-тирә яшькелт ракеталар гына чөя. Ракета күктә тәлгәшләнә, берничә минутка әйләнә-тирә яктырып, җир өстендә һәммә нәрсәнең шәүлә сызыклары күренеп китә. Тәлгәшләр мөлдери-мөлдери җиргә төшәләр, аннары берәм-берәм сүнәләр...

Немец радиосының тавышы ачыграк булып ишетелә башлады. Сөенчалин Сергейга төрттерми түзмәде.

— Сине, разведчик кешене, шушы Геббельс үчекләмиме? — диде ул, немецның оятсызлыгына ишарәләп.

— Канга тоз салу инде! — Сергейның тавышы ачынулы, шелтәле иде.

— Тончыктырып булмыймы?

— Пеленгатор кирәк,— диде Сергей, әллә шуны да белмисеңме дигән кебек итеп.

Сөенчалинның ул хакта ишеткәне юк иде, үзенең наданлыгын белгертәсе килмәде, шулай да беләсе килү аның күңелен кытыклады. Нинди серле корал икән ул?!

— Беркатлыларга хисап тоталар! Шалишь! — диде ул, белмәгәнен яшерер өчен.

— Ә беркатлылар азмы?

Шул вакыт һавада немецча сүзләр яңгырады. Безнекеләр дә дошманның үз ысулы белән немецларны үгетләргә тотындылар. Сөенчалин әз-мәз немецча аңлый иде, Сталинград, генерал дигән сүзләре колагына керде. Плен төшкән генерал чыгыш ясый булса кирәк. Соң безнең тарафтан бу өндәүләр нигезле дә, кешелекле дә, без үз җиребезне азат итәбез! Ә немецның җиңелүе хәзер һәркемгә ачык.

— Моңа чиертүчеләр бармы икән? — диде Сөенчалин, безнекеләрнең нигезле үгетләүләренә чиксез сөенеп. Сергей югарырак урында чуала торган кеше булгач, хәбәрдар дип фикер йөртте ул.

— Кем белә,— дип, Сергей әкрен генә әйтеп куйды.— Немецны уйга төшерү кыйммәт!

— Әйе, немец ахмак әле!

— Ну, үз башларына! Үлемнән куркуга караганда фюрердан ныграк куркалар.

— Әх, шул куркуны! — дип ачынып әйтеп куйды Сөенчалин да.— Һәр кешенең эчендә курку ята. Немецларның бөтен гамәле шуңа хисап тотып эшләнә. Кешене куркытып ерткыч хәленә китергән гитлерчылар нәрсәгә исәп тоталар? Нәрсә дәгъва итәләр?..

Безнекеләр радио тавышын көчәйттеләр, немецларныкы да ярыйсы ишетелә. Диалог дәвам итте, дошман куралатә ялганлый, алдаша, безнекеләр тик хакыйкатьне генә сөйли.

Немецлар тагы ракета чөйделәр. Тау кырыендагы агач-куакларның киртләч-киртләч шәүләләре калкынды. Алгы сызык әллә нинди серле дөнья кебек булып тоелды. Радио тавышлары билгесез ике гигант шәүләнең бер-берсе белән нәрсәдер сөйләшүләре, сүз көрәштерүләре шикелле иде. Шул тавышларны күмеп, сулдарак немецның кул пулеметы тыкылдады: ток-ток-ток, нәкъ трактор моторы сыман. Сөенчалин моны куана-куана искәрде, тик тарафын гына төгәл шәйли алмады. Тирә-як чаукалык-урман, тавыш яңгырап бутала иде.

— Кай төштәрәк? — диде Сөенчалин, Сергейга таба борылып.

— Тау инеше үзәнендә бугай...

— Ул таулар илле-алтмыш чакрымга сузыла. Кызык, һәр таудан диярлек инеш агып төшә.

— Бу позицияне генә дә ике инеш кисеп үтә.

Безнең пехота атудан тынган бер мәлдә сул яктарак немец пулеметы телгә килде. Ул өзек-өзек «тырт-тырт» итеп куйды, һавада утлы сызыклар сызды, зәңгәр җирлеккә кызыл җеп белән чигү чиккән сыман итте. Аннары уң флангтанрак икенче пулемет тырылдап алды.

— Әнә, кызыл карандаш белән имзасын селтәде, күрдеңме? — диде Сергей.— Бусы баш пулемет булырга кирәк. Барысы да тәртиптә дип әйтте бугай. Пулеметлар аша да сөйләшәләр.

Сөенчалин, пулеметларны картада ничәнче квадратка билгеләргә икән, дип баш ватып торды. Сергейдан сорарга кыенсынды, чөнки теге үзен шактый һавалы тота иде. Шулай да Сергей белән сөйләшәсе, дуслашасы килә. Ул зур начальниклар тирәсендә күп була. Алар бу мәхшәрнең кайчан, ничек бетүе хакында сөйләшәләрдер. Аннары немецлардагы шул чаклы ерткычлыкның каян булуын беләсе килә аның.

— Немецларда блат бармы икән? — диде ул, Сергейга табарак елышып.

Сергей уйланып торды, җилкәсен җыерып куйды һәм шунда ниндидер сер белгәнлеге чагылып калды.

— Полкның «смерш»[1] начальнигы үзе Германиядә булган, ахрысы, тик белгертми. Аның сөйләгәне бар: туган-тумачалык, ашнәлек юк ди немецларда.

— Тәртип бик каты, димәк.

— Һәрбер кеше күзәтү астында икән. Укыганрак кешеләр бигрәк тә. Күзәтүчеләр дә үзләре арасыннан, ди.

— Ягъни берсе икенчесен барып әйтә?

— Нәкъ шулай. Шәхси карточкаларына язылып барыла, ди. Менә ничек оештырылган!

— Гаҗәп: аңлы кешеләр үз-үзләренә шулай эшләсеннәр инде, ә?

— Ни кыра аласың? Кем күбрәк органнарга барып әләкли, шул бүләкләнә, әйбәт эшкә, тылга урнаштырыла, ди.

— Юк, юк, алай ук булмас,— диде Сөенчалин ышанмыйча. Әмма ышанмаска да мөмкин түгел иде.— Ничек инде тоташ берсен-берсе чагуга көйләнсен?

---

[1] «Смерш» — контрразведка.

— Немецлар фанатиклар, беләсең килсә. Аларның күңеле шуны теләп тора.

— Күңеле теләмәгәне дә бардыр. Әнә, немецның кайбер снарядлары төшә — ярылмый.

— Сазлыкка эләксә, ярылмый, әлбәттә.— Сергейның тавышы, ай-ай, син беркатлы дигән кебегрәк чыкты.

— Бер төнне шулай ничектер үлеп йоклаганбыз. Иртән торып карасак, блиндаж кырые чүмәлә чаклы бүлтәеп тора. Нәрсә булыр бу, дибез. Төнлә безне немец кукурузнигы бомбага тоткан икән. Ничек төгәл туры китерүен әйт син! Ә бомба шартламаган! Шартласа унлап кешенең көле күккә оча иде. Ә кап-каты ташлы җир! Бу очраклы түгел инде!

— Немецның уйлана башлавына ышанып булмый.

— Гаделсезлек халык арасында каршылык та тудырырга тиеш, югыйсә...

Алар янына Шилов чыкты. Сергей кырыенарак килеп басты һәм аңа бик ышанган кыяфәттә үзенең кайгысын сөйләргә керешге.

— Елдан артык Ленинградта калган әни белән сеңелне эзләтәм, һич очына чыгып булмый,— дип зарланды ул.

— Эвакуация белән китмәделәр микән соң? — Сергейның тавышында аның хәленә керергә теләүчәнлек ишетелде.

— Берсе болай яза, икенчесе — гел башкача. Әй, буталчык.— Шилов, өметен җуя башлаган кебек, кулын селтәде. Аның бу гаҗиз кыяфәте Сергейга шунда ук тәэсир итте.

— Беләсеңме нәрсә? «Смерш» начальнигы минем таныш кеше, әниләреңне шулар аша эзләтсәк, ә?

— Тыңлар микән соң?

— Мин аңа шундый шәп бер эш эшләдем, ул миңа үзен бурычлы саный,— диде Сергей, тавышына бер дә мактану кушмыйча.

— Аларның элемтә көчле инде, тиз табарлар,— дип, Сөенчалин да өстәп куйды.

Шилов кай арададыр күреп тә өлгергән, траншеядан килүче кешегә кычкырды.

— Пароль?

Теге парольне әйтүгә, бирелгеләр бу кешенең рота командиры Бикиев икәнлеген танып алдылар. Аның пехотасы моннан егерме-утыз метр алдарак урнашкан иде.

Шиловны сакка калдырып, алар блиндажга керделәр. Сөенчалин сумкасыннан карта чыгарды, Сергей да куен кесәсеннән ниндидер кәгазьләр алды. Пулемет нокталарын билгеләргә кирәк иде.

— Теге имза селти торган пулемет сигезенче квадратта,— диде Сергей.

— Юк, унберенчедә,— дип, Сөенчалин аңа каршы төште. Алар бәхәсләшә башладылар.

— Һөҗүм башланганчы пулемет ояларын кырыкмаса-кырык мәртәбә алыштыралар,— диде Бикиев, ник юкка «тәпәләшәсез» дигән сыман.

— Артиллерия барысын да белергә тиеш. Бөтен ояларны да туздырмасак, окобыннан баш күтәрә дә алмыйсың бит! — Сөенчалин Бикиевкә сәерсенеп карап алды һәм картасына билгеләр куюын дәвам иттерде.— Пехота өчен тырышабыз, ә ул!..— дип кызып китә язды.

Бикиев исә урынсызрак әйтеп ташлаганын аңлады һәм, иптәшләренең күңелләрен табар өчендерме, үзе дә картасын чыгарды.

— Мәгез, монда да күп ул «оялар»,— дип тегеләргә сузды.

— Менә бу, ичмаса, дусларча! — диде Сөенчалин шатланып, картаны җентекләп өйрәнергә кереште. Андагы тамгаларны үзендәгеләр белән чагыштырып барды, «әһә», «әһә» дип бик канәгать булып кинәнде.

Сергей да бик канәгать иде:

— Отчет сораучыларның да сусынын басарга җитәрлек монда,— диде ул. Сөенчалин тагы төпченде:

— Бирәдә инеш яры, пулемет куйганнармыни?

— Немецлар анда инешне буып, су коенып яталар! — Бикиев авыз кырые белән генә кинаяле итеп көлемсерәп куйды.

— Соң, эссе өстәргә кирәк! — диде Сөенчалин бер дә икеләнмичә. Ул, Бикиев йөзенә текәлеп, эшнең нәрсәдә икәнен чамаларга теләде. Әй, куркаклар, дигән фикерләр башыннан узды.

— Тәвәккәлгә тәгъзим кылыр идем,— диде Бикиев.

— Тоткарлык нидә соң? — Сөенчалин тагы да кызышып, дәртләнеп әйтте. Бу чаклы отышлы хәлне ычкындыруны аңлап җиткерми иде ул.

— Мин, комбатка шалтыратып, ут сорыйм,— диде Сөенчалин һәм телефонны алды.— Цель ничә? — Бикиевкә карады — аның чыраеннан өмет юк дигән мәгънә аңлашылып тора иде. Батареяда комбат юк, замполит Ваһапов кына булып чыкты. Сөенчалин аңа хәлне бик кайнарланып аңлатты. Тик сөйләшү соңында кече лейтенантның йөзе сүрәнләнеп калды. Ваһапов берничә каршы сорау белән аның ялкынына су сипкән кебек итте.

— Ул эшнең арты кортлырак шул,— диде Сергей, телефондагы диалогның асылын аңлап. Сөенчалин трубканы куйды да Бикиевкә карарга уңайсызланыбрак торды.

— Көрчеккә терәлдек, фрицны песиемлибез,— дип, Бикиев ачы итеп көләргә тотынды.

— Позицияне белгертү — хәтәр.— Сөенчалин Ваһапов фикерен кабатлады, тавышыннан аны яклавы аңлашылды.

— Пушкаларны күчерәсең! — Бикиев көлүдән туктады.

— Ансат кына синә, күчерерсең, бар.

— Ул немецтан курыкмый, нәчәлстводан курка,— диде Сергей, әллә Ваһаповны әйтте, әллә Сөенчалинга төрттерде. Киеренке тынлык урнашты. Сөенчалин сумкасыннан ике банка кызыл балык консервасы чыгарды, берсен элемтәчегә ыргытты, икенчесен пәке белән кытыр-кытыр китереп ачты, ашарга кыстады. Болар ялындырмадылар.

— Әлеге дә баягы — башта немец таягы,— дип шаяртты Бикиев, кашыгын алып.

Сергей пәке очы белән чемченеп маташты.

— Минем абый бер полк штабында, үзенә чакыра,— диде ул, гаять ымсындыргыч һәм тәмле итеп. Үзе бик канәгать, горур елмайды.

— Нигә бармыйсың? — диде Бикиев Сергейга ышанып җитмичәрәк,— шундый мөмкинчелектән кем инде файдаланмый? — Сергей һаман елмайган килеш эндәшми торды.

— Браты белән дан бүлешәсе килми,— диде Сөенчалин икеле-микеле.

— Ну, ахмак! — дип, Бикиев кашыгын күн кыныга салып куйды һәм Сергейга карады. Ул аның йөзеннән: чын сөйлиме, әллә ялганлыймы икәнен белергә тели иде.

— Җибәрмиләр! — диде Сергей бәясе зур кеше кебек.

Бикиев тәмәке төрергә тотынды. Самолет тавышлары ишетелде. Ишектә Шилов күренде.

— Җанкайлар төнге сунардан кайта,— диде ул, бер кулы белән күккә ишарәләп. «Кукурузник»лар Опочка тимер юлын бомбага тотып кайтып киләләр иде булса кирәк. Ә очучыларның барысы да кызлар икәне мәгълүм инде.

— Фәрештәләр,— диде Бикиев.

Сөенчалин, самолетларны карарга дип, тиз-тиз атлап чыгып китте.

— Әйтмә дә инде, нәкъ үзләре.— Караңгыдан аның кеткелдәгәне ишетелеп калды.

— Үлем фәрештәләре диген!

Сергейның күзләре очкынланды, карашында очучы кызларның серләрен белгәнлек чагылды.

— Берәрсенең канат җиле тиеп күңелеңне җилкендердеме әллә? — диде Бикиев шуңа ишарәләп. Тыл халкының кызлар полкын атакалавын ишетә белә иде ул.

— Кая! Әнә бит ни белән коралланганнар!..

— Бер карауга ук аяктан егалар диген...

Алар көлешә-көлешә блиндаждан чыктылар. Бикиев траншея эченнән алпан-тилпән атлап китеп барды. Сергей Сөенчалин янынарак барып сөялде: «Геббельс» сөйләүдән туктаган, безнекеләр дә тынган. Таң атып килә. Көнчыгыш тарафта, офыкта, ярадан кан аккан төсле, тар-тар кызыл тасмалар сызыла башлаган иде.

Кинәт авыр ыңгырашкан аваз ишетелде, шунда ук траншеяга нәрсәдер бик нык ышкылып килеп төште. Карасалар, бу бер яралы пехотачы икән. Ул аркасы белән ауган да терсәкләренә таянып, торырга азаплана. Күзләре йомылып бара, күз кабакларын күтәрерлек тә көче калмаган, каты яраланган булса кирәк. Сергей белән Сөенчалин аның янына килделәр.

— Снайпермы? — дип, йөзе турына иелделәр. Солдат эндәшмәде, йөрәк өзгеч итеп ыңгырашты гына. Сергей каешыннан баклашкасын алып, капкачын борып ачты да тегенең авызына китерде. Бу — аракы иде, ахры, бер минуттан солдат күзләрен ачты. Сергей аның сырмасын ычкындырып, ярасын эзләде, ләкин таба алмады. Солдат саташып сөйләнә башлады:

— Әх, башым әйбәт эшли иде, әрәм була инде! Башлыклар гел миңа киңәшкә киләләр иде. Паша, брат, без кая йөзәбез, ә? — Ул боларны үзенең иптәшләре дип белә бугай.— Әйе, гомер буе кешеләргә яхшылык кына эшләргә теләдем, ләкин гел начарлык булды бугай. Әх! Фу, шайтан! — Аның ике күзеннән яшь ага да ага, бөтен йөзен чылатып бетергән.— Командир, әх, син мине сагынырсың әле! Сагынырсың!..

— Кем синең командирың? — дип сорады Сөенчалин.

Солдат аны ишетмәде, һаман үзенекен сөйләнде:

— Мине тыңламадыгыз, әх, тыңламадыгыз, менә ничек булып чыкты?!. Ярар, Паша, мин кешене яманлый башладым, сволочька әйләндем, син ачуланма! Без кайсы ярга йөзәбез, ә?— Ул тынып торды, аннары гырылдаган авазлар чыгарды, кинәт башы бер якка ауды һәм күз төбе чокырына җыелган күз яше чайкалып, йомрыдан түгелгән кебек түгелде.

Немец кечкенә минометтан атарга тотынды: траншеядагы сугышчыларның каскаларын шәйләгән, ахры. Сергей тизрәк Сөенчалинны иңеннән тотып, блиндажга тартты. Шилов трубкасын башына бәйләп куйган килеш йоклый, икенче элемтәче дә изрәгән. Сөенчалин аларга дәшмәде, аңа үлгән солдатның сүзләре бик нык тәэсир иткән иде. «Барыбыз да ут эчендә йөрибез анысы, дип уйлады, үлемеңне зурга кую ничектер уңайсыз! Ә нигә?»

— Немец әллә һөҗүм итмәкчеме? — диде Сергей.

— Буламы соң? Ныгытмаларыннан чыксалар, аларга Гитлер капут!

— Нарва — Опочка — Псков линиясе Маннергейм линиясе кебек дип мактаналар шул.

Ату туктады, аннары тагы кабатланды. Блиндаждагылар рәхәтләнеп йоклыйлар иде. Инде яктырды, көн башланды, биредә бөтен хәрәкәт икенче төнгә хәтле тынып калды.

### 4

Комбат янына «опер» килеп китүен ишеткәч, Ваһапов бик нык шиккә төште. «Нәрсә була инде бу? Мин берни дә белмим. Ә бит иң элек мин, замполит, хәбәрдар булырга тиеш».

Ваһапов, уңайсыз булса да, комбатның үзеннән сорарга исәпләде, ләкин Алексей алгы сызыкка киткән иде инде. Ярый, андый читен сүзне телефон аша сөйләшү җайлырак була, чөнки кешенең йөзен күрмисең, дип уйлады ул һәм элемтәчеләр блиндажына килеп, трубканы алды.

Алексейның бер дә сөйләшәсе килми иде. Ваһапов, турыдан суктырып, тегене бераз кытыклагандай итте:

— Синең анда бик җитди эшләр килеп чыккан, ахры, ә мин берни белмим,— диде ул.

— Нинди эш тагы?

— Җиденче бүлектән килгәннәр икән сиңа.

— Ә-ә, ул болай гына, бер шәхси эш шунда.

— Мин аны белергә тиеш дип уйлаган идем.

— Ялгышрак уйлагансың.— Алексейның тавышында бераз ачу һәм кинаят чагылып калды.

— Син нәрсә ачуланасың әле? Мин сине кайгырткан булам тагы.

— Үзеңне кайгыртасың, Ваһапов.

— Син әллә мине аңламыйсыңмы?

— Аңлыйм. Сәяси сизгерлек күрсәтмәкче буласың. Шул яктан мин вазифама туры килмим икән... Андый эшләр гел «сине кайгырту» маркасы астында эшләнә.

— Юк, аңламадың, Алексей,— дип көлде Ваһапов сер бирмәскә теләп.— Син нәрсәгәдер бүген бик шырпылы.

— Алгы сызыктагы урыным өчен курыкмаганымны беләсең, шуңа әйтәм. Әгәр мине тәрбияләргә теләсәң, әйдә, рәхим ит.

— Үлем сызыгында аның мәгънәсе булыр микән? — Ваһапов ничек тә араны йомшартырга тели иде. Сөйләшүнең мондый төс алуын көтмәгәнгә, сүз кузгаткан өчен үкенә башлады.

— Ә кеше йөгенә керергә тырышуның ни мәгънәсе бар?

— Мин алай дип белмәдем, Алексей, чын! — Ваһаповның ничек тә акланасы килде.

— Мин сиңа ачуланмыйм, чөнки болар синең сүзләрең түгел...

Шулай дигәч, Алексей трубканы куйды, Ваһаповка чыбык өзелгән сыман тоелды. Блиндаждан чыккач кына ул Алексейның «синең сүзләрең түгел» дигәненә дикъкать итте. Ягъни югары начальниклар тирәсендә күп чуаласың дип әйтмәкче ул.

Шуннлыктан бу сүз Ваһаповның эчен тырнап алды. Алексей минем үзен ничек хөрмәт иткәнемне белеп җиткерми әле, дип уйлады. Эх, аңламады, кеше синең чын теләгеңне киресенчә итеп кабул итсә, бик авыр икән! Алексей әле шуны абайлап бетерми, бер яман атың чыкса

бит, батареяга да начар булачак. Яңа өстәмә килгәндә дә, боеприпас белән тәэмин иткәндә дә безне читләтебрәк үтәргә тырышучылар табылыр. «Ә-ә, теге комбатмы?»,— гына диярләр.

Ваһапов дивизионга, начштаб ярдәмчесе Яким Зиновьевич янына барды. Алексейны яманламаска тырышып, читләтеп-читләтеп кенә сөйләп бирде. Яким Зиновьевич чыш-пышны тыңларга бик яратмаса да, аның сүзләренә колак салмыйча булдыра алмады, чөнки Ваһаповны үзе җитәкче урынга күтәргән иде ул.

— Шулаймыни? Берәр гөнаһы бардыр, ихтимал,— диде Яким Зиновьевич, бу хәлгә исе китмичә.

— Үзе шәхси эш кенә, ди, кеше күңеле — караңгы бит ул. Ваһапов Алексей белән никтер уртак тел таба алмавын уйлап куйды, айга якын инде алар — бер батареяда, ә борчаклары һаман пешми.

— «Опер»лар шәхси эш белән маташмыйлар иде бугай,— дип, Яким Зиновьевич Ваһаповка карады. Йөзендә аның борчылуын аңлаганлык чагылгандай булды, шул ук вакытта: «Әй, син, агач матрос, нишләп үз комбатың белән аңлаша алмыйсың!» дигән шелтә дә бар кебек иде. Яким Зиновьевич үзе эшлекле кеше һәм бүтәннәрдән дә эш таләп итүчән. Шуңа күрәдерме, шактый кискен холыклы ул. Ваһапов менә хәзер кызып китә дип көтте. Юк, ачуланмады тагы. Киңәш иткән кебек итеп, әмма каты гына әйтте:

— Комбатка синең йогынтың нык булырга тиеш.

— Мине бик тыңлыйсы килми аның.— Ваһапов болай диярга теләмәгән иде, әллә ничек әләкләү шикелле була бит, авызыннан ычкынды шул инде.

— Ә син тыңларлык ит. Мәсәлән, миңа ахмак киңәш бирәләр икән, нигә тыңлыйм мин аны?!

— Мин үземчә акыллы дип саныйм да соң.

— Үз кубызына биетергә уйлыймы әллә? Андый комбатлар да була. Бик теләп биючеләр дә табыла.— Яким Зиновьевич, йодрыгын язып, бармакларын биетеп алды.

— Андый фигыле сизелми сизелүен дә...— Ваһапов тагы ялгыш сүз ычкындырудан үзен тыеп калган кебек булды. Яким Зиновьевич исә «бии» башлаган икән диебрәк аңлады.

— «Бию» җиңел, уйлап азапланасы юк. Ни кушалар, шуңа чап. Эх, баш эшләтергә ялкаулар без...

— Боерганны яратып бетерми...

— Ә син боерма. Кыскасы шул, Ваһапов, мин сиңа комбат хакында бернинди дә күрсәтмә бирмим. Бер пот тоз аша, әмма комбат белән боткаң пешәрлек булсын. Китәргә мөмкин! — Яким Зиновьевичның йөзендә кырыслык чаткылары күренде. Ул тип-тигез итеп кырган ак башын кулъяулыгы белән сыпырып алды һәм өстәлендәге кәгазьләрне актара башлады.

Ваһапов та тиз генә чыгып китте. Нәрсәгәдер бу бүген үтә кырку иде, килгәнне яратып бетермәде, ахрысы, дип уйлый-уйлый атлады ул.

Шулай да ул махсус бүлек кешеләре белән очрашу Алексейны каты гына борчуга салгандыр, ә бит миңа берни белгертмәде. Астыртынмы, әллә миңа ышанып җитмиме? Әллә үзенең бәлаләрен бүтәннәр белән бүлешергә яратмыймы?

Ваһаповның ишеткәне бар иде: төньякта бер-берсе белән таныш булмаган этләрне, поход чыгар алдыннан, чанага җиккәнче, иң элек талаштыралар икән. Кайсы эт барысын да җиңеп чыга, шуны баш итеп җигәләр. Ә җиңелгән барча эт аңа берсүзсез буйсына икән, яңадан талашу инде булмый, ди. Яким Зиновьевичның соңгы сүзләре

шушы хәлне искә төшерде. Ике кеше бер йөккә җигелгәндә дә моңа охшашрак нәрсә килеп чыга түгелме? Без Алексей белән алай бәрелешмәдек әле, ә ул минем ниятләргә әллә ничә тапкыр каршы килде, әмма җайлап әйткәч тыңлады, тавыш чыгармады.

Берничә көннән тагы штабка барырга туры килде. Анда да комбат хакында аны-моны әйтмәделәр. Ваһаповның эченә җылы керде. Алексей да алгы сызыктан кайткан иде. Кызыл балчыкка буялып беткән сырмадан, погоннарының йолдызлары каядыр сыдырылып өзелгән.

— Өч пулемет оясын «кармакка каптырдык» әле,— диде ул, планшетын актарып. Өстәлгә куелган ашамлыкларны читкәрәк этеп куйды да картаны җәйде һәм шатлана-шатлана ут нокталарын күрсәтеп чыкты.

— Хәзер үк атып булсын иде, эх! — дип куйды Ваһапов. Алексей да, көенеп, телен шартлатты.

Старшина консерва ачып куйды, үзе эшләрен карарга каядыр чыгып китте. Ике командир ашарга керештеләр.

— Ну, «мунча ташына нинди эссе салып» җибәрделәр? Һөҗүм кайчан башлана? — дип сорады Алексей.

— Әйтмәсәләр дә сизелә, тиздән булыр.

— Бу оборона да туйдырды.

— Әйе. Ашау байдан, үлем ходайдан, ә? — Ваһапов тамак төбе белән кеткелдәп куйды да: — Әйе, күбрәк ятылды шул,— дип өстәде.

— Тагы нинди хәбәрләр ишеттең? — Алексей елмаеп замполитка карады.— Шаккатма, гайбәт сөйләшмәгәннәр ахири була алмыйлар, ди.

— Ә ул дуслаштырамы? — дип, Ваһапов көлеп җибәрде, Алексейның кәефе әйбәт булуын искәрде. Ачылып китеп барысын да сөйләвен көтте. Тик Алексей ул мәсьәләнең якынына да килмәде.

— Ник без ахириләр булып китә алмыйбыз? Чөнки без гайбәт сөйләшмибез! — диде Алексей да көлеп.

«Нәрсә булган моңа?» — дип гаҗәпсенде Ваһапов.

— Киңәшмәдә сине юк дип телгә алдылар,— диде ул.

Алексейның йөзендә яктылык кимегәндәй булды.

— Син булгач, җитмәгәнмени?

— Син командир, син баш бит.

— Ә син шул башны бора торган муен. Ахырда муен көчлерәк булып чыга, диләр.

— Бер дә борылганыңны күрмим әле.

— Борасың бик киләме, замполит?

— Дөресен әйтим — килә!

— Синең өчен дигәндә баш та жәл түгел, чын,— диде Алексей. Ваһапов аны һаман шаяра дип уйлады, сүзен хуп күрмәгәнгә эндәшмичә торды. Аннары әйтте:

— Солдат белән артык эшнәлеккә барма син, Алексей!

— Һи-и, шуңа кытыгың киләме?

— Тәртипне йомшарта ул.— Ваһапов кашыгын шакылдатып өстәлгә куйды.

— Киресенчә, командирга ышаныч күбәя.

— Сугышчылар белән очколы уйнаган командирның нинди абруе артсын? — диде Ваһапов, үкенечле итеп.

— Курыкма, карьераңа хилафлык китермәм.

Ваһапов битенә кайнарлык йөгергәнен сизде, ләкин ачуын тыеп өлгерде.

— Минем турыда начар уйлыйсың икән,— диде тыныч кына.

— Минем хакта синең дә уйларың җырлап тормый.
— Ә мин дөресен әйтәм.
— Мин ялганлыйммы? Синнән алдагы замполит та шулай күп сөйләнеп йөрде дә, соңыннан укырга тылга сыпырды.
— Солдатның рухын чыныктыру өчен сөйлим мин. Үземне үлемнән араламыйм.
— Солдат коры сүзләрдән менә болай гарык,— дип, Алексей уч кырые белән тамак төбенә сызып алды.— Сугышчы, немец белән бергә-бер калганда, аны җиңәрлек булсын, шул мөһим. Аның сугышчан осталыгын арттырсаң, үз-үзен корбан итүе әзрәк булыр иде...
— Ялгышасың, Алексей.
— Ихтимал. Мин сугышчы күзлегеннән карыйм, ә үз каланчамнан түгел.
Ваһапов бәхәсне дәвам иттерү мәгънәсез икәнен тойды. Һәм тиз генә җавап кайтармады. Алексей да үз фикерләрен расларга атлыкмады. Ул боегып калды. Нәрсәгә исбатлап маташырга, үзе дә аңлар әле, алгы сызык баштагы томаннарны, чүп-чарны бик тиз сыпырып ата, дигән кебек иде аның карашы. Аннары ул үзенең эчке уйларыннан яктырып киткәндәй булды, Ваһаповка карады, тегенең маңгай сызыклары сыңгалаган, ике каш арасына гаҗизлек җыерчыклары бүлтәйгән иде.
— Әйттем бит, юк-бар гына сөйләшик дип!
— Юк, аңлашу миңа бик ошады,— диде Ваһапов, ничектер кимсенгән тавыш белән.
Шул арада старшина нindидер кәгазьләр алып килеп, комбат алдына куйды.
— Имза кирәк,— диде ул.
Ваһапов тирән уйга чумган кыяфәт белән блиндаждан чыгып китте. Алексей кәгазьләрне караштыргалады: тагы снаряд, автоматлар һәм кирәк-яраклар китергәннәр икән.
— Яңа төр снаряд килә дигәннәр иде? — дип, старшинага төбәлде.
— Сүздән гамәлгә чаклы илле чакрым, диләр.
Старшина киткәч, Ваһапов белән сөйләшүе исенә төште. Замполит булу өчен дә сәләт кирәктер шул, дип уйлады.
Ваһаповның батарея өчен янып йөрүе аңа ошый иде. Тик кайчагында кыюлыгы җитеп бетмәве, кайберәүләр алдында дәрәҗәсе өчен генә баш июргә яратуы бераз йөрәгенә ятмый иде. Юк, ул моны да батареяга әйбәт булсын дигән максаттан чыгып эшлидер, мөгаен. Чыннан да, әгәр Ваһапов булмаса, минем бу холкым белән батареяга күп кенә читенлекләр күрергә туры килер иде.

## 5

Башлыклар алгы сызыкка киткәнлектән, Сөенчалин старшинаны бүген кич «аулак өй» ясап алырга котыртты. Дүртенче орудие командиры кече лейтенант Мушков та килер, диде. Теге бик теләп риза булды. Һәм шунда ук хәстәренә кереште. Шул мәшәкать белән йөргәндә, яңа пополнение итеп бер яшь кенә егетне китерделәр. Бу — Әнвәр иде. Старшина аны кул куеп алып калды. Аннары сүзсез генә, башымы белән әйдәп, блиндажга иярттеп керде. Снаряд әрҗәләреннән корыштырып эшләгән өстәл артына утыртты да кулына каләм бирде. Үзеннең кызылармеец книжкаңа бирегә килүеңне теркәргә кирәк, диде. Әнвәр бүгенге числоны хәтеренә төшереп, тиешле графага 23 май, 1944 ел дип язып куйды.
Старшина кечкенә генә янчыктан печать чыгарды, аны лампа сөременә тотып алгач, өргәләде дә Әнвәр язган җиргә шап иттереп

китереп басты. Түгәрәк печать бик әйбәт чыккан иде. Әнвәр аннан 612 нче артдивизион дигән сүзләрне укыды. Әмма артиллерияне бөтенләй белмәве турында уйлады ул.

Шул вакыт старшина, кулына термос тотып, тагы бер сүз дә әйтмичә, ияк кагып кына ымлады да Әнвәрне блиндаждан алып чыгып китте. Якында гына чаукалыклар башлана, шуның буенча түбәнгә табарак бер такыр сукмак сузыла икән. Старшина, авызында сүзләрен чәйнәгән кебек итеп, иреннәрен әллә ничек кыймылдатып куйды.

— Әнә,— диде,— анда кухня булыр, бер яры борылма, кичке ашны алып кайт.

Ул биштәрле термосны Әнвәргә сузды. Әнвәр тиз генә термосын алып аркасына киеп тә куйды. Борылып караса, старшина кире кереп бара иде инде.

Бу түбә урын иде. Аны әз генә үткәч тә Әнвәр аяк астындагы түмгәкләрнең атлаган саен тирбәлеп калуларын сизде һәм тирә-ягы камышлык, таллар белән капланган сазлык икәнен күрде. Сукмак текә генә булып аска төшә иде. Ул тау түбәсендә сазлык булуына гаҗәпсенеп бетә алмады.

Кояш инде баеп килә, соңгы нурлар, буй җепләр кебек, озын-озын булып сузылганнар. Кайдадыр урманнар артында аткан туп тавышлары ерактагы күк күкрәү шикелле тонык кына ишетелә...

Ул блиндажга кайтып кергәндә, анда ике кече лейтенант нәрсәдер бәхәсләшәләр, исбат итешәләр иде.

— Секундомер белән үлчәдеңме? Ату тавышын ишеткәч тә секундомерны куясың...

— Үлчәдем, ләкин ара ераграк чыга, безгә ата торган немец орудиесе якынрак булырга тиеш.

— Ә син секундомер күрсәткән вакытны ничәгә тапкырладың?

— Өч йөз утызга.

— Ә, баш! — дип бармагы белән маңгаена төртте кече лейтенантның берсе.— Һава тыгызлыгын исәпкә алмаганмын, шайтан!

— Соң! Һава дымсу иде кичә, димәк, өч йөз кырыкка тапкырларга кирәк.

— Җил юк иде, өч йөз кырык дөрес булыр!

Старшина термосны җилкәдән алу белән капкачын ачып карады.

— А-а, токмач, бер дигән! Сөенчалин, ташлагыз! — дип, сары чәчле кече лейтенантка дәште.

Тегесе һаман үзенең хисаплары белән булышты. Икенчесе, бер чакрымлы картаны өстәлгә җәеп, нәрсәдер караштыра иде. Старшина лампаны өстәлгә якынрак куйды. Пластмас стаканнар китерде.

— Мушков, куй, зинһар, тегеләр хәзер килеп җитәрләр,— диде старшина икенче кече лейтенантка. Ул тыңламыйча булдыра алмады. Картасын җыеп, планшетына салды. Сары чәчле лейтенант та, хисапларын ташлап, урыннарны җайлаштырды, тәлинкәләр, кашыклар тезде.

Менә блиндажга көлешә-көлешә ике кыз килеп керде. Берсе каен тузы төслерәк аксыл погонлы кече лейтенант, икенчесе өлкән сержант иде. Әнвәр сержантны тик бераздан гына таныды, баягы повар кыз иде ул, яңа хәрби кием аны танымаслык матурлаткан иде. Кызлар керүгә блиндажга кыйбатлы хушбуй исе таралды. Кара чәчле кече лейтенант, җәһәт кенә урыныннан торып, лейтенант кызга кулын сузды.

— Римма, сезне дәрәҗә алуыгыз белән! — диде ул ничектер ясалмарак рәвештә.

Кызның моңа бер дә исе китмәде.

Ул, башын алгарак бөгеп, сүзсез генә рәхмәт белдерде. Сөенчалин исә, нурлы елмайган килеш, уңайсызланган кебек торды. Аннары Римманы үзе янына ымлап чакырды, алар бер минут күз белән сөйләшеп

алдылар. Римма кыюлангандай булды. Ахры, Бату Сөенчалинның карашы: «Барысы да үз кешеләр»,— диде бугай. Повар кыз старшинага нәрсәдер әйтеп, көлеп куйды. Риммага гына төбәлгән илтифаттан көнләшкән кебек, әле бер егеткә каш сикертте, әле икенчесенә күз кысып алган булды. Янәсе, ул аларның күптәнге якын дусты.

— Мушков, иске дусларны онытма! — дип, шырык-шырык көлде повар кыз.

— Онытырга мөмкин түгел,— диде теге тавышына мутлык кушып һәм аны үз янына утыртты. Римма ничектер көтмәгәнчә күңелсезрәк иде, Сөенчалин аңа куркынып карады. Старшина тәлинкәләргә итле токмач бүлде, стаканнарга флягадан эчемлек агызды. Аннары тиз генә Әнвәрне блиндажның плащ-палатка белән ярым бүленгән бер почмагына алып килеп, телефон янына утыртты.

— Мине сорасалар, мин — передовойда, аңладыңмы? — дип колагына пышылдады.

Әнвәр трубканы алып тыңлады, кемдер телефоннан дәшә башлагач, тизрәк урынына куйды.

Старшина табында стаканны тотып:

— Әйдәгез, туганнар! — диде.

— Нәрсә өчен эчәбез? — дип шыркылдады повар кыз.

— Үз-үзебездән көчлерәк булу өчен,— диде Мушков булмаган мыегын сыпырып.

— Юк, Римманың йолдызы өчен! — диде старшина төчеләнгәнрәк тавыш белән.

— Юк, юк, просто дуслык өчен,— дип кызарды Римма бераз уңайсызланып. Шуның белән килештеләр. Ирләр «залп» белән эчеп тә куйдылар. Тик кызлар гына ялындырды.

— Римма эчсә, эчәм,— диде повар кыз, иркәләнеп. Аннары Мушковның бераз шелтәле карашын күреп йомшады. Римма исә аңа төртеп алды.

— Римма, калышма.— Сөенчалинның карашы гаять ягымлы һәм йомшак иде. Римма аңа карап елмайды, тагы кыстатмас өчен стаканын әз генә уртлап алган кебек итте. Повар кыз аңарга иярде. Аннары тын калып, итле токмач капкаладылар. Старшина кай арададыр котелокка салып, Әнвәргә дә аш китереп бирде. Әнвәрнең алюмин кашыгы һәр вакыт хәзер иде. Теленне йотарлык токмач: фронтта әйбәт ашаталар икән, дип сөенде ул.

Табындагылар оборонада озак ятудан зарланып алдылар.

— Таулар җибәрми, Пушкин таулары,— диде Мушков кашыгын куеп. Аның түгәрәк битле, киң маңгайлы чырае ниндидер сер чаткылары белән тулды.— Бередән Пушкинның туган авылына якын гына, диләр...

— Немецлар анда ниндидер секретный бомба эшлиләр икән,— дип, Сөенчалин Мушковка карады.

— Советлар Союзына бер бомба җитә дип мактаналар икән.

— Кит әле, шундый бомба буламы соң? — Римма һич тә ышанырга теләмичә башын селкеде.

— Әй, ташлагызчы,— диде Рая.— Һи, бу ирләр — бишектән төшү белән мылтыкка ябышалар. Һаман шул турыда сөйләшәләр. Ничек сугыш булмасын!..

— Сугышны без чыгармадык, Рая.— Старшина болар сәясәтне аңлап җиткермиләр дигән кебек елмайды.

— Әнә тарих китабын укып карагыз, гел сугыш турында гына язылган,— диде Сөенчалин.

— Фашистлар булмаса, әллә сугыш булыр идеме? Булмас иде.

— Анысы дөрес шул,— дип, Римма да Раяның фикерен җөпләде.

Сөенчалин кайнар учы белән Римманың кулына тиеп китте. Кыз моңа игътибар итмәгән кебек булса да, егеткә серле итеп карады, егет тә кызга төбәлде, алар тагы күз карашлары белән сөйләшә башладылар.

— Заговор кормагыз,— дип, бармак янады Рая көлә-көлә.

— Беләсезме,— дип, тагы сөйләп китте Мушков,— кайчандыр ир белән хатын-кыз заты икесе бер булган, ягъни икесе бер гәүдәдә, бер тәндә булганнар. Табигатьтә нинди дер көчле давыл аларны икегә аерган да ташлаган. Шуннан бирле бу ике зат бер-берсен эзлиләр, бер-берсенә тартылалар, имеш.

— Димәк, мин синең ортың? — дип әйтеп ташлады Рая һәм уңайсызланып китте.

— Әйе, әйе, син аның ортысы! — дип, кызны уңайсызлыктан чыгармакчы булды Римма.

Мушков дәшмәде, ә Рая аның дәшүен көткән кебек иде.

— Ә минем ортым кая? Сез әйтегез, минем ортым кая? — Старшинаның артык җитди тавышы кинәт калтыранды, башына киткән моның, дип уйлады Мушков һәм, шаяртып, киеренкелекне бетермәкче булды.

— Менә синең ортың! — диде ул, фляганы тотып.

Дәррәү көлеп җибәрделәр. Старшина Мушковка күзенең агы белән карады, ачуланыргамы, юкмы, дип икеләнеп торды, аннары үзе дә көләргә тотынды.

— Анда бар әле, сал! — дип Мушковка кушты ул. Мушков бик теләп стаканнарга аракы бүлде.

Сөенчалин мыштым гына елмая, Римманың кулын тотып, аның учына бармагы белән морзе әлифбасын төртә, әйдә, бирердән тышка чыгыйк дигәнне аңлата. Римма бу шартлы телне аңласа да, аның теләгенә буйсынасы килми, ул горур, итагатьле, иптәшләрдән яхшы түгел икәнен егеткә сиздерә.

Шул вакыт Мушков планшетын тез өстенә куеп, нәрсәдер язды да Риммага сузды. Сөенчалинның көнчелеге килсә дә, белгертмәде.

— О, серләр, серләр! Хәрби серләр! — дип, Сөенчалинга карап көлде Рая, аның белән «заговорга» берләшергә теләгән кебек.

Римма язуны укыды да ирен чите белән генә елмайды һәм кәгазьне ерткалап ташлады.

— Тыелган алым белән эш итәргә ярамый, Мушков! — дип кеткелдәде Сөенчалин.

— Туры наводкага чыгу бик куркыныч! — Рая чәчләрен тузгытып Мушковка таба иелде, күзләреннән нәрсәдер белергә теләде, әмма тынычланырлык өмет чаткысы тапмады, аннан, шул тапмау ачысын күңелендә томалар өчен, көләргә кереште. Һаман көлеп, Мушков каршында үзенең кызыгын югалта баруын ул белми иде.

— Көрәштә теләсә нинди ысул да яхшы, фәкать җиң генә!— диде старшина шаяруны дәвам иттереп.

— Җиңүчеләрне хөкем итмиләр! — дип, Римма Сөенчалин күңелендәге пошаман чаткысына май салгандай итте.

Старшина тагы, стаканын бармакларына кысып, кулын күтәрде.

— Суына, суына, тотыгыз,— диде ул һәм беркемне дә көтеп тормыйча савытын авызына каплады. Тышта каты ату тавышы җирне селкетте. Барысы да тынып калдылар.

— Безнең дальнебойныйлар,— диде Мушков,— Опочка тимер юлына аталар.

Ату тагы кабатланды, нәрсәдер киштәдән чалтырап төште.

— Немец хәзер билгеләп кала да, ну, иртәгә безнең кирәкне бирә инде,— диде Сөенчалин, Мушковның пушкалар белән мактанып әйтүенә каршы. Аңа җавап итеп, старшина стаканына тагы өстәде дә, эчәргә өндәп, кулын табын өстендә йөртте.

— Әйдәгез! — диде Рая Мушковны үзе ягына аудара алмаган гажиз тавыш белән. Егетләр эчү «залпын» кабатладылар, кызлар дә иреннәрен тигереп куйдылар. Кайсыдыр «Зәңгәр яулык» көен шыңшый башлады. Рая шул көйгә фронтта таралган сүзләрне җырлады.

Двадцать второго июня,
Ровно в четыре часа,
Киев бомбили,
Нам объявили,
Что началася война!

Җыр бер-ике тапкыр шуны кабатлаудан узмады. Сөенчалин күкрәк кесәсеннән матур блокнот чыгарып нәрсәдер укырга тотынды.

— Акылыңны безнең белән дә бүлеш әле! — диде Рая, аңа төрттереп. Ул Сөенчалинның шаяруны күтәргәнен, аның белән сүзне үлчәп тормый гына да сөйләшергә яраганын сизә иде.

— Бер акыллы баш болай дигән,— Сөенчалин блокнотына язылганны укый башлады:— Кызлар — май тулы савыт, егетләр — ялкын. Май янына ялкынны китерсәң, пожар чыга!

— Әх, шул пожарда янасы иде! — дип куйды старшина.

— Сугыш пожарында яну почетлырак! — дип, Мушков аңардан көлеп җавап кайтарды.

Сөенчалин тиз генә сәгатенә карап алды һәм блокнотын кесәсенә яшерде. Аннары, хуҗага рәхмәт әйтеп, кузгала башлады. Римма да аның кулына үрелеп вакытны белде һәм ах-вах килеп:

— Семен Израилович кирәкне бирә инде минем! — дип сөйләнде. Үзе Сөенчалинга елмаеп, серле итеп күз сирпеде, егет аңлады: аны санбатка чаклы озатырга булды.

Кинәт Айкилдиев килеп керде.

— Менә сез кайда икән! — Ул яктырып елмайган килеш, боларны «гөнаһ» өстендә тотканга куанган кебек әйтте. Һәммәсе аңа таба борылдылар. Сергей шоколад төсле күн тужуркадан, бил каешына финка һәм наган таккан. Кыяфәте белән дә шаккаттырырга уйлаган булса кирәк.

— Римма, сине эзләп йөрим! — диде ул. Бирелдәгеләргә һавалы караvы тавышыннан ук беленде.

— Нигә? — дип, Римма башын аска иде, сөйләшәсе килмәгәнлеген аңлатты.

— Йомыш бар!

— Әйтегез!

Кызның кырку тавыш белән әйтүен егет сизмәмешкә салынды.

— Үзеңә генә! — Сергей серле елмаеп, кызның йөзенә мөлдерәп карап торды.

— Иптәшләремнән яшерен серем юк,— диде Римма.

— Бар, Римма, нигә инде!

— Юк! — Кызның катгыйлыгында йомшаклык сизелде.

Старшина хәлне җайлау өчен тиз генә стаканга шәраб салып Сергейга сузды.

— Булганда эч, сөрмәсләр, ахирәттә бирмәсләр,— диде. Бу солдат арасында таралган шаяру сүзе иде. Тик Сергей стаканны күрмәде дә, якынрак китергәч, этеп җибәрде. Шаяру барып чыкмады, киеренкелек җиле искәндәй булды.

— Үкенерсең, Римма! — диде Сергей, янаган сыман. Кызны куркыта торган ниндидер власте бар шикелле тоелды. Сөенчалинның ачуы килә башлады.

— Нигә аңа бәйләнәсең? — Яклаудан бигрәк арадашлык итәргә теләгән кебек әйтте ул.

— Арага тыгылмагыз, лейтенант! — Сергей тавышын күтәрде. Ул

әлкән сержант иде. Сержант башы белән шулай үзеннән югары чинга дорфалану өчен артында ныклы терәгең булу кирәктер.

— Бернинди дә ара юк, юк! — Римма гүя ялвара иде.

— Ай-һай, тиз онытасың икән! Яким Зиновьевич...— Сергей, мәгънәле рәвештә әйтеп бетермичә, тагы яктырып елмайды. Римма йөзен ике учы белән каплады, оялуданмы чыраен яшерде.

— Бетер кәмитне, Сергей! — диде Мушков. Рая аның беләгеннән тоткан, чыгарга ашыктырыпмы, әллә Римманы яклауны таләп итепме, тарткалап ала. Үзе чибәр Римманың уңайсыз хәлгә калуына ниндидер яшерен канәгатьлек тә тойган сыман:

— Кирәген әйт тә өз! Нигә куркып торасың? — диде. Әмма Римма дәшмәде, эшләре алай гына өзәрлек түгел иде, ахрысы! Римманың җилкәләре селкенеп китте, ул елый башлады. Сөенчалинга кинәт көч һәм кыюлык өстәлгән кебек булды.

— Ну, аттыр бирердән яхшы чакта! — дип, Сөенчалин Сергейның ачу китергеч җилкәләренә барып ябышудан чак тыелып калды. Тегесе исә аның сүзен бөтенләй ишетми дә кебек, ваемсыз гына басып тора. Сөенчалин килешергә теләпме, аның иңбашына кулын куйды, Сергей кинәт елан чаккан кебек бер якка тайпылды.

— Озайтма кулыңны!

— Ә син бик масайма! Абыеңның полковник булуы да ярдәм итмәс!

— Ташла, лейтенант!

— Сиңа бөтен нәрсә рөхсәт ителгән дип узынма!

— Үзем теләгән кеше белән сөйләшергә хакым юкмы?

— Ә ул кеше синең белән сөйләшергә теләмәсә? Көчләп сөйләштерер идеңме? — дип, тавышын күтәрде Сөенчалин.

— Ах, син ялган адвокат! — дип, Сергей җилкә аша гына ысылдады да кинәт борылып, тиз генә чыгып китте. Иркен сулап куйдылар. Рая Сергейны полк начальникларының узындыруы хакында ишеткәнен сөйләп алды. Разведчик буларак Сергейның даны зур иде. Иң җаваплы операцияләрне уңышлы башкарып чыкканы өчен орденнар белән бүләкләнгән. Күп вакыт ул разведкага ялгызы гына бара. «Тел»не күз буып ала икән дигән сүзләр дә йөри. Аның батырлыгы туган шәһәренә барып ишетелгән. Ышанмаганнар, фронтка делегация килеп, Сергейны үз күзләре белән күргәч кенә ышанганнар. Сергейны яшьләр белән очрашыр өчен кайтып килүен сораганнар. Яким Зиновьевич җибәрә икән, ди. Сергей ул шәһәрдә үзенең башсызлыгы, тәртипсезлеге белән дан тоткан атаклы егет булган дип әйтәләр.

— Әкият! — диде Мушков, кулын селтәп. Рая аны өстерәп диярлек алып чыгып китте. Сөенчалин, Римма янына килеп, кызның кулын тотты. Кыз күзләрен сөрткәләде дә томса гына елмаеп куйды. Теге почмакта старшинаның гырылдаганы ишетелде.

Һавага чыккач та сөйләшә алмый бардылар. Римма бер дә исе китмәгән төс белән, элеккечә шат булырга тырышты, ниһаять, үзе сүз башлап, кызык кына хәлләр сөйләп алды. Ул Сергей турында Сөенчалин төпченер дип, курыккан кебек, дикъкатне читкә юнәлтергә тели иде. Сөенчалин шуны сизде, әмма күңелендә мең төрле сорау-шик туса да, тышка чыгармады. Римманы әле ул аз белә, танышулары да күптән түгел иде. Шулай да бу чәкәләшү егетнең беленер-беленмәс томанлы тойгыларына ачыклык биргәндәй, очкын элдереп җибәргәндәй итте.

— Римма, әйдә, бер-беребезгә бер дә ялганламаска сүз бирик! — Сөенчалин инә белән аңа тиеп атлый, ниндидер илаһи тойгы дулкыны кыздан үзенә түгелүен сизгән кебек була иде.

— Сүзебездә тора алырбызмы соң? — диде кыз, шатлыклы елмаеп.

— Нигә? Һәр вакыт дөресен генә әйтү авырмыни?

— Әйтеп булмый торган нәрсәләр дә була бит.

— Барыбер! Яшереп калмаска!

— Юк, мин алай булдыра алмыйм. Сүз өчен генә вәгъдәләшү?..
— Вәгъдә чын булсын! Мөмкин түгел, дисезме?!
— Әллә ничек үз-үзеңне чылбырлаган кебек!
— Җанда ургылган тойгыларны сөйләп бушата торган дус кирәк, Римма!
— Сиңа дус-тустаган кирәк? — Римма кеткелдәп алды.
— Дус-сандык диген! — Егет тә аңа кушылып көлде.
— Дус-сандыкка бөтен серләреңне саласың да бикләп куясың, ә? Ачкычын үзеңдә тотасың.
— Нәкъ!
— Кирәк чакта барасың да ачасың?
Алар бер-берсенә карашып көлделәр.
— Нигә кеше сер ярата? — диде Римма.
— Кеше үзе сердән тора. Сере беленүен өнәми.
— Ә синең сереӊ бармы? — Моны утыртыйм әле дип, шаянланып кызыксынды Римма.
— Бар,— диде егет, берни булмаган кебек.
— Миңа гына әйт инде? Мин — сандык, бикләрсең дә ачкычын кесәңә салырсың, ә?
— Әйтимме икән?
— Әйт, әйт! — Римма аның серен тартып чыгарырга иткәндәй кулыннан тартты.
— Минем серем... син! — диде егет, көлә-көлә.
— О, бу авыр сер! Мин аны күтәрә алмам,— дип, Римма көлә-көлә җавап бирде.
— Сандыгыңа салмыйсың, ачкычын миңа ышанмыйсың? Сандыгың буш түгел, димәк?
— Буш та, түгел дә! Канәгатьме?
— Ул синең теләгеңдә инде, Римма...— Егетнең тавышы кинәт җитди төстә өзелеп калды.
— Һи, минем теләк — иләк, иләктә берни тормый! — диде Римма, шул ук шаян тавыш белән.
— Сандыгыңны бүтәннәр бикләгән, ачкычын үзләре белән йөртәләр, әйеме?
— Юк, алай димә!
— Курыкма, мин йозак ватучы түгел! — дип, Сөенчалин шаяртып сукмакта туктады һәм Римманың бер җилкәсеннән кочып үзенә таба кысты.
— Я, я, кызма, егет!
— Сине дус итәсем килгән иде, әх!
— Дус булыйк, ары ягына чыкмыйк!
— Ары ягы нәрсә соң аның?
— Син зурга алмакчы буласың...
— Кешем бар дип әйтергә телисеңме?
— Кемем дә юк. Ул хакта сөйләшүне икенче вакытка калдырыйк.
— Икенче вакыт булмавы мөмкин бит!
— Ну, мин аңа гаепле түгел.
— Ә мин сине гаепләмим.
— Ир-ат халкы гаҗәп, барысы да аңа шул минутында булсын. Хатын-кызның үз сроклары бар! — Римма тыныч сөйләшү, киңәшү рәвешендә зарланган кебек әйтте.
— Синең исәпләреңә тукынмыйм, Римма.
— Сугыш барысын да списать итәр дип караучылар бар. Ир-ат өчен бәлки шулайдыр. Бездән бернәрсәне дә списать итмиләр шул!..
— Үз җилкәбездә кала дисең инде син?
— Җилкә нәрсә? Җаныбызда кала!..
Сүз шунда өзелде. Алар санбатка килеп җиттеләр. Римма кулын

егет култыгыннан йомшак кына итеп алды да яшел палаткалар янынннан шыпырт кына атлап китте. Бер минуттан шулар артына китеп күмелде.

Сөенчалин дулкынланган иде, ул ниндидер җыр шыңшый-шыңшый кайтты. Әмма бераздан Сергей белән Римма арасында «тычканлы-мәчеле» уены булган, дигән шик килде башына һәм шул уй аның ачуын кузгатты, кызны ярату тойгысын тагы да көчәйтеп җибәрде кебек...

Старшина йокысыннан уянып, чак җыештырып өлгерде, төн пәрие кебек чожт итеп Ваһапов килеп керде, аңа «күз-колак» дигән кушамат юкка гына тагылмаган, ахрысы.

— Азык-төлек алдыңмы?

— Хәзер шунда барырга тора идем.— Старшина кызарган күзләрен яшерергә тырышып, әйберләрне рәтләп маташа иде. Сүзне Ваһаповның дикъкатен тарта торган нәрсәгә борып, сизгерлектән тайдырасы килде:

— Комбатны бездән алалар, имеш. Җалко!..

— Б. Х. Ә.[1] хәбәреме? Нәрсә сөйлисең? — Ваһапов аптырабрак калды.

— Бик каты кеше киләсе, имеш! — дип, старшина һаман бер ноктага сукты. Ваһапов дәшмичә торды, тирә-ягына каранды, нәрсәдер хәтерләргә тырышкан кебек кашларын җыерды.

— Ә син тегеләйрәк түгелме? — Ваһапов чигәсенә бармагын куеп боргалады.

— Сәяси-әхлак хәлем әйбәт, иптәш капитан! — Старшина сүзне читкә бордым дип сөенгән бер тавыш белән әйтте. Ваһапов кинәт нигәдер елмаеп куйды, башын селкеде.

— Кем белән эчтең? — диде ул йомшак кына.

Старшина кулына тоткан әйберсен төшереп җибәрә язды. Сизде бит тәки, шайтан! Мондый чакта иң яхшысы чын күңелдән тану. Бүтән чара юк.

— Эч пошканнан, иптәш капитан! — диде старшина бу юлы гаепле тавыш белән.

— Алдамавың өчен рәхмәт! — диде капитан дусларча. Никтер бер дә ачуланмыйча чыгып та китте.

## 6

Көн гаять эссе булды. Кояш нык ягылган тимер мич кебек кыздырды, яфрак селкетерлек тә җил исмәде. Кичкә таба күкне болытлар каплады, төн иртә килде. Тик һаман да бөркүлек кимемәде.

Бишенче батарея командирын сорап, блиндажга ниндидер капитан килеп керде.

— Дальнебойный пушкаларны сезнең арткарак куярга уйлыйбыз,— диде симез битле кеше. Комбатның йөзенә икеләнү шәүләсе чыкты, чөнки бу бик артык тәвәккәл эш иде. Ниһаять, һөҗүм башлана икән дип сөенде ул эченнән. Шуңа күрә каршы сүз әйтә алмады.

— Кайчан атасыз?

— Кич, төнлә,— диде теге, безнең бүтән чарабыз юк инде дигән кыяфәттә.

— Демаскировка булмасмы? — Комбат урыныннан торды. Немецларның су коена торган җиренә атарга кыҗрап йөргән Сөенчалин рөхсәт ит дигән кебек аңа карады. Теге капитан исә комбатның шөбһәләнүен белергә дә теләмичә:

— Без урнаштык инде,— диде.

---

[1] Б. Х. Ә.— Бер хатын әйткән.

— Рас, урнашкач...— Комбат сүзен тәмамларга өлгерми калды, сизмез битле капитан ризалык алган кебек итеп кулын козырегына куеп борылды да чыгып та китте.

— Ай-һай, итәгенә ут капканмыни!..— диде Сөенчалин, тегенең бәреләсугыла ашыгуына гаҗәпсенеп. Комбат кашларын җыерды,ниндидер кәгазьләрен папкага салып куйды да идән буйлап йөренә башлады.

Тышта тавышлар ишетелде, ишектә Айкилдиевның тирләгән йөзе күренде. Плащ-палатка изүеннән йомарлап тотып, кемнедер бирегә өстери: «Комь, комь»,— ди ул дәртле, көр тавыш белән. «Бу нинди әкәмәт тагы?» — дип гаҗәпләнүчеләр кинәт төшенеп алдылар: Сергей бер немецны эләктергән! Менә плащ-палатка кыштырдап ачылды, аннан анадан тума шәрә немец килеп чыкты.

— Гансик,— дип, Сергей гадәтенчә тавышсыз гына яктырып елмайды.

Барысы да Сергейның бу «кошны» су коенган чакта эләктергәнен чамалап, шаккатып баш селкеделәр. Сергей үзен бер карышка үскән шикелле сизеп, немецның җилкәсенә тагы плащны элде, әмма теге зәһәр ачу белән иңбашын кыймылдатып куйды. Яңаклары эчкә баткан, озынча йөзле немец күзенең агы белән генә акаеп карады.

— Нәкъ кирәк чакта,— диде комбат, сөенә-сөенә кулларын угалап.

Тиз арада тәрҗемәче килде. Идәнгә чүгәләп, блокнотын тез өстенә куйды. Беренче сорау белән әсиргә мөрәҗәгать итте:— «Нинди частьтан, чины буенча кем?» — Тик немец берни ишетмәгән кебек селкенмәде дә. Тәрҗемәче сорауларын кычкырыбрак кабатлады. Һәммәсе немецка төбәлделәр. Теге авыз эченнән нидер мыгырдады. Йөзенә тискәрелек бәреп чыкты. Тәрҗемәче түземлелек белән тагы үз сорауларын аңлатты. Немец бу юлы гына аңлаган шикелле итте һәм ачу белән: «Менә сезгә!» дигән кебек, кинәт ике ботын ике якка аерып җибәрде. Ишек төбендә кемдер шаркылдап көлеп куйды. Аны төртеп туктаттылар. Сергей, кызуланып, парабеллумын тартып чыгарды. Комбат кулы белән ишарәләп, «сабыр!» дигәнне аңлатты.

— Киендерергә кирәк,— диде Сөенчалин.

Сергей үзенең кызулыгын җиңеп, немецка папирос тәкъдим итте. Теге папиросны аның кулыннан бәреп төшерде. Сергей, каты сүгенеп, тагы фрицка кизәнде, әмма комбат аны бу юлы да туктатты.

Немецка картаны якынрак китерде:

— Чинына, нинди частьтан булуына төкерергә, оборона төзелешен күрсәтмәсме? — диде.

Тәрҗемәче һәр сүзен тәгаенләп комбатның үтенечен немецка җиткерде. Бу юлы ул башын як-якка бутады. Миннән берни дә ала алмассыз, дигән әшәке кыяфәт белән тагы аякларын хәрәкәтләндерә башлады.

— Җанын Берлинга җибәрәм мин аның, әгәр дәшмәсә,— диде Сергей, бу юлы тыныч һәм ышанычлы итеп.

Тәрҗемәче шаян кеше иде булса кирәк, немец янына килеп, Сергейга төртеп күрсәтә-күрсәтә, әйтте:

— Ул татар, аңлыйсыңмы, ике уйлап тормас, кых! — диде, тамак астына уч кырые белән сызып алды. Немецка бу сүз дә тәэсир итмәде бугай, шулай да ул аска карап, уйга калды. Аннары шактый тынычтан соң, кинәт телгә килде:

— Фюрер безгә яңа корал бирә, барыгызны бер көн эчендә юк итәчәк! — Русча ярыйсы гына сукалый иде ул.— Сез сугыша белмисез. Без бер солдат — сез өч солдат!

— Фюрер ыштан төбендәген бирсә генә! — Кемдер тагы «кыңһ» итеп тамак төбе белән буылып көлде.

— Яле, ут нокталары кай төштәрәк? — дип, комбат кырыс тавыш белән эндәште.

— Белмим, белмим,— диде немец.
— Димәк, теге дөньяны күрәсең килә? — дип, Сергей аның йөзенә якын ук килеп җикеренде.
— Сталин пленныйларны үтерергә кушмый!
— Ах, син шулаймы әле? — Сергей йөзенә суккан кебек кинәт калкынды. Ул аны янә плащ-палаткага төргәләде дә изүеннән йомарлап тотып тышка таба өстерәде.
— Анда сөйләрсең, майлаган кебек булырсың! — дип сөйләнә-сөйләнә алып чыгып китте.
Еракка ата торган орудие залп бирде. Түшәмнән шыбырдап балчык коелды, лампа мелт-мелт итеп куйды. Комбат янына тагы кемдер штабтан килде, ниндидер боерык китерде. Шул җайда Сөенчалин блиндаждан атылып чыкты, беренче орудие янына чабып барды. Наводчик снаряд ящиклары куярга чокыр рәтләп маташа иде. «Алар атканда, нигә безгә авыз ачып торырга, барыбер безнең позициядән торып аталар ич!» дип, үз-үзенә көч бирде Сөенчалин.
— Әйдә, кор, атабыз! — диде ул наводчикка. Аның кабалануы наводчикка да күчте, тиз-тиз орудиене җайлый башлады. Сөенчалин цельне һәм атылачак квадрат номерын әйтте.— Башкар,— диде дә үзе элемтәчеләр янына йөгерде. Алгы сызыктагы Бикиевне телефонда тотып, фрицлар хакында белеште.
— «Мунча» керәләрме, эссе өстәмәкче идек,— диде.
— Хуп-хуп! — Бикиевнең тавышы моңсу, пошаманлы иде.
— Прицель 06! — Сөенчалин шул сүзне кабатлады, тагы кызу атлап, орудие янына чыкты. Наводчик ике снаряд аткан, менә тагы берне җибәрде. Сөенчалин немецның яшерен ныгытмадан ата торган пушкасын ялкынынннан чамалап, исәпләп караган иде. Бер кызгач шул цельгә дә атарга булды. Йөгерек ут белән берничә секунд шунда җибәрделәр, аннары цельне алмаштырдылар. Немец ягы дәшми, тавыш кузгатмый, тик рәхимсез ваемсызлыгы белән янаган шикелле булып тора иде.
— Әһә, артларына корт керде,— диде наводчик, ниһаять, немецның ракета чөюләрен күреп.
— Нервылары нык, аналарын сатыйм!..— Сөенчалин рычагны тартты. Туп алга ыргылды, аннары үз урынына чигенеп утырды, казенниктан гильза чалтырап төште. Шул чак еракка ата торган туп та залп бирде. Ул бераз гына арттарак иде.
— Алар егерме чакрымга, Опочка станциясенә аталар,— диде Сөенчалин.
— Атуын аталар...— Наводчик сүзен әйтеп бетермәде.
— Димәк, шулай кирәк.
— Шулаен ул шулай да...— Сугышчы тагы нәрсәдер мыгырданып калды, Сөенчалин блиндажга кереп китте.
Иртән кухнядан ботка алып кайтып, ашарга әзерләнгәндә, немец артиллерия һөҗүме башлады. Орудиеләрдән арттарак еракка ата торган теге зур туп сураеп тора. Тәгәрмәчләре чылбырлы, аны бирегә дизель тракторы китергән иде. Снарядлар хәзер шул тирәдәрәк ярыла.
— Йөз дә бишле белән ата, имансыз! — диде Мушков, блиндаж ишеге төбеннән күзәтеп.
— Иптәш лейтенант, кер, кер, юкса...— Эчтән чакырган тавышлар ишетелде. Мушков снаряд төшүеннән немец батареяларының ераклыгын чамаларга ниятли иде. Якында гына каты шартлау җирне бишек урынына тирбәтте, снаряд зур тупның янында гына шартлады, аны балчык фонтанына күмде. Тукта, икенче снаряд тупның көпшәсе өстенә төште, тагы берсе нәкъ механизмнар турында ярылды. Мушков: «Бетте!» — дип кычкырып, күзен йомды һәм башын ике учы белән кысты. Ул күзен ачканда, кемдер ах! дип, каты сүгенеп җибәрде, немец снаряды боларның боеприпас саклый торган чокырына туры килгән иде.

Коточкыч шартлаулар бер-бер артлы җирне дер селкетеп торды. Дары төтене, дегет кебек корым ятыкны каплады. Үлем ачысы белән каргануларыш ишетелеп китте.

Бер кырыйгарак урнашкан җиденче орудиенең сафтан чыкканлыгын налеттан соң гына күрделәр.

Замковой Юлтисов каты яраланган иде. Комбат, Сөенчалин, сугышчылар бирегә җыелды. Юлтисов янына тезләнгән Мурзыев үзләренчә нәрсәдер сөйләнә, тегесе бер сүз дә әйтә алмый, бары аягын кочаклап, тавышсыз гына елый иде. Кинәт Юлтисов башын артка каергандай итте, аяклары кулыннан ычкынды, ирен кырыйларыннан кызыл кан күбекләнеп чыкты. Каяндыр яралының уң кулында бер кечкенә янчык пәйда булды, ул аны Мурзыевка сузды. Яндагылар таныдылар: бу ногыт ташлары салынган янчык иде. Юлтисов аз сүзле, кешене тыңлаучан, буш вакытта янына якташларын җыеп, ногыт салырга, язмышны юрарга яратучан иде.

Санинструктор кыз килеп җиткәндә ул үлгән иде инде. Мурзыев аның баш очында, ясин чыккан кебек, авыз эченнән нәрсәдер укыды. Комбат, Сөенчалин һәм бүтән сугышчылар моңа бер дә сәерсенмәделәр, гүя шулай тиеш шикелле тынып тордылар. Җиденче орудиенең исән калганнары комбат янына килеп бастылар, аннан боерык көттеләр. Алар орудиесез ничектер ятим калган балалар кебек боеклар иде.

Комбат Юлтисовны күмәргә Шиловка, Әнвәргә кушты, старшина да алып барышыр, диде. «Ятимнәргә» яңа позиция казырга урын күрсәтте. Ә Сөенчалин еракка ата торган җимерек орудие янына барып килгән иде.

— Безне дә, үзләрен дә харап иттеләр,— дип сүгенде ул.

— Расчеты ничек?

— Исән калган.— Сөенчалин комбат минем атканны белгәндер дип шелтә көтте. Әмма ул берни дә сиздермәде.

— Узган ай белән Юлтисовны өлкән сержант итеп оформить итик әле. Балаларына пенсиясе күбрәк булыр! — диде комбат.

— Замполит кул куярмы? — дип, Сөенчалин комбатның йөзенә карады, барысын да белгән, ләкин әйтми генә дип уйлады. Менә ничек сабыр була белергә кирәк!

— Куймаса, минем имза да җитәр.— Комбатның ачуы бик кабарган иде булса кирәк, кырт кистереп әйтте. Замполитның кайчагында артык төз булып маташуын ул өнәп бетерми иде. Сөенчалин исә, миңа ачуы килгән, дип нәтиҗә ясады.

Алар блиндажга керделәр. Сөенчалин Юлтисовка документлар тутырырга кереште. Комбат, яңа орудие алыр өчен, таләп кәгазьләре язды. Шул арада Сөенчалинны сугышчылар дәштеләр. Ул чыгып китүгә Ваһапов кайтып керде. Ул кичә замполитлар җыелышына, штабка чакырылган иде.

— Нәрсә бу, комбат? — диде ул борчылган тавыш белән. Кай арада барсын күреп, белеп тә өлгергән.

— Тар-мар!

— Әллә демаскировкаданмы?

— Әнә, еракка ата торганнан!..

— Бирелән атарга соң, әй, ахмаклар! — Ваһаповның чиксез ачуы килде. Өзгәләнүе йөзенә чыкты.

— Соңыннан уынып ни файда!

— Якын җибәрмәскә иде! Синең яхшылыгың инде! — диде Ваһапов.

— Сиңа ник куркырга, замполит? Юриспруденциядә алиби дигән сүз бар — гаепләнүченең җинаять урынында булмавы. Так, синең алиби!

— Беркатлылык караклыктан да начар, диләр руслар.

— Бик хак, бик хак! — Комбат авыр сулап куйды, чыраенда канәгатьсезлек, гаҗизлек пәйда булды.
— Яхшы булып дан казанырга тырышасың.
— Баш очында үлем торганда, нинди дан ул, замполит?
— Сәясәтсезлегеңне аңлый алмыйм.
— Сәясәтнең бирегә ни катнашы бар?
— Ул һәр эшне хәл иткәндә компас.
— Орудие приказ нигезендә килгән. Приказны мин язмыйм, юкка да чыгара алмыйм.
— Соң, «хуҗага» шалтыратырга кирәк иде. Юк, сәясәтсезлек, йомшаклык шул!
— Артык сәяси накалда тәрбияләнгәнгә күрә, миндә икенче якка тайпылу, күрәсең...
Ваһапов, сүзнең тирәнгә киткәнен сизеп, тынычрак тавыш белән:
— Сәясәтсезлек ягына димәкче буласыңмы? — диде.
— Юк, демократлык ягына, замполит! — дип, комбат гаепле кеше сыман елмайды.
Ваһаповның киң маңгаендагы җыерчыклар хәрәкәткә килде: ул комбатның сансызлыгы өчен чын күңелдән борчыла иде.
— Мин теге бәхетсез тупны безнең позициягә куйдырмасам, каршы торсам, синеңчә, барысы да әйбәт булыр идеме?
— Әйе! Синең яхшылыгың харап итә безне, Алеша!
Комбат кәефе китеп, кесәсеннән папирос алды, аны бармаклары белән изгәләде. Ваһапов та тынып калды.
— Эх! — дип ачынып куйды Алексей.
— Ярар, нәтиҗәдә эшкә зыян килдеме? Килде! Кырысрак булсаң, махы бирмәс идең син. Әгәр шул сәгатьтә немец һөҗүмгә күчсә, нишләр идек? Трибунал! — Ваһапов тәнкыйть итеп түгел, ә аңлашырга тырышучан итеп әйтте. Аның гаепне үз өстенә дә алуы сизелде. Комбатны шул йомшартты. Ваһаповның кәефен табар өчен ул:
— Синдә дә дөреслек бар, замполит,— диде.
Баш китәрлек бәла булу ихтималы аларны тагы бергә бәйләде, арада булган аңлашылмауны эретеп ташлаган кебек итте.
Шул чак дивизион штабыннан Яким Зиновьевич шалтыратты. Ул комбатны комдив чакыруын әйтте дә трубканы куйды. Комбат кәгазьләрен җыештыргалады, китәргә җыенды.
— Әнә, законник дәшә,— дип көлгән булды.
— Син анда кызма тагы, түземеңне җыеп бар!
— Түземем минем — йөземем, дип әйткән ди бер кыз.— Алексей һаман шаярткан булды. Чыгып барганда Ваһапов аның гаепле тавышын ишетте, чакмадан бер очкын чыгардым дип уйлап куйды.
Эшкә зарар китерү хисабына яхшы булырга яратучыларны замполит сөйми иде, ләкин комбат андый түгел, ул табигате белән яхшы кеше, артык гадилеге күп чакта аның үзенә бәла булып төшә иде. Кешене яхшы яки начар, ак яки кара дип кенә аерып куеп булмый шул. Яхшы кеше начар эшләр кыла, начар кеше яхшылыклар эшли,— барысы да безне урап алган хәлләргә бәйле, ахрысы. Юк, юк, болай әйтү дә дөрес түгелдер, кеше бит ул курчак булмаска тиеш! Юк, моңа баш җитми, бик четерекле, катлаулы нәрсә бу...
Чыкса, Юлтисов гәүдәсен күмәргә илтүчеләр очрады: старшина, Шилов, Әнвәр носилканы күтәреп баралар иде.
— Чиркәү янындагы зираткамы? — дип сорады Ваһапов.
Тегеләр носилканы җиргә куйдылар, әлсерәгәннәр, борчак-борчак тирләре тама иде.
— Әйе.— Старшина янчыгын алып, тәмәке төрде, кояшта чагылганга бер күзен кысыбрак карады.
— Анда немецлар да үзләренекен күмгәннәр бит.

— Туганнар каберлеге, димәк.— Старшина иптәшләренә таба борылып елмайды.

— Да, гаҗәп туганлык,— дип мыгырдады Ваһапов, аннары бер сүз дә әйтмичә китеп барды.

Старшина да уйга калды, бу хакта башына килгәне юк иде әле аның.

— Үлем бар кешене дә тигезли икән шул, ләкин фашист белән кабере якын булмасын,— диде старшина. Зиратта чынлап та немец тәреләре бик күп иде, әле яңа гына күмелгән «безнең брат» каберләре дә шактый. Чиркәүгә санбат урнашкан икән, тегендәрәк урман эчендә зур-зур яшел палаткалар тезелгән, кыекларына эре итеп USSR хәрефләре язылган.

Старшина санбаттан көрәкләр һәм бер казучы алып килде дә үзе каядыр китте, чырае бик җимерек иде.

Шилов риясыз егет икән, бик каты эшләде, Әнвәр дә аннан калышмады, каруланып казыды. Җир биредә сабын кебек үзле, кызыл балчык. Метрдан артык төшкәч тә су чыкты. Күмүче карт солдат, кулы белән изәп, җитәр дигәнне аңлатты, мәетне ләхеткә төшерергә әзерли башлады. Шилов мәетнең йөзен ачты: чырае бик мәһабәт, бөтенләй үлгән кебек тә түгел, җан газабы кичермәгән, ахры, ничектер кыюсыз гына елмайган шикелле. Киң маңгаеның сул кырыенда кан саркып торган кара нокта да аның мөлаемлыгын җуя алмаган. Пәһлеван гәүдәле бу кеше чиксез әйбәт җанлы булгандыр, үзе янындагыларны бәхетле итеп торгандыр кебек тоела иде.

— Кеше иде, өендә биш баласы калды...— диде Шилов мәеткә ишарәләп. Карашында аның чиксез кайгы, тавышында югалту һәм чарасызлык сагышы иде.

— Димәк, без кояшны күмәбез? — дип раслаган кебек әйтеп куйды карт солдат.

— Нәрсә, нәрсә, атакай? — диде Шилов.

— Балалары өчен һәр ата — кояш! Менә шул! — дип тел шартлатты карт солдат, Шиловның шул хакыйкатькә төшенмәвенә көрсенеп. Аның кашлары, күз кабаклары җыерылды, күзләре шул җыерчыкларга күмелеп калды. Авыр тынлык урнашты. Карт тәмәке кабызды һәм, төтен пошкыта-пошкыта, мәетне шинеле белән төргәләде. Шилов чокырга төште, карт белән Әнвәр солдатны кабер кырыеннан аска шуыштырдылар. Чокыр төбе инде су белән тулып өлгергән иде, мәетне суга куярга туры килде. Шилов чокырдан сикереп чыгу белән, карт балчыкны ишә башлады. Хуш, солдат, тыныч йокла, сөякләрең туган җиреңә кайта алмады, якыннарың синең үлемеңә ышанмаслар, төрле сәбәпләргә юрап, һаман сине көтәрләр!.. Әнвәр дә кызганудан эче әрнеп куюын сизде, бу таныш булмаган солдатның үлеме нәрсәсе беләндер аңа да килеп бәрелде.

Эш беткәндә генә старшина килде, ул бик кәефле иде, битендәге җыерчыклары да язылган, конфет суырган кебек итеп тәмәке суыра иде.

— Сезгә НП белән батарея арасында «урталык» ясап торырга куштылар, малайка белән шунда барырсыз,— диде старшина, Шиловка төбәлеп.

— Ә аппарат?

— Миндә трофейный бар,— дип, старшина китеп барды. Әнвәр белән Шилов аның артыннан атладылар. Карт носилканы, көрәкләрне җыя калды.

Юл уңаеннан кухняга кереп, батарея өчен икмәк һәм аш, ботка, тагы шикәр һәм тәмәке алып кайттылар. Старшина, күтәрешеп кайткан өченме, аларга мул итеп ашарга бирде. Шилов бик ашамсак, ахры, урды гына, ашагач, йөзенә елмаю чыкты, хәрәкәтчән һәм уенчан булып

әверелде. Үзенә дигән тәмәкене Әнвәр аңа биргәч, бөтенләй башы күккә тигәндәй булды. Әнвәрнең тартмавына гаҗәпсенде, тартырга кыстады. Бераздан аппарат һәм ярты катушка чыбык алып, батарея блиндажына килделәр, аппаратта элемтәче Никишин утыра иде. Шуннан линия буенча «урталык» буласы җиргә киттеләр.

Йөргән эткә сөяк табыла дигәндәй, Шилов куаклар арасында бер ташландык блиндаж тапты, үрмәләп кенә йөрешле үзе, шулай да ярады, җир казып өшәнәсе булмады. Шунда урнаштылар, кояш кызуыннан анда хәтта рәхәт тә иде. Шилов пластмас немец аппаратын ишек авызына куйды, линия егерме метрлап бер кырыйдарак, шуннан бирегә чыбык ялгап китерергә кирәк дип Әнвәргә аңлатты, чыбыкны әрчеп, ничек тоташтырырга икәнен күрсәтте. Әнвәр пәкесен алып, ялт итеп кабель очын әрчеп тә куйды (авылда зелпе тамыры әрчеп, бу эшкә бик остарган иде). Ялгап килергә дип чапканда аңа карабины комачаулады.

— Ташла, элемтәчегә карабин — ул эткә таяк кебек. Аның белән мәшәкатьләнгәнче немец бер минутта җаныңны теге дөньяга озата! — дип киңәш итте Шилов.

Әнвәр карабинын калдырып йөгерде һәм ә дигәнче ялгап та килде. Бу очын аппаратка тоташтырдылар, трубка шунда ук гүли дә башлады. Шилов батареяны һәм НПны алып сөйләште. Әнвәр карабинын тоткан килеш уйлана калды: чынлап та линиягә чыкканда аппарат, катушка алырга кирәк, ә мылтыкны ничек йөртергә? Шиловның сул касыгында пистолет, уңында финка, әх, миңа да булсае, дип кызыгып карап торды ул.

Шилов исә ракета патроннары сүтәргә керешә, бусы да кызыклы иде: картон патрон эчендә бераз дары һәм биш тиен акча хәтле генә түгәрәк киез таңкәләр.

— Аларга фосфор сеңдерелгән, шуңа матур яналар,— диде Шилов, бер-бер эш майтарырга ниятләгәндәй, таңкәләрне кесәсенә тутырып.— Әйдә, әнә тегендә атыш-атыш уйныйбыз, курыкма! — Шилов тирәли агачлар белән уратылган коры елга чокырына таба күрсәтте.

Блиндаж авызыннан түбәнгә сөзәкләнеп матур үзән сузылып киткән иде.

Әнвәрне әле һәрбер нәрсә кызыксындыра, ату бигрәк тә хыялны кымырҗыткан әйбер. Шилов бер зирек кайрысына ике «таңкә» кыстырып куйды да егерме адым санап килде, пистолетын касыгыннан тартып чыгарды һәм шул мишеньгә атып та җибәрде. Мишень шырпы кебек кабынды да сүнде, тизәп тә тормыйча икенчесенә дә атты, анысын да яндырды.

— Менә шулай! — диде бик каефләнеп. Әнвәр алдында ул чын герой булып басып торды. Төзәмичә тидерде бит, чынлап та мактанырлыгы бар. Берәр хәйләсе юк микән моның дип, Әнвәр шикләнә калды. Шилов тагы шуны егерме биш адымнан кабатлады, Әнвәр бу юлы бик җентекләп күзәтте, ләкин бернинди хәйлә-мазар сизмәде. Гаҗәп, ничек шулай булдырырга мөмкин?! Әнвәрнең шаккатуы йөзенә генә чыгып калмаган, бөтен кыяфәтенә таралган иде. Шилов аның каршында кинәт бик үсеп китте, рус егете үзе дә күкрәген киеребрәк җибәрде, киң җилкәләре тагы да мәһабәтрәк һәм тагы да көчлерәк төс алды. Әмма Шиловның йөзендә бер дә искитмәгәнлек, моңа гади бер нәрсә итеп карау чагыла иде.

— Үләсең килмәсә өйрәнәсең аны, үлем өйрәтә ул,— диде тәмәкесен тәмләп суыра-суыра.

Әнвәр нәрсә әйтергә белмәде, мактарга теле дә җитеп бетми, гаҗәпсенүен ул куллары белән башын чайкап кына аңлатты.

— Мә, син дә ат!

Әнвәр үз колагына ышанмыйча тагы да ныграк шаккатып калды. Шилов бил каешыннан пистолетын алып, аңа сузды. Әнвәр өчен бу

могҗиза иде, ул пистолетның шактый авыр икәнен тойгач кына исенә килде.

— Парабеллум бу, нык тот!— диде Шилов, ул нәзакәтләнеп маташуны сөйми иде бугай.

Әнвәр бик ныгытып, җайлап тотты, теге киез тәңкәләрне мушкага алды да тәтене тартты. Ләкин парабеллум кинәт... кулыннан ычкынып, Әнвәрнең борынына китереп бәрде, авызыннан кан китте, ул тәлендә тоз тәме сизеп җиргә төкерде, ә парабеллум төтенләп чирәмдә ята иде. Шилов шаркылдап көлә, учы белән тезенә суга-суга көлә иде. Әнвәр авызын тотып, якында гына җыелып торган суга иелде. Шилов та аның артына килеп басты, көлүдән тыелып, тиргәү тавышы белән әйтте:

— Татарлар — сугыша белә торган халык, диләр тагы! Ә син камыр, нинди татар син! Ата-бабаларыңа хыянәт итмә! — Аның шелтәсе дә яратып әйтелгән кебек иде.

Әнвәр битен юып бетергәч, калынайган иреннәре һәм бераз кыйшайган авызы белән елмаеп иптәшенә карады.

— Әйдә, барьер артына! — диде Шилов тагы да дәртләнеп, аңарда өйрәтүче шаукымы кузгалды, «миннән өмет өзмәсен» дип Әнвәр бөтен көчен җыеп, тагы парабеллумны кулына алды, аны һавага чөеп, шаярган булды. Көрчеккә барып басты да төзәде, бармагы белән тәтене тартканын сизми дә калды. Парабеллум бу юлы битенә китереп бәрмәде бәрүен, тик Әнвәр барыбер мишеньне яндыра алмады.

— Әй, анаң яламаган! — дип тиргәнде Шилов, ләкин аның ачулануы бик урынлы һәм Әнвәргә рәхәт кенә иде. Әнвәр тагы төзәде, тагы атты, әмма барыбер цельгә тидерә алмады. Шилов чирәмгә кырын яткан килеш башта көлде, аннары сүгенде.

— Сыбызгы! Менә болай төзә!

Аның ачулануына Әнвәр һаман гаепле кеше сыман елмайды гына, бер дә аңа кимсенмәде, тик үз-үзенә хәтәр каны кызды. Киеренкелектән бөтен тәне тирләде. Хәер, көн болай да эссе иде, тик Шиловның борычлы сүзләре аны күбрәк тиргә батырды.

— Кулны күнектерергә кирәк! Лаф орып кына немецны җиңеп булмый, брат! — Шилов бераз кайтып төште, монда Әнвәрнең гаепле түгеллеген шулай икърар итмәкче булды. Ничек төзәргә кирәк икәнен күрсәтеп бирде. Тик Әнвәр барыбер мишеньгә тидерә алмады. Инде кояш кичкә авышкан, наратларның суган кабыгы төсле кызгылт кайрыларында нурлар алтын-сары булып балкый иде.

Әнвәр бик дулкынланган килеш йокларга ятты, ул эчтән генә үзен тиргәде, йодрыкларын йомарлады, тик үз йөзеңә үзең төкереп буламыни? Аның йөрәген гарьлек кимерде, чөнки төз атарга өйрәнү — хыял иткән нәрсәсе иде. Ул җан ихтыяҗы шикелле көчле иде.

Әнвәр төнен юньләп йоклый да алмады, яктыра башлау белән «ату үзәненә» юнәлде һәм үчләнеп, зәһәрләнеп тагы өйрәнергә керешә. Барча гайрәтен уң кулына туплады, кул буыннарын шарт-шорт боргалап бетерде. Нык бер үҗәтлек һәм җан көче белән атты да атты. Тырыша торгач, ике тапкыр тидерде, шуңа чиксез күңеле булып, як-ягына каранып куйды. Кояш күтәрелә башлагач, кайтырга кирәк иде. Ул моржа чистартучы кебек, корымга буялган, эттәй арыган, кулбашлары салынып төшкән хәлдә атлады, әмма күңелендә чиксез канәгатьлек сизде, үзен бер баскычка югары күтәрелгән итеп тойды. Ул ниндидер моңарчы билгеле булмаган нәрсәнең серенә төшенгән шикелле булды, үз-үзенә ышанычы артты, күңеле күтәрелде. Әнвәр парабеллумның сабын бик сөеп тотып карый, салкын тимер аның учына йомшак һәм ягымлы тоела иде хәзер.

Шилов блиндаж авызында иртәнге ашны сыптырып утыра иде. Кай арада кухняга барып кайтырга да өлгергән. Яңаклары, иякләре ләззәт белән хәрәкәтләнә.

— Әйдә, шәкерт! Бик ошады, ахры? — диде Шилов, Әнвәрнең сул касыгына асылган коралга ымлап. Ашый-ашый гына сөйләнеп алды: — Шулай ук, бер жиле кагылса, тынгы көтмә.— Ахры, ул үзе дә Әнвәр кичергәнне башыннан уздырган. Үзе дә бик мавыгучан егет, Әнвәрнең дә шундый булуын ошатып, аны үзенең бөтен кыяфәте белән хуплап тора иде. Әнвәр котелогын тотып, кашык алырга кесәсенә тыгылды, нәкъ шул чак жир калтырап китте һәм ниләрдер убып төшкән кебек саңгырау авазлар ишетелде. Икесе дә тын калып, снарядларның кая юнәлгәнен бөтен тәннәре белән сейсмограф шикелле шәйләп тордылар. Шилов хәвефнең читләп үтүен беренче сизеп, шаяртып куйды:

— Иртәнге ашка добавка!

Әнвәр барысын онытып, ашыгып-ашыгып боткасын капкаларга тотынды.

## 7

Көн тагы эссе. Кояш бик каты кыздыра. Алексей текә ярлар буеннан, куаклар арасыннан сузылган такыр сукмактан атлады. Кинәт башыннан кичкән күптәнге хәлләр исенә төште. Кырык беренче елның жәе дә шулай кызу булды. Сугыш юлы ул чакта аны Фира белән очраштырган иде. Бергә күргән михнәт-газаплар аларны бер-берсеннән читләштергән дә шикелле булды бугай. Әллә, киресенчә, бер-берсенә бәйләде микән? Елдан артык вакыт узгач, Алексей Фираны иске адресы буенча эзләтеп тапты. Фираның гажәеп чыдам булуы Алексейның күңеленнән һич кенә дә китмәде. Булса да була икән кешедә түземлек! Бигрәк шунысы Алексейны тетрәтте: Фира тәжрибәсез, яшь бер хатын, сугыш уртасында калып, мең бәлагә дучар ителсә дә, бер дә күңел төшермәде, беттем дип, күз яше чыгармады. Барысын да шулай булырга тиеш итеп кабул итә, һич тә өзелеп төшми, сабыр гына түзә, күтәрә иде. Гүя ул бәлаләрне күп күреп үскән, берни белән дә, бернинди фажига белән дә аны шаккаттыра алмыйсың. Мөлаем йөзендә кешегә карата илгәзәклек чаткысы һич тә сүнми иде. Ахыры аңардагы яктыны сүндерерлек көч тә табылмас дип уйларга мөмкин иде. Була бит шундый кешеләр...

Текә яр астына урнашкан кухня янынннан үткәндә, Алексейга дәштеләр.

— Син ничек монда? — дип гажәпләнеп сорады Алексей. Дәшүче рота командиры Бикиев иде. Ул чикләвек агачыннан трубка әмәлләп маташа иде. Бер кулына бинокль линзасы тоткан, шуның белән кояш нурын фокуска жыеп, малайлар шикелле, трубканың кәкре башына тәмәке сала торган «оя» яндыра. Жеп шикелле нечкә генә аксыл төтен күтәрелә.

— «Сакал» бер көн отпуска бирде,— дип, Бикиев көләч йөзен Алексейга таба күтәрде.

— Сергей белән алган теге «тел» өченме әллә?

— Алай да харам булмас.— Бикиев канәгать төс белән елмая бирде.— Утырып жибәр! — Трубканың яндырган жирен пәке очы белән кыргалады, ташка бәргәләп күмерен койды. Алексей агач күләгәсенәрәк чирәмгә сузылды. Бикиев шөгылен ташлап, аның янына килеп утырды. Түш кесәсеннән «Казбек» кабы чыгарды, ачып, комбатка сузды. Алексей гажәпсенеп аңа карады, бер папирос алып иреннәренә кыстырды.

— Борының кычыткандыр!..

— Ничек болай баедың? — дип елмайды Алексей.

— Йөз дустың булганчы бер блатың булсын! — Бикиев сумкасыннан бер чөлти аракы һәм кечкенә генә кырлы рюмка чыгарып Алексей алдына куйды.

— О-о, мин сине болай ук даһи дип белми идем. Хәтта пичәтле, ә?!

— Суы агыр, комы калыр, сал! — дип, Бикиев үзенең бөтен җайга да килә торган яраткан сүзен әйтте. Алексей аракыны рюмкага салып эчеп җибәрде. Кабарга юк иде, Бикиев «табында» гына үсеп утырган ниндидер үлән яфрагын өзеп, Алексейга бирде.

— Ә-ә, кузгалак икән,— диде Алексей чәйни-чәйни. Бикиев калганын үзе салды, закускага шулай ук яфрак капты. «Казбек» кабыздылар, бер минутка дөнья тигезләнгән кебек булды.

— Әле исемә килде, безнең Төмәндә дә декабристлар булган. Кызыгы шунда: җәлләпме, фикер-карашлары уртак булыпмы, Франциядән ике француз кызы алар янына килгән һәм алар кияүгә чыгып, бөтен газапны бергә кичергәннәр. Гаҗәп бит! Газапны үзе теләп алырга нәрсә мәҗбүр иткән диген?

— Кешелек бурычы йөртә адәмне.

— Нинди зур эшләргә сәләтле кеше, ә?

— Түбәнлеккә дә сәләте җитә.

— Әйе. Фрицлар үзләренең әшәкелекләрен уйлап карыйлар микән, ичмаса?

— Уйлар! Уйласа, немец солдаты — бетте! Уйларга ирек бирмиләр аңа.

— Хайван өере урынына теләсә нишләтәләр.

Бу көннәрдә Бикиев немецларның вәхшилекләре турында күп уйланган иде. Моның төбендә нәрсә ятканын белә алмады.

— Адәм заты дөньяны тәмугка әйләндерә ала!

— Оҗмахка әйләндерү дә аның кулында.— Алексейга буш хыяллар ошамаса да, дусты күңеле өчен генә гәпне өзмәде. Бикиев бүген ничектер бик моңсу, гаҗиз иде. Шулай да Алексей китәргә кузгалды, Бикиев, аның белән сөйләшкәнгә чиксез шатланып, чыраена: «Китмә әле», дигән сорау чыгарса да, телдән берни дә әйтмәде.

— Сиңа нәрсәдер сөйлисем бар иде, исемнән чыкты,— дип борчылып алды.

— Икенче вакытта! — дип хушлашып, Алексей сул кулын өскә күтәрде һәм әкрен генә атлап китте. Бикиевнең сораулы күз карашын ул аркасы белән тойган кебек булды. Нәрсә булган аңа бүген?.. Алексей нигәдер, Бикиев белән корырак сөйләшенде бугай дип, үкенеп тә куйды. Үзе бик якын итә, Алексейны җан дусы күрә, яратканын яшерми. Яратуга һәр вакыт ярату белән генә җавап бирергә кирәк. Ахры, мин андый юмартлыкка сәләтле түгелмендер...

Көтмәгәндә, почтальон очрап, Алексейга хат бирде. Искитмәле, бүген генә Фираны исенә төшергән иде, менә хәбәре дә килеп җитте. Сөенеч белән хатны ачып укый башлады, ләкин күңелсезлеккә килеп төртелде. «...Бүген генә дөньяга күземне ача алдым. Маратны җирләгәнгә бер атна тулды. Минем тәнемдә бер тере төшем дә калмады бугай. Бар әгъзаларым үлеп бетте кебек. Синең аттестат бик зур ярдәм булды. Марат баш авыртудан үлде, врачлар менингит диделәр. Вөҗүдем үлсә дә, фикерем бар әле, аннары син бар. Мине, ахрысы, шул тотып тора. Марат бик газап чикте, сөйләп кенә бетерерлек түгел. Квартирага Ленинград эвакларын куйдылар. Рәшитнең хәбәрсез югалуы турында кәгазь килде. Аннары теге акчаларны тапшырган өчен горисполком рәхмәт әйтеп язу җибәргән...» Акчаның беразын үзеңә тотсаң да әйбәт булыр, дип язган иде Алексей. «Юк, тапшырмасам, мине көне-төне намусым талар иде. Акчаларны илтү белән тынычланып, иркенәеп калдым»,— дип җавап язды Фира.

Алексей хатны тагы бер кат укыды, һәрбер сүзеннән аны үз итүе, чиксез яратуы аңкып тора иде. Ул хатынның әллә нәрсәсе бар, аның чарасызлыгымы, йомшаклыгымы, әллә буйсынучанлыгымы үзенә тарта инде? Алексейның Фираны күрәсе килеп, күңеле алгысынып, дулкын-

ланып куйды. Улының газаплануларын ул язгалаган иде. Малай аңа бик үз, якын, шуңадырмы аны бик күрәсе килә иде. Насыйп булмаган икән... Шул минут Алексейны үз балам булсын иде дигән теләк-хыял биләп алды. Нинди сәер теләк иде бу алгы сызыкта!..

Тупларны туры наводкага куярга дип, кичкә таба ашыгыч приказ килде. Бу бик хәтәр нәрсә иде. Гадәттә дивизионный пушкалар алгы сызыктан ике-өч чакрым арткарак урнаша, ә хәзер пехота белән рәттән, немецның авызына кереп дигәндәй торырга кирәк. Бу хәл танк һөҗүме алдыннан гына була... Алексей штабка шалтыратты. Анда тагы да кыздырып әйттеләр. Немецлар фронт сызыгын тигезләргә ниятлиләр, ди. Һаман кикрикләре шиңми әле. Исәпләре бик йомры: Великие Луки шәһәренә биредән иң кыска юл.

Ваһапов полк штабындагы әшнәсеннән тагы шуларны белде: Бикиев ярдәмендә Сергей Айкилдиев эләктергән тел бик «ганимәтле» булып чыккан. Безнең якта хезмәт итүче антифашист немецлар аңардан бик мөһим мәгълүматлар алганнар...

Алексей Ваһапов белән тиз генә киңәшеп алды да командирларны җыйды. Приказны укыды. Аннары тупларны ничек, кая урнаштыру турында сүз барды. Комбат һәрбер тупка картада урын билгеләп, әйтеп чыкты.

— Мин орудиене анда куймыйм,— диде Мушков үз фикеренә нык ышанган кыяфәттә.

— Ни өчен? — Комбатның кашлары җыерылды.

— Тычкан тәбесе кебек урын! Кая ата алам, күрегез! — Әмма кече лейтенантның ризасызлыгы карышу түгел иде, шуңа комбатның ачуы килмәде.

— Тәбегә кемне куйыйк? — диде комбат. Барысы да тынып калдылар.

— Нигә пополнение бирмиләр? Һәр расчетта ике-өч сугышчы гына калды? — дип сүзгә кушылды икенче орудие командиры сержант Черняев.

— Квадратларга атканда расчетка ике кеше дә житә, ә туры наводкага,— белмим! — диде Сөенчалин.

— Дөрес,— дип әйтергә мәҗбүр булды комбат.— Тиздән өстәмә вәгъдә итәләр. Ә бүгенге приказ шундый.

Мушков, комбат фикеренә каршы килеп маташуына уңайсызланып, дәшми торды.

— Ярар, беткән баш беткән,— диде ул аннары кинәт калкынып, кулын селтәде. Комбат әгәр аңа каты итеп әйткән булса, Мушков әле үзсүзләнеп маташкан булыр иде. Йомшак, ипле сүз аны эретте дә куйды. Ә кайберәүләргә каты булу кирәк бит. Комбат үзенең властен кулланырга яратмый, чөнки ул нәрсә үзенә буйсынырга тиешлеләрнең мин-минлегенә тия, ут эчендә йөргән кешеләрне түбәнәйткән кебек була, дип уйлый иде. Замполит Ваһапов Алексейны шушы йомшаклыгы өчен тиргәштергәли иде.

— Катылык кешедәге яхшыны бетерә, изә,— ди Алексей.

— Эш фәкать катылык белән генә бара! — ди Ваһапов.

Алар шул мәсьәләдә һич килешә алмыйлар... Менә бу юлы да Алексей үзенең тыныч холкына турылыклы булды.

— Сержант Кәбиров кайда? — диде комбат, бераз уйланып торгач.

— Санчастька китте,— диде Мушков һәм папирос кабызып тарта башлады. Комбатның тавышыннан Кәбировның иске позициядә калачагын абайлап алды.— Аның расчетыннан берәр кешене миңа бирегез!

— Юк, мөмкин түгел,— дип кырт кисте комбат.

Җиргә караңгылык иңү белән, кызу эшкә тотындылар. Ярый әле, төн болытлы иде. Тупларны тизрәк яңа позицияләргә урнаштырырга кирәк. Бер студебеккергә ике туп тагып, үргә таба менгерергә туры

килде. Немец та нидер сизенгән кебек, парашютлы ракеталарын еш-еш һавага чөя, җирне яп-якты итә. Бер флангтан атканы сүнәргә өлгерми, икенче флангтан яктырта. Фрицлар ракеталар җибәреп үзара нидер сөйләшәләр иде.

Икенче тупка урын казышырга Шилов белән Әнвәр дә килде. Тупны инде китергәннәр, аңа позиция җайлыйлар. Ракета яктырткан саен чүгәргә, ятарга туры килә, бу ачыграк урын икән. Өлкән сержант Черняев бил тиңентен чишенеп яткан, таза гәүдәсе караңгыда аксыл кәүсә кебек булып күренә. Снаряд ташучы үзбәк Нурманов манма тир булган, борын эченнән нидер мыгырдана-мыгырдана эшли. Әнвәр аның аллага ышануын һәм һәр вакыт укынып йөрүен белә. Бер тапкыр аларны «Юнкерс»лар бомбага тотканда ул блиндаж буенча тәкбир әйтеп йөргән иде.

Черняев исән калуына шикләнгән шикелле, никтер ачылып, тәмәке тарткан арада сөйли дә сөйли:

— Кырык икенче елны Вязьма янында чолганыштан чыктык шулай. Берәм-берәмләп кенә. Ул чакта фриц, ай-ай, хәтәр иде! Мин бер хутор янында облавага эләктем. Ындыр артындагы печән кибәненә яшеренгәнемне өч-дүрт яшьлек балалар күреп калганнар. Менә бервакыт әллә нинди ерткыч тавышлары белән немецларның кычкырышканнарын ишетәм. Лап-лоп кибәнгә таба чабышалар. Җан уч төбендә. Беттем, дим. Ләкин алар кибәнгә аяклары белән типкәләп, китеп тә бардылар. Ничек ут төртмәделәр. Бераз эчкә җан керергә өлгермәде, русча сүзләр ишетәм — «үзебезнекеләр» — полицайлар. Озын япьле тимер сәнәк белән кибәнне тишкәләргә тотындылар. Немецтан котылып булды, ләкин халуйлардан котылып булмас дим. Менә, балтыр итен үтәли тишеп чыкты шул халуйның сәнәкябе. Тик барыбер тавыш чыгармадым, чыдадым. Төнлә бер хатын өенә кереп, киемнәрне гражданскийга алыштырып, көчкә котылдым...

Дүртенче тупны Сөенчалин җитәкчелегендә урнаштыралар. Ул да гимнастеркасын салып ташлаган, көрәге белән зур-зур кантарларны бруствергa өя. Наводчик Михеев көрәк кырые белән куак төбен чаба иде. Чапкан тавышы дөп-дөп итеп яңгыраганга Сөенчалин аны ымлап туктатты.

— Кулың белән тарт! — диде лейтенант, аның колак төбендә пышылдап.

— Куак төбендә фриц юк ич! — Никишин Михеевның бервакыт аксыл тал куагын немец дип белеп, курка-курка батареяга чапканына ишарәләде. Михеевка, шаярган булып, һаман шуны төрттереп әйтәләр иде.

— Немец, имеш! Миңа тавык күзе булган иде, шайтан малае,— диде Михеев.

— Ну, кибәк очырасың да, парень, күзгә кәрә...

— Чын, чын. Әнә, командирдан сора, ышанмасаң,— диде Михеев, күз акларын ялтыратып. Сөенчалин немецлар ягына колак салып тыңланып торды да, ул-бу юк кебек әле, дип исәпләп куйды. Тик шунда ук Римма исенә төште. Аның белән танышканнан бирле, Сөенчалин үз уйларына йотылучан булып китте. Гомумән, ул үзен шул кыз белән бергә куеп уйлый башлады. Ихтыярыннан тыш хәтер кызның әйткән сүзләрен казып чыгара, алардан нindидер мәгънә эзли, шуның белән кинәнеп ала иде.

Шул вакыт кинәт позициягә комбат килеп чыкты.

— Ну, әзерме?

— Менә җайлыйбыз,— диде Сөенчалин.— Стволны кай юнәлешкәрәк төбик, ничә градуска, ә?

— Кырык биш градуска көнчыгышкарак. Позицияне маневрга

жайлаштырып киңәйт,— диде комбат киеренке-кайгыртучан тавыш белән.— Снарядларны кая ташыйсыз?

— Әнә, уң кул яккарак,— дип, Сөенчалин да дулкынланып җавап кайтарды.

— Яхшы!

Комбат, алардан риза булуын тавышы белән дә аңлатып, китеп барды. Аның сырма кигәч бераз бөкшәеп күренгән кыяфәтеннән Сөенчалин хәленең шактый кискен икәнен чамалады.

Комбат Мушков орудиесе янына килгәндә, әле ярты эш тә башкарылмаган иде. Ул лейтенантны үзенә буйсынган кешеләре каршында орышмый торган иде, бу юлы кычкырмыйча булдыра алмады. Үзе казышмаганга бик ачуы килде.

— Син нәрсә, Мушков, озакламый таң ата бит!

— Алексей Егорыч, сезне кызартмам, валлаһи!

— Синдә немецка нәфрәт юк, ахры.

— Мин аларны менә бу кулларым белән...— диде Мушков, беләкләрен бөтереп божра ясады.

— Сүз бер, эш икенче, Мушков. Немецларга нәфрәтне сүрелдермәскә кирәк. Командир эчендә шул өтә торган ут сүнсә, солдатлар шунда ук сизеп алалар. Ә нәфрәтсез сугышчы — мунчала белән бер ул. Нәфрәт, безнең хаклык — солдатны утка күтәрә торган рычаглар,— диде комбат карлыккан тавыш белән, лейтенантның колак төбендә мытырдап. Аннары үзенең шушылай акыл сатуыннан уңайсызланган кебек, кинәт сорап куйды:

— Ник кирәк тотмыйсың? Әй, шул гадәтеңне!..

— Анысы төп нәрсә түгел, Алексей Егорыч!

— Биш минуттан орудие урынында булсын! — Комбат Мушковның аңлатмаларын тыңларга теләмичә, җир казучы расчет янына килде, күрсәтмәләр әйтте. Берсеннән кирәк алып казый да башлады. Ә Мушков барыбер кулына кирәк тотмады...

...Бу вакытта батарея тылындагы туп янына замполит Ваһапов килгән иде. Коручы Николаев постка баскан. Расчет алгы сызыкка булышырга киткән, туп командиры сержант Кәбиров, сырма өстеннән шинель кигән килеш, күшегеп тора. Аның теше сызлый иде. Замполит килү белән ниндидер дару эчте һәм бераз аруланып киткән кебек булды. Замполит бу кешегә шикләнеп карый, аның авыру булып кылануларына ышанмый иде. Тагы моңа җай килде, дип уйлады ул. Кәбировны туры наводкага куярга иде, комбат ике тупны биредә калдырасы итте. Бәхете.

Сөйләшкән саен, аның белән әләгешеп китәсең. Кәбиров бик ачы телле, ачулы. Нигә ул шулай тискәре? Ахры, аны кемдер бик каты кимсеткән, хәзер җай килгән саен шул ачуны чыгара. Юк, бәлки алай түгелдер?

— Нәрсә, бик исәпкә баттың, Кәбиров, ә? — диде замполит төртмәле итеп. Кәбиров хәйләкәр генә елмаеп куйды.

— Минем исәпне белә алмыйсыз, иптәш замполит. Ичмаса, сез белә алмаган уйларым бар.

— Серләр, хыяллар инде.

— Киткәндә эти белән ачуланышкан идем, хәзер шул эчне тырный.

— Үкенderәме? Минем дә элекке кайбер эшләрем искә төшә дә, эх, ник алай эшләдем икән дим.

— Әти бераз эчәргә ярата иде, тавыш та шуннан чыкты.

— Ул эчүдән дә алама нәрсә юктыр, чын. Әй, харап итә лә адәм башларын!

— Яз чыгу белән безнең авыл яшел суган сатарга керешә. Кәсебе

шул. Кайберәүләр суганны Беренче май бәйрәменә җитештерәләр, ну, акчаны умыралар инде. Кырык беренче елның язында безнең дә суган майга өлгерде. Кояш иртә карый торган җиргә чәчкән идек. Иплән кенә суганны йолкыдык, сары кыякларыннан чистарттык, күзгә ачысы кереп гел яшьне агызып торды. Вак-вак кына бәйләмнәргә бәйләдек, сатарга җайлы булсын дип. Бригадирдан көчкә ат юнәттек һәм әти суганны төяп Бөгелмәгә китте.

Зур өметләр белән көтәбез этине. Әни үзенә күлмәклек, мин аякка ботинка булмасмы дим, миннән кечкенәләр тагы күп әле анда, аларның да өметләре канатлы.

Икенче көнне хәбәр килеп ишетелде, Бөгелмә базарында исерек көе күргәннәр этине. Кайтты бу бер заман, күлмәклек тә юк, кечкенәләргә хәтта конфетлык та калмаган, бар акчасын эчеп бетергән. Әни дуларга тотынды, минем китәсе елым, куркып тормыйм, мин дә ябыштым тегеңә.

— Ичмаса, күршеләрдән оялыр идең әзрәк,— дим. Ачу килде. Урамга чыгарга гарьлек!

— Әнә, мич башында гына ят,— ди.

— Ну, бер армиягә китсәм, гомеремдә дә бу йортка әйләнеп кайтмыйм, дим. Минем анттан әнинең коты чыкты.

— Ант итмә, улым, ант итмә,— дип елый ук башлады.

— Син кайтмаганнан мич кырые кителеп төшмәс,— ди әти, һаман айнып җитмәгән килеш. Бер атнадан армиягә алдылар. Хәзер уйлыйм да нигә кайтмыйм дип әйттем икән, дим, эх!..

— Синең этиең кем соң?

— Тәгәрмәч эшләүче.— Кәбиров тагы дару капты.

— Дәртле кеше икән этиең, дим.

— Башсыз диген, башсыз, кем инде муеннан бурыч чакта шулай итә ала.— Кәбиров тамак төбе белән ачы көлеп куйды.— Хәзер оныталды инде, этинең ул эшләрен сагынып искә төшерәм.

— Үзең кайсы фронтта булдың?

— Башта Киев янында, аннан менә бу сазлыклар ягына җибәрделәр. Чолганышта да булдым. Әй, анда күргән газаплар...

— Нигәдер бер дә наградаларың юк?

— Ә нәрсәгә ул миңа? Чолганыштан ничек котылуны үзем генә беләм. Сөйлимме? Сез барыбер ышанмассыз! Ярар! Монысы Ржев районында булды. Патроннар беткәнче сугыштык, ләкин таң алдыннан безне әсир алдылар. Командирыбыз киемен чак алыштырып өлгерде. Ну, кеше иде! Мине ул коткарды. Әйе, безне элеккеге бер май заводы йортына китереп яптылар. Йорт түбә җирдәрәк, уйсулыкта ниндидер бер пычрак күл бар. Лейтенант каяндыр белгән, бәдрәфтән торба шушы күлгә барып төшә, имеш. Торбага кеше сыярлык икән. Лагерьның бөтен шакшысы шуннан күлгә ага. Без моны ике көн күзәттек, булдыра алганча разведка ясадык. Суны берәр сәгать агызып торырга мөмкин, торба эченең бераз чистаруы ихтимал. Монда да үлем, анда да, диде лейтенант, котылуга әллә ни ышанмыйча. Канализация торбасы күлгә җитү белән бетсә, котылуыбыз ихтимал, судан сразы өскә калкырга була, әгәр өч метр күл эченә керсә — беттек. Торбадан кире чыгып булмаячак. Бу чәч минем шунда агарды.— Кәбиров туктап, яңагын учы белән кысты. Теше сулкылдап авырта иде... Тагы ниндидер дару капты, аннары сөйләвендә дәвам итте: — Лейтенант: «Әйдә, тәвәккәллик, Кәбиров», диде. Без немецларның ниндидер бәйрәм көнен чамаладык. Сак ул көнне йомшак иде. Кич булу белән торбага килә торган суны бикләп, икенче юлдан җибәрдек тә төшеп киттек. Ул минем билемнән бау белән алып, үзенең биленә бәйләде. Пычрактан үрмәлибез, тын алып булмый, әшәке ис үпкәне мең энә белән чәнчи, һава әйтерсең тимердәй каты, бугаздан буа да буа. Үз-үземне белеш-

термим, өстерәлмәскә тырышам. Күпме барганбыздыр, лейтенант туктады, мин килеп терәлгәч, бауны чиште. «Прощай!» — диде. Мин торба бетеп, суга житкәнлекне аңладым. Бер минуттан ул суга кереп, юкка чыкты. Мин ялгыз калдым. Мин шунда бөтен белгән догаларымны эчтән укыдым, бөтен таянычым бер аллага гына калды, бүтән бернинди ышаныч юк иде. Алла булмагае чурт булсын, миңа шул секундта, үлем авызына кергән кешегә, тагы бер талпыну өчен таяныч кирәк иде...— Кәбиров тагы тынып калды, Ваһапов аны сүз белән бүлдерергә базмады, ул хәзер үзенең бу кешегә карата фикерләре үзгәрә башлаганын тойды. Кәбиров чынын сөйли иде, ул тирән итеп көрсенеп куйды, тамак төбенә тыгылган яшен белгертмәскә тырышты.

— Бер минуттан мин дә шул үлем суына баш белән ыргылдым, артка юл юк иде. Ничек өскә калыкканымны белмим, лейтенант яңагыма тигәч кенә исемә килдем, безнең башлар пычрак өстендә йөзә иде. Каршы як ярдагы таллыкка чыкканда таң атып килә иде, тизрәк ешкынлыкка кердек. Эндәшерлек хәл юк, күзләр белән генә аңлашабыз. Егылганчы бардык та бардык. Немецлар куа килсә дип, сакланып, бер сазлык эчендәге утрауга кереп йокладык. Аннары тагы бик күп тәмуг газаплары кичеп, унөч көн дигәндә үзебезнең якка чыктык. Лейтенант бик башлы, уңган кеше иде, ул булмаса, мин беткән идем. Кайтып, полк командирына сөйләп бирдек. Ул лейтенантны кочаклап үпте, күзләренә яшь тулды.

— Ну, Савельев, брат, үпкәләмә, жәл, сине үземдә калдыра алмыйм! — диде аннары, авыр сулап. Лейтенант барысын да аңлады, туптуры командирга карады, эх, аның ул карашын гомергә онытасым юк. Часть расформировать итәлде, яңа часть белән Ржев янында прорыв ясаганда мин каты яраландым. Ә калганы сөйләп тормасаң да аңлашыла, иптәш замполит,— дип сүзен тәмамлады Кәбиров һәм, бер ноктага төбәлгән килеш, еракка киткән караш белән тынып торды.

— Әйе, безнең солдат күргәнне сөйләсәң кеше ышанмас! — диде Ваһапов, портсигар капкачын шартлатып, папирос алып кабызды...

Комбат таң атканчы тупчылар янында кайнашты. Тупчыларны траншея казып тоташтырырга житешеп булмады, яктырды. Бәлки әле иртәгә хәтле фриц кузгалмас дип тә уйлады комбат. Курск дугасында җиңелгәннән соң да немецлар үзләренең «тигр»лары белән мактаналар. Бер яманның бер яхшысы була дигәндәй, фрицлар безнең өскә хәзер килсәләр, алдагы һөҗүмнәр өчен бу «театр» безгә файдалы гына булачак. Безнең көчле һәм көчсез як беленәчәк. Тик туры расчеты булмаган, моңарчы квадратларга һәм аерым цельләргә атып гадәтләнгән тупчыларга бик кыен туры килер. Немец әле һаман көчле, аңарда үләрдәй яраланган ерткыч көче бар. Бу гаять куркынычмыни? Бәрелештә түземлек һәм салкын канлылык белән генә җиңәргә була.

Кояш күтәрелеп килә. Кояш, ә кич житкәндә күрерменме мин сине, юкмы? Комбатның күңеленә кинәт әнә шундый уй килде. Каян әле шундый хорафат башка килә? Бүген үк Фирага хат язам... Кинәт Фираның озын матур муенын, баш борышын сагынып күз алдына китерде. «Эх» дип ачынып куйды. Ул яңа НП блиндажына керде, чишенеп тормыйча гына идәнгә ятты, шунда ук йоклап та китте. Бер минуттан инде сәер төш күрергә тотынды. Имеш, ургылып-ургылып ага торган ташулы елга. Суының төсе коңгырт, бик куркыныч, шомлы. Ә ташкын эчендә аксыл бүрәнәләр кыймылдашып ага. Кинәт шунда бер бүрәнәгәме баскан килеш, кәлә-кәлә Бикиев килеп чыкты. Алексей аңар эндәшергә дә өлгерә алмый калды, елга борылышында күмелеп, тегe юкка чыкты... Нәрсә булыр бу? — дигән уй төшен дәвам иттерде. Шул вакыт аны иртәнге ашка уяттылар. Әз генә йокы да миен сафлан-

дырып, фикерләрне ачыкландырып җибәргән иде. Уянганда төше инде онытылган иде, хәтере, шул арада юнәлешен үзгәртеп, хәзергегә тоташты.

— Ничек анда, янмыймы? — дип элемтәчеләргә кычкырды.

— Әлегә үзгәрешсез,— диде кемдер йокылы тавыш белән.

— Иптәш комбат, сезне сорыйлар,— диде яңа гына линиядән эт кебек арып кайтып, дежурга баскан Әнвәр. Комбат борчылган һәм шомлы кыяфәттә трубканы алды. Тыңлаганда йөзенә үзгәреш чыгармады, димәк, әллә ни юк икән әле, дип уйлады Әнвәр. Комбат «хуҗалыкка» кайтып китсә, бераз йоклап алырга хыялланды. Йокламаудан аның күз төпләре көйгән, йөзе тагы да агарган иде.

— Сүздә яхшырак, эштә начаррак димәкче буласызмы? Дөрес! Бу теге, ничек әле — гаепсезне кыйна, гаепле гаебен танысын, диләрме? Шулай инде анысы, мине тагы читләтеп үттеме бәхет? Әллә мин бәхет белән аймыл булдыммы? — Комбат көлә-көлә сөйләшә, әйбәтрәк хәбәр әйттеләр, ахры, кәефе күтәрелгән шикелле булды. Әнвәр аның батареяга китәчәген йөзеннән күрде, йокларга әзерләнде. Ләкин комбат трубканы куйды да:

— Шундый эшләр, эт үз хуҗасын танымый...— диде үзенә тәнбиһле рәвештә. Аннары каешын җайлый-җайлый:— Малайка, минем белән, Шилов, телефон төбенә! — дип өстәде.

Әнвәр, бәхете, карабинын ташламаган иде, хәзер комбатка коралсыз ничек иярер идең? Китеп барганда комбат блиндаж авызында кайнашкан Сөенчалинга:

— Минем урынга калып торасың! — диде, үзенең кая киткәнлеген кул изәп күрсәтте.

Батареяга җиткәндә, кинәт куаклар арасыннан Римма килеп чыкты. Комбат та, кыз да туктадылар.

— Иптәш капитан, вакытлыча сезгә җибәрделәр, рөхсәтме? — диде кыз, честь биреп тормыйча гына. Ул боек иде, нәрсәгәдер кимсенгән кебек иде. Битендә әз генә беленгән алсулык шәүләсе пәйда булды.

— Мин шат, безне буксирга аласыз, димәк?

— Шулайрак.

— Сугышчыны санграмотага да өйрәтсәң, дим.— Комбат нәрсәдер әйтеп бетермәгән шикелле булды.

— Анысын да эшләрбез, ләкин сездә калырга җыенмыйм,— диде Римма, комбатның тел төбендә ниндидер киная сизеп. Алексей күзләрен шаянландырып елмайды.

— Нигә, без сөйкемсезләрмени?

— Белмим.— Кыз сүзне озайтырга теләмәде.

— Рая янына урнаш. Ничек, ризамы?

— Рәхмәт, Алексей Егорыч.

Кыз, китәргә ашыгуын белгертеп, капчыгының бавын тартып куйды. Алексей «хәзергә» дигәндәй сул кулын күтәрде, һәм Римма китеп барды. Алексей, немецларның һөҗүм итү ихтималы шулай ук реаль микәнни, дип уйлады һәм Ваһапов блиндажына керде. Замполит исә ниндидер бер калын китап укып утыра иде.

— Тугыз нуль-нульдә хуҗа дәште,— диде комбат.

Ваһапов китап, дәфтәрләрен җыештыргалады да чемоданына салып куйды. Күкрәк кесәсеннән тарагын алып чәчен тарады. Аның йомры киң маңгаенда җыерчыклар бер язылды, бер җыелды. Ул җитез генә урыныннан торды, ременен кысты, төзәтенде, җыйнак һәм канәгать кыяфәткә керде. Сүзсез генә Әнвәрне телефон төбендә калдырып, алар чыгып киттеләр. Почмакта радист үзенең рациясен көйләп маташты. Әнвәр телефон трубкасын башына бәйләп куйды. Идәнгә кырын ятып, стенага сөялде, ул хуҗалар юклыгыннан файдаланып бераз черем итеп алырга уйлаган иде, тик бу нияте барып чыкмады...

...Повар кыз Рая үзенең дустын шатланып каршылады.

— Югалмабыз, Римма, кешеләр мировой монда,— диде. Куркып, шикләнеп торган кызны кочаклап, сөенечен белдерде.

— Мин теге бәйләнчектән качып килдем, Рая. Нишләргә дә белмәдем, һаман миңа кагыла.

— Әллә ярату шулай була микән, Римма? — дип, хыялчан, яратуга сусаган чырай белән кинәт кенә сорап куйды Рая. Аның да Римма шикелле үзе артыннан егетләрне елатып йөртәсе, буйсынмаучан, горур буласы килә иде. Ләкин теләге коры хыял гына булып кала, аны җиңел генә баш идерәләр, матур сүзләр белән күңеленә үтеп керәләр һәм ул үзе дә сизмәстән эри дә төшә иде.

— Ярату түгел, хайванлык,— диде Римма. Ул Раяга барысын да сөйләп бетерми, үзенең шул кеше белән дуслашуына ачына иде. Сергейны бит Яким Зиновьевич та бик мактаган иде, үзем дә артык йомшак булдым, ахры, дип уйлады Римма, үзен-үзе эчтән битәрләп. Раяның йөзенә дустының хәлен аңлаган төс чыкты.

— Барысы да шул нәфесен сузарга ярата, ә син кирәк түгел.— Повар кыз җәберсенгән һәм кимсенгән тавыш белән әйтте, Римма белә: Рая күз артында гына шулай яманлап маташа, ә егетләр алдында аның авызы колагына җитә.

Шулай дип уйларга өлгерүе булды, ишектән керүче Сергейны Рая көлә-көлә каршы алды.

Римма бу көтелмәгән хәлне берничек тә башына сыйдыра алмыйча югалып кала язды. Шул мәлне Рая үзенең казаннары янына ашыга-ашыга чыгып та китте.

— Рая, тукта, кая барасың? — дип ялварды Римма. Аның Раяга бик ачуы килде. Сергей белән берүзе калудан курка иде бугай.

— Боткам көя, Римма, мин хәзер...

— Минем дә боткам көя,— диде Римма һәм ишеккә омтылды, ләкин Сергей аның юлына аркылы төште.

— Я, кыланма әле, зинһар. Әйдә сөйләшик әле, Римма, аңла,— дип ялварды Сергей, иңле һәм юаш тавыш белән. Римманы тотып алды, тик кыз елгыр җәнлек кебек аңардан ычкынып китте дә Рая янына чыкты.

— Барыбер тотам,— диде Сергей, Римма артыннан көлә-көлә атлап.

— Комбатка әйтәм, Сергей, маташма!

— Һе, комбат! Мин полковник белән менә болай! — дип, егет ике бармагын янәшә куеп күрсәтте, янәсе, әшнәләр. Сергейны разведкадагы батырлыклары өчен гел мактыйлар. Әлбәттә, лаек ул, әмма кайбер шәхесләр мактануны күтәрә алмыйлар, үзләрен әллә кем итеп күрә башлыйлар. Сергейда да шундыйрак сыйфат чаткылары күренгәли...

— Мине полковник полкның энҗесе дип йөртә, ә син? — Сергей сөйләнә-сөйләнә Римма артыннан китте. Римма, аның сүзләрен ишетергә дә теләмичә, кухня янындагы бер наратка барып сөялде.

— Сергей, кысма мине, син уйлаганча арзанлы түгел мин,— диде Римма инәлеп.

— Римма, ну, өйләнешәбез, син шулай телисең икән... Полковник рөхсәт бирәчәк,— диде Сергей, Рая ишетмәсен өчен шыпырт тавышка күчеп.

— Юк, юк, Сергей, зинһар бәйләнмә!

— Әйдә, блиндажга керик әле, бер сер әйтәм.

— Юк, юк, уйлама да!

— Үзең котырттың да!..— Җанына җыелган дәрт егеткә сүзләрен әйтергә комачаулады. Моңарчы үз дигәнен тормышка ашырырга гадәтләнгәнлектән, ул, аптырап, нәрсә әйтергә белмәде. Римманың горурлыгы аны үтерә иде.— Мин сине яратам, Римма! Ну, ярар, синеңчә

булсын! Барыбер бер җәнлеккә калҗа булырсың! Үкенерсең әле! — Сергей бик кимсенгән төс алып, аска караган килеш, урман арасына кереп китте. Аның кыяфәте миңа хәзер барыбер дигән кебек иде. Ул берни күрмичә атлый, гүя шулай башсызланып бара-бара, ялгыш минага эләгеп шартлар шикелле иде. Римма тагы Сергейны җәлләп куйды. Бераздан егетнең гәүдәсе нарат кәүсәләре арасына кереп югалды. Римма үзе сөялгән наратның суган кабыгы төсле кайрысын кубарып алды, учында ваклады. Аның тизрәк онытыласы, йомшаклыгы аркасында үзе өчен дә, бүтәннәр өчен дә туган читенлектән арынасы килә иде.

Штабта өстәмә күрсәтмәләр алгач, комбат белән замполит ашыга-ашыга батареяга кайттылар. Комбат шунда ук алгы сызыкка туры наводкага куелган орудиеләр янына китте. Ваһапов та, хуҗалыкта эшләрне җайлаштырганнан соң, шулай ук анда барырга тиеш иде...

«Ун тулып килә,— дип уйлады Алексей, НПда күзәтә торгач,— димәк, немец бүген артын кысып ятарга булды. Бәлки әле бөтенләй кымшанмаслар. Алар өчен бу һөҗүм бары башбаштаклык кына булачак...» Тик фикерен тәмамларга өлгермәде, аяк астындагы җир калтырап куйды, немец тупларының аткан тавышы ишетелде, шул ук минутта снарядлар бер-бер артлы төшеп шартлый да башлады. Бар тирәне туфрак фонтаны, ябышкак майлы корым, ачы кара төтен һәм җан кыя торган ярчыклар өере күмде. Алексей кинәт НП авызына чүмәлеп килеп төшкәнен сизми дә калды. Якындагы шартлау дулкыны аны стенага китереп бәрде, тик ул шунда ук сикереп торды һәм, колакларының тонганын сизеп, накатка беркетелгән стереотрубкага текәлде. Эчтән Шилов белән Тәкәнәев элемтә өзелде дип килеп чыктылар.

— Элемтә! — дип кычкырды комбат. Линиягә чыгарга куркып торган элемтәчеләргә шунда ук кыюлык керде. Тәкәнәев, траншея өстенә үрмәләп менеп, шуыша-шуыша линиягә китте.

Кинәт көн караңгыланды, улап, чыелдап килгән миналар җанны суыра, башны тизрәк яшерергә тырышасың. Миңа куркырга ярамый, дип уйлый Алексей, шартлау булган саен окоп төбенә иелә, башта чиркәнчек алганчы шулай итте. Бераздан үз-үзен җиңеп, орудиеләр янына барырга булды. Ләкин миналар шул чаклы еш шартлый, ул берничә минут окоптан күтәрелә алмый маташты. Кемнеңдер йөрәк өзгеч кычкыруы ишетелде,— каты яраланган булса кирәк. Тавышны каты шартлау күмде, аяк астындагы җир басма кебек гел селкенеп, тирбәлеп тора иде. Бар төшне актарылган балчык кантарлары күмә, күзне куе тол газы әчеттерә. «Котырды бу, хәзер танклары киләчәк»,— дип уйлады Алексей.

Бу тирәне тетеп бетереп, немец утны бераз арткарак күчерде. Комбат окоптан атылып чыгып, Черняев орудиесенә таба чапты. Алар исән-сау иде, бик нык саңгырауланудан зарландылар. Черняев үзе нәрсәгәдер елмая иде.

— Әнә коручы Шавлинның тезләре калтырый,— диде. Каска астыннан аның күзләре елтырап тора, ул юри ирештереп сугышчының рухын күтәрмәкче.— Атакай, син берни дә уйлама, башыңны ахмаклыкка сал, бетсәм бетәм, калсам калам диген!

Шавлин саргылт мыеклы, тулы йөзле кеше, сержантның сүзенә каршы:

— Минмени, мин курыкмаска тырышам, үзе бит! — дип җавап бирде.

— Җай белән генә ат, кара аны! — дип, комбат бүтән орудие янына ашыкты. Сөенчалинны барламасаң да ярый, ул ышанычлы, сак, каушап калмас. Немец атакасы вакытында төп нәрсә — түземлек, ашыкмау!

Мушков янына килеп житкәндә, беренче траншеяләрдагы пехотачыларны каушамаска өндәгән Бикиев тавышы ишетелеп китте. Алексейнең аны күрәсе килә иде, әмма хәзер вакыт юк инде. Кемдер жанны өзгән кебек:

— Танклар! — дип кычкырып җибәрде. Комбат биноклен күзенә китерде, кечкенәрәк тау артыннан ике кара колонна булып танклар шуыша иде. Мушков шунда ук орудие янына сикереп менде, подрамникка йөзе белән ябышты, прицельне чамаларга итте, маховикны борып, көпшәне турыларга маташты.

— Иртәрәк әле,— диде комбат, Мушковны окопка чакырып.

Тынычлану өчен папирос алып кабызды, расчетка да бирде. Ул аларның сөйләшүләрен тели, бу авыр көтү минутларыннан игътибарны бүтән нәрсәгә юнәлтәсе килә иде, ләкин расчет сөйләшмәде, һәрберсе окоп төбенә утырган килеш, гасабиланып һаман тәмәке суырды да суырды, бер-берсенә карамаска тырышып, эчтән генә үзенекен кичерде.

— Эх, гомер — тутык тимер,— диде берсе тәмәкесен төкереп.— Ну, тизме инде?!

— Тегә дөньяга ашыкма! — дип тыныч кына әйтте Мушков.— «Тигр»ларны каршы аласы бар әле!

Танкларның җирне калтыратып һәм каты тавыш белән якынаеп килүләре ишетелде. Йөзләр чытык, фикерләр әчке бер ноктага тупланган. Кыргыз Үтәш кенә тыныч шикелле.

— Бронебойныймы, фугасныймы? — дип комбаттан сорый. Комбат аның сүзен ишетмәде, Мушковка таба борылды:

— Башнясын «чөйләсәң», стволын бора алмый ул.— Алексей маңгаена тир, балчык белән ябышкан чәчләрен сыпырды. Каска эче манма су иде. Комбат, НПга кайтырга ниятләп, китеп барды. Сул кулын күтәреп, расчет белән саубуллашты да траншея борылышында күздән югалды.

— Ярый, тапшырдык! — дип, картларча озатып калды аны Мушков. Бер минуттан ул танкларның кирәкле дистанциягә житеп килгәнлекләрен күреп, расчетка команда бирде, кинәт барысы да, шуңа чиксез сөенгәндәй, хәрәкәткә килде, баягы аерымлык кинәт юкка чыкты, расчет тиз хәрәкәт итә торган бер бөтен организмга әйләнде...

Алексей НПга килде, элемтә һаман юк иде.

— Чыбыкны өзгәләп бетергән, табып булмады,— диде Тәкәнәев.

— Яна катушканы сузсаң, тагы тетеп бетерәчәк,— дип аңлатты Шилов.

Комбатның ачуы ташыды.

— Хәзер үк элемтә булсын!..

Шул чак тылдан Әнвәр һәм радист килделәр. Әнвәр комбатка Ваһаповтан язу тапшырды. Чыбык белән элемтә тоту мөмкин түгел, рация җибәрәм, элемтәчеләрне расчетта файдалан, дигән иде замполит. Башка чара юк иде, комбат приказ бирде:

— Шилов, Мушков расчетына! Тәкәнәев, Сөенчалинга, живо!

— Тегеләр шуны гына көткән кебек, төрлесе төрле якка чаптылар.

Тукта, нәрсә бу? Алексей икенче тапкыр алгы сызыкка күз салганда, танкларның сул флангка таба авышып китеп барганнарын күрде. Анда беренче, икенче, өченче батареялар танкларга каршы көчле ут ачканнар иде. Бу ничек була инде? Мушков орудиесе дә бер снаряд ату белән туктады. Бирeдә тынлык булгач, немецлар төп каршылык сулда дип уйладылар бугай. Алексей, аптырап, сугышчылары янына борылып килде. Алар да киеренке рәвештә көтәләр, танкларның аларны читләтеп үтүенә ышанмыйлар иде.

Бикиев ротасының сул флангысында, куаклар артында, пулемет тырылдады. Танкларга ябышып килгән немецларны күрделәр булса кирәк. Бикиевнекеләр кистерә торган ут белән дошманга үтәргә бирмә-

деләр. Тегендәрәк ике-өч җирдә кара төтен чүмәләләре калкып чыкты. Танклар яна иде. Бирегә күренми торган үзәннән чигенеп баручы танкларның аксыл башнялары чагылып киткәләде.

Өйлә авышып килә иде инде. Немец һөҗүменең икенче дулкыны булыр дип сагаеп торганнар иде, алай булмады. Немецның бу кыланышында берәр мәкер яшеренгәндер кебек иде.

Алексей тизрәк штаб белән элемтәгә керү өчен блиндажына кайтты. Әмма радист егет пароль белән эфирга чыгып караса да, штаб дулкынын тота алмады. Комбат озынча ак чырайлы бу яшь кенә малайның тирләп-пешеп җан-фәрманга тырышуын күрде. Аннары үзе наушникны киеп, рацияне боргаларга тотынды.

Шулай да позициягә немец ерактан ата торган фугасный белән һаман төшергәли тора иде.

Шилов, снаряд чокырыннан бер ящикны өстерәп чыгарды да бауга эләктереп, Мушков орудиесенә таба юнәлде. «Немецның атакасы тонтыга, ахры», дип нәтиҗә ясады, шул вакыт күз алдында зур ут көлтәсе һәм балчык өермәсе пәйда булды. Шартлау дулкыны аны каядыр очыртып алып китте, ул җиргә тотынмакчы булды, ләкин кулы, мускулы өзелгән шикелле, аны тыңламады. Гәүдәсе ничектер авырлыгын югалтты, күкрәгеп нәрсәдер бик каты итеп китереп кысты, ул тын ала алмыйча каядыр очты да очты. Авырлыгын җуеп, тирән коега очып төшкән кебек хис итте. «Кое эче салкын булырга тиеш» дигән уй башыннан йөгереп узды. Аңа ничектер рәхәт шикелле тоелды, тәне арып оеган, күзенә ниндидер кайнар нәрсә ага, күзне пешерә,— нинди нәрсә икән ул? Нигәдер гәүдәм җиңеләйгән кебек, дигән сорау аның миен бимазалады. Ләкин шул төштә фикер җепләре өзелде. Бераздан тагы аңына килде. Аңа ничектер бөтен газаплардан шулай ансат кына котылу әйбәт булып, рәхәт сыман тоелды. «Ә бит начаррак та булган булыр иде» дигән уй килде башына, тик дәвам итә алмады, аңы томаланып, тагы караңгылыкка чумды.

Шилов таң атканда гына кемнеңдер үзәк өзгеч ыңгырашуын ишетеп аңына килде. «Мин кайда, мин кайда?» — дип уйлады ул. Бу юлы күзләре ачылды, әмма караңгылыктан башка нәрсә күрмәде. Күзләрем сукырайган икән дип, имәнеп куйды. Ләкин кайдадыр, яшеннеңме, ату ялкынынынңмы бер чаткысы аның күзенә бәреп керде, ул шуңа чиксез сөенде. Ахры, ул йоклаган, тәне шундый җиңел кебек, ә ник бер әгъзаны да кымшатып булмый? Кемдер үлем ачысы белән ыңгыраша, шул аваз колак барабанын ишек каккан кебек кага. Мин кайда соң, нишләдем, әллә мин яраланганмынмы?

— Кем бар анда? — дип кычкырды Шилов, үзенең тавышына гаҗәпсенеп, үз тавышын үзе танымады, ыңгырашкан тавыш бераз тынган кебек булды.— Кем бар анда? — дип тагы кычкырды Шилов.

— Камарада,— диде көчсез, үлә башлаган тавыш.

Шилов немецча сүзләр ишетеп шаккатты. Мин әллә немец алган җирдә калдыммы дип, сикереп тормакчы булды, ләкин кымшана да алмады, аяклар кургаш койган кебек авырайган, кулларны кемдер тотып тора шикелле иде. Юк, мин немец алган җирдә түгелдер дип, исәпләп, үзен тынычландырырга уйлады, ләкин курку аны кинәт айнытып җибәргәндәй итте. Ә немец: «Камарада, камарада?» — дип өзгәләнә иде. Шилов бик нык зиһенен җигеп аның кайбер сүзләрен аңлады. Мин үләм, мине тыңла әле дип үтенә иде ул.

— Нәрсә кирәк сиңа? — дип кычкырды Шилов, немец сүзләрен ватып-җимереп.

— Мин үләм, мине бәйлә, зинһар,— дип ыңгырашты немец.

— Мин үзем яралы, үлеп ятам,— диде Шилов.

— Минем каным агып бетә бит.
— Син кем соң? — дип сорыйсы итте Шилов.
— Мин эшче, дәрәҗәм ефрейтор.
— Ник килдең бирегә?!
— Юк, юк, мин үзем теләп килмәдем,— диде немец.

Шилов кинәт үзләрен унынчыда укыткан немец теле укытучысының тавышын ишеткән кебек булды. Аны Ленинградка Германиядән килгән, дип сөйлиләр иде. Юк, әйбәт немец иде ул. Ә бу бер канечкечтер, мөгаен!

— Алдама, син үзең теләп килгәнсең!
— Көчләп китерделәр,— диде фриц,— әз генә су бирче!
— Мин кузгала алмыйм,— диде Шилов. «Бирермен мин сиңа су! Фашист, ничек сайрый, көчләп китерделәр, имеш! Сезнең барыгызга да фашистлык каныгызга сеңгән!» — дип уйлады эчтән. Аның чиксез ачуы купты, тагы көчсезләнә башлаганын һәм аңы томалана баруын сизде, фикер очлары чуалды, чуалдылар да тагы өзелделәр. Ул кабат уянганда, таң аткан, яктырып беткән иде. Күзен ачып караса, үзенең бер зур снаряд чокыры читендә балчыкка күмелеп ятуын күрде, воронка эче су белән тулып, аның башы янына ук килеп житкән... Ул теге немецны инде оныткан иде. Чокырның теге ягында ярты гәүдәсе су читендә яткан немецны күргәч кенә, кичәге сөйләшү исенә төште. Юк, ул аны төштә күргән иде бугай, төшкә ниләр генә керми, дип гаҗәпсенде. Немецны күзәткән саен өнендә булган хәлне төш дип ныграк ышана барды. Ул ыңгыраша иде бугай, ә хәзер ыңгырашмый, әллә өн булды микән, югыйсә, дип тагы икеләнеп калды. Немец ыңгырашмый да, кыймылдамый да. Аяклары суда йөзә, су аны ике аягыннан тотып жирдән үзенә таба өстери шикелле иде. Йөзе чытылмаган, киң маңгаенда ниндидер самимилек сизелә, гүя бөтенесе дә шулай булып беткәненә ул үкенми, ә киресенчә, бик канәгать кыяфәттә иде.

Шилов аяк тавышлары ишетеп, чиксез куанды, менә ниндидер солдатлар килеп, аны балчыктан казып та алдылар. Шиловның маңгае яраланган икән, берсе индакетын бирде һәм, санбат юлын өйрәтеп, алар китеп бардылар. Юк, тауга таба түгел, янга табарак атладылар. Шилов ни дип уйларга да, нәрсә булганын сораштырырга да өлгерә алмый калды. Атлап китмәкче булган иде, артына кинәт утырырга мәҗбүр булды, гүя аның тез астына суктылар. Аннары көчкә торып, таудан түбән таба төшеп китте, таныш түгел солдатлар очрады. Димәк, бирегә икенче часть урнаша икән дип нәтиҗә ясады Шилов. Ә безнең орудиеләр кайда? Тирә-якта чокырлар да чокырлар, жир тәмам снарядлар белән сөрелеп беткән. Кинәт Шилов комбат Алексей Барановны күреп алды. «Әллә бу тагы төшме? Мин кайда соң? Юк, безнең комбат ич!» — дип, Шилов үзен-үзе ышандырып азапланды. Өн икән болар, өн. Әнә сугышчылар плащ-палаткада кемнеңдер гәүдәсен алып килделәр, юк, төш түгел бу! Комбатның йөзе тырналып, суелып беткән. Иреннәре калтырый, куллары ни тотарга белми тырпайган, кыяфәте коточкыч. Юк, төш түгел икән, әмма нәрсә булыр бу?!

— Командирны ник сакламадыгыз! — дип, контузияле тавыш белән кычкырды ул төркемгә. Шинель почмагын күтәреп, шунда иелде. Бикиевнең өнсез калган матур йөзе агарып күренде.

Комбат хәлсезләнеп, Бикиев гәүдәсе янына килеп тезләнде. Пычранып беткән учлары белән йөзен тотты, жилкәләре дерелдәде, умырылган гимнастеркасы аша ямаулык кебек булып эчке күлмәге күренде.

Сугышта да кешегә рухи таяныч кирәк. Бикиев Алексей өчен рухи терәк иде. Көтмәгәндә барысы да кинәт чәлпәрәмә килүе аны чыгырдан чыгарды...

...Немец һөҗүме үзенең басымын арттырган вакытта бер самоходка безнең тылга үтеп чыккан. Сул флангтагы кырык биш миллиметрлы берничә батареяны изеп ташлаган. Үзенә корбан эзләп, әкияттәге аждаһа шикелле тылда йөргән. Аны ни сәбәптәндер җимерә алмаганнар. Ул оста маневрлар ясап, безнең батарея хуҗалыгына килеп чыккан.

Кәбиров самоходканы күргәч күзләренә ышанмыйча торды, аннары гына исенә килде. Снаряд ташырга куелган казакъ Мурзыев бик тыныч иде, гүя хәлне аңламый, үлем янаганын да тоймый. Аның шул чаклы ваемсыз булуына Кәбировның тәмам ачуы чыкты. Ул кабалана-кабалана һаман нишләргә белмәде. Самоходка әгәр аларны күрсә, килеп, һичшиксез, изеп ташлаячак. Кәбиров моны бөтен барлыгы белән аңлады. Мурзыев, кысык күзләре белән аның каушавын күзәтеп, тик тора иде. Кәбиров шунда:

— Гранаталар, гранаталар! — дип ысылдап кычкырып җибәрде.

Окопка төшеп, аларны ыргытырга җайлап маташты, запалларын таба алмыйча каушап бетте. Самоходка һаман килә, Кәбиров нишләргә белми, атаргамы, атмаскамы? Маңгайга атып мәгънә чыкмаячак, орудиене генә белгертәчәкбез, әле самоходка «сукыр» килеш бара.

— Ат, ат! — дип кыстый Мурзыев кысык тавыш белән. Аңарга да хәлнең үлем яки исән калу икәнлеге аңлашыла башлады бугай.

Кәбиров ачу китергеч рәвештә ыгы-зыгы килә. Әллә куркуын җинә алмыймы? Әллә берәр могҗиза үзен коткарыр дип атмыйча торамы? Могҗиза булмаячак! Исән калсаң, шул гына могҗиза булса булыр... Самоходканың саргылт-яшькелт бронясы да аждаһа төсен хәтерләтә.

— Ат, ат! — дип лафетка тезләнгән килеш ысылдый Мурзыев.

— Турыга ату — аңа борчак белән аткан кебек кенә! — ди Кәбиров калтыранып. Кинәт башын бер уй кисеп үтә: бер кырыйга аткан булып, самоходканы алдарга. Ул узып киткәч, артына бәрергә!.. Инде бүтәнчә мөмкин түгел, хәл кискен, ни булса, шул булыр, дип, Кәбиров стволны борып тылга табарак атып җибәрде. Самоходка корбан эзли иде, тагы берне атты. Куркуы да бераз кими төшкәндәй булды, хәзер кул һәм ми автомат шикелле тиз эшли...

Көчле җил төтенне җирдән себереп алып китте. Нәрсә булыр? Нәрсә булыр, дип йөрәкләр чигәдә тибә. Бер минут, ике... карасалар, самоходка боларны узыбрак бара. Кәбировның ашыгуы ток шикелле Мурзыевка бирелде, тыныч чагында өч-дүрт кеше генә кузгата торган орудиене икесе бер минутта борып куйдылар. Кәбиров панорама артына басты, ләкин күзе берни күрми, аны тир каплаган, тир тозы күзен шешендергән иде. Көчкә күзен тырмап ачып, маңгаен пилоткасы белән сөртте, самоходка бу орудиене эзләп китеп барганда, жалюзына төзәп атып җибәрде. Ләкин ашыгычлык белән тигерә алмады, тагы төзәп атты, анысы да ары үтеп төште. Самоходка туктап калды. «Беттек, кире борылса, беттек!» дигән уй миен яндырып узды. Тагы төзәп атты, аннары тагы. Соңгысы гына тиде, ләкин самоходка янмады, ахры, снаряд бронебойный булган.

— Хәзер борыла алмас, паразит! Шул чак кинәт самоходкадан өч фриц чыкты да боларга таба килә башлады. Автоматларын тырылдаталар гына.

— Мурзый, кая кул пулеметы? — дип кычкырды Кәбиров.— Кая карабин? — дип, икәүләшеп буталышып бетә яздылар. Кул пулеметын таптылар. Мурзыев ата башлады, Кәбиров аны этеп җибәреп, күбәне үзенә алды. Зәңгәрсу мундирлы өч немец ятарга мәҗбүр булдылар. Кәбиров аларның яткан җирендәге үләннәрне чалгы кебек кистерде. Шунысы шәп, бу юлы Кәбировлар өстәрәк, ә фрицлар түбәндәрәк урында булып чыкты. Бер минуттан фрицның берсе яраланды бугай, алар самоходкага таба чигенә башладылар. Мурзыев карабинын тоткан

килеш алар артыннан «ура-а-а!» кычкырып чабарга кереште. Кәбиров пулеметын җилкәсенә элде. Тегеләр самоходкага кире керделәр дә пулеметтан ут ачтылар. Хәзер болар ятарга мәҗбүр булды. Самоходканың пулеметы кырыйгарак бәрә, чөнки башня туры борыла алмый иде. Мурзыев, шуны төшенеп, Кәбировка кочкә генә аңлата алды.

Немецларны терелэй алырга өметләнеп, эчтә үчләре ярсыды. Пулемет уты тими торган буйны шәйләделәр, шуннан самоходкага таба үрмәләделәр. Кәбиров, шушы әсирләр белән замполитның «күзенә төртер» идем, дип хыялланды. Ник ышанмый ул миңа?

— Хенде хох! — дип кычкырды Кәбиров шуышып килгән шәпкә. Ләкин тавышы зәгыйфь чыкты, ул тагы катырак шул ук сүзне кабатлады. Әллә шуны ишетеп, әллә болай, самоходка пулеметы яңадан тырылдый башлады. Әмма тию почмагы ераграк, болар броняга шактый якын иде инде, уттан шул коткарды.

— Хенде хох! — Кәбиров кул пулеметы көпшәсе белән броняга бәрде. Җавап булмады, ул торып, самоходканың икенче ягына чыгарга ниятләде, ләкин кинәт тәгәрмәч арасыннан калкып чыгып, аның өстенә бер гәүдә ташланды. Кәбиров тизләнгән килеш иде, чалкан китә язды, немец пулемет көпшәсеннән эләктереп алып, аны җиргә дыкыды. Шул мәл тәтене тартырга гына иде дә бит, теге бөгелеп төшкән булыр иде, тик Кәбиров алай эшли алмады. Пулемет, каешы өзелеп китеп, читкә очты һәм ул ике күзе янып торган иләмсез кара чырай белән маңгайга-маңгай килде. Фриц үрә басып моның өстенә аварга итә. Ялт тегенең кулында финка чагылып китте. Кәбиров җан-фәрманга аның беләгенә ябышты һәм бик каты, тимер борган кебек итеп каерды. Кинәт янда гына граната шартлады, әллә Мурзыев булды, әллә самоходкадан ыргыттылар? Немецның чигәсеннән кан ага башлады, Кәбировның битенә дә буялды, теге бер якка янтайды, броняга таянмакчы булды. Кәбиров та калак сөяге турында арттан бик каты сукканны, аркасын пешереп узганын һәм хәле бетүен, немецның кызыл кан буялган битенә таба ава баруын тойды. Бүтән ул берни ишетә дә, хис итә дә алмады.

Мурзыев ни сәбәптәндер самоходканың икенче ягына чыгып аның астына «лимонка» ыргыткан, эчтәгеләрне дөмектерергә ниятләгән булгай. Әмма кызулык белән ялгышкан: үз гранатасыннанмы, немецныкыннанмы, контужен булып, җиргә ауган. Безнекеләр килгәндә, Кәбиров, бер фриц белән кочаклашкан хәлдә, үлеп ята иде. Мурзыев кеше тавышларына сискәнеп, башын күтәрде, тик берни дә аңлый алмады.

— Әй, Гансик, чык, килеп җиттек! — дип, кемдер броняга тимер белән суга иде...

*Дәвамы бар*

Марс Шабаев

# ЯЛТА АҺӘҢНӘРЕ

•

Мин Ялтада ялда.
Як-ягымда —
Кипарислар матур, мәһабәт!
Ләкин ятлар,
Холыклары башка —
Юк аларга миндә мәхәббәт.

Алар җиргә гүя юри генә,
Уйнап кына кадап куелган.
Кипарислар көязләнә бирсен,
Каеннарым китми уемнан.

Язгы кар исеннән исерә-исерә,
Каен суы эчеп йөргәндә,
Умырзая зәңгәр ялкыннарын
Кызганмыйча юмарт биргәндә,
Кызлар чәчәк кебек ачылганда,
Яз җилләре кагылып китүгә,
Нәни кояш булып балкыганда
Алар йөзендәге сипкелләр,
Иделемдә бозлар ташыганда,
Актарылып,
Күкрәп,
Дөбердәп,—
Яшел орчык төсле салкын, җансыз
Кипарислармыни күңелдә?!
Хет кисегез!
Мин — сут җыйган каен,
Умырзая.—
Минем ялкыннан
Бозлар түгел, кызлар эрер иде!
Зәңгәр ялкыннарым балкыган.
Мин — язгы җил —
Кызлар йөзендәге
Сипкелләрне сыйпап үтүче.
Мин ул — Идел бозы —
Кузгалырга
Ташкын суны зарыгып көтүче.

Кипарислар гүя юри генә,
Уйнап кына кадап куелган.
Алар, әйдә, көязләнә бирсен,
Каеннарым китми уемнан...

●

Суың зәңгәр,
Исемең — Кара диңгез!
Үз итмәссең, ахры,
Кагарсың.
Читтән килгән татар малаена
Чит йомычка итеп карарсың.

Эзләгәнем син түгелен тоеп,
Үчләнәмсең шулай, ярсынып?
Әүлия син!
Минем күз алдымда
Бормалана һаман ярсу ЫК.

Юк, юк, үпкәләмим.
Искәртүең,
Кисәтүең әле ярады.
Мин — йомычка.
Ыкта чайкалырлык,
Бер учакта дөрләп янарлык,
Ләкин,
Кирәк булса,
Диңгезеңдә
Батмыенча гомер агарлык.

●

Әйтерсең дулкыннар —
Уйныйлар дельфиннар:
Ял иткән халыкка тамаша.
Инде төн. Караңгы.
Кешеләр таралды...
Дельфиннар калдылар таңгача.

Таң белән килделәр,
Кешеләр күрделәр:
Дельфиннар һаман да шаяра.
Уйныйлар дельфиннар,
Чәчрәтеп дулкыннар,
Ярга ук сикереп кай ара.

Өч тәүлек дигәндә,
Чумдылар тирәнгә,
Куркытып вак-төяк балыкны.
Киттеләр, киттеләр...
Һәм моңсу иттеләр
Яр буен, андагы халыкны.

4*

Аларның уйнамый,
Дулкыннар кыйнавын,
Елавын сизмәде беркем дә.
Зар булып соңгы кат
Килгәндер дельфиннар:
— Аңлашыйк, кеше,— дип,— бер телдә!

●

Ташлар өстеннән йөгерә дә утә,
Йөгерә дә утә Учан-су...
Саф суларында синең шәүләңме?
Нигә соң әле уйчансың?

Күренми миңа Учан-суларның
Көмештәй чиста төбеннән:
Йөгерә дә утә, йөгерә дә утә
Гайбәтме әллә күңелеңнән?

Кемнәр тырыша күңелеңне шулай
Айкап, болгатып карарга?
Тау чишмәләре һәр вакыт сафлар,
Пычрак иярми аларга.

Йөгерә дә утә, йөгерә дә утә...
Ташлар өстеннән Учан-су...
Кеше сүзләре йөгерер дә утәр —
Нигә соң әле уйчансың?

●

Дәһшәтле сугыш еллары.
Син сабыйга табигать
Әйткәндер: «И бала, бала...
Нинди көчләр табыйм, әйт!
Еракларда — утлы сөрем,
Биредә — явым болыт.
Җылытырга, яратырга
Калганмы ягымлылык?
Бар булган матурлыгымны,
Сафлыгымны ал, әйдә!
Бер сабыйга төкәнерлек
Бардыр әле алай да.
Сугыш ялмап бетергәнче,
Сиңа бирим, кыз бала.
Кыз бала бит — булыр ана,
Анадан кем кызгана?
Сугышны үтереп үлә
Еракта әтиләрең.
Уллары ятим булмасын
Синең күк ятимнәрнең.
Үс кенә, әйдә, авыз ит
Балтырганнан, юадан...
Баһадир егетләр итеп
Кайтарырсың яңадан».

...Үсеп җиттең.
Сөйгәнең бар —
Матурлыгың кызганма:
Табигатьнең әманәтен
Үтәр вакыт, кыз бала!

●

Диңгез җәйрәп ята иркәләнеп,
Сукайлары зәңгәр фирәзә.
Чуерташлар җыеп яр буеннан,
Белгәнемчә итәм күрәзә.

Менә ак таш.
Түп-түгәрәк үзе.
Кемнең бәхетләре түгәрәк?
Дулкын ялмамасын.
Алып куйыйм
Бәхет ташын бераз түргәрәк.

Монысы — яшькелт.
Әле чарланмаган.
Бу кемнеңдер, ахры, яшьлеге.
Суга салам:
Әле сыналырга,
Кыйналырга тиеш яшь кеше.

Менә — кызыл.
Нәни генә тамчы.
Кан-яшьләрнең әллә тамчысы?
Җыйганмы ул диңгез төпләреннән
Кайгы диңгезенең ачысын?
Мин ыргыттым аны бик еракка.
Кире чыкмас булсын,
Югалсын.
Барыбер чыгар ләкин —
Кеше канын
Нинди сулар гына юалсын?

Ә бу — зәңгәр!
Үтә күренеп тора.
Мәхәббәткә аны юрыйм мин.
Оялтасым килми,
Аңа тимим,
Күрмәмешкә салынам юри мин.

Ә монысы — сары.
Миңа пары.
Сары сагышларым тамгасы.
Күеныма салам:
Миндә калсын,
Диңгезләрдә сагыш калмасын.
Кирәк булса,
Диңгез янә табар —
Диңгез бит ул изге, олы җан.
Сагыш байлык миңа бу көннәрдә,
Сагышларым белән җылынам.

Җәйрәп ята диңгез иркәләнеп,
Сукайлары зәңгәр фирәзә.
Чуерташлар җыеп яр буеннан,
Мин үземчә итәм күрәзә.

●

Таудан иңде болыт,
Кара булып.
Була икән кайчак танышы
Болытның да!
Хәтерләтте кинәт
Ай-Петрида күкрәү тавышы
Нәкъ шушындый кара бер болытны...
...Ык буенда идек,
Куышта...
Икәү генә идек...
Ә ул болыт
Метрәй тауларыннан шуышты.
И ишелде өскә!
Яшен телде
Утлы камчы белән күкләрне.
Гүя сине сукты —
Миңа аудың...
Кайнар иде синең күкрәгең...
Шомлы иде куыш.
Дөм караңгы.
Рәхмәт инде кара болытка:
Яшеннәрдән якты хисләр алдым,
Сине таптым караңгылыкта.

...Әле менә иңде дә болыт,
Йөрәк гүя куйды убылып.

●

Янә салкын, шыксыз, шомлы
 төн килде,
Ялгызлыгым белән таңгал,
 тиң килде.
Йомшак урын, ак җәймәләр
 өстендә,—
Гүя судан алган балык
 төсле лә!—
Бәргәләндем, боргаландым,
 әйләндем...
Ай үттеме, ел үттеме? —
 Әйтәлмим.
А, ниһаять, балкып көләч
 көн туды!
Битләремә җылы, йомшак
 нур кунды.
Назлы җил сарылды иңгә
 иркәләп.
Шатлык тоеп тетрәнде җан
 иртәрәк...

Син түгел бит, син түгел бит,
ах! түгел!
Ник соң шулай җанга якын
ах! бу көн!

●

— Сим-сим, ач ишекне! —
Бер ваемсыз,
Бер риясыз авыл баласы, —
Юри генә мин шакыган идем
Ишегеңне, Казан каласы.
Ачылды да куйды!
Кердем киттем...
Таш урамнар булды лабиринт.
Әйттең, ахры, кала:
«Бу балага
Ягын онытырлык яр бирик!»
Серле идең, кала, сихри идең...
Туып килә иде алсу таң...
Пәйда булды гүзәл яр дигәнең,
Шык-шык атлап шыксыз асфальттан.
Аны тапкан асфальт урамнарда
Мин ваз кичтем болын-кырлардан.
Онытылды сиртмә коеларым,
Сулар эчтем колонкалардан.
Казанда да тополь мамык коя,
Кыркып торсалар да башларын.
Җирсүемне җилгә очырдым шул,
Сагышымны кыркып ташладым.
Авыл алачыгы.
Анда — чыңнар...
Йотылдылар оркестрларда.
Эх!
Кайтарып кабат шул елларны
Сандалларга салып сугарга!
Инде хәзер күпме шакысам да:
— Сим-сим, ач! — дип,— серле ишекне.—
Әкият онытылган...
Тылсым үткән...
Таш лабиринт...
Беркем ишетми...

●

Үпкәләмә.
Кыз чакларың түгел.
Сүреләдер матурлыгың да...
Йөрәгемә иртә кергән идең,
Соңлап урын таптың җырымда.
Булды вакыт:
Сыеша алмый, ташып,
Кага идең кайнар күкрәгем.
Чайпалдырмадым да,
Түкмәдем дә —
Барыбер сине җырга кертмәдем.

Күңел — комсыз,
Йөрәк көнчел булды:
Яшереп килдем кеше күзеннән.
Аз идеме гыйшкын җырлаучылар,
Җырлап бетермичә өзелгән?!
Җырга кереп күпләр онытылды.
Ә син идең һаман моң гына.
Шауламадың,
Урын дауламадың,
Үз урыныңны белдең тын гына.
Син һәр вакыт янда,
Янәшәдә,
Әйтерсең лә минем күләгәм.
Сиздермәдең...
Ләкин ул җырлардан
Йөрәгең көнләгәндер, көнләгән!
Кил әле, кил!
Йомшак башмаклардан,
Кухня исе сеңгән халаттан
Булсаң ни соң?
Сине җырлыйм әле
Тарсынмыйча гына халыктан.
Җырлыйм әле...
Сине һәрчак янда,
Янәшәмдә кебек хис итеп:
Казаннардан килеп җитмәссеңме,
Соңлап туган җырым ишетеп...

## Әдхәт Синеголов

### Таулар иле

Йөрәк кебек Урал тавы тибә
Башкортстан күкрәге өстендә.
Канатланып очтым тауларыңнан,
Синдә туып, синдә үстем дә.
Уралыма билбау булып аккан
Агыйделгә гыйшкым төшмәсә,
Иңен-буен колач салып иңләп,
Су коенып, суын эчмәсәм, —
Мин үземне Урал чаклы тауның
Варисы дип санар идемме...
Янар таулар булып капкан утлар
Йөрәгемдә янар идеме?
Яшьнәп чапкан чаптарларың сыман
Күкрәп үткән яшьлек бу җирдә...
Әллә шуңа сагынып ул якларның
Мин тауларын йөртәм иңемдә.

### Чаң

Тыңласаң,
Уйласаң,
Уйлансаң, —
Таңнарның
Чыңнары
Яңача...
Кага чаң,
Кага кан,
Тибә кан.
Көн туа,
Уй туа,
Туа таң.

Йөрәктә —
Җан булып,
Гамь булып,
Кага кан!
Кага аң!
Кага чаң!
Тыңласаң,
Уйласаң,
Уйлансаң, —
Чаңнарның
Чыңнары
Яңача.

●

Кораблар океанга китәләр,
Кемнедер каядыр илтәләр,
Кемнедер кемнәрдер көтәләр...

Кораблар кәрванын карап кал:
Кораблар океанга китәләр;
Киткәннәр кулъяулык селкәләр,
Калганнар яшьләрен сөртәләр.
Барын да хәтерләп карап кал:
Океанга китәләр кораблар...
Исеңдә калсын бу иртәләр —
Кемнәрдер кайтмаска китәләр,
Ярларда калганнар көтәләр, —
Кораблар океанга китәләр...

●

Балыкчы кыз, кил, чибәрем,
Балыгың калсын комда...
Утыр яныма, серләшик
Кулларны салып кулга.
Куй башыңны күкрәгемә,
Качма иркәләвемнән.
Уйныйсың ич син диңгездә
Һәр көн язмышың белән...
Минем йөрәгемдә диңгез —
Давыллар китә-кайта...
Үзәгендә китмәс-кайтмас
Гаҗәеп серләр ята.

●

Күкләрнең бар үз йолдызы,
Диңгезнең үз энҗесе...
Йөрәкнең бар берәүгә дә
Әйтелмәгән бер хисе.
Күкләр, йолдызлар, диңгезләр
Сыйган да йөрәгемә,
Балкып, янып, шаулап, тынып
Сөяләр сине генә...

**Кирәй Мәргән,**
башкорт язучысы

# СОЛДАТ ХАТЫ

хикәя



Фәнүзәне бу йортка бригадир үзе китереп куйды.

— Мөнирә апа,— диде ул,— менә шушы кызыкай сездә торып торсын әле?

Хуҗабикә ишек төбендә кыюсыз басып торган кызны күзе белән сөзеп карап алды да:

— Эшкә килгәнме? — дип сорады.

— Әйе, безгә эшкә җибәргәннәр,— диде бригадир һәм үзе шунда ук Фәнүзәгә борылып өстәп куйды.— Монда сезгә әйбәт булыр. Күрәсез, Мөнирә апаның өе иркен. Бала-чагасы юк.

— Нинди эшкә җибәргәннәр?

— Балалар бакчасына.

— Торса ни, торып карасын алай булгач.

Бригадир чыгып китте, Фәнүзә шулай итеп торып калды.

— Хәзерге яшьләр килештерә инде,— диде хуҗабикә,— безнең заманда яслесе түгел, басуда утырып бала имезер өчен ышыгы да юк иде. Барыбер үстеләр. Берни дә булмады. Чишен әйдә, нишләп аптырап торасың?

«Мыжыграк, ахры,— дип уйлады Фәнүзә,— кыен була башласа, икенче кешегә күчми туры килмәс».

«Пешмәгәнрәк, ахры,— дип уйлады хуҗабикә аның турында,— бик йомшак күренә башласа, тотып булмас».

Кичке чәйгә утырганчы сүз булмады. Фәнүзә, чемоданын актарып, өстәлгә сәйлүн чәе чыгарып куйгач кына хуҗабикәнең йөзе әзрәк ачылып китте.

— Кайсы яктан буласың?

— Дүртимән авылыныкы.

— Якыннан икәнсең. Укудан килдеңме?

— Әйе!

— Кеше баласын карарга укымасаң, юньлерәгенә кереп булмадымыни?

Әлбәттә, мондый тозсыз сорауга кискен сугып җавап бирергә булыр иде. Фәнүзә алай итмәде, юаш елмаю белән үткәреп җибәрде.

Өстәлне җыеп алгач, Фәнүзә хат язарга утырды. Мөнирә җиңги кулына бәйләмен алды.

«Әнкәсенә язамы икән? — дип уйлады ул, Фәнүзәнең бармаклары кәгазь өстендә бик җитез йөгерүен күзәтеп. — Берәр егет-җиләнме икән? Үзе шулай өтек кенә булса да, аның да берәр шүрәлесе бардыр әле!»

Түзмәде, сорап алды:

— Әниеңә язасыңмы?

Фәнүзә җанланып китте.

— Юк. Бергә укыган кызларга яздым. Дүртимәнгә үземә кайтып килергә туры килә инде. Мендәр-фәлән алып килергә кирәк ләбаса. Карават кирәк, юрган...

— Кайчан китәсең?

— Иртәгә булырмы икән, иртәгәдән соңгамы?

— Алайса, киткәнче, миңа да бер хат язып ташлыйк әле.

— Языйк соң, хәзер үкме?

— Хәзер яз. Армиядәге улыма. Исеме Зөфәр була. Гайнетдинов.

Фәнүзә дәфтәренең куш битен өзеп алды, сорап та тормый, башына: «Кадерле улым, Зөфәр!» дип язды. Тавыш-тынсыз гына көтә башлады.

— Үзем язганны таный алмый шул,— дип тезеп алып китте хуҗабикә,— мин бит искечә язам. Гарәпчә. Латинчасын да вакытында аз гына укып калдык. Хәзергечә язарга тырышып буталып китәм дә, бер нәрсә дә аңлашылмый.

Фәнүзә көтеп утырды, ә хуҗабикә һаман кирәкле сүзен әйтмәде.

— Нәрсә дип языйм?

— Бәй, сәлам хаты язганың юкмыни? — диде кинәт Мөнирә җиңги һәм шунда ук үзе тезеп алып китте, — башта бер күрергә зар-интизар булып торучы әниеңнән дөнья хәтле сәлам, дип куй. Аннан соң туган-тумачадан, күрше-күләннән, яшь-җилкенчәкләрдән, карт-корылардан — барчасыннан аермыйча күп сәлам, дип яз.

Фәнүзә, боларның берсен дә төшереп калдырмаска тырышып, дәфтәр битенә юллар салды. Мөнирә җиңги, бала тибрәткәндәге кебек, моңсу гына тавыш белән башына килгән хәбәрен тезде:

— Авылда, иншалла, иминлек әле, дип яз. Маллар быел, ходайга шөкер, көр чыкты, диң. Язгы сабанны «ә» дигәнче бетереп куйдылар, дигең. Дәяркәләр ярышында безнең Камилә алга чыккан иде. Премияне алгач, эше тагын хөртәеп китте, дип куй. Эшен юньләп карамый башлады, дигең. Бала-чага хәзер ихахай да михахай бит. Эшеңне карамый, гел сикергәләп йөри башлагач, ул сөт каян килсен, ди? Сыер бит ул әдәм баласы кебек: сыйлап-сыйпап торсаң гына мал була, сөтен дә бирә, каймагын да... Мин үзем менә фермада унсигез ел эшләдем. Уникешәр сыер саудым. Ул чакларда мал азыгы да җитешмәде. Үзебез әзерли торган идек. Шул көе без кызыл тактадан төшмәдек. Ә хәзер нәрсә? Әллә нинди кумбикурмыларына кадәр әллә кайчан әзерләп, күптән китереп куйганнар!

Хат эченә бу хәбәрләрнең кайсысы керергә һәм кайсысы төшеп калырга икәнен, әлбәттә, язган кеше үзе билгеләргә тиеш иде. Кабатлап сорарга оялыпмы, әллә мыжык хуҗабикәнең әрләвеннән куркыпмы, Фәнүзә моны эшләмәде. Колагы ни ишетә, шуны язды да язды. Кәгазьнең дүрт бите дә тулгач, алар икесе берьюлы тынып калдылар.

— Я, нәрсә яздың, укып чык әле?

Әле генә үзе авызыннан чыккан сүзләрне Фәнүзәнең талгын гына тавышы аша кире кабул итү Мөнирә җиңгине кәефләндереп җибәрде. Ул кеткелдәп көлеп куйды.

— Зөфәрем укый башласа, егылып китеп көләр инде. Бигрәк берсен дә калдырмагансың! Әнә азагыннан Камилә турында тагын берике сүз өстәп куй әле. Юньсез булып чыкты, дигең, җиңел холыклы, дигең, халык үзен бер дә яратмый, дип җибәр. Укысын, белеп торсын!

Мөнирә апаның улы Зөфәрнең ни өчен шул Камилә турындагы бөтен хәбәрләрне дә белеп торырга тиеш икәненә Фәнүзә берничә айдан соң гына төшенде. Ә хәзергә ул шуңа игътибар итте: авылдагы яңалыклар, берсе дә калмый, хат эченә кереп бетте. Ләкин балалар бакчасы ачылуы турында, аның мөдире булып яшь кенә, ыспай гына бер кыз килүе һәм ул кызның үзләрендә яшәве турында карчык ләм-мим бер сүз әйтмәде. Хәтта алдагы хатларда да яздырмады. Һәм улыннан килгән җавап хатларының берсендә: «Безнең өйдә торучы Фәнүзә исемле кызга да күп сәлам», — дигән юлларны укыгач, үзе дә аптырап калды.

Ул, әлбәттә, Фәнүзәне гаепләде. Авылда Зөфәр белән хәбәрләшердәй башка кешеләр барлыгын, шул ук, үзе яратмый торган Камиләнең хат алышып торуын башына да китермәде. Ә Фәнүзәгә аерып әйтелгән сәлам хат саен килде һәм килгән саен тынгысыз ананың күңелендә борчылу тудырды.

Зөфәр әнисенең фоторәсемен сорап язды. Мөнирә җиңгинең алай ерак җирләргә җибәрерлек юньле төшкән рәсеме юк иде. Авылда шуның белән маташучы Гыйльман исемле малайны чакыртырга мәҗбүр булды. Ләкин чос Гыйльманның бер уңай Фәнүзәне дә төшереп алуын ул сизмәде. Әгәр күреп калса, һәм бигрәк тә үзенеке белән бергә, бер үк конвертта, Зөфәргә җибәрелгәнен белеп калса, эш хөрт иде. Ярый әле, Зөфәр үзе дә сак булды. Фотоларны алгач язган хатында: «Рәхмәт, әнкәй, рәсемнәрне алгач, кайтып күргәндәй булдым»,— дип, аермый гына әйтеп кую белән канәгатьләнде. Шуның артыннан ук Зөфәрнең парад киемендә төшкән рәсеме килеп төште. Артына: «Кадерле әнкәемә, сагынганда бер карап алу өчен»,— дип язылган иде һәм шуннан түбәнрәк вак хәрефләр белән: «Теләге булган башка кешеләргә дә сирәкләп булса да карап алырга мөмкин», — дигән сүзләр өстәлгән иде.

Мөнирә җиңги улына хатны күп яздырды. Зөфәре исенә төшкән саен, ул Фәнүзәне җилтерәтеп өстәлнең бер башына утырта да, үзе икенче башына урнашып алып, авылдагы хәбәрләрне тезә башлый. Кәефе бармы Фәнүзәнең, юкмы, исәпләшеп тору башына да килми. Эштән арып, ачыгып кайткан чакларында да форсат бирми, шунда ук тарткалап ала.

— Язып ташла әле. Ашарга өлгерерсең.

Фәнүзә, әлбәттә, карышмый. Ләкин эченнән уйлый: «Гомер буе шундый мыжык кеше белән яшәргә язмасын». Ә кайчакта, хәтта үзе дә сизмәстән, уйлаганы кәгазь өстенә төшеп куя...

— Яздыңмы? — дигән тавышка уянып китә дә ашыга-ашыга хаталык белән килеп кергән сүзләрне сызгалап ташлый. «Кайнанаң шундый булмасын»,— ди ул эченнән.

Фәнүзәнең әкрен генә кайтып керүендә һәм мыштым гына чишенүендә үк зур җитешсезлек тотып алган хуҗабикә өстәл янында иягенә таяна биреп, улына китәчәк хат өчен хәбәр сөйләп утырганда, өлгерә алмавын яки ялгыш язып ташлавын күреп, отыры кәефсезләнеп китә. Аның да башына бик үк яхшы булмаган уйлар килә: «Шундый пешмәгән, йомшак бәндәгә көнең калмасын». Ачу белән Фәнүзәгә карап ала да әмер итә:

— Мин әйткәннәрне сызма! Барсын да яз!

«Киленең шундый була күрмәсен, — дип уйлый ул, йөзен читкә алып, — йөрәгең ярылыр, ходай сакласын!»

Хат саен ул ферма эшен телгә алмый калмый һәм шул уңайда мотлак Камиләне китереп кыстыра. «Камилә ялкау да, Камилә начар. Сөтне колхозда иң ким алган кеше — ул, чөнки башын уен-көлкегә салган».

Билгеле, Фәнүзә боларның барсын да яза. Ләкин, дөресен әйтергә кирәк, эченнән пошынып куя. Чөнки ул кыз бер дә начар күренмәгән кебек. Яшьләр арасында үткәрелгән бөтен эшкә катнашып, ярдәмләшеп йөри. Нигә инде алай кеше өстенә гаеп ташларга? Юк, болай ярамый.

Фәнүзә бу турыда сөйләшүне кирәк тапты. Әгәр алдагы хатны язганда тагын шул Камиләне начар яктан китереп кыстыра башласа, озынрак телле хуҗабикәнең тезгенен тартып куярга булды. Ләкин берничә көннән соң клубта Камиләнең үзен күргәч, кинәт бу фикереннән кире кайтты. Чөнки Камилә янындагы кызларга әле генә Зөфәр җибәргән хатны укып һәм шул хат эчендә килгән җыйнак киенгән солдат рәсемен күрсәтеп, мактанып утыра иде.

Фәнүзә шул чак эсселе-суыклы булып китте. Гомерендә беренче тапкыр каушап һәм дулкынланып алды. Ул түзмәде, рәсемне Камилә кулыннан тартып алып, азрак карап торды да:

— Бездәгесе зуррак, — дип куйды.

Мактанчык Камиләне чеметеп алу теләге кузгалып китте аның күңелендә, һәм шушы ният белән ул бераз арттырыбрак, кабартыбрак җибәрүен сизми дә калды:

— Ә минем үземә җибәргәне — тагын да матуррак. Анысында Зөфәр шинелендә төшкән...

Кинәт аларның күзләре очрашты. Кырыс һәм мәгънәле караш белән алар бер минутка гына бер-берсен көйдереп алдылар да икесе ике якка китеп тә бардылар.

Шундый минутларда кинәт кабынып киткән хисләреңне уртаклашыр кеше таба алмау авыр була. Бу хәлне хуҗабикәгә әйтеп булмый бит инде һәм Зөфәрнең үзенә дә язып булмый. Кая барасың? Онытылыр өчен ул авылына, әнисе янына, кайтып килмәк булды. Бүген үк! Хәзер үк!

— Сиңа хат язганнар,— диде аңа хуҗабикә, ишектән килеп керү белән, — әнә, әле генә Гыйльман китереп ташлап китте.

Хат сүзе Фәнүзәне сискәндереп җибәрде. Үз гомерендә әле ул әнисеннән һәм кечкенә туганнарыннан башка кешедән хат алганы юк иде. Билгеле, бу хат Дүртимәннән булырга тиеш түгел. Конвертны кулына алгач, ул йөрәге җилпенеп куйганын тойды. Хат аның эшләгән урынына язылган иде. Матур чыксын өченме, әллә кызыксынучылардан яшерер өченме, адресны ташка баскан хәрефләр белән язганнар.

Үзеңә адресланып килгән беренче хатны ачканда туган ләззәтле минутларны кем генә кичермәгән? Фәнүзә каушавын мөмкин кадәр яшерергә тырышып:

— Өйдән язганнардыр,— дигән булды.— Я берәрсе авырып киткәндер әле.

— Өйдән килгәнгә охшамаган, — диде Мөнирә апа, мәгънәле итеп, — ерактан килгәне күренеп тора.

Ана кешенең нидер сизенеп, авыр көрсенеп алуы юкка гына булмады: хат Зөфәрдән иде.

Ул хатта әллә ни язылмаган иде язылуын, ерак җирдәге солдат, күп итеп «йөрәгеннән чыккан» сәламен җибәргән дә, әнисенә хат язышып торуы өчен һәм, гомумән, олы кешегә ярдәмләшеп, иптәш булып аларның өендә яшәгәне өчен зур рәхмәт белдергән. Иң азактан үз исеменнән дә бер хат язып салуын үтенгән.

Хуҗабикә сорашмады, ә Фәнүзә бер сүз дә әйтмәде. Өйдә авыр тынлык урнашты. Берсе шатлыгын җыя алмый аптырады, икенчесе ачуын тезгенли алмый җәфаланды. Берсе, рәхәтләнеп, онытылып, иртәгә язачак җавап хатын ниндирәк ягымлы сүзләр белән башлап

китэргэ кирэклеге турында уйланды. Икенчесе ничек итеп бу кызны улы белэн хат язышудан туктату турында фикер йөртте.

Кыз йөзендэ шатлык билгелэре кечэйгэн саен, хуҗабикэнең сөмсере коела барды. Эгэр дэ Фэнүзэ акыллы чара күрмэгэн булса, бэлки хуҗабикэнең ачуы, бик күп көттерми, шунда ук тышка бэреп чыккан булыр иде. Бу куркынычны кире кагу өчен Фэнүзэ кулында шактый уңайлы һэм тээсирле көч бар иде. Ул шуны файдаланды:

— Камилэгэ хат килгэн, — диде ул, тавышын үзгэртеп, — эчендэ фотосы да бар.

«Кемнэн»? дигэн сорау урынына хуҗабикэ:

— Кайчан күрдең? — диде.

— Бая клубта кызларга күрсэтеп, мактанып утыра иде.

— Чикерткэ! Сыеры тибеп очыргыры нэрсэкэй!

Фэнүзэ ялгышмады. Хэбэр Мөнирэ җиңгинең уй-фикерен бөтенлэй икенче якка борып җибэрде.

— Кая, утыр эле өстэл янына, — диде ул ашыгып, — яз! Шэп итеп, җиренэ җиткереп яз! Камилэгэ кэртечкэ җибэргэнсең икэн, дигең, телэсэ кайда күрсэтеп, мактанып, үзеңне рисвай итеп йөри икэн, дип эйт. Моннан кире алай эшлэмэсен. Я ул кэртечкэсен кире соратып алсын.

Ул көнне Мөнирэ апаның күзенэ йокы кермэде. Улының алдагы язмышы, өйгэ кемне алып килэчэге турында ул төне буе баш ватып чыкты. Шаталак булганы өчен ул Камилэне күңеленэ якын да китерэ алмый. «Шул эйтүгэ, шул язуга, эгэр туң булмаса, Зөфэр дэ төшенергэ тиеш иде бит инде, — дип уйлады ул, төнге йокыларын калдырып,— эллэ аңламый, эллэ юрамал шулай эшли. Э менэ бу җыбыткы Фэнүзэсенэ ни дип язган була икэн инде? Һэй Зөфэр, Зөфэр, катырасың бит эниеңнең газиз башларын!»

Мөнирэ җиңгинең булачак килене боларның икесенэ дэ охшамаган. Ул, элбэттэ, уңган булырга тиеш, лэкин уенчак түгел. Ул, элбэттэ, эдэпле, юаш булырга тиеш, лэкин җебеп төшкэн бозау түгел. Бер сүз белэн эйткэндэ, кайнанасы сүзеннэн дэ чыкмасын, иренэ дэ гадел хезмэт итсен. Эйткэнне көтеп тормасын, үзе белеп эшлэсен, итэген җыеп йөрсен, теле-теше булмасын, иреннэн алда түшэккэ барып ятмасын, кайнанасыннан соң тормасын, уңган булсын, таза булсын, гадел булсын...

Йокысыз төннэрне Фэнүзэ дэ еш кына үткэрэ башлады. Зөфэр турында уйлану аның күңеленэ рэхэтлек бирэ. Бигрэк тэ солдатның кыска язылган хатларында эйтелгэн кайбер ягымлы сүзлэрне кабатлау аңа күңелле була. Зөфэрдэн хат килгэн саен, Фэнүзэ күзгэ күренеп үзгэрэ: өй эчендэ, хуҗабикэсе эйткэнне көтеп тормый, бөтен җирне ялтыратып куя; урамга чыкса, кешелэр белэн кыюрак сөйлэшэ, эшендэ дэ үзен ышанычлырак тота.

Фэнүзэнең кэефе күтэрелгэн көннэрдэ инде Мөнирэ апа, киресенчэ, күңелсезлэнеп китэ. Күңел төбендэ сакланып килгэн шикле уйлар калкып чыгалар. Йөрэк тибеше ешаеп китэ. Килэ-килэ аның йөрэгендэ Фэнүзэгэ карата дошманлык хисе кузгала башлый.

Мондый ярашмау, үзара килешми яшэү тирэнэя башласа, яхшы булмаячагын күздэ тотып, имин чакта ул Фэнүзэдэн котылырга дигэн карарга килде.

— Кызым, — диде ул бер көн гадэттэн тыш йомшак тавыш белэн, — Зөфэремнең кайтыр вакыты җитеп килэ. Бездэн чыгарсың инде...

Фэнүзэ баскан урынында катып калды, э хуҗабикэ ачыкларга ашыкты:

— Егетле өйдэ кыз баланың булуы килешмэс. Эниең дэ риза булмас.

Фәнүзә эндәшмәде.

— Иртәгә үк бригадирга әйтерсең.

Фәнүзә җавап та бирмәде, бригадирга да барып тормады.

Зөфәр кайтырга бер атна чамасы вакыт калгач, бөтен әйберләрен төйнәп, Дүртимәнгә кайтып китте. Мөнирә җиңги иркен сулыш алып җибәрде.

Хезмәт срогын тутырып, зураеп һәм матурланып, авылга Зөфәр кайтып төште. Аны зурлап каршы алдылар. Хәтта клубта махсус очрашу кичәсе оештырдылар һәм өйдән-өйгә ашка-чәйгә йөртеп чыктылар.

Мөнирә апа чиксез шат булды. Бигрәк тә улының чикерткә Камилә тирәсенә сугылмавын хуп күрде. Аның алдында хәзер күзгә күренеп торган куркыныч юк иде. Улы эшкә башлагач, килен дигән нәрсәне әкренләп үзе табып бирәчәк иде.

Авылда кунак булып йөргән арада Зөфәр районга да барып кайтты. Күрше авылларга да чыгып килде. Урам кыдырып, бушка җилләнеп йөрү туйдыра башлады, ахры, бер көн идарәгә барып, эш турында сөйләште дә, кайтып, әнисенә яңа хәбәр әйтте:

— Әнкәй, мин сиңа килен алып кайтырга булдым. Ял бирергә кирәк үзеңә.

Мөнирә апаның кулыннан әйбере төшеп китте.

— Кайдан? — дип сорады ул кинәт бөтенләй ят кеше тавышы белән. — Кемне?

— Анысын кайткач күрерсең. Күрше авылдан. Машина белән алып кайтабыз. Әзерләнеп тор.

Зөфәр, нинди дә булса зур сүз булыр, әнисен үгетләргә, хәтта бәлки үтенергә, ялварырга туры килер, дип уйлаган иде. Ләкин Мөнирә апа телсез калды. Егет әнисен кызганып куйды:

— Кайгырма, әнкәй, барысы да яхшы булыр, — диде китәргә ашыгып. — Без сине тәрбияләп кенә торырбыз. Ә хәзер самоварыңны куя башла...

Улы чыгып китте, әнисе тавыш-тынсыз көтеп калды.

Ике-өч сәгать тә үтмәгәндер, Зөфәр киленне җилтерәтеп алып та килде. Килен кеше алдына килеп баскач, йөзенә төшкән яулыгын ачып җибәргәч, Мөнирә җиңги егылып китә язды: аның алдында Фәнүзә басып тора иде.

— Әнкәй! — диде Фәнүзә, аңа ташланып.

— Килен, — диде Мөнирә җиңги, аны кочаклап.

Алар икесе дә, яшьләнгән күзләрен сөртеп, бер-берсенә карашып алдылар.

«Менә мин хәзер бөтенләй килдем, — ди иде булачак киленнең күзләре, — күпме киреләнсәң дә, улың минеке булды».

«Улым синеке түгел, син үзең улымныкы булдың, — ди иде булачак кайнананың күзләре, — ә улымныкы дигән сүз — минеке дигән сүз, белеп тор...»

Ә котларга килгән халыкка:

— Үзем димләп алдырдым, — диде кайнана кеше, — улым әрмиядә чакта хат саен әйтеп яза торган идем.

— Улын ныклап белмәсәм дә, кайнанама була килдем, — диде килен кеше, — ел ярым бергә яшәдек бит. Ачуланып караган чагы да булмады...

## Лена Шакирҗанова

### Үземә кайтып төштем

Тагын кайтып төштем үземә,
Мин үземне үзем сагынып.
Ничә тапкыр инде адашып,
Ничәнче кат инде абынып...

Зарыктырды чит-ят гадәтләр,
Гарык итте ашы-табыны.
Бушка узган күпме сәгатьләр,
Ятлар почмагына табынып...

Тагын кайтып төштем үземә,
Арып-талып, әмма бушанып.
Соңгы кабат, бүтән китмәскә,
Үз-үземә тәмам ышанып.

Ахры, кайтып төштем үземә,
Сусап, сырхаулардан арынып...
Ятсынасыз. Беләм, үзем дә
Мин үземне көчкә таныдым.

### Чишмә эзләп

Су алырга төшсәм тау астына,
Бу ни хикмәт: чишмә югалган...
Улаклардан ташып моң түгелә,
Тирәкләргә сагыш уралган...

Юл буена җырлый-җырлый килгән
Чиләкләрем тынып калдылар.
Төсе китте гүя көянтәмнең,
Бизәкләре тоныкландылар.

Чишмә эзләп киттем тау буеннан,
Сусыз ничек кайтыйм авылга?
Мөлдерәмә сулы чиләкләрне
Иңнәремә хәтле сагынган...

Я табармын шундый татлы чишмә:
Йотылып-йотылып һәркем эчәрлек.
Я табармын шундый серле бер җыр:
Чишмәләрнең телен чишәрлек.

## Фәһимә Галиева

●

Урамнар була бормалы,
Урамның була ун гына йорттан торганы.
Ун йорттан торганы —
Коммунарлар корганы.
Тапкан-табынганын бүлешеп,
Бөрлегәндәй бергә оешып,
Яшәпме-яшәгән бертугандай
Безнең ул олы туганнар.
Эзлим эзләрен, күзгә бәрелми:
Чәчәккә күмелгән курганнар.

### Әткәм кабере

Карабашлар үскән күл генәм,
Кайнар яшем сиңа түгелгән.
Кара тасма булып йөрәгемә,
Йөрәгемә бер көн үрелгән.

Баш иделәр уг. көн җикәннәр,
Туктап калды кебек җилкәннәр...
Күңелемдә уйлар уелды,
Кара җирдән таучык өелде.

●

Мин яраткан сылу кыналар
Гөлбакчаңа нигә соң алар?
Гөлбакчаңны бизәр өченме?
Чит-ят куллар өзәр өченме?

●

Ай туды. Кем туды икән?
Йолдызлар тамәр төсле!
Шигъриятнең шәмдәлендә
Якты ут янар төсле.

## Майя Румянцева

### Чал чәчләр турында баллада

Горур атлап кызлар
Урамнардан уза —
Чал чәч — мóда, имеш,
　　　　　　чал чәч — ямь-яшь кызда!..
Саксыз кагылмагыз шундый изге төскә —
Җанда әрнү булып яши торган хискә!
Мóдамыни — кайгы,
　　　　керфектәге яшьләр?
Ничек мóда булсын
Чал йөгергән чәчләр?
Тукта, хәтер...
　　　　　Сабыр...
　　　　　Без онытмыйк моны.
Бу — китаптан түгел, бу — әрнеткеч моңым.
Искә алам шуны
　　　　әрнү-каһәр белән:
Чолганышта калган Ленин шәһәреннән
Нәни малай кайтты
Көчкә җанын саклап:
Карашлары — җитди,
　　　　　　ә чәчләре — ап-ак.
Җанда саклыйм аның авыр истәлеген.
...Яраланган солдат һаман истә минем:
Ул саңгырау калган
Шартлау тавышыннан,
　— Аһ! — дигәнче чәче ап-ак булган —
Шуннан.
Агардылар чәчләр —
　　　　үлем күзгә баккач,
Янган утка дошман
　　　　сабыйларны аткач,
Шәһәрләрне берүк ятка бирмик, диеп,
Шәһәрләрне хәтта ятка бирдек, диеп —
Агардылар чәчләр!
Чал чәч —
　　　　　мóда, имеш.
Ул чак — кайгы иде
　　　　чәчләрдәге көмеш.

Чал төтеннәр күккә менгән иде
                    ургып,
Ашар өчен без чал алабута урдык.
Япа-ялгыз толлар...
            чәчтә — кайгы кары —
Чаларды күк хәтта яшьле карашлары...
Кайнар сугыш көле
                бәгырьләргә кунды:
Нурлы йөзгә хәтта чал кергәндәй булды.
Заман тыныч,
            сүнде сугыш ялкыннары:
Тик
        агарта чәчне
Кайгы гына бары!
Туктатасы килә
Сине,
        кискен дәшеп,
Их, син, мо́да, мо́да...
            Их, син, саксыз яшьлек!
Оят түгелмени чәчне кумү акка —
Илле тиен хакка, илле тиен хакка!..
Булсын мо́да кыю,
Каршы килмим һич тә,
Ләкин
        берүк саксыз кагылмагыз
                төскә;
Чәчләреңне әгәр агартсалар синең
Авыр кайгы уты,
                кайнар газап җиле —
Хаклы дан күк горур йөртелергә тиеш
Чәчләрдәге көмеш, чәчләрдәге көмеш...

ЗӨЛФӘТ тәрҗемәсе.

**Вакыйф Нуруллин**

# ӘГӘР СИН БУЛМАСАҢ...

ПОВЕСТЬ[1]

## 12



Октябрь бәйрәменә каршы көнне алар бергә кайтырга сөйләшкәннәр иде. Рухия иптәш кызларыннан чак кына арткарак калып чыгармын дигән иде. Ләкин Рухия сүзендә тормады ул көнне. Равил аны әлеге күпер төбендәге әрәмәлектә тәмам караңгы төшә башлаганчы көтте. Аптырагач, Чүкәйгә кире барып, интернатта торучы кызларның «әнкәсе» Нурҗамал ападан сорарга мәҗбүр булды. Нурҗамал апа башта кычкырып көлде, аннары: «Егет булсаң, мут булырга, ике күзең ут булырга кирәк, энем, авызыңны ачып йөрмә, яме! Ә Рухиянең кайтып киткәненә биш былтыр инде. Иптәшләреннән бер дәрес алдан ук китте ул!» — диде. Аңа ышанырга була, чөнки ул инде интернатны гөл итеп юып-җыеп чыгарып, өенә кайтырга әзерләнеп тора иде.

Рухиянең әнә шулай сүзендә тормый кайтып китүенә бик нык аптырады Равил. Ни булды икән, нигә алай итте икән, дип сәбәбен белергә бик теләсә дә — белә алмады. Ахырында ул, әллә бу шайтан кызы берәр бүтән егет белән йөри башлаган микән, дигән фикергә килде һәм шул мәсьәләне ачыклау өчен иртәгә — Октябрь бәйрәме көнне кич — Укмаска барып карарга булды. Мәктәптән кайтышлый да, кичен атларны кырга илткәндә дә, иртән атларны эзләп йөргәндә дә гел шул Укмаста булачак очрашу турында уйлап, баш ватып йөрде. Аның фикеренчә, ул очрашу менә болайрак булырга тиеш иде.

Кич караңгы төшкәч, председатель Фәйрүзә апасы җигеп йөри торган юртак «Карлыгач»ка атлана да Равил, җире туңган Укмас урамын дер селкеттереп чабып, туп-туры Рухияләр капкасы төбенә барып туктый. Аннары атын тегеләрнең капка баганасындагы боҗрага

[1] Ахыры. Башы 2 санда.

бәйләп куеп, өйләренә барып керә һәм егетләрчә кыю гына итеп: «Гафу итегез, Басыйрова Рухия шушында яшиме?» — дип сорый. Аның тавышын ишетү белән түр яктан Рухия үзе балкып килеп чыга да: «Бәй, Равил абый, син икәнсең ич! Ничек, башың җитеп, килеп чыгасы иттең? Әйдә-әйдә, түргә уз!» — дип, Равилне кыстый башлый. «Рәхмәт, Рухия! — ди аңа Равил, түргә үтмичә генә.— Анда ук үтеп тора алмыйм. Клубыгызга бәйрәм кичәсен карап китәргә дип кенә килгән идем. Тик менә атымны куеп торырга урын юк. Әти-әниеңнәр рөхсәт итсә, сезнең ишегалдында калдырып торырмынмы әллә дип кенә керүем иде».

Равил шушы сүзләрне сөйләп торган арада Рухиянең әтисе белән әнисе дә түр яктан ишек катына киләләр. «Бу абый Ташый елгалыкы,— ди аларга Рухия.— Ул да Чүкәйдә сигезенче класста минем белән бергә укый. Теге миңа бәйләнеп йөдәткән Тәкә Әнәсне шушы егет акылга өйрәтте инде менә. Велосипедына утыртып йөри торган кеше дә шушы абый була инде». «Ә-ә! — ди Рухиянең әтисе, моңарчы шактый кырыс карап торган булса да, кинәт дустанә елмаеп җибәреп.— Бик әйбәт, алайса, бик әйбәт! Әйдә, энекәш, мактап йөрисең икән әле, какрас ашарга гына утырган идек. Әйдә-әйдә, клубка җитешерсең әле. Давай, син кожаныңны сала тор, ә мин хәзер атыңны ишегалдына урнаштырып керим».

Равилне барыннан да күбрәк гаҗәпкә калдырганы шул: әнисе гел Рухиягә охшаган икән! Буй-сыны да, төсе-бите дә, хәтта елмаюы да нәкъ менә Рухиянеке инде. Бер дә уналты яшьлек кызның анасы димәссең: таушалмаган да, картаймаган да. Егерме яшьлек кызлардан һич ким түгел! Тик менә чәчләре генә агара төшкән икән. Алары шул әтиләре теге вакытларда тәртәдән ычкынып йөргәндә агаргандыр, күрәсең.

Рухиягә дә, әнисенә дә шактый зур борчулар китергән кеше булгач, Равил аларның әтиләрен ничектер усал, ямьсез, нурсыз адәмдер дип уйлаган иде. Ә ул бик мәһабәт гәүдәле, кара тут чибәр йөзле, таза, ыспай кеше икән ләбаса!..

Өчәүләшеп кыстый-кыстый бәйрәм ризыклары — инде ничә елдан бирле Равилнең төшенә дә кермәгән ит бәлеше, ап-ак оннан йомыркага изеп кенә пешерелгән кош теле, тары кыстыбые һәм юкә балы белән сыйлаганнан соң, Рухия Равилне клубка бәйрәм кичәсенә алып китә. Юлда ул тагын бер кат: «Ничек, башың җитеп, киләсе иттең, Равил абый? Молодец! Югыйсә, минем үземне генә клубка мәңге җибәрмәячәкләр иде бүген. Тоткындагы кош шикелле, бер кая чыга алмый утырасы идем»,— дип, Равилне мактап куя...

Рухиянең әти-әниләре генә түгел, Укмасның егетләре дә киң күңелле, ачык йөзлеләр икән. Равилнең клубка килеп керүен күреп алуга, дәррәү кубып, кул биреп күрешеп чыгалар да: «Я, нинди һөнәрең бар, агай-эне?» — дип сорыйлар. «Аккордеонда уйный беләм!» — ди Равил, оялыбрак кына. «Булды гына инде, алайса!» — дип куанышып, тегеләр минут эчендә Равилгә өр-яңа аккордеон китереп тоттыралар. Барлык телләре дә төзекме икәнлеген белер өчен, Равил башта болай гына шыгырдатып-тикшереп чыга. Аннары, башын чак кына кыңгыр салып, «Алмагач»ны уйнап җибәрә. Ул уйный башлауга бөтен клуб тып-тын калып, сокланып тыңлап тора. Аннары барысы да берьюлы җырлап җибәрәләр:

А-а-а-ал-ма-га-чым а-а-ал-ма бир-ми,
Г-е-е-ел кор-ган чы-бык кына ла!
Бу-у-у-ул-дым ин-де са-а-ай-рар кош-лар,
Са-а-а-ай-ра-мыйм чы-гып кы-на!

Тик Рухия генә җырга кушылмый. Равилнең шулай дәртле итеп, бөтен кешенең күңеленә үтеп керерлек итеп уйнавына куанып һәм хәйран калып булса кирәк, клубны берүзе балкытып, елмаеп кына утыра. Равил клубтагыларны байтак җырлатканнан соң аның янына килә дә, колагына гына пышылдап: «Рәхмәт, Равил абый, ну, булдырасың икән үзең дә! Тик нигә соң мәктәптә тәнәфес вакытларында бер тапкыр да уйнаганың юк синең?» — ди. «Мәктәпнең аккордеоны юк бит, Рухия,— ди аңа Равил,— тальян гармун гына бит анда. Ә мин гармунда юньләп уйный белмим». «Шулаймыни,— ди аңа кыз, исе китеп.— Ярый инде алай булгач. Ә хәзер, әйдә, «Бишле бию»не уйна әле, Равил абый? Биим әле бер рәхәтләнеп! Бүтән чакта биим дисәң дә, Укмаста рәтле уйнаучысы юк аның». «Әйдә, Рухия!» — ди Равил, куанычыннан үзе дә биеп китәр хәлгә җитеп. Һәм, илаһи бер дәрт белән, кыз сораган көйне сыздырып җибәрә.

Менә, гадәтенчә, горур гына, үз дәрәҗәсен белеп кенә атлап, Рухия уртага чыга һәм, күбәләктәй җиңел генә җилпенеп, биеп китә. Барысының да игътибары шул озын толымлы чибәр кызга юнәлә. Барысы да, ачкан авызларын ябарга да онытып, аңа карап торалар. Бу тикле дә җиренә җиткереп биер икән кеше! Үзләренең Ташый елга кызларын да, авылларына килгән кунак кызларны да бик күп мәртәбәләр биеткәне бар Равилнең. Әмма беркайчан да, беркемне дә менә шушылай рәхәтләнеп, бер дә көч куймыйча биетә алганы юк иде әле. Ул хәзер көй һәм аны ничек уйнау турында бөтенләй уйлап та карамый: барысын да бармаклары үзләре башкара. Хәтта аккордеонын да тартыпсузып тормый, бәлки үзеннән-үзе шулай нәкъ кирәгенчә генә тартылып-сузылып тора...

Рухия биеп туктаганнан ары бөтен клубны дер селкетеп кул чабалар. Аннары бүтән кызлар бии башлый. Аларга да рәхәтләнеп, арутагуны белмичә уйный Равил...

Шулай байтак җырлашканнан һәм биешкәннән соң, кино буласы дип, клубтагы халыкны, шул исәптән Равил белән Рухияне дә, куып чыгаралар да билет сата башлыйлар. «Киногa керәбезме?» — ди Равил Рухиясенә. «Әлбәттә, керәбез! — ди кыз.— «Александр Матросов»ны карамый калдыралармы соң? Мин аны Казанда яшәгәндә биш тапкыр караган идем инде. Ләкин тагын егерме биш тапкыр карарга да риза!» — ди. Кыз Равилне култыклап ала да алар билетка чират торучылар сафына килеп басалар. Ләкин чиратлары җиткәч, Рухия кинәт сискәнеп китә: «Бәй, акча алып чыгарга онытканмын бит мин, Равил абый!» — ди. Ә Равилгә шул гына кирәк тә. «Борчылма, Рухия! — ди ул, бер дә исе китмичә генә.— Хәзер мин үзем алам!»

Һәм ул шунда үз өлешен акчалата гына алырга акылы җиткәнгә чын күңеленнән куанып куя. Хикмәт менә нәрсәдә: Равилләрнең Ташый елгасында колхоз яралганнан бирле килә торган бер гадәт бар: һәр елның Октябрь һәм Май бәйрәмнәре көннәрендә авылның әле яңа гына туган баласыннан алып, тәнендә җаны булган карт-карчыкларына тикле колхоз хисабына бәйрәм ашы әзерлиләр. Ул ашны мәктәп балаларына көндез мәктәпкә алып килеп ашаталар. Олылар мәҗлесе кич эштән соң үткәрелә. Ә кеше арасына чыгып йөри алмаган карт-карчыкларга һәм имчәк балаларына тиешле өлешләрне (җан башына 200 грамм ит, ярты кило ипи, токмачлык он, күпмедер бәрәңге) туган-тумачалары һәм әти-әниләре колхоз амбарына барып алып кайта. Кыскасы, берәү дә өлешсез калмый. Ташый елга халкы шуңа күрә әлеге бәйрәм көннәрен һәр вакыт сагынып көтеп ала. Ул бәйрәмнәрнең тагын бер үзенчәлекле ягы бар: колхозда эшләүчеләрнең һәркайсына, шулай ук колхоз исәбеннән һәм шулай ук бушлай, бирәр «чәкүшкә» ак аракы бирелә. Үзе мәктәптә укып йөрсә дә, колхозда зурлар белән эшләгәнлектән, Равилгә дә яздырган иде аны Фәйрүзә апасы. Һәм ул

менә бу кичтә Ташый елгада зурлар белән бергә бәйрәм табынында утырырга тиеш кеше иде. Ләкин Равил, акылы җитеп, ул мәҗлескә бармаска булды. Үзенә тиешле ит белән ипине әнисен җибәреп әйберләтә генә алып кайтарырга, ә аракысын, китап-дәфтәрлек булса да ярар дип, Самат абыйга сатарга булган иде.

Менә шуның акчасы ярап куйды хәзер! Равил, шытырдап торган унлыкны суздып, кассадан ике билет алды да, Рухияне култыклап, клубка керде...

Кино карап утыралар. Күзләре экранда булса да, күңеле белән Рухиясенең керфек какканына тикле тоеп утыра Равил. Хәтта йөрәк тибешенә кадәр ишетеп тора. Менә шушылай аның җылысын тоеп утырудан да рәхәт нәрсә, мөгаен, юктыр да һәм була да алмас кебек Равилгә. Һәрхәлдә, мондый искиткеч рәхәт минутларны үз гомерендә бары тик икенче кат кына кичерә әле. Беренче тапкыр мондый зур рәхәтне Чукәйдә, клуб тәрәзәләрен каплап, көндез мәктәп балаларына күрсәтелгән кино вакытында Рухия белән рәттән утырганда татыган иде ул. Бүген исә шундый ук шатлык тойгыларын Укмас клубында кичереп утыра...

Ә экранда сугыш бара. Туплар шартлый, бомбалар ярыла. Кешеләр үлә. Алар да нәкъ Равил кебек, Рухия кебек адәм балалары бит инде. Араларында нәкъ менә шушылай, Равил Рухияне сөйгән кебек, берәр кызны яратып йөргәннәре һәм шул яратуларын, нәкъ менә Равил кебек, сөйгән кызларына әйтергә йөрәкләре җитмичә, сугышка китеп барганнары, хәтта шунда һәлак булып, мәңгегә ятып калганнары да күптер әле. Алар аны беркайчан да әйтә алачак түгел бит инде... Үзе сугышка киткәннән соң дөньяга килгән улларын һәм кызларын бер генә мәртәбә дә күрә алмыйча, бу дөньядан китеп барганнары да аз түгелдер. Уйлый башласаң — чәчләрең үрә торырлык хәлләр ләбаса...

Кинонының иң киеренке урыны якынлаша. Дошманны чигендерер өчен бүтән бернинди чара да калмагач, Матросов туктаусыз ут чәчеп торган амбразурага таба шуыша башлый. Хәзер ул аны үз күкрәге белән капларга тиеш. Ара һаман якыная. Яшь-яшь егетнең гомере мәңгелеккә киселергә санаулы секундлар гына калып бара. Ул да менә, Равил Рухияне сөйгән шикелле итеп, өзелеп-өзелеп берәр кызны сөйгән булгандыр бит инде. Ә хәзер ул үлеп калачак. Әнә Александр амбразурага якын ук килеп җитте. Әнә... Шул чак, кинәт сискәнеп китеп, Рухия Равилгә тагын да ныграк сыенып куя һәм уттай кайнар куллары белән аның кулын кысып ала. «Курыкма, Рухия,— ди Равил, ниһаять, үзен кулга алып.— Чын үтереш түгел бу, кинода гына шулай күрсәтәләр аны».

«Матросов бик кызганыч бит,— ди аңа Рухия.— Күрә торып үлемгә барды ич! Ә син аның урынында булсаң, шулай эшләргә йөрәгең җитәр идеме, Равил абый?»

«Җитәр иде, Рухия!»

«Ә мин? Мине калдырып китәргә кызганмас идеңмени?»

«Нәкъ менә шул сине сөйгәнгә күрә күкрәгем белән каплар идем дә инде мин ул амбразураны!»

«Моны ничек аңларга, Равил абый?»

«Моны дошман тизрәк җиңелсен дә син дә, дөньядагы бүтән барлык намуслы кешеләр дә бәхетле яши башласын өчен шулай эшләр идем мин».

«Синсез миңа бик күңелсез булыр бит, Равил абый».

«Баштa, әлбәттә, шулайрак булыр иде. Ләкин тора-бара ияләшер идең әле. Ә исеңә төшкәндә мине сагынып сөйләр идең. Сөйләр идеңме?»

«Әлбәттә, сөйләр идем! Тик минем сине һич тә үтерәсем килми, Равил абый!»

«Мин үзем дә уләргә атлыгып тормыйм, Рухия. Әмма шулай кирәк булса, һич икеләнеп тормас идем. Ахыр чиктә, беребез дә мәңгегә килмәгән бит бу дөньяга. Беркемгә дә зыян да, яхшылык та итмичә, үз мәнфәгатеңне генә кайгыртып, үзең өчен генә озак еллар яшәп үлгәнче, аз яшәп, ләкин шул вакыт эчендә дә кешеләр сагынып сөйләрлек берәр эш эшләп калдырып үлүең йөз тапкыр артыграк, минемчә».

«Бәлки шулайдыр да. Ләкин мин үзем дөнья шаулатып яшь кенә көйгә бу якты җир йөзеннән китеп баруга караганда, озак яшәп, тыныч кына итеп китеп баруны артыграк күрәм».

Рухиянең болай фикер йөртүе гаҗәбрәк тоела Равилгә. Бәхәсләшәсе килә аның бу хакта. Ләкин ул, кызның күңелен кырмас өчен, бәхәсләшеп тормый.

Кино беткәч, Укмас яшьләре тагын җырлашырга һәм биешергә телиләр. Равилне сырып алалар да: «Әйдәле, агай-эне, уйнале тагын, рәхәтләндер әле безнең күңелләрне!» — диләр. Таңга кадәр уйнарга да риза Равил. Ләкин бүген бүтән уйнарга ярамый аңа. Һич тә ярамый! Әгәр ул хәзер уйный башлап, тегеләрнең күңелләре булганчы уйнаса, кичәдән таралышканда яшьләрнең аңа, иртәгә дә кил, яме, дияргә онытып куюлары мөмкин.

Ә ул аларның онытуын һич теләми, чөнки Рухия белән бергәләп кино карар өчен, тагын Укмаска килергә кирәк аңа. «Кыставыгыз өчен бик зур рәхмәт, дуслар! — ди ул Укмас егетләренә һәм кызларына.— Ләкин хәзер үк кайтып китәргә кирәк шул миңа: атлар көткән җирдән — кырдан гына килгән кеше мин».

Шулай дигәч, хәлен аңлап, аны артык кыстамыйлар. «Алайса, артык тоткарлап булмый икән шул. Ләкин, кара аны, агай-эне, безне онытып бетермә, башка вакытларда да килеп чыккала шулай, яме!» — дип җыйнаулашып озатып калалар.

Әлбәттә, Рухия дә Равил белән чыга.

Капка төпләренә кайтып җиткәч, Равил тегеләрнең ишегалларыннан атын алып чыкканчы, Рухия урамда көтеп тора. Равил атына атланырга әзерләнә башлагач, янына килә дә: «Рәхмәт, Равил абый, күңелләребезне ачтың, ичмаса, бер! Тагын шулай кил, яме!» — ди.

«Киләм, Рухия, киләм, алтыным!» — ди аңа Равил. Шул сүзләрне әйтә дә кызны йомшак кына кочып, бит очыннан гына үбә. Аннары: «Сау булып тор, Рухия! Хәерле төн сиңа!» — дип, ялт кына атына менеп атлана. Ат таптап китмәсен өчен, кыз читкәрәк тайпыла да: «Сиңа да шулай ук, Равил абый! Адашмый гына атларың янына кайтып җит инде, яме!» — ди.

«Хәзер мине бернинди җен-пәриләр дә адаштыра алмаячак, Рухия!» — ди аңа Равил. Һәм ул, төнге тын урамны тояк тавышына күмдереп, атын юртып кайтып китә...

## 13

Әйе, Җиденче ноябрь таңында кырдан атларны җыеп йөргәндә Равилгә бөтенесе дә менә шушылай иple генә, ансат кына булыр төсле тоелган иде. Ләкин бу очракта аның хыялы белән чынбарлык берберennән чамасыз ерак булып чыктылар.

Ярый әле, адәм баласының бер яхшы ягы бар: ул киләчәген һәр вакыт бүгенгедән әйбәтрәк, матуррак итеп күз алдына китерә, шуны тели, шулай булырына чын күңелennән ышана. Шул ышаныч, шул өмет нинди-генә кыен чакларда да аңа көч һәм рух биреп тора һәм беренче карашка бөтенләй мөмкин булмаган эшләрне дә башкарып чыгарга ярдәм итә. Моның шулай икәнлеген расларга кирәк булса, Равил бик күп дәлилләр китерә алыр иде. Әлеге шул сигезенчедә укый

башлавы да нигездә якты өмет һәм матур хыяллар белән бәйләнгән иде бит аның. Соңыннан да үз гомерендә андый хәлләрне күп кичерде Равил. Ләкин кайчакта дөньяны һәм кешеләрне гел ал да гөл итеп кенә күрү дә бик үк ярап бетми икән. Равил ул чакта нәкъ әнә шулай бар кеше дә әйбәт дип хыялланып йөрүе аркасында харап була язды да инде.

Атларны көтүлеккә — уҗым кырына — илтеп (ул елларда авыл җирендә Октябрь бәйрәме көннәрендә дә эшлиләр иде), тышаулап җибәрде дә, Фәйрүзә апасы җигеп йөри торган әлеге «Карлыгач»ка атланып, Укмаска китте Равил. Укмасның басу капкасы төбенә барып җитеп, иртәнге хыялларын тормышка ашыру мәсьәләсе каршына килеп баскач — каушады да калды. Бәйрәм кичендә Рухияләргә ни йөзең белән тиктомалга барып кермәк кирәк тә, ничек кыюлыгың җитеп сүз башларга кирәк? Өс-башы арурак булса да бер хәл иде әле. Ләкин киеменең дә рәте юк ич аның. Өстендә шул кырык икенче елдан бирле кия торган шинеле дә колхоз биргән брезент кожан, аягында шулай ук колхоз алып биргән резин итекләр. Бүреге болай ярыйсы кебек тә, тик бер бүрек белән генә эш бетми ләбаса. Аннары бүрек вакыты да түгел ич әле. Төнлә суык булганга, ат көтүчесе булганга гына киде бит Равил аны... Киемем сәләмә булса да, күңелем изгелектә минем — яратам мин сине, Рухия, дип әйтә алмый бит инде ул аңа! Юк-юк, өйләренә барып керү турында уйларга да ярамый!.. Ә нишләргә соң? Әллә борылып кайтып кына китәргәме? Алай итү ансат та соң, әмма ачыклыйсы мәсьәләсе бар ич әле аның. Аннары Рухиянең кичә, көтеп торам дип тә, көтмичә кайтып китүе дә бик сәер бит әле.

Басу капкасы төбендә әнә шулай байтак баш ватып торганнан соң, ниһаять, атны калдырып торып булмасмы дип, Укмасның конюшнясына барырга булды Равил. Шунда барып, каравыл өенә керде дә каравылчыга — сакал-мыегына атна-ун көн пәке тимәгән, агач аяклы, чандыр гына гәүдәле бер абзыйга — гозерен әйтте. Карап торырга өтек кенә булып күренсә дә, хәйран акыллы һәм иплe кеше булып чыкты ул агай.

— Син, олан, кино карарга килдем дигән булып мәтәштермә инде, яме! — диде Равилгә.— Бик сизеп торам: кызлар күзләргә килгәнсең син. Түлке кара аны, безнең Укмас егетләре этәчрәк халык, алай-болай бәйләнешеп китә күрмә!

Шулай диде, Равилнең атын конюшняга куеп торырга берсүзсез риза булды. Аннары, авыл агайларына хас булганча, барысын да жентекләп сораштыра башлап, Равилнең заманында Ташый елгада колхоз председателе булып эшләгән Нәҗметдинов Нуриәхмәт малае икәнен белеп алгач, бөтенләй үк ачылып китте дә «Карлыгач»ның алдына подаукасы белән солыга тикле китереп куйды.

— Клубтан кайтырыңа үзеңә дә бәрәңге күмеп торырмын. Ә кәкже, Нуриәхмәт малае дисең бит. Һәй, барые безнең Нуриәхмәт белән дөньяны дер селкетеп, синең шикелле егет булып йөргән чаклар! — диде ул, туктаусыз сөйләнеп.— Ну, душа да кешие синең атаң, наный! Олыга — олыча, кечегә — кечечә була белә торган бик тә прастуй, бик тә әгъла җаные, мәрхүм. Син үзең ничектер, анысын белмим, ну, атаң белән утка да, суга да керергә мөмкиние...

Туп-туры Укмас клубына барып керергә йөрәге җитмәде егетнең. «Минем шикелле сәләмә киемлеләр бармы икән бу авылда? Булса, керермен, булмаса борылырмын да кайтып китәрмен»,— дип, башта шактый гомер клуб тәрәзәсеннән карап торды. Шунда берочтан Рухияне дә күреп булмасмы дип өметләнгән иде. Карый торгач, менә нәрсә мәгълүм булды: Равил шикелле брезент кожанлылар да бар иде клубта. Күп түгел түгелен, әмма бар. Ләкин менә Рухияне күрә алмады анда Равил. Хәер, кеше дә бик күп иде шул клубларында: аяк басар

урын да юк — дыңгычлап тутырганнар диярсең. Шулай булса да, ничектер җаен табып, биешеп яткан була үзләре. «Ярар, бәлки ул аргы почмактарак утыра торгандыр. Тәвәккәлләп кереп карарга кирәк. Башкалар, әнә, брезент кожан белән кергән бит әле. Шулай булгач, мин нигә кермәскә тиеш? Мин дә әллә кайдан килмәгән ләбаса, күрше авылдан гына!» — дип, үзен-үзе кодрәтләндереп җибәрде дә кыяр-кыймас кына барып керде Равил.

— Исәнмесез? — диде.

Үзенә калса шактый кычкырып та әйткән шикелле иде. Ләкин әллә ишетмәделәр, әллә ишетеп тә игътибар итмәделәр — сәламен алу түгел, хәтта борылып караучы да булмады Равилгә. Ә ул, юләр, иртән хыялланып йөргән чагында, күтәреп үк алмасалар да, бик хуплап каршылар дип уйлаган иде. Кая ул сиңа «нинди һөнәрең бар?» дип сорау да, кая анда аккордеон китереп тоттыру! Мәхшәр көнендәге төсле дуызгы киләләр. Ташый елга егете Равилгә генә түгел, Мөхәммәт пәйгамбәр үзе килеп керсә, аңа да әйләнеп карамас болар!

Гомере буена клубсыз кечкенә генә авылда яшәп, мондый шаушулы, йөзләгән кеше сыйдырышлы клубларны күреп өйрәнмәгәнгә, Равил беркавым, тәмам югалып, ишек төбендә торды. Азрак иядәшә төшкәч, колагына аргы башта сәхнә тирәсендә гармун уйнаган тавыш керде. Ләкин гармунчысы алай шаккатмалы музыкант булырга охшамаган: көе бик зәгыйфь чыга иде. Укмаста бәйрәмгә үзләренең электр станциясе эшли башлаячак дип сөйләгәннәр иде, чын булган икән: клубларында дүрт бөртек электр лампочкасы да янган була. Исемнәре генә лампочка инде, ә яктылыклары сукыр тычкан утыннан бер дә алай әллә ни артык түгел. ...Хәер, бер караганда, аның шулай булуы Равил өчен уңайрак та булып чыкты әле. Гел төнлә ат көтеп, аның күзләре караңгыда да күрергә күнеккән инде. Аның каравы, Равилнең үзенә беркем дә игътибар итми. Әгәр якты булса, бу нинди йолкыш икән тагы дип, Укмас егетләре дә аның белән кызыксына башларлар иде...

Рухия клубка көтмәгәндә килеп керде. Килеп тә керде — клубны балкытып та җибәрде! Кара син аны: егетләре дә Равил уйлаганча ук ваемсыз һәм мәгънәсез түгелләр икән ләбаса! Үзләренә кирәккәндә күзләре дә бик шәп күрә, матур гына исәнләшә дә беләләр икән. Рухия бусагадан атлап үтәргә дә өлгермәде — биш-алты егет сырып та алды үзен. Читтәрәк булганлыктан, Равил аларның сүзләрен ишетми, әмма кыяфәтләрен бик яхшы күрә: барысы да шат, барысы да кызның әмерен үтәргә әзер булып, авызларын ачып, Рухиягә карап торалар. Ә Рухия, гадәтенчә, дәрәҗәсен белеп кенә, җайлы гына кылана. Үзен шул кадәр күп егет сырып алганга бераз уңайсызлана да булса кирәк: бит алмалары алсуланып кызарып чыккан. Башында матур бизәкле ефәк косынка, аягында биек үкчәле нәфис туфлиләр. Ә өстендә өр-яңа аксыл-соры көзге пальто. Шуңа ул өсләренә сырма кигән, башларына соры мамык шәл япкан авыл кызлары арасында балкып һәм әллә кайдан аерылып тора.

Равилнең аны мондый әйбәт киемнәр кигән чагында бер дә күргәне юк иде әле. Әнисенең кибетче, әтисенең инженер икәнен белсә дә, болай ук бай кешеләрдер дип күз алдына да китермәгән иде. Рухия мәктәпкә, нәкъ авыл кызлары сыман, өстенә сырма, аягына коры көннәрдә зәңгәр брезент туфли, яңгырлы көннәрдә иске резин итек киеп, башына гади косынка бәйләп йөри. Шуңа ул чакта Равил үзе белән бу кыз арасында әллә ни зур аерма сизми иде. Ә менә хәзер аны шушындый затлы киемнәрдә күргәч, бөтенләй аптырап калды. Үзе белән шушы чибәр кыз арасындагы аерма — җир белән күк арасы кадәр булды да куйды. Нишләсен инде ул бу хәлендә? Ничек итеп брезент кожаны белән шушындый шәп киемле кыз янына барсын? Гөнаһ шомлыгына

каршы, нәкъ шул чакта гына уты да яктырып китте, хәерсез. Сиздерми генә чыгып сызарга да мөмкин түгел...

Рухияне сырып алган әрсез егетләр бераздан төрле якка таралыштылар, әмма бер козгыны һаман Рухия янында калды әле. Кыланышын гына кара син аның: яшь этәч кебек, бер урында туктаусыз таптанып торган була бит, зәхмәт! Ак күлмәгенә таккан кара галстугы күренеп торсын диптер инде, пальто төймәләренә хәтле чишеп җибәргән булган. Төсе-бите болай ярыйсы гына чибәр күренә күренүен. Буйга да Равилдән ким түгел. Ләкин тәнгә бик ябык: элеп киптергән шикелле. Хәер, буе-сыны кадалып китсен иде әле, ә менә күлүенең бер рәте-чираты юк инде: карт алаша кешни диярсең!

Беләсе иде: кем икән шул кипкән балык? Равилдән биш-ун яшькә олырак икәнлеге бәхәссез: анысы әллә кайдан «кычкырып» тора. Кем икән ул? Кыланышларына, үзен чамасыз иркен тотуына караганда, шушы Укмасныкы булырга охшый. Ә киемнәре шәһәрнекенә тартым: башында, сәләмәрәк кенә булса да, эшләпә, аягында кара хром ботинка, ә өстендә күзге кара пальто. Анысын да әле күптән түгел генә алган булса кирәк — бер дә кыршылган җире сизелми. Һәрхәлдә, Равил шикелле ватылып, көн-төн колхоз эшендә эшләп йөргәнгә охшамаган бу. Их, үз авылларында булса бик тиз белер иде Равил аның кем икәнлеген! Авыз җәйдереп, Рухиясе янында шушылай озак лыгырдатып тотмас иде. Ташый елга түгел шул бу... Кара инде син ул имансызны?! Әрсезләнеп сөйләштереп торуы гына җитмәгән, култыклап ук алды бит кызны! Әнә туп-туры монда таба алып килә башлады. Кеше азрак почмакка алып кереп, бөтенләй иркенәеп сөйләштермәкче була, ахрысы. «Тукта, юри каршыларында басып торыйм әле! Рухия мине күрер микән? Күрсә нәрсә дияр икән?» — дип, тегеләрне күрмәгәнгә салышып, Равил үз турына килеп җитүләрен көтәргә булды. Менә алар аның турына килеп тә җиттеләр, менә үтеп тә киттеләр. Күргәндерме Рухия Равилне, юктырмы, ләкин бер сүз дә дәшмичә үтеп китте. Ә Равилнең күреп торып та сүз әйтергә йөрәге җитмәде.

Тегеләр арырак почмакка үттеләр дә туктадылар. Эшләпәсе туктаусыз нидер сөйләнә, ә Рухиясе мөкиббән китеп тыңлап тора, чырык-чырык көлгәләп куя. Беләсе иде: Рухия тикле Рухияне шулай кычкырып көлдерерлек итеп нәрсәләр сөйләгән була икән? Кыяфәтен генә кара әле син аның: эшләпәсен көязләнеп кыңгыр салган, күн перчаткасын кулына тоткан да, сайрапмы сайрый! Гармунчыларын гына күр әле син боларның: һич тә тегеләр сүзен ишетергә ирек бирми — бүре улаган тавышлар чыгарып акырта! Начар гармунчының һәр вакыт шул инде аның: осталык белән, моң белән алдыра алмагач, гармунның бар булган бакаларын акыртып, яхшы уйнаган атлы булып күренергә маташа... Их, үзләренең Ташый елгаларында булса! Менә хәзер үк Равил аның янына барыр, кая, агайне, син чак кына ял итеп тор, мин дә аз гына кычкыртып карыйм әле, дигән булып, иплəп кенә үзенең аккордеонын сыздырып...

Юк, сыздыра алмый шул инде ул аны. Йосыф абыйның теге чакта алыш-бирешкә ни өчен алай ансат ризалашуы соңыннан ачыкланды. Үзе уйнар өчен тырышмаган икән ул, имансыз! Велосипед белән алмашып алуына атна-ун көн дигәндә Равил аккордеонының башына тәки җитте бит. Казанга илтеп саткан да шуның акчасына өр-яңа велосипед алып кайткан иде ул.

— Ну, шәп нәрсә булып чыкты, малай, синең ул нәмәстәкәең. Талчук базарына барып керүем булды — минуты белән алып киттеләр. Менә шушы әле яңа завуттан чыккан биләсәпитне алгач та, тагын искерәк бер биләсәпитлек акчасы калды әле! — дип, Йосыф абый үз авызы белән әйтте Равилгә.

...Равил шуларны уйлап торганда, аның ризасызлыгын сизгәндәй, гармунчы гармунын акыртуны азрак кимет[ә] төште. Әһә, әнә Рухия янында торган теге калай әтәчнең дә кайбер сүзләре ишетелә башлады. Ләкин Равил аңлый торган итеп түгел, ниндидер чит-ят сүзләр белән сөйли ул: «деканат»... «доцент»... «кафедра мөдире»... «ассистент»... Ике сүзнең берендә әнә шулай дип кенә җибәрә. Юк, болай булгач, Равил ише авыл малае гына түгел инде бу! Мөгаен, берәр югары уку йортында укучы студент булырга тиеш. Ай-яй-яй, эшләре шәп түгел бит Равилнең болай булса. Хөрти аның хәлләре! Ни өчен дисәң, кызлар өтек кенә студентларга да алланың үзенә караган шикелле карый бит алар. Узган ел студентларның ял вакытында заманында Чүкәй мәктәбендә укып, соңыннан төрлесе-төрле уку йортларында укырга киткән студентлар белән очрашу кичәсе булган иде. Шунда өлкән класс кызлары очрашуга килгән студентлар тирәсендә әйләнчек сарыклар сыман йөрделәр! Ә Рухияне авызына караткан әлеге Эшләпә күрер күзгә дә алай бөтенләй үк бетереп ташларлык нәрсә түгел. Килешле генә кылыч борын, тигез ак тешләр, чиста түгәрәк йөз. Күзләре моннан бик үк ачык күренми күренүен, әмма алары да бөтенләй үк нурсыз булырга тиеш түгел. Бөтенләй үк нурсыз булса, Рухия аның белән болай озак сөйләшеп тора алмас иде. Андый теләсә кем белән теләсә ничек сөйләшә ала торган талымсыз бәндә түгел ул!

Кыланышларына караганда, Эшләпәнең Рухия белән беренче генә сөйләшүе булырга тиеш түгел. Беренче генә сөйләшүе булса, үзен бу тикле иркен тотмас иде... Бигрәк йомыкый булды шул Равил. Инде ике айга якын бергә укып, ничә тапкыр мәктәпкә бергә барып, бергә кайтып йөреп, тәки шушы көнгәчә, егетең бармы синең, Рухия? дип сорарга йөрәге җитмәде! Кыз гел үзе белән бик ачык булып, чын дусларча сөйләшеп йөргәч, бүтән кеше белән дә ул шулай була аладыр дип уена да китермәде. Ә ул, әнә, Эшләпә белән дә бик рәхәтләнеп ләчтит сатып тора! Ичмаса, Таня белән Вәсимә дә клубта күренмиләр. Монда булсалар, алардан гына сорашып, мәсьәләне ачыклар иде дә кайтып китәр иде...

Теге юньсез гармунчылары танцы көе уйный башлады. Клубтагы яшьләр, уртада буш урын калдырып, стена буенарак сыеныштылар. Аннары Эшләпә Рухияне култыклап шул буш урынга алып чыкты һәм алар танцевать итәргә керештеләр. Алар артыннан бүтәннәр дә иярде.

Үзе туктаусыз бөтерелә, ә үзенең күзләре гел Рухиядә Эшләпәнең. Гашыйк икәнлеге әллә кайдан кычкырып тора. Рухия белән бию аның өчен чиксез рәхәт икәнлеге йөзенә үк чыккан... Рухиянең кичә Равилне көтмичә кайтып китүе дә шушы студент өчен булмады микән әле?.. Их, ичмаса, танцевать итә белми Равил! Белсә, билләһи, өстендә брезент кожан, аягында котсыз резин итекләр дип тормас иде. Көй алмашынганда туктап торган чакларында Рухия янына барыр иде дә аны танцыга чакырыр иде. Кечкенә авылда тумасын икән егет кеше. Тугачтугач, менә шушындый зур авылда, клублы авылда тусын икән! Ташый елгада танцының ни икәнен дә юньләп белүче юк, ә болар, әнә, теттереп бииләр.

Әнә шулай бик күңелсезләнеп, бөтен өметләре өзелеп, клубтан теләр-теләмәс кенә чыгып барганда:

— Нәҗметдинов! — дигән искиткеч нәфис тавыш ишетте Равил.

Шундук туктап калды. Ул арада, кояштай балкып, Рухия аның янына килеп җитте дә:

— Бәйрәм белән, Равил абый! — диде. Аннары йөзенә үпкәләү галәмәте чыгарып, бармак янады.— Ай-яй, Равил абый, мин сине бу кадәр үк һавалы кешедерсең дип уйламаган идем!

— Минме? Туктале, ни сөйлисең син, кызый? — диде Равил, үзе үпкәлисе урында кыз аңа үпкәләп торганга исе китеп.

— Нигә икәне билгеле инде,— диде кыз, үз нәүбәтендә шулай ук Равилнең аны аңламыйча торуына аптырап.— Мине кайчаннан бирле күреп торасың, ә үзең килеп исәнләшергә дә теләмисең! Үзем дәшмәсәм, тәки шулай, күрмәгәнгә салышып, чыгып китеп барасы идең, әйе?

— Әй! — диде ул, Рухия клубка килеп керү белән янына барып күрешмәгәнгә үкенеп.— Һавалы булудан түгел лә ул! Син теге Эшләпә белән сөйләшә башладың ич, шуңа сүзегезне бүләргә кыенсынган булган идем.

— Кыенсынмаган булсаң — яхшырак буласы иде, Равил абый! — диде кыз.— Мине кичәдән бирле тәмам туйдырып бетерде инде ул.

— Әһә, аңлашылды: димәк, кичә синең мине көтмичә дә кайтып китүең шушы Эшләпә аркасында булган икән.

— Киресенчә,— диде кыз, исе китмичә генә,— ул үзе Чүкәйгә килгән иде. Ат белән дә булгач, әйдә дә әйдә дип кыстап та торгач, шуңа утырып кайттым да киттем, Равил абый.

— Ә мин сине кичкә кадәр көтеп тордым. Әйтеп тә китмәгәнсең.

— Гаеп миндә, әйтергә кирәк иде шул. Әллә ничек хәтергә килмәгән инде, Равил абый.

— Ә нинди бәндә соң ул?

— Әй, бер студент инде шунда!

— Кайда укый?

— Алабугада, педагогия институтында.

— О-о-о! Укытучы буласы икән, алайса.

— Әйе. Быел өченче курста укый. Математик булачак икән. Унынчы класста сине дә укытырга туры килер әле, дигән була. Ходаем язмасын! Минемчә, аннан барыбер рәтле укытучы чыгачак түгел.

— Нигә алай хурлыйсың әле син аны? Яңа гына дөньяңны онытып, шуның авызына карап тора идең бит!

— Сагыз урынына ябышкач, ни эшлисең инде, Равил абый. Син килеп коткармыйсың, ул үзе белеп китми!

— Мин аны китә торган итимме соң, Рухия? Тәкә Әнәсне өйрәткән шикелле өйрәтимме шуны?

Рухия нидер әйтмәкче иде, кинәт, кемнәндер курыккан сыман, тотлыгып калды. Ә Равил тагын да әсәрләнеп дәвам итте:

— Синең янына килү түгел, урамда очраганда да сине читләтеп үтә торган итимме шул Эшләпәне?!

Шулай диюе булды — арттан кемдер якасыннан каптырып та алды. Каптырып алды да:

— Кемне шулай якын да китерми торган ясамак буласың әле син, йолкыш? — дип селкеп тә куйды.

Борылып караса — Эшләпә икән. Яшькелт күзләрен акайтып, көченнән килсә кабып йотардай усал итеп, Равилгә текәлгән иде ул. Дөресен әйтергә кирәк, башта каушабрак калган иде Равил. Ләкин Эшләпәнең явыз карашын күрүгә, үзендә дә усаллык хисе котырынып китте һәм ул да, ачу белән тегенең кулын читкә кагып:

— Ә-ә! Килеп тә життеңмени әле син-шымчы? Әйе, сине өйрәтергә иде минем исәп! — диде.

Каяндыр килеп кергән сәләмә генә киемле яшь бер килмешәк егетнең болай кискен җавап бирүенә шаккатып калган иде булса кирәк, Эшләпәнең күзләре маңгаена ук сикереп менде. Бите, колаклары гына түгел, муенына тикле чөгендер шикелле кызарып чыкты. Артык нык ачуланудан һәм каушаудан сүзен дә юньләп әйтә алмыйча, нидер мыгырданып, ул кырт борылды да халык арасына кереп югалды.

— Әй, Равил абый, алай ук әйтергә кирәкмәс иде лә! — диде Рухия. Нигәдер куркып, агарып ук киткән иде ул.

— Аптырама, Рухия! — диде Равил, әле һаман кызулыгы бетеп җитмичә.— Әгәр алай-болай бүтән чакта да шулай бәйләнә башласа,

мәктәпкә килгәч, үземә генә әйт. Тәкә Әнәсне акылга утырткан шикелле генә итмәм, җанын суырып алып, учына тоттырып җибәрермен мин аның!

— Ярар, әллә ниләр сөйләп торма әле, Равил абый,— диде кыз, тагын да ныграк борчыла башлап.— Әйдә, тизрәк чыгып китик моннан!

Чыгып барышлый, ишекне ябам гына дигәндә Равилне тагын якасыннан эләктереп алдылар. Тагын шул калай әтәч-Эшләпәдер инде дип, ачу белән борылып, селкеп атмакчы булган иде — өлгерә алмады: башта аның колак төбенә бик каты итеп суктылар, аннары бәреп үк ектылар. Каршылык күрсәтергә түгел, башлап кем сукканын абайларга да өлгерә алмыйча калды Равил. Ул бары үзенә ташланучыларның биш кеше һәм шуларның берсе әлеге Эшләпә икәнлеген генә күреп калды. Аннары Рухиянең «ой!» дип кычкырган тавышы колагына чалынып китте. «Аны да кыйныйлар, ахрысы!» — дип, соңгы көчен җыеп, сикереп торырга талпынып караса да, булдыра алмады: дыңгырдатып сөйрәп, Равилне урамга алып чыгып киттеләр дә җыйнаулашып типкәләргә тотындылар. Шуннан соңгысын ул инде хәтерләми.

Аңына килгәндә Равил клубтан шактый еракта, су буенда ята иде. Күрәсең, кыйнап туйгач, шунда илтеп ташлаганнар.

Тирә-як тып-тын. Вакыт бик соң булса кирәк — авыл өйләренең берсендә дә ут күренми. Тик һавадагы йолдызлар гына, аптырама, егет, дөнья булгач андый гына хәлләр булгалый инде ул, дигән сыман, Равилнең күңеленә сабырлык һәм өмет чаткылары сибеп, тоныкк кына җемелдәшәләр. Ә Чүмеч йолдыз кай тирәдәрәк икән соң әле? Әһә, әнә ул... Димәк, сәгать төнге икеләр булырга тиеш. Шулай ук озак ятты микәнни Равил монда? Ул Эшләпә белән бәйләнешеп киткәндә кичке тугызлар чамасы гына иде бит...

Кайшылган-сынган җирем юк микән дип, Равил яткан килеш кенә кулларын-аякларын селкеткәләп карады. Бер дә кузгаласы килми, бөтен тәне оеп-сыкрап тора иде аның. Шулай да сөякләре исән икән: куллары да, аяклары да хәрәкәтләнә иде. Шунысына да бик шөкер итеп, ул әкрен генә торып басты да тирә-ягына каранды. Нигәдер менә шушы минутта Рухия аның янында басып торадыр шикелле тоелган иде. Тик кыз күренмәде. Аңа алай-болай берәр хәл ясамадылар микән дип шикләнеп, Равил башта Рухияләр урамына барды. Шактый гомер өй турыларында басып торды. Аларның өе тыныч иде. «Димәк, аңа тимәгәннәр. Андый-мондый хәвефле хәл булган булса, өйләрендә ут булыр иде. Ә болар йоклый»,— дип тынычланып, каравыл өенә — Сафиулла абзый янына китте.

Равил килеп кергәндә карт йокымсырап утыра иде. Ул башта иркенләп һәм рәхәтләнеп озак кына иснәде. Аннары сәгатькә күз салды. Төнге өченче ярты икәнен күргәч, Равилгә карап, мәгънәле генә күз кысып куйды:

— Я, бер дә яшермичә генә әйтеп бир әле: кем кызын шушылай озак сөйләштереп тоттың бу суыкта?

Ул Равилгә текәлебрәк карады һәм, кинәт аптырап:

— Ни булды сиңа, наный? Нишләттеләр сине? — диде.

— Нәрсә, әллә биттә кан эзләре бармы, Сафиулла абзый?

Карт Равилгә якын ук килеп карады.

— Һей! Кан эзләре генә булса ничава булырые ул, наный! Анысы җуарыең да бетәрие. Бөтен битең кара янып, күгәреп чыккан лабаса синең! Бар, көзгедән кара әле!

Колхоз яралганнан бирле каравыл өендә эленеп торып, тутыгып беткән көзгедән үзенең кыяфәтен күргәч, Равилнең тәннәре чымырдап китте. Битенең карарлыгы да калмаган — күгәреп, тиреләре сыерылып беткән иде. Эшләпә эшедер инде бу. Ул шушылай «матурларга» тырышкандыр. Шушылай итеп аны бөтен дөньяга көлкегә калдырмакчы

булгандыр. Ә бит сугышуның да үз катыйдәләре бар, югыйсә: гадел һәм юньле сугышчы беркайчан да дошманының йөзенә сугарга тиеш түгел! Дошманыңны кеше яллап тукмату шулай ук чын егет эше түгел бит инде... Юк, эшләпә киеп йөрсә дә, егетләрчә кыланмаган бу!

— Ярый, Сафиулла абзый,— диде Равил, әнә шуларны уйлап күзге янында бераз торгач.— Буласы эш булган монда! Минем сиңа бер үтенечем бар: зинһар, бу мәсьәләне фаш итеп йөрмә, яме!

— Үзең гаепле булдыңмыни соң, олан? — диде каравылчы, бик нык борчылып.— Башлап үзең бәйләндеңмени?

— Бәйләнүен мин бәйләнмәгән идем дә...

— Алай булгач, шушылай адәм мәсхәрәсе итеп кыйнап ташлаган ул явызларны судка-җавапка тарттырмыйча гына калдырырга ярамас бит инде?

— Судка бирмим, Сафиулла абзый. Судка бирсәм, аларның бишесен дә хөкем итәчәкләр. Ә миңа шул биш кешенең тик берсен генә хөкем итү кирәк. Үзем хөкем итәм мин аны!

## 14

Сафиулла абзый көлгә күмеп бәрәңге пешергән иде. Равил шуны ашап, кайтырга чыкканда таң беленә башлады. Башка көннәрне ул таң беленгәнне сагынып көтеп ала торган иде. Ә бүген менә, яктылык арткан саен, аның күңеле караңгылана, шомлана гына барды. Күгәрепканап беткән йөз белән әнисе күзенә ничек күренә инде ул? Үзе ашыйсын аңа ашатып, үзе киясен аңа кидереп, адәм көлкесе булып йөрсен өчен үстермәгән ләбаса аны әнисе! Яп-яшь көенчә, сорап торучысы булганда да кияүгә чыкмыйча, Равиле менә шушылай ямьсезләнеп йөрсен өчен ялгыз чиләнмәгәндер бит инде ул!

Ярый, ахыр чиктә, әнисе янына кайтып күренү ул тикле үк куркыныч та булмас әле. Төнлә аттан егылып төштем дисә, әнисе ачуланмас. Бүре килеп чыкты да атым куркып егып төшерде дисә — авыл халкы да әллә ни шаккатмас. Ләкин менә мәктәпкә бу кыяфәте белән ничек барып күренер соң ул? Укытучыларга ни дияр? Дәрескә кергәне бере: «Ни булды сиңа, Нәҗметдинов?» — дип сораячак бит. Хәнифә Вәлиулловна да күрәчәк... Ниһаять, аларына да түзәр иде әле. Төнлә ат кеткәнне Хәнифә Вәлиулловна белә, аттан егылдым дисә, ул да ышаныр иде. Иң яманы шул: Рухия бар бит әле бу дөньяда! Әгәр бу хәлендә аңа күренсә — коты алыначак ул кызыйның. Болай да иләс-миләсрәк күңеле Равилдән мәңгегә суыначак! Ә Равил аның күңеле суынуын һич тә теләми. Чөнки Рухия аның якты маягы, илһамчысы, шатлыгы, бәхете ләбаса!

Уйлады-уйлады да, укытучылары алдында да, Рухия алдында да йөз кызартып, кеше көлдереп йөргәнче, кыяфәте адәм төсенә кергәнгә кадәр укырга бармый торырга булды.

## 15

Равилне «эшкәртеп» кайтарганнарына бүген алтынчы көн. Барысы да нәкъ ул көткәнчә дип әйтерлек килеп чыкты. Аттан егылып төштем, дигәч, әнисе дә кызганып елап җибәрүдән башка сүз әйтмәде. Ә авыл халкы исә Равилгә бөтенләй исе китеп, батыр итеп карый башлады. Имеш, елгадан килеп чыккан бүре, Равил аттан егылып төшкәч, аның өстенә ташланган. Әмма Равил каушап калмаган — бүренең койрыгыннан эләктергән дә алган! Бүре Равилдән ычкынмак булып тыпырчына

икән, ләкин Равил аңа борылырга да ирек бирми икән. Шулай байтак тартышканнан ары Равил бер түмгәккә абынып егылып киткән дә ялгыш бүрене ычкындырып җибәргән. Бите әнә шул чакта сыдырылган аның, иреннәре әнә шунда күгәреп-шешеп чыккан...

...Ноябрьның сигезендә кар яуды да ат көтүне туктатырга туры килде. Фермага каравылчы булып урнашмады әле Равил. Хәбир бабай бу ай ахырына тикле үзем эшләп торам, ди. Ә Равилгә эш кирәк. Кыяфәте ямьсез булса да, тәне сау-сәламәт бит аның. Шуңа ул хәзер ындырда эшләп йөри: барабанга көлтә биреп тора. Ә кичләрен сәгать төнге икеләргә-өчләргә тикле барыбер ферманың каравыл өендә — Хәбир бабай янында үткәрә. Чөнки анда төн буена ут яна: җаның теләгәнчә укып утырырга мөмкин. Ә өйләрендә алай озаклап утырырлык керосиннары юк аларның. Аннары, гомумән, Равилнең әнисе китап укыганны өнәми. «Күз бетереп, шул шайтан сабагын укып утырганчы, чабата ясап сатсаң — мең мәртәбә әйбәтрәк булыры!» — дип, гел сукранып тора. Үзе хәзергечә бөтенләй укымаган шул ул. Яңалифне генә азрак сукалый. Шуңа китапның кадерен дә, аны укуның тәмен дә белми.

Дөрес, Хәбир бабай да алай зур белемлеләрдән түгел. Ул да бер-ике кыш мәдрәсәдә укудан ары китә алмаган. Ләкин ул Равил үзе янына китап укырга йөргәнгә бер дә сукранмый. Сукранмый гына түгел, кайчакта хәтта Равилгә кычкырып укырга куша да йөткерәсе килгән йөткерекләренә хәтле тыеп, исе китеп тыңлап тора...

Әгәр теләге кабул булып, Рухия белән яңадан бергә укый башласа — бу Равил өчен үзенә күрә бер революция булыр иде. Кыскасы, ничек тә күбрәк укырга кирәк Равилгә. Бу үткән атнада Габдрахман Әпсәләмовның «Ак төннәр»ен, Шәриф Камал хикәяләрен, Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ын, Сибгат Хәкимнең шигырь һәм поэмалар җыентыгын, Фатих Кәрим, Һади Такташларның шигырь китапларын, Тажи Гыйззәт, Риза Ишморат пьесаларын укыды ул. Барысын да бик яратып укыды. Алар аңа җан юанычы булдылар. Югыйсә, гел Рухия турында уйлап, акылдан язарга да бик мөмкин ләбаса! Китап укымаган чакларында гел Рухия күз алдында, гел күңеленнән аның белән сөйләшеп йөри бит ул.

Бүген Рухия иптәш кызлары Таня һәм Васимә белән Ташый елга кырыннан үтеп китәргә тиеш. Их, барабанга көлтә биреп торасы булмаса, ике дә уйламас иде Равил: юл буенда көтеп торып, шул кызларны каршы алыр иде. Каршы алыр иде дә Рухия белән туйганчы бер сөйләшеп кайтыр иде...

Әнә шулай хыяллана-хыяллана, тирләп-пешеп барабанга көлтә биреп торганда, кемдер Равилнең җилкәсенә кагылды. Әһә, үз сыерларын җигеп, кырдан ындырга көлтә ташучы яшьтәше Габделгазиз икән. Ни кадәр кычкырса да, барабан тавышы сүзен ишеттермәячәген чамалап, Габделгазиз, кул ишарәсе белән генә үзенең Равил урынына көлтә бирә торачагын «әйтте» һәм, ындыр табагының аргы башында тузансызрак җирдә басып торган бер кызны күрсәтеп, Равилгә шуның янына барырга «кушты». Кызның Рухия икәнен абайлагач, Равил өс-башындагы тузанны каккалап алды да, бик нык дулкынланып, кыз янына китте. Төзәлеп житмәгән яралары шар ярылып тормасын өчен, ярты битен каплап торган барабанчы күзлеген юри салмады.

— Я аллам, исән икәнсең ич син! — диде кыз, Равил килеп житкәнне дә көтмичә.

— Ә син мине инде үлгәндер дип уйлаган идеңмени? — диде Равил.

— Тфү, тфү, авызыңнан җил алсын, Равил абый! — диде кыз. Аның әле генә балкып торган йөзенә кинәт курку галәмәте чыкты.— Сиңа түгел, дошманыма да үлем теләмим мин! Атна буе синең өчен борчыл-

дым. Көн саен көттем. Ә син юк та юк! Инде бүген дә килмәгәч, кайтышлый хәлеңне белеп китәргә булдым менә.

— Үзең теләпме, класс җитәкчесе кушыпмы?

Әле яңа гына менә шушы Рухияне бер күрер өчен дөньяның аргы ягына чабарга әзер торган Равил, кыз каршына килеп баскач, нигәдер, үзе дә сизмәстән, дорфаланып китте. Ярый әле, Рухия аның шулай сөйләшүенә игътибар бирмәде. Чак кына уйланып торды да:

— Ничек дип әйтсәң дә дөрес булыр, Равил абый,— диде.— Бүген без кайтырга җыенганда Суфия Гайнетдиновна килеп керде дә: «Кызлар, кайтышлый Ташый елгага кагылып, шушы язуны Нәҗметдиновка калдырып китегез әле. Кайсыгыз иренми?» — диде. Вәсимә белән Таня авызларын да ачарга өлгерә алмый калдылар, мин язуны эләктердем дә очтым гына.

— Каяле, нәрсә язган икән?

— Нәрсә булсын, укырга нигә килмисең дип сорагандыр инде. Ә нигә бу атнада укырга йөрмәдең син, Равил абый?

— Күрмисеңмени бу битне? — диде Равил. Хатны ача башлаган җиреннән туктап, күзлеген маңгаена күтәреп куйды.— Бу кыяфәт белән ничек итеп анда барыйм ди мин?

Рухия Равилгә якын ук килеп, текәлеп карады да йомшак, кайнар кулы белән аның битен сыпыргалап:

— У-у-у! Хәтәр булган икән шул, Равил абый! — диде.— Ләкин хәзер алай куркыныч түгел инде. Бер-ике көннән бөтенләй төзәлеп бетәргә тиеш. Ачуланма инде, Равил абый, минем аркадарак килеп чыкты бу күңелсезлек.

Ул шулай сөйләнгән арада Равил Суфия Гайнетдиновнаның хатын күздән кичерде: «Сине авырый дип әйттеләр, Равил. Ни белән чирлисең? Озак авырма, яме. Югыйсә, укуыңда артка калуың мөмкин. Авыруың турында белешмә алып килергә онытма! Тизрәк сәламәтләнүеңне теләп: С. Сәйфуллина».

— Юк өчен хафаланма, Рухия! — диде Равил, хатны кесәсенә салып.— Син анда булмасаң да бәйләнешергә тиеш идек без ул Эшләпә белән! Башта ук ошамады ул миңа.

— Чынлап та миңа үпкәләмәдеңме, Равил абый? — диде кыз.

Гадәтенчә, тирә-якны балкытып, елмаеп куйды.

— Әйтәм бит инде: башыма да китермәдем! Ә сиңа тимәделәрме соң ул адәм актыклары?

— Тиюен тимәделәр. Ләкин сиңа ярдәм итәргә дә ирек бирмәделәр. Клубка төртеп кертеп җибәрделәр дә тыштан ишекне терәп тордылар. Ә терәп торучы киткәч, мин чыкканда син клуб янында юк идең инде. Нишләтте алар сине, Равил абый? Кая алып китеп кыйнадылар?

— Ярый, Рухия, үткән-беткән, аңа баш ватып тормыйк. Син миңа шуны аңлатып бир әле: кем әйтте Суфия апага мине авырый дип?

— Мин әйттем, Равил абый. Ә нигә, ярамый идемени?

— Алдашкансың бит син, кызый! Авырырга уйлап та караганым юк минем. Сигезенче ноябрьдан бирле колхозда эшләп йөрим!

— Ярар инде! — диде Рухия, мәк чәчәгедәй кызарып.— Ачуланма инде, Равил абый! Бер мин генә уйлап чыгарган нәрсә түгел, дәрес калдырган кеше гомер-гомергә «авырдым» дип әйтә иде. Аннары мин сине чыннан да авыргансыңдыр дип уйлаган идем. Бигрәк каты кыйнаганнар бит сине ул идиотлар.

— Ерунда! — диде Равил, сер бирәсе килмичә.— Тоймадым да мин алар тукмаганны! Тик менә битне эштән чыгарулары гына азрак кәефне бозды. Теге Эшләпәгә әйт кайткач: әгәр Ташый елгага килеп гафу үтенмәсә — кәҗә догасы укытам, дип әйтә диген, яме!

— Ул киткәндер инде, Равил абый. Бәйрәмгә генә кайткан иде ич.

— Китсә, мәңгегә китмәгәндер әле, кышкы каникулга тагын акаеп кайтып житәр. Кайчан кайтса да, әйтергә онытма, ярыймы?
— Аңлашылды. Барысы да сез боерганча булыр, иптәш Нәҗметдинов! — диде кыз, мәсьәләне уенга алыбрак. Аннары шундук житди тонга күчте:— Димәк, дүшәмбе көнне укырга барасың инде, Равил абый, шулаймы?
— Ә куып кайтармаслар микән соң? Әнә Суфия апа авыруым турында врачтан белешмә алып килергә кушкан бит анда.
— Кушса, апкилерсең! Белешмәң бардыр бит инде синең?
— Мин медпунктка бармаган идем шул. Ә хәзер барсам да бирмәсләр инде.
— Чынлап барганың юкмы медпунктка?
— Уйлаганым да булмады. Белешмә кирәк буласын башыма да китермәгәнмен бит!
— Эх, син!..— диде кыз.
— Әй, ярар ла, юкка аптырама, укырга рөхсәт итмәсәләр, борылырмын да кайтырмын!
Рухия кинәт куркынып китте дә:
— Юк, Равил абый, мине якын итсәң, син укырга тиеш! — диде.— Син укымасаң — беттем мин! Менә шушы узган атнада гына да тригонометрия белән физикадан берәр «икеле» чәпәделәр инде.
Өйдә эшләп килергә биреп җибәргән мәсьәләләрне Рухия үзе чишми, я иртән дәресләр башланганчы, яки тәнәфес вакытларында Равилдән генә күчереп ала торган иде. Аның алдында оятка калмас өчен, Равил шуңа һәр вакыт иң элек математика белән физикадан бирелгән мәсьәләләрне чишеп куярга гадәтләнгән иде. Укытучы кушканнарны гына түгел, алдагы дәрестә үтелергә тиешле теоремаларны, физика законнарын һәм шул теоремаларга, шул законнарга нигезләнгән мәсьәләләрне дә үзлегеннән өйрәнеп-белеп барырга тырыша ул. Дөрес, Рухиянең гел үзеннән генә күчереп баруын Равил бик үк өнәп бетерми. Болай эшләүнең нәтиҗәсе ахыр чиктә Рухиягә файдага түгел, киресенчә, зыянга әйләнергә мөмкинлеген дә бик белә. Ләкин кызының үтенечен кире кагарга да йөрәге җитми иде шул.
— Ә белешмә өчен кайгырма, Равил абый! — диде кыз, Равилнең уй агышын бүлеп. — Аны мин сиңа үзем алып киләм. Ә каян һәм ничек алачагымны син сорама, мин әйтмим.
— Алай ярап бетәр микән соң?
— Ярый, әлбәттә, нигә ярамасын!
— Үзең чамала инде алайса, тик... бер сүз әйтсәм үпкәләмәссеңме?
— Әйтеп кара, Равил абый.
— Рухия, әйдә... Әйдә, мин сине...
Ул «авылыгызга тикле озатып куйыйм әле» дип әйтмәкче иде, ләкин өлгерә алмый калды.
— Равил! — дип кычкырды аңа шул чак Габделгазиз.— Син нәрсә анда, кыз күрдем дигәч тә дөньяны онытырга ярамый бит инде. Давай, кил әле монда! Тагын рименең өзелде.
Рухиясен күрү куанычыннан сизми дә тора икән: Габделгазиз инде сугу машинасын әллә кайчан туктаткан да көненә кимендә ике-өч тапкыр өзелеп үзәккә үткән, барабанны маховик белән тоташтыра торган иске ременьне ялгарга керешкән иде.
Хәзер инде, әйдә, озатып куй, дип кыз үзе ялынса да, барып булмый — ременьне ялгарга кирәк иде.
— Булмады инде, болай булгач! — диде Равил, эченнән генә ременьне бик каты сүгеп. — Ярар, Рухия, яхшы хәбәр китерүеңә бик зур рәхмәт!
— Тукта әле, Равил абый, син нәрсәдер әйтергә җыенган идең шикелле?

— Ә-ә-ә! Ни... мин сине дүшәмбе көнне теге урман буендагы куш имән янында көтеп торырмын, яме!

Кыз, күрәсең, тынып калган ындыр табагындагы кешеләр ишетмәсен диптер, баш кагып кына «ярар» диде һәм нәфис аяклары белән искиткеч матур итеп атлап китеп барды.

Равил Габделгазиз янына килгәндә ындырдагылар барысы да, күрче син аны, карап торырга мокыт кына булса да, нинди чибәр кыз белән сөйләшеп йөргән була бит дигән сыман, гаҗәпләнеп һәм елмаеп карап калдылар.

— Алла, малай Равил, шәп нәрсә икән! Сине сорап яныма килгәндә, матурлыгына шаккатып, башта, билләһи, өнсез калдым! Кем ул, кайдан килгән нәрсә, сине кайдан белә? — дип, Габделгазиз дә тел озайтырга ниятли башлаган иде, әмма Равил күп сөйләшеп тормады:

— Бар, агайне, яхшы чакта тай әле моннан! Биш минут эшләмәдең, ременьне өздереп тә өлгергәнсең! — дип, тегенең соравын бөтенләй игътибарсыз калдырып, ашыга-ашыга ремень ялгарга тотынды.

## 16

Алар дүшәмбе көнне Чүкәйгә бергә бардылар. Ул көнне Рухия Таня белән Вәсимәдән алданрак кузгалган иде.

— Мин сиңа шул тикле ияләшкәнмен икән, Равил абый, узган атнада, син булмагач, ничектер классның бөтенләй яме киткән шикелле тоелды. Әгәр син укый башламасаң, эти белән әни үтерәбез дисәләр дә, мин дә, мөгаен, укуымны ташлар идем!

Чынлап әйтүе булгандырмы, әллә Равилнең күңелен күтәреп җибәрер өчен генәдерме, очрашып исәнләшкәннән соң беренче сүз итеп кыз аңа әнә шулай диде.

— Мин дә тик син шул мәктәптә укыганга гына укып йөрим бит инде, Рухия! — диде Равил дә, ниһаять, йөрәксенеп. Һәм ул, бу кызый тагын кылтаеп китмәсә ярый инде дип, шикләнеп тә куйган иде. Ләкин Рухия үпкәләмәде генә түгел, рәхмәт инде, Равил абый, дип, гадәтенчә матур итеп, елмаеп та куйды әле.

Рухия сүзендә торган: Равилнең бер атна авырып ятуы һәм шуның нәтиҗәсендә укудан азат ителгән булуы турында Укмас медпунктыннан белешмә алып килгән иде. Бу ялган белешмәне ничек итеп юллап алганлыгы белән бик нык кызыксынса да, Рухия үзен өченче көн кисәтеп куйганлыктан, Равил артык төпченеп тормыйча:

— Ярар, кызый, моның гөнаһсы икебезгә уртак булсын инде. Әйдә, киләчәктә беркайчан да болай алдашып эш итмәскә сүз куешыйк, яме! — дию белән генә чикләнде.

Равилне шактый зур борчуга төшергән ул белешмәнең бөтенләй кирәге булмады. Әллә онытты, әллә исендә булып та вакланып торасы килмәде — Суфия апасы Равилнең битендәге яра эзләре хакында сорашты да белешмә хакында бер сүз әйтмәде. Ул сорамагач, Равил дә эченнән тынды һәм бер атна өзелеп торган укуын дәвам иттерде. Әмма...

Кырык эш кырык елдан соң да беленер, дип бабайлар тикмәгә генә әйтмәгән икән. Кырык елга түгел ,кырык көнгә дә бармады Равилнең теге «эше». Яралары төзәлгәч укый башлавына ун-унбиш көн үтүгә бер тәнәфестә Хәнифә Вәлиулловна үз кабинетына чакырып кертте аны. Бүтән чактагы шикелле урын тәкъдим итеп, хәл-әхвәлен сорашып тормады, Равил килеп керү белән:

— Минә тыңла әле, Нәҗметдинов! — дип, өстәлендә яткан бер хатны алып укый башлады.

Октябрь кичендә Укмаста булган хәлләр турында язылган иде ул хатта. Барысы да бик дөрес язылган, ләкин бөтенесе дә тискәре ягы белән әйләндереп куелган: Укмас клубында сугыш башлап, бәйрәм кичәсенең ямен җибәрүче кеше — Равил дип әйтелгән иде. «Безгә мәгълүм булганча, — диелгән иде ул хатта, — сезнең шул сугыш чукмары Нәҗметдинов Равилегез мәктәптә алдынгы укучы дип санала икән. Җитмәсә тагы, тиздән комсомолга да керергә йөри икән үзе! Сезгә, иптәш Х. В. Нәбиуллина, мәктәп директоры буларак бер сорау бирәсебез килә: Равил Нәҗметдинов кебек алдынгы укучыларыгыз шушылай совет яшьләренә (ә совет укучыларына бигрәк тә!) хас булмаган хулиганлык эшләп йөргәч, күпчелек тәшкил иткән урта кул укучыларыгыз нинди икән сезнең? Уйлана белә торган җитәкче булсагыз — уйланырлык хәлләр бар монда, иптәш директор!

Ярый, без сезгә ул мәсьәләдә акыл өйрәтергә җыенмыйбыз. Анысын үзегез карарсыз. Ә менә совет яшьләренең культура учагында — клубта сугыш чыгарып, изге, революцион бәйрәм көнендә безнең матур кичәбезне бозып киткән укучыгыз Равил Нәҗметдинов мәсьәләсендә конкрет шуны таләп итәбез: андый ышанычсыз, хулиган кеше совет мәктәбендә укып, совет укучысы исемен күтәреп йөрергә тиеш түгел! Тагын шунысын да искәртеп куябыз: әгәр алдагы ун көн эчендә Нәҗметдиновка без таләп иткән чара күрелмәсә, бу эшне РОНОга, кирәк булса, хәтта Мәгариф министрлыгына кадәр җиткерәчәкбез.

Бу сигналны без, Укмас авылының йөзләгән яшьләре, бергәләп яздык. Исем-фамилияләребезне күрсәтеп торуны кирәк дип тапмыйбыз, чөнки аның үзенә генә дә болай да бик кадерле булган биш-алты бит кәгазь әрәм итәргә туры килер иде.

Тагын шуны да исегезгә төшереп куябыз: изге теләктән чыгып бирелгән бу сигнал уңае белән сезнең нинди чаралар күрүегезне бик яхшылап күзәтеп барачакбыз. Әгәр сез без таләп иткән чараларны күрмәсәгез, шул сәбәпле без бу эшне зурга җибәрсәк — безгә үпкәләмәгез».

Директор хатны укый башлаганда Равилнең куркудан маңгаена салкын тир бәреп чыккан иде, ахырына килеп җиткәндә ул тынычлана төшкәндәй булды. Чөнки бу хатта пычрак яла ягудан һәм куркытудан башка бер генә дөрес сүз дә юк иде. Тик кем эше икән соң бу? Равилнең миен әнә шул сорау бораулый иде ул минутларда.

— Я, Нәҗметдинов, — диде директор, коры гына итеп. — Ничек боерасың: ышаныргамы монда язылганнарга — юкмы? Әйдә, бер нәрсәне дә яшерми генә, ничек-ничек булганын сөйләп бир әле миңа!

Равил бөтенесен дә тәртибе белән сөйләп биргәч (ул бары Рухиянең исемен генә әйтмәде, «бер кыз» дип кенә әйтте), Хәнифә Вәлиулловна бу юлы да нәкъ теге чактагы шикелле итеп, стенадагы Ленин рәсеменә карап, аннан киңәш сорагандай беркавым уйланып торды.

— Яхшы, — диде аннары, — аңлашылды. Мин сиңа ышанам, Нәҗметдинов. Ләкин алай-болай эш зурга китеп, бүтән җирдә дә җавап бирергә туры килсә, башкаларны да ышандыра алырсыңмы икән соң? Башлап син түгел, бәлки сиңа бәйләнгәннәрен күрүчеләр булдымы ул чакта?

— Булды, Хәнифә Вәлиулловна. Бар андый кеше.

— Яхшы. Ә син аның дөресен әйтеп шаһитлык итүенә ышанасыңмы? Ниндирәк кеше ул, кем?

— Ышанам, Хәнифә Вәлиулловна. Үзебезнең класс укучысы Басыйрова ул.

Шулай дигәч, директорның йөзе күзгә күренеп яктырып китте.

— Бар әле, иренмичә генә чакырып кер әле үзен!

Хәнифә Вәлиулловна Рухиядән сораштырганда шунда тыңлап утыру — үлем белән бер булыр төсле тоелды Равилгә. Ничек итеп ул, егет

кеше, кыз бала үзен яклап сөйләгәнне мескен булып тыңлап утырсын ди? Юк!..

— Гафу итегез, Хәнифә Вәлиулловна, мин аны чакыра алмыйм. Басыйрова белән миннән башка гына сөйләшегез.

Әүлия ук булгандыр ул Хәнифә Вәлиулловна. Билләһи шулай булгандыр! Аның урынында шул чакта башка берәү булган булса, бу нинди капризлану тагы, фәлән дә фәсмәтән, дип пыр тузына башлар иде. Ә ул, изге җан, Равилнең хәлен шундук аңлап алды да:

— Ярар, алайса. Бар, дәресеңә кер. Ләкин карабрак йөр киләчәктә! Сезнең низагларыгызны гына тикшереп утыру түгел, башка эшләрем дә күп минем! — дип иплэп кенә чыгарып җибәрде...

## 17

Аннары алар классларыннан утыз өч кеше комсомолга керделәр. (Бишесе инде узган елны ук кергәннәр иде.) Ул чакта шунысы бик гаҗәп тоелды Равилгә: монда да аңа әлеге Укмас клубында булган күңелсез хәлне искәртеп үттеләр. Райкомол секретаре үзе искәртте. Дөрес, алай зурлап түгел түгелен. «Узган елгы Октябрь бәйрәмендә ясаган хатаңны киләчәктә кабатламассың дип ышанам, иптәш Нәҗметдинов» дип кенә әйтеп китте. Ләкин хикмәт аның ничек әйтүендә түгел, хикмәт теге хәлнең секретарьга да билгеле булуында иде. «Димәк, әлеге аноним хатны язган кешенең эше инде бу. Ай-яй, вак җанлы бәндә икән! — дип уйлап алды Равил. — Әгәр шул кешенең кем икәнлеген белсәм, себер китсәм китәм, иманын укытып китәм!» — дип күңеленә беркетеп куйды.

Комсомолга аны бик ансат кабул иттеләр. Бюро членнарының берсе, нигә бер ел укуыңны калдырып тордың, дип кенә сорады да, Равил аңлаткач, бүтән сорау бирмәделәр. Ә бит ул комсомолга керергә әзерләнеп йөргәндә, бюрода уставны да, комсомол тарихын да, илдәге экономик һәм политик мәсьәләләрне дә, хәтта чит ил хәлләрен дә сорыйлар дип куркытып куйганнар иде. Әгәр үзенә дә шундый сорауларны бирсәләр, җавап бирә алмыйча авыз ачып калмас өчен, Равил төненә дүрт-биш кенә сәгать әлегә торган кадерле йокыларын бүлеп, бик ныклап әзерләнгән иде. Яшь гвардиячеләр белән Александр Матросовның биографияләренә хәтле яттан өйрәнеп куйган иде ул. Ә аннан үз автобиографиясен дә сөйләтеп тормадылар. Райкомол секретаре «кем дә кем...» дип әйткәннән соң, ризалыкларын белдереп, бюро членнары кулларын күтәрделәр һәм бөек Ленин комсомолы члены булуы белән котлап, секретарь Равилнең кулын кысты да шуның белән эш бетте. Шунлыктан егетнең күңелендә канәгатьсезлек сыманрак бер хис утырып калды. Тик соңыннан классташларының кайберләрен шактый тинтерәткәннәре, кайсыларына хәтта унар сорау биргәннәре мәгълүм булгач кына, ярый әле, әзерләнеп барган булганмын, сорамасалар да белеп торуның зыяны тимәде, дип тынычланып, иркен сулап куйды.

Аннары аларга район культура йортында бушлай кино күрсәттеләр. Кинодан соң бүтәннәр, шул исәптән Рухия дә, «тамак ялгап алырга» ашханәгә кереп киттеләр. Ә Равил, анда кереп вакыт уздырып тормыйм, дигән булып, чынында исә акчасы булмаганга, үзенең Ташый елгасына кайтырга чыкты. Аның ягына бүтән кайтучы юк: классташлары, шул исәптән Рухия, Таня һәм Вәсимә дә, Чүкәйгә икенче юлдан кайтачаклар иде.

Равил басу капкасыннан чыгып, чаңгыларын кигәндә дөньяга караңгы иңгән иде инде. Шактый салкын һәм тып-тын кич иде ул. Атлаган саен чыр-чыр итеп таяклары «сыкравыннан» һәм чаңгылары чыҗылдавыннан башка дөньяда һичнинди тавыш та юк иде.

Адәм баласының күңелен дулкынландырып, уйларын канатландырып җибәрү өчен әллә ни күп вакыт кирәкми икән. Бер карагында ул көнне Равил тормышында әйтерлек зур үзгәреш тә булмады шикелле. Иртән районга килергә чыкканда нинди Равил булган булса, хәзер дә шул ук Равил бит инде ул. Ләкин, шул ук вакытта, ул иртәнге Равил дә түгел иде инде. Комсомол булган минуттан башлап, ул олыгаеп, кирәклерәк кешегә әверелеп китте шикелле. Бүтән кешеләр каршында да, укуында да җаваплылыгы арта төште сыман тоелды. Ул үзен бик зур, эшчән, батыр һәм көчле семьяның тулы хокуклы бер кешесе итеп хис итте. Гражданнар сугышында аклар белән, колхозлашу елларында кулаклар белән аяусыз рәвештә сугышып йөргән, Днепрогэсны һәм Комсомольск шәһәрен төзүдә актив катнашкан, аннары килеп, Бөек Ватан сугышы елларында фашистларга каршы көрәшнең иң авыр урыннарында каһарманнарча сугышкан һәм җиңеп чыккан Ленин комсомолларының эшен дәвам иттерүче булуын тойды. Шуңа горурланып һәм рухланып атлады да атлады...

Ләкин кайтасы юлы озын иде аның. Егерме җиде километр иде. Качкалакка килеп җиткәндә ул бик нык арган иде инде. Аяк атлар хәле дә калмаган иде. Качкалакта туган тиешле кешеләре дә бар, аларның өендә әле ут та сүнмәгән, барып керсә, әлбәттә, борып чыгармаслар: тамагын да туйдырырлар, тели икән — кунарга да калдырырлар иде. Хәер, туганнарына гына түгел, теләсә кайсы йортка барып керсә дә якты йөз белән каршы алган булырлар иде. Авыл җирендә халык алай шәһәрдәгечә ишек биклән яшәми бит. Ләкин Равилнең кеше борчып, вакыт уздырып йөрисе килмәде. Төнге каравылга кайтып җитәргә кирәк иде аңа. (Егерме өченче ноябрьда Хәбир бабай авырып китте дә шуннан соң ул эшне Равилгә йөкләгәннәр иде.) Кичке уннан да соңга калмыйча кайтып җитәргә тиеш иде ул. Югыйсә, ферма эшчеләренең дежур торучысы ачуланачак. Ул көнне бик яман холыклы, зәһәр телле Нурлыгаян дигән хатын дежур булырга тиеш, ул дөнья сасытып кычкырмасын өчен, Равилгә ничек тә иртәрәк кайтып җитәргә кирәк иде.

Кирәген кирәк тә соң, әмма Качкалакны үткәч тә алты километр җир кайтасы бар иде әле Равилнең. Авырлык белән генә булса да, шул алты километрның да яртысын ару гына үтеп китте. Ләкин шуннан ары аяклары бөтенләй атламас булып, тартышып калды. Хәтта басып та тора алмыйча, ул юлга сыерылып төште. Кичә кич мәми авыз булып, Фәйрүзә апасы белән юньләп сөйләшә алмавына үкенеп куйды. Район үзәгенә барырга туры килгәндә колхозчыларга һәр вакыт диярлек ат бирәләр иде. Бары колхоз эшен бик үк өнәми торган һәм «үз йомышлары» белән йөрүче сату-алуга маһир кешеләргә генә ат бирелми иде. Ә менә Равил кебек чакыру буенча барган кешеләргә ат бирмичә калу гадәте юк иде Ташый елгада. Шуңа кичтән Равил дә Фәйрүзә апасы янына идарәгә кереп, ат мәсьәләсен кузгатты. Ләкин анда да хәерчегә җил каршы булып чыкты.

— Д-а-а-а! Бик авыр мәсьәлә китереп куйдың бит әле син, энекәш! — диде ана председатель.— Бөтен атларга нәрәт биреп бетергәнием шул инде мин. Үземнең атны бирер идем, ну иртәгә Качкалакка барасы бар. Давай, энекәш, бу юлга чаңгың белән генә барып кайт, ярыймы.

Менә шул чакта Равил аңа: «Син ничек тә җаен табарсың әле, Фәйрүзә апа. Качкалак ерак җир түгел бит ул. Мин менә көн саен уналты километрга да йөрим ич әле. Әйдә, бер яхшылык эшлә әле, Фәйрүзә апа — синең атың белән генә барып кайтыйм иртәгә. Комсомолга гомергә бер генә тапкыр керәләр бит!» дип әйткән булса, Фәйрүзә апасы, ихтимал, ризалашкан да булыр иде. Әмма Равил алай дип әйтә алмады шул. «Ярар инде алай булгач», дип кенә әйтте дә боегып идарәдән чыгып китте. Гомер буе шул булды инде: иң кирәк чагында югала да кала. Аннары менә шушылай үкенеп йөрергә туры килә... Ярый, мо-

нысы киләчәккә акыл булыр. Башка вакытта ничек сөйләшергә кирәк икәнен белер ул. Тик бүген исән-сау гына кайтып җитә алсын. «Каяле, торып карыйк әле әкрен генә... Әйдәле, әйдә, сер бирмә әле, комсомол!..»

Ничек кенә үзен рухландырып караса да, Равил урыныннан куба алмады. Бөтен тәне изрәп-оеп калган, селкенерлек тә хәле юк иде аның. И рәхәт иде аңа шулай кымшанмыйча гына ап-ак кар өстендә утыру! Мондый да оеткыч рәхәтне аның әле бер дә татыганы юк иде...

## 18

Ул кичне Равил исән-сау кайтып җитә алыр идеме, әллә шул юл читендә утырган җирендә мәңгегә «оеп» китәр идеме — анысын өзеп кенә әйтүе кыен. Тик бөтенләй үк бәхетсез бала түгел икән ул. Әле һаман кузгала алмыйча утырганда ат пошкыруы колагына керде. Аннары Качкалак ягыннан килүче чана шыгырдавы ишетелде. Бераздан ат үзе дә күренде. Кем булса да ташлап китмәс әле, дип өметләнеп, соңгы көчен җыеп, Равил атлыны аягүрә басып каршы алды. Председатель Фәйрүзә апасы булып чыкты ул.

— Нихәл, наным, Равил, юлларың уңдымы? Комсомол булдыңмы? — диде председатель, атын туктатып, Равилне утырткач.

— Булды, Фәйрүзә апа, алдылар.

— Кая, бир әле бишне! — Шулай диде дә Равилнең бияләен үзе үк тартып алып, аеруча бер көч һәм дәрт белән кулын кысты. — Бүтән ягың ничектер, әмма кулың, ай-яй, кайнар икән, егетем!

Шунда Равил Фәйрүзә апасының яхшы ук салмыш икәнлеген сизеп алды: авызыннан аракы исе бөркелә иде.

— Нигә эчтең, Фәйрүзә апа?

Председатель кулын гына селекте:

— Беләсеңме, энекәш, нәрсә: давай, син дә дупруслап маташма әле, ярыймы! Синнән башка да дупруслаучылар күп бу апаңны. Бүген дә, районнан килеп, дүрт-биш сәгать талкыдылар. Шуннан кайтып кына килеш. Минем урында бүтән берәү булса, эчү генә түгел... Тик мин бүген аның аркасында гына салмадым. Колхозны адәм рәтле итеп алып барасың килсә, хатын-кыз булсаң да, салу гына түгел, чукынырга әзер буласың кайчакларда, чукынырга! Белдеңме шуны?

Фәйрүзә апасының мондый хәлдә булуына шаккатып, Равил ни дияргә дә белмичә барганда тегесе тагын сөйләргә тотынды.

— Әнә, чана башында ята торган теге нәмәрсәкәйне күрәсеңме?.. Юк, күрәм дип кенә утырма, күзеңне ачып, ипләбрәк кара әле син аны!

Кузгалыр хәле дә юк иде Равилнең. Әмма председатель бик каты таләп итә башлагач, чана башындагы печәнне актарып карамыйча булдыра алмады. Анда ул заман өчен алтынга тиң нәрсә — сугу машинасының барабанын маховик белән тоташтыра торган ремень ята иде.

— Аңыштыңмы инде нәрсә икәнен? — диде председатель, эчке бер канәгатьләнү белән.

— Яңамы бу, Фәйрүзә апа?

— Ә мин искене нигә ташып йөрим? Кем дип беләсең син Фәйрүзә апаңны искене алып кайтырга?

— Анысы шулай инде, син юк-бар нәрсә белән чуалмыйсың, Фәйрүзә апа, — диде Равил, тегенең йон уңаеннан сыпырып.

— Менә шулай! Күптән шулай диләр аны синең нше тишек борыннар! Ә син минем бу «әҗәл даруын» каян алганны беләсеңме соң?

— Миңа каян алсаң да барыбер, тик булсын гына, Фәйрүзә апа! — диде Равил, сүзне озынга сузарга һич тә теләмичә.

Ләкин председательнең туктар чамасы юк иде әле.

— Менә шул-шул! — диде ул, отыры кызып китеп. — Синең ише җыым бозауларына каян алсаң да — барыбер! Ә менә миңа, прсидәтел кешегә, барыбер түгел. Беләсеңме ни өчен барыбер түгел ул миңа?..

Равилнең авыз ачып сүз әйтерлек тә рәте юк иде. Шуңа тегенең соравын ишетмәгәнгә салышты.

— Синнән сорыйм бит мин, ник авызыңа су каптың? — диде председатель, көтеп-көтеп тә Равилдән җавап булмагангa ачуланып.

— Арыдым мин, Фәйрүзә апа, бик арыдым, зинһар аптыратма әле, яме!

— Әй! — диде председатель, тәмам өметен өзгәнне аңлатып, кул селтәде. — Мактанмасана шул хәлсезлегең белән! Ярар, ишетәсең килмәсә дә әйтәм әле мин сиңа шушы чана башындагы ременьне ничек итеп тапканымны. Син бу нәрсәне, алтын бирәм дисәң дә, кибеттә дә, мытыеста да табып булмаганны беләсең инде, шулай бит... Ярар, дәшмәсәң дәшмә, ахмак булмасаң — белергә тиеш син аны. Ә мин менә табып кайтып килəм шуны. Әллә кайдан да түгел, үзебезнең күрше авылдан — Качкалактан алып кайтып киләм мин аны! Аңладыңмы?.. Ярар, дәшмәсәң дәшмә, ну мин синең аңлаганыңны беләм, бүтән яктан мактар җирең булмаса да, башың эшли синең. Ну вәт, мин шушы ременьне Качкалактан табып алып кайтып киләм бит менә! Аның әле иң кызыгы шунда: колхоздан түгел, трактористлардан да түгел, техникага сукыр бер тиенлек тә катнашы булмаган Сәли Шәвәлне дигән бер кешедән сатып алдым мин моны. Хөкүмәт куйган бәясе чүп кенә бу ременьнең. Ә Сәли абзаң аны миңа йөз тапкыр кыйбатрак сатты. Ике сарык та бер савыт түләп алып кайтып киләм мин бу нәмәстәкәйне. Менә шунда, мин хатын-кыз, миңа ярамый дип, кәнфитләнеп, мәгәричтән баш тартып кара син: ул сиңа бу әйберсен мәңге бирәчәк түгел! Нигә бирсен, теләсә кайчан, теләсә кайсы колхозга мәгәричләп сата ич ул аны!.. Менә шулай, энекәем, кайчакта теләмәгән эшләрне дә эшләргә туры килә Фәйрүзә апаңа. Ә син, панимаешь...

Председательнең бу шактый сәер, ләкин нигездә хакыйкатькә туры килә торган фәлсәфәсен тыңлап килә торгач, кайтып җиткәннәрен сизми дә калды Равил. Атны капка төпләренә китереп туктаткач Фәйрүзә апасы кинәт айнып китте. Нәкъ бүтән вакытындагыча җитди итеп:

— Ярар, энем Равил, кайда булган — шунда калсын, яме! Мин дә тере кеше, мин дә адәм баласы бит. Прсидәтел булсам да, иң элек кеше бит мин! Бая кызыбрак китүем өчен үпкәләмә инде, наным! Ә хәзер бар, ирепмичә генә шушы атны двурга илтеп тугарып кайт инде! — диде дә, теге шактый авыр ременьне җиңел генә итеп култыгына кыстырып, җиргә нык басып, өйләренә кереп китте.

Ә Равил, шәп булды әле бу, югыйсә, каравылга ничек барырмын дип куркып тора идем, болай булгач эш пеште — ат белән генә барам икән, дип куанып, башта ашап чыгу нияте белән атны үз өйләренә таба борды.

## 19

Комсомолга кергән ул көн әнә шулай шатлыклы да һәм бик кыен да булып, Равилнең күңелендә мәңгегә уелып калды.

Аннары классларында беренче тапкыр комсомол җыелышы булды. Равилне комсорг итеп сайладылар. Тик мәктәп комсомол комитеты секретаре Килдеков Әнәс кенә:

— Сез яхшылап уйладыгызмы, иптәшләр, Назмутдинов мондый зур довериене аклый алырмы? — дип шикләнү белдерде.

Ләкин аңа карап кына классташлары шөбһәләнмәде... Равил үзенә йөкләнгән эшне тырышып, бирелеп үтәде. Кирәгеннән артыграк та тырышмадымы икән әле... Көннәрдән бер көн аның, комсомолец Нәҗ-

метдиновның «эшен» тикшерделәр. Класс бюросында гына да түгел. Мәктәп комсомол комитеты бюросында! Көн тәртибендә ике мәсьәлә: комсомол комитетының алдагы айга эш планын раслау һәм комсомол члены Равил Нәҗметдиновның тәртибен тикшерү.

Бюро членнары — җиде кеше. Шуларның берсе — Рухия Басыйрова. Икенчесе Әнәс Килдеков.

Бюро утырышы башланды инде. Беренче көн тәртибен хәл итәләр. Аннары Равилне дәшәргә тиешләр. Әлегә ул залда көтеп утыра. Зал тып-тын. Укучылар, дәресләрен тәмамлап, өйләренә таралышты. Алар тәртиплеләр шул. Ә менә Равил юләрлеге аркасында көтеп утырырга мәҗбүр... Кызык: мәктәп буш, ә һавасы авыр. Үзләре кайтып китсәләр дә, балаларның исе калган.

Бюро членнары җидәү, ә Равил берүзе булачак. Равилнең язмышы шулар кулында. Ни эшләтерләр икән аны? Бер караганда алай зурлап куркырлык сәбәбе дә юк кебек инде кебеген... Шулай да...

Әһә, план мәсьәләсен хәл иткәннәр булса кирәк, әнә бюро членнарының берсе — унынчы класс укучысы — ишектән башын тыгып Равилгә кул изәде.

Равил бүлмәгә кереп, иң арттагы партага утырмакчы иде, комсомол комитеты секретаре Әнәс Килдеков — теге чакта Равилнең тешен сындырган Әнәс! — үзләре янына өстәл тирәсенәрәк утырырга кушты. Аннары ул алдында яткан кәгазьләрне читкәрәк этәрде дә аягүрә басты. Тамагын кырып куйды. Башын чөеп, кара бөдрә чәчләрен сыпырган булып, ә асылда исә сүзен ничек итеп тәэсирлерәк башлау турында уйланып, түшәмгә текәлде. Шул чакта ишек ачылды, һәм, Килдековтан рөхсәт сорап, мәктәп партоешма секретаре, Равилләрнең класс җитәкчесе Суфия Гайнетдиновна килеп керде. Аның кайсы якны яклаячагы билгеле булмаса да, ул кергәч Равилгә җиңелрәк булып китте.

Үзе кергәч ничектер каушабрак калган Әнәскә Суфия Гайнетдиновна «дәвам итегез» дигәнне аңлатып ым какты һәм Әнәс сүзгә кереште:

— Безнең алда, иптәшләр,— диде ул,— хәзер бик ямьсез мәсьәлә тора. Файдалы эшкә кулланасы кыйммәтле вакытыбызны сигезенче «б» ның комсоргы Назмутдинов Равилнең персональ эшен тикшерүгә әрәм итәргә мәҗбүрбез. И вот ни өчен шулай килеп чыкты, иптәшләр: соңгы вакытта комсомолец Назмутдиновның тәртибе бик каты бозылды. Бу каян күренә — хәзер мин сезгә сөйлим...

Китте шуннан, китте шуннан Равилнең кайда, ничек комсомол исеменә тап төшергәннәрен санап! Узган дүшәмбедә дәрескә бер сәгать соңга калып килүен дә, бер көнне бөтен класс тригонометриядән мәсьәлә чишеп утырганда кычкырып җырлап җибәрүен дә, тарих дәресендә укытучы Абдулла Мифтахычны сораулар биреп йөдәтүен дә, татар теле укытучысы: «Такташның «Җир безнеке булыр. Ачулансак, шлем кигертербез айга да» дигән шигъри юллары космополитизм рухы белән сугарылган»,— дигәч, «Юк, апа, Такташ дөрес язган, менә күрерсез әле, озакламый аның хыялы чынга ашачак!» — дип кычкырып, галимнәр тарафыннан әйтелгән һәм дәреслектә басылып чыккан фикергә каршы килүен дә; психология укытучысы Нәҗия Гобәевнаны бөтен класс алдында хур итүен дә бик җентекләп, иренмичә сөйләп чыкты.

Өстән караганда Килдеков сөйләгәннәр барысы да дөрес иде. Тик шунысы бик гаҗәп тоелды Равилгә: Килдеков аның бер генә гөнаһсын да калдырмый санап чыкса да, теге чакта Рухиянең биленнән оятсыз рәвештә тотканы өчен, Килдековның яңагыннан ут чыгарганын әйтергә никтер онытты. Анысын да әйткән булса, Равил аңа бирәчәк җавабын да әзерләп куйган иде: «Син ул чакта үзеңә эләктергән өчен рәхмәт кенә әйтергә тиешсең миңа, Әнәс. Әгәр шул вакытта мин акылга утыртмаган булсам, бүген менә монда комсомол комитеты секретаре булып, мине тикшереп утырулар тәтемәячәк иде сиңа. Утырырга туры килсә

дә анда, өстәл артында, мине гаепләүче булып түгел, менә монда, парта арасында, үзең гаепләнүче булып кына утырган булыр идең!» — дип әйтмәкче иде.

Дөресе дә шулай иде шул аның. Равил теге чакта әзрәк «майлап» алганнан ары бик нык үзгәрде Килдеков. Яхшы якка үзгәрде. Ләкин, шулай булуга да карамастан, Равил фикеренчә, мәктәп комсомол комитеты секретаре булырга ук лаеклы кеше түгел иде ул. Укулары ягыннан булсын, тәртибе, кешелеге ягыннан булсын, Килдековтан күп тапкыр лаеклырак комсомоллар бар иде алар мәктәбендә. Әнәснең башкалардан өстенлеге тик шунда гына: ул русчаны бик шәп белә һәм җыелышларда, юк кына нәрсәләрне дә зур итеп күтәреп чыгып, озаклап сөйли ала.

— Я, иптәшләр, — диде Әнәс, Равилне «бөтереп салганнан соң» бюро членнарына мөрәҗәгать итеп. — Тагын кем сүләмә кели?

Башлап Рухия сөйләр шикеллерәк тоелган иде Равилгә. Чөнки менә шушы бюрода утыручылар арасында Равилне иң яхшы белүче кеше Рухия бит. Шуңа күрә, яклап ук булмаса да, һич югында, минем өчен азрак аптырап-борчылып башта ул сөйли башлар дип көтте Равил. Аннары Рухия, гомумән, сүз эзләп күршегә кергә торганнардан түгел. Килдеков кебек үк атлыгып тормаса да, җыелышларда шактый еш, шома сөйли һәм активлар чутында йөри торган кыз иде.

Тик бүген ул сүз алырга ашыкмады. Киресенчә, миңа сүз бирмәсәләр генә ярар иде дигән сыман, башын аска иде. Башкалар арасыннан да сөйләргә теләүче күренмәде.

Килдеков тагын бер кат «пожалуйста, кем сүләмә кели?» дип әйтеп карады. Ләкин бюро членнарыннан берсе дә кузгалмады. Башкалар өчен дә, Равил өчен дә авыр, уңайсыз минутлар иде бу. Шул киеренке тынлыктан класс җитәкчесе Суфия Гайнетдиновна коткарды:

— Бәлки Нәҗметдиновның үзенә сүз бирергә кирәктер, — диде ул. — Әйдә, Равил, аңлат бюрога: нигә шулай комсомолга хас булмаганча тота башладың син үзеңне?

Бюро членнары да, аның фикеренә кушылуларын белдереп, авыз эчләреннән мыгырданышып куйдылар.

— Сүз бирелә Назмутдиновка! — диде Килдеков, эчке бер канәгатьлек белән.

Тегенең сүзен бөтенләй ишетмәгәндәй, Равил кымшанмыйча да утыра бирде. Шуннан да яхшысы юк иде аңа бу очракта. Әнә бит Килдеков аның никадәр гаебен фаш итте. Адвокат яллап яклатсаң да акланып булырлык түгел!

Дөрес, дүшәмбе көнне дәрескә соңарып килүенең сәбәбе бар иде барын. Кар яуганнан бирле Равил Чүкәйгә олы, әйләнеч юлдан түгел, турыдан, үзе салган эздән генә барып-кайтып йөри иде. Үткән дүшәмбе көнне дә әнә шул үз юлы белән мәктәпкә барышлый ап-ак һәм типтигез кар өстендә бүрек сыман булып күпереп торган саргылт кар өеме күзенә чалынды аның. Нәрсә икән ул, дип кызыксынып, шул саргылт өемнең янына барып җитүе булды, чак кына аркан авып китмичә калды. Теге өем йомарланып йоклап яткан куян булган икән. Равил килгәч куян, куркып уянып, үзен-үзе ике-өч метр читкә ыргытты һәм, озын колакларын сыртына салып, күз ачып йомганчы юкка да чыкты.

Ярый, булган беткән, шуннан соң үз юлы белән китеп кенә барасы иде бит инде Равилгә. Ләкин күрәчәк күз йомдыра икән шул. Әгәр куян бик каты курыкса, озак яши алмый, йөрәге ярылып үлә икән, дип сөйләгәнне ишеткәне бар иде Равилнең. Кем сөйләгәне дә хәтерендә: әлеге шул «Ашыгыч ярдәм» — Йосыф абый сүзләре иде бу. Менә шул исенә килеп төште дә, туктале, үлә башласа ул җан биргәнче суеп өлгерермен дә башта, мәктәпкә алып барып, үзем куып тоттым дип

бераз шыттырып, Рухияне шаккаттырырмын, аннары, өйгә алып кайтып, әнигә куян бәлеше пешертермен, дип өметләнеп, тегенең эзе буйлап куа китте. Биш-алты километр чамасы артыннан йөгереп тә карады. Әмма куян-таш йөрәкнең үләргә һич тә исәбе юк иде. Равил якынайганчы ял итеп, озын колакларын тырпайтып утырып тора да, йөз илле, ике йөз метр ара калгач, тагын сыпырта иде ул.

Әнә шул имансыз куян артыннан йөреп бер сәгатькә дәрескә соңарды ул көнне Равил. Куян качты да котылды. Ә Равилне эләктерделәр менә...

Тригонометрия дәресендә җырлап җибәрүе дә ялгыш кына килеп чыккан иде. Бөтен класс, дөньяларын онытып, мәсьәлә чишә. Каләм кыштырдавыннан һәм классташларының ара-тирә көрсенешеп, борыннарын тартып куюларыннан башка, шылт иткән тавыш та юк. Укытучы Сөләйман Габдуллыч та үз эше белән мәшгуль: акрын гына атлап, укучыларның мәсьәләне ничек чишүләрен күзәтеп, парта араларында йөри. Ә Равилгә күңелсез. Чөнки ул классташлары чишеп азаплана торган әлеге мәсьәләне кичә кичтән үк чишеп куйган иде инде. Гомумән гадәте шундый аның: алдагы дәрестә үтелергә тиешле физика законнарын, математик теоремаларны һәм шуларга нигезләнгән мәсьәләләрне үзлегеннән эшләп куярга ярата. Ә менә шул хәлне Габдуллыч нигәдер бик үк ошатып бетерми. Үзе аңлатканчы ук Равил белеп барганга хәтере каладырмы, әллә гомумән Равилне яратмый торгандырмы — анысын әйтүе кыен. Ләкин шунысы көн кебек ачык: гел Равилгә бәйләнергә генә тора. Үзе инде кичтән үк чишеп куйган мәсьәләне иптәшләре әле яңа гына чишеп азапланганда, тик утырганчы эш булыр ичмаса дип, берәр язучының романын яки повестен укый башладымы, Габдуллыч шыпырт кына килеп җитә дә, китабын алып китеп, болай да буаз сыер шикелле күбенеп торган, почмакларындагы калайларына тикле кубып беткән котсыз портфеленә тыгып куя.

Әле Килдеков искә алып киткән көнне дә шулайрак килеп чыкты. Парта астында гына тотып, Равил Пушкинның «Капитан кызы»н укый башлаган иде. Ләкин ике-өч минут үтүгә Габдуллыч йомылып кына килде дә аның китабын тартып алып та китте.

«Капитан кызы»ннан да мәхрүм калгач, тагын шул эше юклыктан аптырап, Равил тәрәзәгә боздан ясалган бизәкләргә карап утыра башлады. Башка кешеләргә ничектер, әмма җентекләбрәк карап торган чакларында Равилгә тәрәзәдәге бозда әллә нинди сурәтләр күренә башлый. Ә ул көнне тәрәзәгә ап-ак чәчәккә күмелеп утырган шомырт агачы рәсеме ясалган иде.

Әнә шул шомырт чәчәкләренә карап утыра торгач, Равил күз алдына искиткеч җылы, кояшлы һәм хуш исле май көне килеп басты. Аннары ул Рухия белән шул ап-ак шомырт чәчәгенә күмелеп утырган урманга кереп китте. Агачларда да чәчәк, җирдә дә чәчәк иде урманда. Бөтен дөньяга сулап туймаслык хуш исләр таралган. Шул хозурлыкка, шул матурлыкка куанышып кошлар сайраша. Башта әкрен генә, тыелыбрак кына сайрыйлар. Аннары тавышлары һаман көчәя, ачыла бара һәм тоташ бер симфониягә әверелә... Юк, симфония генә дә түгел ул. Симфониягә аңа дирижер җитәкчелек итә диләр бит. Ә аның ничек дирижерлык итүе төрле шартларга һәм үз кәефенә бәйле була. Монда исә табигать үзе дирижер! Ул беркайчан да алдашуга, ялгышуга юл куймый. Кәефе дә һәр вакыт яхшы аның. Барча җан иясен тигез күрә ул. Шуңа аның җырында бернинди ясалмалык юк. Ихтимал, менә шушы гомеренә бер елмая белмәс Габдуллыч та аз булса да тоя торгандыр әле аның тәэсирен...

Чәчәкләр исенә исереп, кошлар сайрашуына хәйран калып, Рухиясе белән җитәкләшеп бара торгач, дәрестә утыруын бөтенләй онытып, үзе дә сизмәстән җырлап җибәргән иде ул көнне Равил. Бары тик шул

гына иде аның сәбәбе. Килдеков әйткәнчә, һич тә «аңлы рәвештә тәртип бозып» утыру түгел иде аның уенда!..

Тарих укытучысы Абдулла Мифтахычка биргән сораулары да аны хөрмәт итмәүдән түгел, бабаларыбызның элек ничек яшәгәнлекләрен тирәнрәк, ачыграк белергә омтылудан гына иде. Такташның космополитлыгы мәсьәләсенә дә совет галимнәренә ачу итеп түгел, бәлки үзенең йөрәк кушуы буенча гына каршы чыккан иде. Психология укытучысы Нажия Гобәевнага шулай ук бернинди дә үче юк иде Равилнең. Хикмәт бары тик шунда, ул укытучы үзен бик тә белдеклегә саный, бик игътибарлы булып кылана, бер карау белән теләсә кайсы укучының нәрсә уйлаганын белеп алам, дип сөйли, класстагы барлык укучыларны исә игътибарсызга һәм бик тә инде наданга исәпли иде. Ә Равилнең гадәте шундый: кеше сөйләгән сүзләрнең барысына да шундук ышанып житә алмый. Кайчакта хәтта укытучы сүзенә дә. Гөнаһ шомлыгына каршы, Нажия Гобәевна сүзләренә дә бик үк ышанып бетмәде ул һәм, аның ни дәрәҗәдә игътибарлы икәнлеген үзе тикшереп карарга булып, бер көнне ул дәрескә керергә тиешле тәнәфестә укытучы урындыгына акбур кисәге куйды.

Нажия Гобәевна дәрескә кереп, класс белән исәнләште дә, берни абайламыйча, теге урындыкка килеп утырды. Укучылардан алдагы дәрестә биреп җибәрелгән материалны сөйләтте. Аннары урыныннан купты да, такта янында арлы-бирле йөреп, яңа материалны аңлата башлады. Аның кара йон юбкасының арты ап-ак иде.

Менә шул хәлне күреп, бөтен класс башта елмаеп кына, аннары кычкырып ук көләргә тотынды. Үзенең акыллы һәм кызык итеп сөйләвеннән көләләр дип уйлады булса кирәк, Нажия Гобәевна башта артык игътибар итмәде. Киресенчә, рухланыбрак, кычкырыбрак кына сөйли башлады. Класс әле һаман көлүен дәвам иткәч, житәр дигәнне аңлатып, тавышын калынайтты. Ләкин башка вакытта аның шул кисәтүен сизеп, тып-тын булып кала торган класс бу юлы тыела алмады. Ә Нажия Гобәевнаның муен тамырлары һаман юаная, бит алмалары күзгә күренеп агара барды һәм ул, ниһаять, «шартлады»; сөйләп торган җиреннән кырт туктады да, Равилгә текәлеп һәм күзләрен калайландырып:

— Нигә шушылай ыржаеша бу класс, комсорг? Кайда аю биетәләр? — диде.

Бик каты кычкырырга теләп әйтсә дә, артык нык ачулы булганлыктан, аның тавышы нечкә һәм хәлсез килеп чыкты. Класс тагын да ныграк кычкырып көлеп җибәрде. Башка вакытта да бик кызу, нервлы Нажия Гобәевна, эшләр болайга ук киткәч, түзә алмады: соравына Равил җавап биргәнне дә көтеп тормастан, пыр тузып класстан чыгып китте. Әгәр аз гына сабыр иткән булса, Равил аңа, әлеге көлкегә үзе сәбәпче икәнлеген әйтеп, мәсьәләне аңлатып бирмәкче һәм гафу үтенмәкче иде. Ләкин соң иде шул инде...

Равил әнә шулай уеннан уймак чыгарып ташлавына үкенеп утырганда, укыту мөдире Наталья Георгиевнаны ияртеп, Нажия Гобәевна әйләнеп тә керде. Шуннан соң Равилне тәнәфестә тагын Хәнифә Вәлиулловна кабинетына чакырттылар...

— Я, Нәжметдинов, көтәбез сине! — диде Суфия Гайнетдиновна әле һаман да кымшанмыйча утырган Равилгә. — Аңлат бюро членнарына: ничек итеп шушы тәртипсезлекләрне эшләүгә барып җиттең?

Мондый чакта, житмәсә тагын Рухия дә карап торганда, акланырга азапланy егетлек булмас иде, әлбәттә. Шуңа күрә Равил кырмыска оясына таяк тыгып тормаска — сүз озайтмаска булды.

— Мин гаепле, иптәшләр! — диде ул. — Килдеков сөйләгәннәрнең бөтенесе үк булмаса да, күбесе дөреслеккә туры килә. Ләкин болар берсе дә Килдеков әйткәнчә дошманлык нияте белән эшләнгән нәрсәләр түгел! Уйлап житкермәвем аркасында, ялгыш кына килеп чыккан нәр-

сәләр... Мин үземне акларга җыенмыйм. Нинди җәза бирсәгез дә риза, тик мине комсомолдан гына чыгармагыз? Ышаныгыз, киләчәктә беркайчан да мондый юләрлекләрне эшләмәм, комсомол исеменә тап төшермәм.

«Син бит инде бала түгел, Нәҗметдинов, класста иң олы укучы, комсорг, бүтәннәргә үрнәк булырга тиешле кеше, ә син үзең башлап тәртип бозып йөрисең», — дип, Равилне бюро членнары нык кына кыздырдылар. Ләкин Килдековның комсомолдан чыгарырга, мәктәптән куарга дигән фикерен берсе дә якламады. Суфия апа да:

— Эшне алай ук зурга җибәрергә кирәкмәстер. Минемчә, Нәҗметдинов алай ук ышанычсыз укучы түгел, биргән сүзендә торыр,— дип сөйләгәннән соң ары Равилгә каты шелтә бирү белән генә чикләнделәр.

Дөрес, монысы да кечкенә җәза түгел иде түгелен. Ләкин монысына гына түзәргә була, монысы ул тикле үк куркыныч түгел иде инде.

## 20

Бюро утырышы тәмамланганда караңгы төшкән иде. Равил башкалардан алданрак чыкты да, чаңгы бауларын рәтләгән булып, мәктәп ишеге төбендә Рухияне көтә башлады. Шунда аны ялгызын гына туры китереп, Әнәс сөйләгәннәргә карап, минем турыда син дә начар уйлый күрмә тагын, мин ул әйткәнчә явыз кеше түгел, Рухия, дип әйтмәкче иде ул. Аннары, әгәр йөрәге җитсә, соңгы вакытларда син нигәдер миннән читләшә башладың, кызый, алай итмә, әйдә, көз көне теге имән төбендә дәрес әзерләнеп йөргән чаклардагыча үзара дус булыйк, яме, дияргә дә ниятләгән иде.

Әмма аның бу ниятенә дә тормышка ашу насыйп булмаган икән. Кыз ялгызы гына түгел, буш мәктәп залын яңгыратып көлә-көлә, Килдеков белән бергә чыгып килә иде. Ә иң яманы шул: Килдеков Рухияне култыклап ук алган иде. Бу хәлне күргәч, Равилнең аяк астындагы җирләр чайкалып киткәндәй булды. Ләкин ул сер бирергә теләмәде: тегеләрне күрмәгәнгә салышып, чаңгы бавына тотынды. Шул арада сизеп калды: Рухия дә, секундның меңнән бер өлешендә генә булса да, каушап-сискәнеп китте. Әмма шундук ясалма елмаеп һәм Равил өчен борчылган атлы булып:

— Бәй, Нәҗметдинов, нишләвең бу? Әллә төнгә каршы авылыгызга кайтырга җыенасыңмы? — диде.

Равил дәшмәде. Рухиянең Килдековка култыклатып чыгып килүенә шул тикле хәтере калган — сүз әйтерлек хәле дә юк иде. Аның үпкәле карашын сизенеп булса кирәк, Рухия:

— Ни булды сиңа, Нәҗметдинов? Нигә болай төсең китте? — дип, аптыраган кыяфәт белән Равилгә таба омтыла башлаган иде, ләкин Килдеков ирек бирмәде:

— Мешайть итмә кешегә, Рухия, адә! — диде дә, култыклаган хәлендә җилтерәтеп, кызны алып чыгып китте.

Бер Рухия генә шушылай кыйбласыз, аумакаймы, әллә кызларның бөтенесе дә бер чыбыктан сөрелгән микән?... Әле кайчан гына мәктәптән бергә кайткан чакларында сүз иярә сүз чыкканда Килдековны бер дә алай мактамый торган иде ләбаса шушы кызый. Мактанчык, гербиян, эгоист кына дип җибәрә торган иде. Ә хәзер, әнә, Килдеков аны мәктәп ихатасының аргы почмагына — интернат ишеге төбенә кадәр үк илтеп куйды. Әнә, һаман китәргә җыенмый әле: сөйләнеп торган була! Ә Рухиясе чырык-чырык көлә, шул буш бугазның буш сүзләрен рәхәтләнеп тыңлап тора. Болай булгач теге Эшләпә белән дә шушылай кылана торгандыр бу, мөгаен. Узган Октябрь бәйрәме кичендә Равилне бик ансат кына калдырып китүе дә тикмәгә генә булмаган, күрәсең! Ул чак-

тагы хәлләрне Килдековка да, мөгаен, шушы кызый сөйләгәндер әле. Уйландыра торган хәлләр бар монда, бар!..

Әй, кадалып китсеннәр лә! Аларның кыланышларын үз күзе белән күреп калуы әйбәт булды әле. Акыллырак булыр Равил киләчәктә. Югыйсә, Рухия дә Рухия дип, шул аумакайны изге фәрештә итеп күреп, тәки авызын ачып йөргән булыр иде...

Тегеләргә ачуы чыкканга гына игътибар итмәгән икән: азрак тынычланып, кайтырга дип чаңгыларын кия башлагач, бик нык буранлап тора булып чыкты. Җиле дә шәп иде. Дөнья бүген аеруча караңгы һәм шомлы сыман тоелды Равилгә. Барыннан да хәтәррәге шул: җил бер юнәлештән генә исми. Әле бер яктан, әле икенче яктан китереп бәреп, выж да выж сызгырып, уйнаклап тора. Мондый чакта сигез километрдагы Ташый елгага кайту — уен түгел. Бер кирегә китсә — гел кирегә тәгәри икән шул адәм баласының эшләре. Тәкә Әнәснең бюро утырышын шушылай соң уткәрүен кара инде син. Беренче смена дәресләре бетүгә бюроны җыйган булса, Равил инде күптән Ташый елгасына кайтып җиткән булыр иде...

Равил басу капкасын чыккач, буран отыры нык котыра башлады. Вакыт-вакыт шундый итеп дулатып җибәрә — күз ачарга да мөмкинлек юк! Ә кайтмыйча ярамый Равилгә. Мондый ямьсез чакта түгел, җилсез, аяз көннәрдә аз гына соңгарса да ут йотып тора әнисе. Ә бу мәхшәрдә кайтмыйча калса — бөтенләй тилегә сабышуы бар!..

## 21

Әйләнечрәк булса да, ышанычлырак булыр дип, Равил олы юлдан кайтырга чыккан иде. Барыбер файдасы булмады: Чүкәй фермаларын үтеп бер-әр километр бару белән юлдан язды. Себертеп тору өстенә, күктән дә ишеп яуганлыктан, кар юлны бөтенләй күмеп киткән иде. Күрә торып үлемгә барып булмый инде, юлны таба алсам кире Чүкәйгә генә кайтырмын, дип әллә ни гомер эзләп караса да, юк, тәки таба алмады Равил юл катысын. Җиле дә тәртипсез искәнлектән Чүкәйнең кай якта калганын да чамалавы кыен иде.

Чүкәйгә кире кайтудан өметен өзгәч, ни булса — шул дип, чамалап кына авыллары ягына таба атлый башлады ул. Ләкин Ташый елга ул уйлаган якта булып чыкмады, ахрысы: инде дүрт-биш сәгать барган-дыр, кайтып җитә алганы юк әле. Кая ул сиңа кайтып җиту, хәтта Чүкәй белән Ташый елга арасындагы урманга да җитә алмады әле. Һәй, урманга житсә! Анда барып житсә, Ташый елгага күзен бәйләсәләр дә кайтыр иде.

Ичмаса, эт өргән тавыш ишетелмәсме дип, туктап-туктап тыңлап та карый Равил. Юк шул, җил улавыннан башка берни дә ишетелми. Берәр җирдә ут яктысы күренеп китмәсме дип, текәлеп-текәлеп тирә-якларына да карангалап бара — анысы да юк...

Арыды инде ул. Бик нык арыды. Аякларындагы чаңгыларын көч-хәл белән генә сөйрәп бара. Их, менә шушы йомшак кар өстенә сузылып ятасы иде дә, ярты гына сәгать булса да, хәл җыеп, черем итеп аласы иде... Ләкин юк, ярамый алай итәргә. Әнә, утыз бишенче елның кышында Равилнең этисе шул аз гына ял итәм дип карга ятып тору аркасында харап булган лабаса. Яткан да йоклап та киткән. Дөрес, иртән табып алып өйләренә китергәннәр аны китерүен. Тик эш узган булган шул инде. Кар өстендә төн кунганда тигән салкыннан мантый алмыйча, үпкә авыруыннан үлеп киткән ул бичаракай... Юк, этисе ялгышын кабатларга һич тә ярамый аңа!

Ярамый!..

Ярамый...

Әй, булсын иде хәзер бер чүмеч салкын су! Бөтен арыганнары онытылып, җаннары кинәнеп китәр иде Равилнең... Юк, бер чүмеч кенә җитмәс иде аңа! Бер чиләк эчәр иде ул хәзер. Әгәр туйганчы эчәргә мөмкинлек булса, тагын бер тәүлек адашып йөрсә дә бер сүз дә әйтмәс иде... Ә кар нәрсә ул?! Ике чиләк кар ашагандыр инде Равил, ләкин сусавының тамчы да басылганы юк әле...

Төтен исе дә килми, ичмаса. Берәр яктан төтен исе килсә, тотар иде дә шунда таба китәр иде Равил. Ә болай кая барганын шайтан белгәнме аның. Шулай ук бер урында озак басып торырга да ярамый: бик каты тирләгән бит ул — каны оешып, бөтенләй хәлсезләнеп китүе бар... Таң атарга ерак микән әле? Бик күп вакыт үтте бит инде ул юлга чыкканга... Шушылай бер дә юктан катып үләр микәнни инде ул?.. Юк, нишләп үлсен ди! Яшь әле ул. Тәкә Әнәсләргә, аумакай Рухияләргә үч итеп, дөньясын җимертеп яшәячәк әле Равил! Һәм моннан соң Рухияне бар дип тә белмәячәк. Булды! Җитте! Гарык! Моңарчы да шул анасының... тәти кызы Рухия дә Рухия дип, тинтәкләнеп күп йөрде инде ул! Ә Рухия, әнә, уйлап та бирмичә, Әнәс белән кылтыклашып йөри икән анда. Әйтәм аны соңгы вакытларда кылтаебрак киткән шикелле иде. Менә хикмәт нәрсәдә икән!.. Юк, бүтән әйләнеп тә карамаячак аңа Равил. Тик менә исән-сау өйләренә генә кайтып җитсен... Их, адашканнарга юл күрсәтүче Хозер Ильяс чын булсын да салкын су китереп бирсен иде хәзер! Яна бит эчкәйләре, ялкынсыз яна!..

Әһә, әнә, бер кара нәрсә күренә бит алда. Әнә, кыймылдый да үзе. Чү, монда таба килә ич ул! Атлы кеше түгел микән, әйдәле, егет, шуңа таба барып кара әле! Чанасына ук утыртмаса да, ичмаса, шуның эзеннән барырга булыр...

Юк, булмады. Янына барып җитәм дигәндә генә атлы тагын арырак күчте. Аннары бөтенләй күздән үк югалды. Равил өметен өзеп туктап калгач, тагын пәйда булды... Янына бара башлагач тагын юкка чыкты. Шулай да юк нәрсәгә алданып, өметләнеп гел алга баруның файдасы тиде: инде тәмам хәле бетеп, менә егылам, менә авам дип барганда ул бер салам эскертенә төртелде. Монысы тегеләре шикелле мираж гына түгел, бусы чын салам эскерте иде инде! Аруы да, тәкатьсез булып сусавы да онытылып китте Равилнең. «Ярый бу, ярый! — дип куанып куйды ул. Чаңгыларын салып, кар күмеп китмәсен өчен эскерт буендагы көрткә кадады да эскертнең җилгә аркан ягына чыкты. — Каяле, тикшереп карыйк әле, нәрсә саламы икән бу?.. Урра! Борчак саламы икән ләбаса! Шәп бу, бик шәп: борчак саламы җылырак та, йолкыр өчен ансатрак та булырга тиеш. Болай булгач үлми инде Равил. Яшь әле ул болай булгач! Салам эскертендә туңып үлгән кеше турында ишеткәне юк әле аның. Ә менә шушындый борчак саламы эскертендә яшәгән кешеләрне күргәне бар. Бер елны Ташый елга кырындагы шушындый эскерттә, әче суык январь аенда унлап чегән бер атна яшәп киттеләр. Зурлары гына түгел, балалары да бар иде, алар да катып үлмәде...

Эх, булсын иде хәзер Равилнең кесәсендә шырпы, ягып җибәрәсе иде дөрләтеп ут.

Шулай да Равилнең эшләр ярыйсы хәзер. Бер уч салам йолкып алган саен куышы тирәнәя бара. Ә менә әнисе ни хәлдә икән аның? Ул бичараның күзенә йокы керми инде бүген. Көткәндер-көткәндер дә, Равил һаман кайтмагач, каравылга үзе барырга мәҗбүр булгандыр инде. Бүген исән-сау шушы төнне үткәреп өйләренә кайтып җитә алса, үтерәбез дисәләр дә бүтән вакытта болай соңга калмас иде Равил.

Менә, менә, тырышкач була икән ләбаса! Рәхәтләнеп бер кеше керерлек ятарлык оя ясап куйды Равил. Кереп ятарга кирәк... Ихтимал, иртәгә бураны да басылыр. Басылмаса, көн яктырылгач ничек тә юлны табарга булыр әле...

## 22

Равил уянып эскерт куышыннан чыкканда буран басылган, җил тынган, ялтырап кояш чыккан һәм ул инде шактый югары күтәрелгән иде. «Кара ничек озак йокланган!» дип гаҗәпләнеп һәм, үзенең төнлә кая килеп тап булганын чамаларга теләп, куыштан чыгу белән сикереп тормакчы иде дә — булмады: сул аягының аны күтәреп торырлык хәле юк, әллә нишләп бөтенләй җансызланып калган иде. Йоклаганда җайсызрак калып оеды микәнни, дип кулы белән селкеткәләп-суккалап караса да, файдасы тимәде. «Өшеде үк микәнни?» — дип куркып куйды Равил. Ныклап ышкысаң, өшегәнне бетереп була икән, дигән сүзне исенә алып, аякларын бер-беренә ышкырга, бәргәләргә кереште. Тик барыбер сул аягына җан кермәде. Ә уңы ут кебек кызып китеп, бик каты сызларга тотынды.

Хәзер инде болай утырудан мәгънә юк, ничек тә тизрәк кайту чарасына керешергә, ә иң элек аңа үзенең кайсы авыл кырында икәнлеген ачыкларга кирәк иде. Куыш буенда утырган килеш кенә, Равил тирәякны күзәтергә кереште. Башта аңа моннан бер-ике километрдагы зур гына бер әрәмәлек күренде. Үз колхозларыныкын гына түгел, күрше колхозларның кырларын да бик яхшы белә иде Равил: ат көткән вакытларында, көтүдән качкан яшь айгырларны эзләп, әллә кайларга барып чыккан чаклары булды. Әмма мондый әрәмәлекне һич тә очратканы юк иде! Әрәмәлекнең сул ягында тип-тигез кыр — кар диңгезе. Шул диңгез уртасында ябалдаш ботаклы ялгыз агач басып тора. Ул да Равилгә таныш түгел. Ә әрәмәлектән сулда шактый еракка сузылган калкулык. Аның битенә куак чыбыклары тараткannар — кар тоту өчендер инде. Андый җирләрне Равилнең шулай ук күргәне юк.

Ни эзләп тә үзенә таныш нәрсә таба алмагач, Равил мүкәләп эскерттән икенче ягына чыкты. Һәм шундук җиңел сулап куйды: эскерттән нибары йөз-йөз илле метрда гына маяклар күренә иде. «Димәк, анда юл булырга тиеш!» дип кычкырып ук җибәрде Равил. Ләкин кая бара торган юл — монысы аңа мәгълүм түгел иде әле. Хәер, барыбер берәр авылга алып барыр әле, дип үзен рухландырып, төнлә эскерт буена кадап куйган чаңгыларын алды да, йомшак карда батмас өчен шул чаңгыларын кулларына киеп, түше белән шуышып, юлга таба китте.

Башта хәйран тиз шуышты ул. Әмма юлга якынлашкан саен хәле кыенлаша барды: күрәсең, хәрәкәтләнә башлагач каны кызып, тәне җылынып киткәнгә булса кирәк, уң аягы тагын да ныграк сызларга тотынды. Юлга чыгып җитәргә нибары утыз-кырык метр калгач, тәкате тәмам төкәнеп, Равил туктарга мәҗбүр булды. Шунда аның миен куркыныч уй ярып үтте: «Булмый, исән-сау кайтып җитә алмыйм мин, болай булгач!» Ләкин күңеле бу ямьсез уй белән килешергә теләми иде. Бераз хәл алгач: «Үлә калсам да, юлга чыгып үләргә кирәк, югыйсә, гәүдәмне дә таба алмаслар» дип, актык көчен җыеп, ул тагын алга шуыша башлады. Ун-унбиш метр ара үткәч, тагын хәлсезләнеп туктапып калды. Шулай бераз яткач ат пошкырып куйган шикелле булды. Башын күтәреп караса — кар салган юлны ярып, чыннан да бер атлы кеше якынлашып килә иде. Шуны күреп алуы булды, бар көченә кычкырып та җибәрде:

— Э-һә-һә-һә-һәй! Э-э-эй!

Равилнең тавышын ишетте булса кирәк: теге кеше атын туктатты да, толып якасын төшереп, як-ягына карана башлады. Равил тагын кычкыргач, күреп алып, атын юыртып, аның турына килде. Ул кеше — мәктәп директоры Хәнифә Вәлиулловна иде.

— Нәҗметдинов?! Син ничек килеп чыктың монда? — диде директор, шаккатып.

— Кичә мәктәптән кайтышлый адаштым да әнә шунда кунарга туры килде, Хәнифә Вәлиулловна,— диде Равил, салам эскертенә күрсәтеп.— Аяклар әллә нишләгән минем, юлга чыга алмый азапланам әле менә.

Хәнифә Вәлиулловна чанасыннан сикереп төшеп атының башын каерып тартага бәйләде дә, билдән кар ерып, Равил янына килде.

Безнең директор сугышта булган кеше икән, дип классташлары сөйләнгәнне ишеткәне булса да, Равил моңа бик үк ышанып бетмәгән иде. Ни өчен дигәндә, Хәнифә Вәлиулловна сабыр, тәмле телле һәм йомшак күңелле кеше. Ә сугышта булган кеше алай ук йомшак күңелле була алмас, дип уйлый иде Равил. Ләкин классташларының сүзе хак булган булса кирәк: Хәнифә Вәлиулловна Равилне егетләрчә җиңел генә итеп, иңенә күтәреп юлга алып чыкты да җайлап кына чанасына китереп салды. Аннары Равилнең аякларын тоткалап карады. Бер дә аһ ормыйча гына:

— Өшегән болар, энем,— диде һәм, кичәге буран кар салганлыктан юл авыр булса да, атын юырттырып алып та китте.

Йомшак печән өстенә җайлап сузып салгач, уң аягының сызлавы кими төшкән шикелле булды. Ә сулы һаман берни тоймый, гел шулай җансыз иде. Шулай да, бәхетенә Хәнифә Вәлиулловна очраганга, юл буенда тилмереп ятарга туры килмәвенә куанычы зур иде Равилнең. Тик бер генә нәрсә күңелен кытыклап тора — директор үзен кая алып барганны белми иде ул.

— Бу кая бара торган юл, Хәнифә Вәлиулловна? — диде Равил, башта кыюсызланыбрак барса да, бераздан батыраеп китеп.

— Син үзеңнең кая килеп чыкканыңны да белмисеңмени әле, энем?..

Хәнифә Вәлиулловна мәсьәләне аңлатып биргәч, тәннәре чымырдап куйды Равилнең. Үткән төндә адашып йөри торгач, Чүкәйне читләтеп үтеп, авылларыннан бөтенләй кире якка киткән икән ләбаса ул! Чүкәйдән егерме өч километрдагы район үзәгенә барып җитә язган — нибары биш-алты километр гына калган икән бит!

— Ярый әле, эскерткә тап булгансың да, ярый әле, мине бүген роного чакырганнар! Югыйсә, белмим, нишләр идең икән,— диде Хәнифә Вәлиулловна, Равилнең ничек адашып йөргәнен җентекләп сорашкач, исе китеп.— Тик менә аягыңны гына саклый алмагансың. Син соң ул эскерткә башыңны тыгып яттыңмыни? Аякларың тышта калган идемени?

— Аякларны да җыеп, эчкә тыгып яткан булган идем, Хәнифә Вәлиулловна. Күрәсең, йоклаганда сузылып китеп тышка чыкканнардыр инде.

— Аякларыңны эчкә тыгып, башыңны күыш авызына куеп ятарга иде сиңа, энекәем!

— Анысы башка килмәгән шул, Хәнифә Вәлиулловна. Бик арыган идем.

Хәнифә Вәлиулловна Равилне туп-туры район больницасына илтте. Директорның анда да сүзе үтә икән: минут та көттермичә, ике ак халатлы хатын-кыз носилка тотып килеп чыктылар да, ай-ваена карамыйча, Равилне шуңа салып, бер бүлмәгә алып керделәр. Анда аны шулай ук ак халатлы ике ир һәм бер хатын-кыз көтеп торалар иде инде. Ирләрнең берсе — кечкенә, ябык гәүдәлесе — Равил янына килеп, аякларына йомшак кына кагылып карады да кашларын җыерып: «Так, понятно!» диде. Аннары алып кергән сестраларга Равилнең өстен чишендерергә, теге ир кешегә итекләрен ярып алырга кушты.

Тәнендә җаны була торып, өстен кешеләргә чишендертергә теләмәде Равил. Сырмасын үзе салып бирде, әтисеннән калган йон фуфайкасын да үзе салды. Итекләрен дә үзе салырга ниятләгән иде дә, ләкин тарта башлау белән йөрәгенә төшеп аягы сызларга тотынды. Шул ук вакытта

итекләрен куралатә ярдыру да бик кызганыч иде аңа: алары да әтисеннән калган һәм күз карасы кебек итеп саклап кия торган итекләр иде.

— Хәнифә Вәлиулловна! — диде ул, русча яхшылап белмәгәнлектән аңа мөрәҗәгать итеп,— әйтегез әле шуларга, ярмасыннар иде итекләрне! Авыртса авыртыр аяклар, тартып кына алсыннар иде.

Директор күрсәтмәләр биреп торучы бәләкәй врач янына килде дә пышылдап кына аңа нидер әйтте. Шуннан соң теге врач Равилнең итекләрен инде яра ук башлаган таза кешегә:

— Отставить! — диде һәм сестраларның берсенә Равилгә укол кадарга кушты.

Шуннан аны ни эшләткәннәрен һәм ул үзе ниләр кыланганын Равил белми...

## 23

Менә шул көннән бирле ята инде Равил больницада. Уналтынчы февральдә салганнар иде аны. Ә бүген инде бишенче март. Уң аягы соңрак, Равил уяныр алдыннанрак кына куыштан тышка чыккан булса кирәк — анысының өшүе артык зыянлы булмады. Берәр атна бик нык сызлап интектерде интектерүен. Әмма бер кат тиресе кубып, бармак тырнаклары төшкәннән соң ул кадәр үк борчымый инде хәзер. Ә менә сулының хәле мөшкел булып чыкты. Анысының бармакларын гына түгел, хәтта ярты табанын ук кисеп алырга туры килде. Дару белән өшеткәнгә булса кирәк, кискән чагында алай нык авыртмады үзе. Нәрсәдер кытыклаган сыманрак булып кына торды. Әмма өшетүе кайткач үзәкләрен өзде инде Равилнең! Хәзер дә туктаусыз сыкрап тора әле аның ул киселгән аягы. Операция ясаган баш врач — әлеге нәни гәүдәле Николай Иваныч әйтә:

— Молодец, энекәш, егет икәнсең! — ди.— Синең урында бүтән берәү булса операциядән соң дөнья бетереп акырган булыр иде. Ә синең тавышың да чыкмады,— ди.

Бик белеп тора Равил: үзе урынында башка кеше булса, бу хәйләкәр керәшен аңа да шулай дип әйтер иде. Һәркемгә шулай тәмле сүз табып, күңелен күтәрергә тырыша ул.

Равилгә операция ясаганнан соң Хәнифә Вәлиулловна тагын бер килеп китте. Әллә никадәр күчтәнәч китергән.

Теге чакта әнисенә дә Равилне больницага салган көнне үк хәлне ул аңлатып биргән. Әйләнеч була дип тормаган, кайтышлый ук Ташый елгага кагыла кайткан!

Равилнең әнисе икенче көнне иртүк килеп җитте. Башта улын кызганып елап җибәрде. Аннары, ярый әле, исән калгансың, яртысын киссәләр дә, ярты табаның бар бит әле, кайбер кешеләрнең ике аякларын тиң кисеп ташлыйлар, исән калуына шөкерана итик, дип үзен дә, Равилне дә юатып утырды.

Больницада озак ятарга туры килсә, миңа быел укырга да рөхсәт итмәсләр, имтиханнарга да кертмәсләр, тагын бер елым әрәм була инде, дип бик нык кайгырып тора иде Равил. Хәнифә Вәлиулловна ул яктан да тынычландырып китте. Шул ук көнне, каяндыр табып, сигезенче класс дәреслекләре һәм дәфтәрләр алып килеп бирде дә:

— Укый тор, энем! Күпме яткырсалар да аптырама! — диде.— Сиңа хәзер уку бүтән теләсә кемгә караганда да кирәгрәк булачак,— диде.

Шуннан бирле көннәр буе үзлегеннән укый башлады Равил. Һәм бу аңа әллә ни кыен да түгел. Физика белән математиканы моңарчы да укытучы аңлатканны көтеп тормыйча өйрәнеп бара иде бит ул. Ә тарихны, географияне һәм татар теле белән әдәбиятын кат-кат укый торгач, ничек тә имтихан тапшырырлык кына үзләштерер әле. Дөрес, бо-

лай да ташка үлчим генә белгәнлектән, рус телен һәм әдәбиятын нишләтермен инде дип борчылган иде ул борчылуын. Әмма тора-бара ул мәсьәлә дә хәл ителде: Равилнең бер үзенә бер укытучы хәзер! Үзе белән бер палатада ята торган авыру — Хатип Хәкимович бик теләп рус телен укыта аңа.

Гаҗәп кеше булып чыкты ул Хатип агай. Укытучы ук булмаса да, кайбер укытучыларны ишекле-түрле куып йөртерлек мәгълүматы бар икән аның. «Сугыш булмаган булса, — ди ул, — педагогия институтында укып чыгып, минем дә укытучы булырга иде исәп. Ну барып чыкмады — планнарны Гитлер бозды. Студент булып йөрисе елларны фашистлар тартып алды». Күрәсең, күңелендәге шул хыялын вакытлыча гына булса да тормышка ашкандай хис итмәкче булыптыр, Равилне чын укытучылар шикелле итеп укытырга тырыша ул. Башта больница телефоныннан әллә кемнәргә шалтыратып, татар мәктәпләре өчен рус теле һәм әдәбияты программасы таптырып китерттерде дә шуның буенча укытырга тотынган иде. Ләкин бер-ике көн үтү белән, аны ошатмыйча: «Монда сездән бик аз нәрсә таләп итәләр икән, ә мин сине по-настоящему русча укытырга телим»,— дип, рус мәктәпләре программасын китертеп, шуның буенча укыта башлады. Бу тикле дә иренмәс кеше булыр икән: дүртәр сәгать буена Равилгә грамматик кагыйдәләрне өйрәтеп, диктантлар, изложениеләр яздырып, аннары шуларны Равил белән бергәләп тикшереп утыра. Әдәбият программасы буенча өйрәнелергә тиешле әсәрләрне башта үзе кычкырып укып күрсәтә, аннары Равилгә укыттыра. Рус теле һәм әдәбияты «дәресләрендә» бер авыз сүзне дә татарча әйттерми. Равил ялгыш ычкындырса да, ишетмәгәнгә салыша. Рус сүзләрен дөрес әйтмәгән чакларында иплэп кенә үзе төзәтеп әйтеп күрсәтә. Ә инде больницада йокы сәгате җитеп, дежур сестра утны сүндереп чыгып киткәч исә русча сөйләргә керешә. Равил отып барсын өчен, һәр сүзен җиренә җиткереп, ашыкмыйча сөйли. Хатип абыйның сөйләве гадәттә үз башыннан үткәннәрне тасвирлауга кайтып кала. Ә аның башыннан шактый гыйбрәтле хәлләр узган заманында. Фашистларга каршы сугышның беренче көненнән алып соңгы көненә тикле гел фронтта, гел алгы сызыкта дошман белән көрәшеп йөргән ул. Дүрт тапкыр яраланып, госпитальдә ятып чыккан. Ике тапкыр чак кына әсирлеккә эләкмичә калган. Ач йөргән көннәре дә, атналар буена гел дөньядагы иң тәмле ризыкларны гына ашап, үзе әйтмешли, патшаларча яшәгән чаклары да булган. Рядовой солдаттан башлап, рота командиры дәрәҗәсенә тикле күтәрелгән. Равил карта буенча да юньләп белмәгән Европаның яртысыннан артыгын аркылы-буйлы йөреп чыккан. Ә үзе Равилдән нибары унбиш яшькә генә олы ул. Буй-сыны да бик мәһабәт Хатип абыйның. Төс-биткә дә тел тидерә торган түгел: үткен карасу-коңгырт күзләре, байтагы инде агарган коңгырт чәчләре һәм куе калын кашлары үзенә бик килешеп тора. Эш урыны да район җире өчен җитеп ашкан — милиция начальнигы. Кыскасы, Равилгә һич тә иптәш булырлык кеше түгел инде бер караганда. Ләкин менә шушы Хатип абыйсы беренче көннән үк шул тикле үз, шул тикле якын итте Равилне — әйтерсең алар арасында бернинди дә аерма юк, әйтерсең алар бертуган агай-энеләр!..

Баштарак Равилгә больницада үткән бер көн дә елга тиң булып тоела иде. Ә менә Хатип абый белән танышып киткәч һәм үзлегеннән укуын дәвам итә башлагач исә, киресенчә, көннәр озаюга таба барса да, кыска булып тоела аңа.

Тамчы таммаса да, бүген көн аеруча җылы булса кирәк: больница тәрәзәсенең кыш буе боз белән капланып торган пыялалары иртәдән үк күзгә күренеп эри башлады. Кояш югарырак күтәрелгән саен палата эче яктыра һәм тәрәзәдән күренгән манзара киңәя бара. Равил инде байтактан шул тәрәзә төбендә тышкы дөньяны күзәтеп утыра. Әнә,

больницадан ерак та түгел тау астында гына — Кама. Аның өстендәге кар, бихисап ак энҗеләр белән чигелгән йомшак юрган сыман, кояшта ялтырап, күзләрне чагылдыра. Кама өсте тип-тигез. Анда кеше эзләре дә, җанлек эзләре дә юк. Тик бер урында гына, әлеге энҗе белән чигелгән ак юрганны урталай ярып, саргылт тасма сузылган. Шул тасмадан сирәк-мирәк кенә атлылар һәм җәяүлеләр әле тегеякка, әле бу якка үткәләп тора. Ә Каманың аргы ягында офыкларга барып тоташкан урман һәм болыннар җәелеп ята. Их, китәсе иде чыгып, киясе иде чаңгы да әнә шул әлегә беркем дә аяк басмаган чиста, ак энҗеләр өстеннән аргы якка үтеп, шул урман буйларына барып, болыннарны урап кайтасы иде бер! Хәзер кар утыргандыр инде — чаңгы батмый торгандыр. Рәхәтләнеп, чыжлатып кына йөреп кайтыр иде Равил...

Шунысы гаҗәп: бар җире дә исән-сау булганда, кая тели — шунда бара алган чагында нигә бик гамьсез була икән бу адәм баласы?

Равилгә әле чыгып йөрергә рөхсәт ителми. Хәер, рөхсәт ителсә дә, чыгып йөри алырлык хәлдә түгел әле ул. Шуңа тормышны палатадагы менә шушы бердәнбер тәрәзә аша гына күзәтеп утырырга мәҗбүр. Хатип абыйның эшләре көйлерәк: ул аяклы авыру. Ашказанын «ремонтлатырга» кергән кеше генә. Аңа больница ихатасына чыгып йөрергә дә була.

Хатип абыйның Равилдән тагын бер өстен ягы бар: аңа көн саен хатыны, таныш-белешләре һәм үз кулы астында эшли торган хезмәттәшләре — милиционерлар килеп китмичә калмый. Буш кул белән дә килмиләр. Ә хатыны хәтта кай көннәрдә икешәр килә. Әнә хәзер дә берәрсе килгән булса кирәк — сестра тагын чакырып чыгарды үзен...

Ә Равил янына бер тапкыр әнисе, бер тапкыр Хәнифә Вәлиулловна килеп киткәннән бирле һичкем килгәне юк. Кем килсен соң аның янына? Кемгә хаҗәт, кеме бар аның бу райүзәктә? Ә авыллары — ерак. Шуңа моңарчы Равил үзе дә беркемне дә көтми, ял көннәрендә, бүтәннәр янына килгән кешеләрне күреп, йөрәген бозмас өчен, палатасыннан бөтенләй чыкмыйча укып ята торган иде. Әмма бүген, ике күзен дүрт итеп, классташларыннан берәрсе килүен көтә ул. Өченче көн мәктәптән — класс җитәкчесе Суфия Гайнетдиновнадан хат алды. Хатында Суфия апасы аңа, киләсе ялда класстан берәрсе синең янга барып та чыгар әле бәлки, дип язган. Дөрес, өзеп әйтмәгән, «бәлки» генә дип язган. Шулай да күнеле көтә бит Равилнең. Палата ишеге турыннан үтеп киткән кешеләрнең аяк тавышын ишетсә дә, йөрәге дерт итеп куя...

Килүен кем дә булса килер бәлки. Тик кем килер икән? Их, могҗиза булсын иде дә, гадәтенчә, дөньяларны балкытып, Рухия килеп керсен иде менә хәзер! Булыр иде дә соң ул чакта хәлләр! Әй, сөйләшеп тә карар иде Равил шул озын толымлы кара күзкәй белән!

## 24

Могҗиза, чыннан да, булды ул көнне. Тик Равил уйлаганча түгел, бөтенләй башка могҗиза иде бу.

Сәгать көндезге уникегә тикле көтеп тә килүче булмагач, киләсе кеше унберләрдән дә калмый инде ул, чөнки әйләнеп кайтасы да бар бит аның, дип, тәмам өметен өзеп, нәүмизләнеп койкасына барып яткан гына иде, дежур сестра — инде чәчләре агара башлаган Нина Сергеевна — килеп керде дә:

— Кыен булса да, коридорга чыкмыйча булмас сиңа, Нәҗметдинов, бер көтү кеше килгән анда, палатага гына сыярлык түгел! — диде.

Равил палата ишегеннән чыгуга, дәррәү килеп, классташлары аны урап та алдылар. Барысы унбер кеше иде алар.

— Нишләп болай көтүегез белән килдегез? — диде ул, куанычыннан әле һаман өненә килә алмыйча.

— Сине сагындык та килдек менә!

Моны Таня әйтте.

— Рәхмәт сезгә, дуслар! — дип кычкырып җибәрде Равил. — Кая, азрак кулларыгызны җылытыйм, ичмаса! — дип ашыга-ашыга барысы белән дә күрешеп чыкты. Шул чакта ул менә нәрсәгә игътибар итте: аның янына килгән классташларының унысы Чүкәйнең үзендә яшәүчеләр булып, чит авыллардан йөреп укучылардан тик бер Таня гына иде. «Чүкәйдән безнең класста барысы унбер кеше укый бит. Шуларның унысы монда. Ә кайсысы килмәгән икән соң?.. Әһә, Килдеков юк икән! Бик шәп, аның ишеләрнең килмәве хәерле,— дип уйлап алды Равил, тегеләр бер-берен бүлә-бүлә хәлен сорашкан арада. — Ә менә Таня молодец!.. Тукта, Таня килгән, ләкин Рухия юк. Нигә килмәде икән ул кызый? Бүтәннәр килмәгәндә дә ул килергә тиеш түгел идеме соң?..»

— Син ничек бу Чүкәйләргә ияреп йөрисең әле, Таня? Ялга авылыгызга кайтмадыңмыни? — дип сорады Равил.

Таняның нигә кайтмавы белән кызыксынудан бигрәк, Рухия турында берәр җылы сүз ишетүне өмет иткән иде ул.

— Сезне сагынган идем, Равил әфәнде, шуңа бу атнада өйгә кайтып тормадым. Ә нигә алай дип сорыйсыз әле? Сез галиҗәнабләргә комачауламыйммдыр бит? — диде кыз, гадәтенчә, драма әсәрләрендәге персонажларча сөйләшергә тырышып.

Җае чыгудан файдаланып, Равил Рухия турында җентекләбрәк сорашмакчы иде, ләкин классташлары алдында ул турыда сүз башларга йөрәге җитмәде. Ә тегеләр иң элек Равилнең ничек һәм кайда адашуын, ничек операция ясауларын, хәзер үзен ничек хис итүен бәйнә-бәйнә сораштылар. «Хәнифә Вәлиулловна, Нәҗметдинов анда укуын да дәвам итә әле, дигән иде. Эшләрең ничек бара соң, бик кыен түгелме?» дип кызыксындылар. «Шундый күз ачкысыз буранда төнгә каршы кайтырга чыгалармы соң инде? Теләсә кайсыбызның өенә кереп куна ала идең бит!» — дип, дусларча гына шелтәләп алдылар.

Беренче күрешкән минутлардагы ыгы-зыгылары тыйлыгып, классташлары бераз тынычланып калгач, Равил алардан мәктәптәге яңалыклар турында сораштырырга тотынды.

Равилнең классташлары мәктәп яңалыкларын сөйләп, көлешеп-шаярышып утырдылар. Алар әле тагын да утырган булырлар иде, ләкин һәр эштә тәртип ярата торган әлеге Нина Сергеевна килеп, Равилгә перевязкага барырга, ә иптәшләренә кайта башларга вакыт икәнлеген искәрткәч, тынып калырга мәҗбүр булдылар.

Иптәшләре китәргә кузгалгач, Равил Таняны бер читкә чакырып алды.

— Карале, Таня, ни... Рухия белдеме соң сезнең монда киләсен?

Таня Равилнең Рухиягә мөкиббән китеп йөрүен белә иде, әлбәттә. Белә һәм чак кына көнләшә дә иде бугай ул. Менә хәзер дә аны телгә алу белән дерт итеп китте. Йөзендәге елмаюы да, юып алгандай, кинәт юкка чыкты.

— Белде, ник белмәсен! — диде Таня, кемгәдер үпкәләгән сыман төксерәк итеп.

— Ә ул алай-болай киләм дип әйтмәдеме соң? — диде Равил, бер чирканчык алгач хәйран батыраеп китеп.

— Киләм дипме? Әйткән иде. Ләкин соңыннан, юк, булмый, бара алмыйм, бу ялда авылга кайтып килмәчә һич тә ярамый икән миңа, дип кире уйлады. Сиңа күп итеп сәлам тапшырырга кушты! Һәм син больницадан чыкканчы обязательно бер барып кайтам әле дип калды.

— Сәламен әйткәч, килеп йөрмәсә дә ярар инде,— диде Равил. Бер дә алай исе китмәгән булып күренергә тырышты.

Таняны алдап буламы соң? Ул кыз, хәйләкәр елмаеп:

— Нигә бер төрле уйлап, икенче төрле сөйләргә инде аны? Ярый, мин Рухиягә нәкъ менә синең сүзләреңне әйтермен, яме! — дип бармак янады да иптәшләре артыннан чыгып та йөгерде.

## 25

Аякларын бәйләтеп чыкканнан соң Равил тагын тәрәзә төбенә барып утырды. Рухия нәкъ менә бүген килер шикелле тоела иде аңа. Әгәр кызның килүен күреп алса, нык итеп сызгырып җибәреп, кул изәмәкче иде.

Шул өмет белән күз бәйләнә башлаганчы тәрәзә төбендә көтеп утырды ул. Аның әле һаман китәргә исәбе юк иде. Тик Хатип абыйсы, шактый кырыс итеп:

— Җитәр, егет, кит аннан, югыйсә, тилегә сабышуың мөмкин! — дигәч һәм: — Киләсе булса күптән килергә тиеш иде инде ул. Хатын-кызга бик үк ышанырга ярамый дип әйттем ич мин сиңа? — дип өстәп куйгач кына караватына барып ауарга мәҗбүр булды.

Катырак әйтеп ташлавына үкенеп һәм Равилнең нәүмизләнеп тынсыз-өнсез генә әчтән сызып ятуына борчылып булса кирәк, Хатип абый бераздан аның янына килеп утырды да үгетләргә тотынды:

— Аңлыйм мин синең хәлеңне, энекәем. Бик яхшы аңлыйм! Үзем дә кичергән мин мондый хәлләрне. Менә син хәзер уйлыйсың инде: миннән дә бәхетсез кеше юк бу дөньяда, дисең. Ни булды икән ул кызга? Миңа бары тик классташ кына булган бер көтү кеше үз теләкләре белән якын итеп килгәндә нигә ул килмәде икән, дисең. Ә аның нигә килмәвен мин бик яхшы сизеп торам. Әйткән идең бит әле, адашасы кичендә мәктәптән комсомол секретаре белән култыклашып чыгып китте дип. Димәк, шул егет үзенә каратып өлгергән инде аны! Ә хатын-кызлар шулай: кем дә булса аларның башын әйләндергән икән, кем дә булса аларга ошап куйган икән — башта алар ул кешегә эттән дә турылыклырак булалар. Бәлки ул кызың синең янга килергә дә теләгәндер, ләкин теге егеткә турылыклы булып калу өчен, соңыннан килмәскә булгандыр.

— Җитәр инде, Хатип абый! Болай да янган йөрәккә нигә бензин сибәсез? — диде Равил, чын-чынлап үпкәләп. Һәм ул үзенең беркемгә дә сөйләгәне булмаган иң яшерен серләрен шушы пеләш башлы, ак чырайлы ябык кешегә сөйләп ташлавына үкенеп куйды. Үкенерлек тә иде шул. Равил бит аңа якын итеп кенә серен ачкан иде. Ә ул, кара, ни кылана? Чак кына берәр нәрсә булдымы, хәзер килеп җитә дә, хатын-кызларны яманларга, Равилнең болай да иләс-миләс күңеленә вәсвәсә салырга тотына.

Ләкин Хатип абыйның туктар чамасы юк иде әле:

— Менә-менә! — диде ул, Равилнең хәтере калуга һич тә аптырамыйча. — Мин дә сиңа нәкъ шул сүзләрне әйтергә тора идем, энекәш: әйе, җитәр! Дөньяның кендеге шул бер кызга гына барып тоташмагандыр. Башта гына шулай авыр булып тоела ул, энекәш. Соңыннан үтә, онытыла. Төкер син аңа? Хәзер генә түгел, больницадан чыккач та аның турында уйлама. Уйласаң да тыштан сер бирмә. Бөтенләй исең китмәгән атлы булып йөр. И-и, җүләр, хатын-кыз кавемен беләм инде мин! Әгәр синең чынлап яратуыңны сизеп алсалар — хәзер хан кызына әйләнәләр дә борыннарын күккә чөя алар. Әгәр дә инде син артык исең китмәгәнгә салышсаң — үзләре синең тирәңдә кырыкка бөтерелеп йөриләр. Беләм инде мин аларны! Ә син нык бул, бирешмә!

## 26

Равилнең шикләнүе нигезле булган икән. Больницадан чыгып укырга килгәч, беренче дәрестә үк Таня аңа менә шушы язуны язып бирде: «Рухия дип авыз суыгыз коруын беләм, Равил әфәнде. Соңыннан андыймондый күңелсезлек килеп чыкмасын өчен, шуңа алдан ук сезне кисәтеп куюны кирәк дип саныйм. Сез больницада яткан арада Рухия туташыбыз Килдеков Әнәс галиҗәнабләре белән бик тыгыз дипломатик мөнәсәбәт урнаштырды. Сак булыгыз, араларына кереп, тагын бер тешегездән мәхрүм кала күрмәгез. Сезнең яшьтә яңа теш үсми диләр. Ә яңа мәхәббәт туарга бик мөмкин».

Дөресен генә әйткәндә, бу хәбәр Равил өчен әллә ни зур яңалык түгел иде. Шулайрак буласын үзе дә сизенгән иде бит ул. Әмма эшләр менә шушылай бөтен мәктәпкә мәгълүм булуга (Таняга мәгълүм булган нәрсә — бөтен мәктәпкә билгеле дигән сүз!) кадәр үк барып җиткәндер дип башына да китермәгән иде.

— Кисәтеп куюың өчен рәхмәт, Таня! — диде Равил, тәнәфескә чыккач. — Ләкин миңа аларның кирәге бер тиен. Минем тик шуны гына беләсем килә: элемтәләре ничек алып барыла соң аларның? Хат ашамы, сөйләшүләр аркылымы?

— Гафу итегез, Равил әфәнде, мин гайбәтче дә, шымчы да түгел. Боларын да сезгә яхшылык теләүче буларак кына әйтеп куярга кирәк дип таптым. Калганын үзегез карарсыз инде. Кирәк тапсагыз, әлбәттә.

Шулай диде дә, хәйләкәр елмаеп, класска кереп китте.

Тиздән ул мәсьәлә дә ачыкланды. «Дипломатик мөнәсәбәтләрен» дәрес барышында хат аша тормышка ашыра икән тегеләр. Равил бик яхшы күреп тора: алты сәгать укыган көнне Килдеков Рухиягә сигезәр хат язып бирә. Тегесе аңа ике генә мәртәбә җавап бирә бирүен. Ләкин хикмәт андамыни!

Тора-бара тагын шунысын да тәгаенләде Равил: тегеләрнең элемтәчесе әлеге сипкелле Вәсимә икән! Равил аны моңарчы тыйнак кына, акыллы гына кыз дип йөргән иде. Класста иң якын күргән кызларының берсе шул иде. Ә менә Әнәс белән Рухия арасында элемтәче вазыйфасын үтәвен һәм бик теләп үтәвен күргәч исә шундук күңеле кайтты. Астыртын, хөсетле һәм ышанычсыз кеше булып тоела башлады ул Равилгә.

## 27

Бер яктан, әнә шундый куштаннарга йөрәге сыкрый Равилнең, икенче яктан, аягының рәте юк. Больницадан соң нибары өч кенә көн кайта-килә йөргән иде, теге кисек аягы гөбе юанлыгы булып шешеп чыкты. Җәяү йөргәндә бер дә авыртыр төсле түгел иде. Итекләре дә, бик үк яңа булмаса да, йомшак, ипле һәм җылы иде. Күрәсең, Хәнифә Вәлиулловна телефон аша баш врач белән хәбәрләшеп, сорашып торган булгандыр: Равил больницадан чыгасы көнне, аны алмага мәктәп атын җиктереп завхозны җибәргән, итекне дә завхоз алып килгән иде. Ул итек Хәнифә Вәлиулловнаның сугышта вафат булган иренеке икән. Мәктәпкә кайткач, Равил аларны илтеп бирмәкче булган иде, ләкин директор авызын да ачтырмады:

— Мокаддәс абыең булмагач, аларны барыбер киюче кеше юк инде. Рәхәтләнеп киеп йөр,энем! — дип, бөтенләйгә Равилгә бирде.

Ләкин чаңгы киеп йөри башлагач, эшләре начарланды егетнең: аягын чаңгы бавы кыскан булырга кирәк. Хәзер инде кайта-килә йөрүне уйларга да ярамый иде. Чүкәйдә торып укырга шулай ук мөмкин түгел. Бердән, төнлә каравыл торасы бар. Болай да больницада айдан артык ятып чыккан кеше ич инде ул. Ул вакытта каравылга әнисе йөр-

гән иде Равилнең. Аны да гел көн-төн эшләтеп булмый бит инде. Аннары килеп, Чүкәйдә торып укый башласа, фатир хакы да түләргә, фатир хуҗасына кимендә бер кубометр утын илтеп бирергә дә кирәк булачак. Мәктәп интернаты кызлар өчен генә бит ул. Нәрсә белән түләсен ди Равил фатир хакын, кайдан алып китерсен ди утын?.. Ә укырга кирәк аңа! Хыянәтче Рухиягә (ул аны хәзер чыннан да хыянәтче дип саный), куштан Вәсимәгә һәм калай этәч Әнәскә ачу итеп, аларны көнләштерерлек итеп укырга кирәк аңа!..

Менә шуларны уйлады да тәвәккәлләп Фәйрүзә апасы янына идарәгә барды Равил. Үзеннән алда килгән кешеләр йомышларын йомышлап бетергәч, председательнең янына ук килде дә:

— Комсомолга керергә барганда ат бирмичә бер үтерә яздың инде, Фәйрүзә апа, ләкин бу юлы үтермә, зинһар! — диде. Аннары итеген салып, иләмсез юанаеп шешкәнлектән оекбашсыз гына кигән аягын күрсәтте. — Менә, Фәйрүзә апа, бу аяк белән кайта-килә укый алмыйм мин. Хәзер әллә ни кызу эш өсте түгел, шушы аякның шеше кайтканчы бер кырыкмыш тайга гына булса да атланып йөрим әле, ә?

Хәбир бабай әйтмешли, фәрештәләрнең амин дигән сәгатенә туры килдеме, әллә үзенең кәефе яхшы чак идеме — Фәйрүзә апасы аның хәлен бик тиз аңлап алды һәм күп сөйләшеп тормыйча гына:

— Булды, энем, әйдә, менә болай итәбез. Иртәгәдән Чүкәйгә ат җигеп йөри башла. Пушты Хисмәт картайды, хәтере бер дә юк, аның өчен мине гел тиргәп торалар, Чүкәйгә ат җигеп барасың, хатларны, газитләрне алып кайтасың. Сарык та исән, бүре дә тук дигәндәй, укуың да бара, авыл советыннан акча да аласың. Килештекме? Юллар өзелгәнче рәхәтләнеп чанага утырып йөр, юл өзелгәч, атланып йөрерсең.

— Ә почтаны кем тарата? Минем бит кеше саен кереп йөрергә вакыт юк, аяк та исән түгел.

— Анысын әниең таратыр. Я булмаса, өегезгә килеп алырлар.

Эшләр җайга китте Равилнең. Ялга каршы көннәрдә Укмас кызлары өчесе дә Равил атына утырып кайталар. Рухияне алмага атна саен әтисе килсә дә, ни хикмәттер, кыз әтисе атына түгел, Равил атына утырып кайта. Аның бу гадәтен Равил тычкан белән уйнаган мәчегә охшата: үзен тычкан, кызны мәче сыман хис итә. Шуңа күрә үзенә дә, Рухиягә дә ачуы килә. Ялга каршы көнне көн буе: бүген утыртып алып кайтмыйм мин аны, нигә шул хыянәтче белән бер чанада утырып йөрергә тиеш ди әле мин, дип күңеленнән бик нык этәчләнеп йөри. Ләкин Таня белән Вәсимәгә ияреп, гадәтенчә бөтен дөньяны балкытып, Рухия интернаттан килеп чыгуга — сары май күк эри дә китә Равилнең күңеле. Алдан әзерләп куйган сүзләрен бөтенләй оныта да, минем чанага утырса гына ярар иде, дип тели башлый.

Тимер артлы чанага җигелгән яхшы айгырын чаптырып, башта Рухиянең әтисе кайтып китә, аннары сәләмә атка җигелгән, урәчә баулары өзелеп, табаннары ашалып беткән сәләмә чанасына өч кыз төяп, Равил юлга чыга.

Кызлар өчесе дә юл буе көлешеп һәм җырлап кайталар. Узган көз җәяү кайткан чакларында да шулай җырлаштыргалый торган иде алар. Ул чакта Рухия Таня белән Вәсимә шикелле генә түгел, алардан йөз мәртәбә шәбрәк җырлый торган иде. Ә менә хәзер, Килдеков белән чуала башлаганнан бирле, нигәдер алай ук әйбәт булдыра алмый шикелле... Равил хәзер Рухиягә беркайчан да үзе башлап дәшми. Рухия сүз кушканда да «әйе», «юк» дип кыска гына җавап бирә. Хатип абый өйрәткәнчә, горур һәм бәйсез тотарга тырыша ул үзен. Шактый дөрес сөйләнгән икән теге Хатип абый. Равил шулай салкын һәм битараф мөнәсәбәт күрсәтә башлагач, Рухия аның тирәсендә бөтерчек урынына бөтерелә башлады. Шуңа кайчакларда Рухиягә ачуы да чыгып куя Равилнең...

Тик шулай да, махсус рәвештә кызын алмага килгән этисенең яхшы айгырына утырмыйча, Рухиянең сәләмә чанада, үз янында утырып кайтулары барыбер ошый аңа.

Әй, рәхәт иде дә соң ул чаклар, шайтан алгыры! Ләкин шунысы кызганыч булды: бәхетле көннәре озакка бармады.

Кашрак җирләр азрак кибә башлау белән колхозларда җиң сызганып язгы кыр эшләренә тотындылар. Мондый чакта Равил үзе дә бер башы бер атка атланып йөрергә оялыр иде, әлбәттә.. Ләкин Фәйрүзә апасы аның оялганын көтеп тормады, чәчүгә чыгарга өч көн кала ук:

— Булды, энем, бүгеннән соң ат бирә алмыйм мин сиңа. Чәчү өстендә дә сине ат белән йөртә башласам, тотып атарлар мине! Пуштыга җәяүле берәр кешене куярга туры килә, — дип, авыз ачарга урын калдырмыйча, җәяү генә тәпили башларга кушты.

Җәяүгә калгач, теге кисек аяк тагын шешмәгәе дип шикләнгән иде Равил. Ат белән йөргән көннәрдә шактый ныгып калган, ахрысы, артык зыянлы булмады. Билгеле, сәламәт чагындагыча шәп йөри алмый ул хәзер. Чүкәйгә элек сәгать тә ун минутта бара торган булса, хәзер шул араны үтү өчен ике сәгать тә ун минут вакыт китә. Ләкин, ничек кенә булмасын, ул үз аягы белән бара-кайта йөри, укуын дәвам итә һәм шуңа бик канәгать иде. Болай булса эшләр җайлана, тагы берәр атнадан юллар кибәр дә велосипедка гына утырып элдерә башлармын, дип аеруча рухланып йөргән иде.

Тиздән юллар да кипте, ләкин Равилнең өмете акланмады. Велосипедка атланып мәктәпкә барырга чыккан көнне үк, аягының кисек урынын теккән җөе сүтелә башлап, канарга тотынды да Равил кире кайтырга мәҗбүр булды. Шуннан ары тагын берничә тапкыр утырып карады ул велосипедка. Тик барыбер рәт чыкмады: кисек аягы педаль әйләндерергә ярамады.

## 28

Бүгенгедәй хәтерендә Равилнең: илле беренче елның унҗиденче мае иде. Җир өсте матур гына булып яшел юрганга төренеп килә, каеннар үтә күренмәле яшел ефәк челтәр бөркәнгән иде. Җилләп торса да, көне дә бик җылы. Күктә тургайлар, урманда сандугачлар сайрый, күкеләр кычкыра. Ә Чүкәй мәктәбенең сигезенче-унынчы класс укучылары колхоз кырына бәрәңге утыртырга килделәр. Һәр укучыга егерме бишәр сотый исәбеннән, кишәрлекләр алдан ук бүленеп куелган иде. Класс җитәкчесе Суфия апа тугызынчы «б»га үзара парлашырга кушты. Башка класс җитәкчеләре гадәттә укучыларны үзләре кемне кем белән парлаштыруны кирәк тапсалар, шулай парлаштыралар. Ә менә Суфия апа ул яктан демократ кеше иде. Бу юлы да ул мәсьәләне укучыларның үз карамагына куйды.

Ләкин Равилләр классында малайлар азрак иде шул. Утыз сигез кешенең егерме бише кызлар иде. Һәм алар барысы да малайлар белән эшләргә теләгән иде. Чөнки парлары малай булса, аларга җиңелрәк: әзер чокырга бәрәңге ташлап кына барасы. Менә шуңа малайлар, шактый эредән кыланып, кызларны үзләре сайлап ала башладылар. Тик бер Равил генә, аяк авырта башлар да, юньләп эшли алмыйча, оятка калырмын дип шикләнеп, бер кызны да чакырмыйча, боегып, һәм бөтен авырлыгы гел үзенә генә килеп торганга, дөньяны каргап басып тора иде.

Әгәр аягы сәламәт булса, кемне сайлап алырга кирәк икәнлеген белер иде ул хәзер. Юк, Рухия-җилбәзәкне алмас иде Равил. Аңа ачу итеп, юри Таня белән эшли башлар иде. Тик шунысы кызганыч: «иде» дип кенә сөйләргә калды шул инде.

Равил әнә шулай уйланып, моңсуланып, Килдеков, мөгаен, Рухияне алыр инде, дип бер читтә басып торганда, Әнәс, чыннан да, тегенең каршына килде дә, бик ышанычлы итеп:

— Әйдә, Ручешка, киттек! — диде.

Менә шунда Равил өчен бер могҗиза булып алды. Рухия тегеңә кискен генә итеп:

— Беренчедән, мин үз исемем белән эндәшкән кешеләрне генә тыңлыйм! Икенчедән, мин бүген әнә теге иптәш белән эшләргә теләр идем! — диде дә Равил янына килде: — Син минем белән эшләргә каршы түгелме, Нәҗметдинов?

Равилнең бөтен ачу-үпкәләре секунд эчендә юкка чыкты һәм ул:

— Әйдә, эшләп карыйк, — дигәнен сизми дә калды.

Бер буш кишәрлеккә барып алар шундук эшкә дә керештеләр.

Әнәс Килдеков алар артыннан мыскыллы итеп:

— Син нәрсә, балакай, шул аксак барин белән эшләмәк келисеңмени? — дип кычкырып калса да, Рухия аны бөтенләй ишетмәгәнгә салышты.

Бу көтелмәгән хәл Равилнең көчен арттырып һәм күңелен күтәреп җибәрде. Һәм ул, көрәген батырып-батырып, бәрәңге оялары казып бәра башлады. Ә Рухия, шул ояларга бәрәңге салып, аның артыннан килә. Равил көрәк белән җирне каерып алганда, бәрәңгесен салыр өчен, ул да иелә. Шул чакларда аларның битләре биткә тия язып кала. Иелгәндә җиргә төшеп буялмасын өчен, Рухия озын толымнарын, култыкларны аша үткәреп, аркасына бәйләп куйган. Ә бит алмалары, түп-түгәрәк булып, яңа пешкән чиядәй кызарып чыккан. Сулыш алганда нәфис борынының нәфис яфраклары күпереп-күпереп китә. Иреннәре шулай ук чиядәй алсу, сусыл. Кызның өстендә кара трикотаж спорт костюмы. Бу костюм аңа шундый килешеп-сыланып тора, аны шундый чибәр итеп күрсәтә — гомереңбуена карап торсаң да, күреп туеп булмас! Сорыйсы иде бер: үзенең шушы сылулыгын белә микән ул? Мөгаен, белеп җиткерми торгандыр. Белсә менә шушылай, Килдековны кире кагып, аксак Равил белән эшләп йөрмәс, аннан чибәррәк һәм аяклары сау-сәламәт малайлар тирәсендә чуалыр иде ул хәзер.

Ярый, ничек кенә булса да, ул әлегә Равил янында. Аның чәчләренең хуш исен, битләренең кайнарлыгын әлегә Килдеков түгел, Равил тоеп тора. Шунысы да бик җиткән хәзергә Равил өчен.

— Имтиханнар килеп җитә бит, Равил абый, сизәсеңме син шуны? — диде Рухия, бераз эшләгәч.— Башкалары өчен уйлап та карамыйм, ну, шул физика белән математикадан котларым алынып тора инде!

— Миңа гына ышанып торма, кызый. Үзең дә яхшылап әзерлән!

— Кара әле, Равил абый, больницада ятканда синең аягыңа гына түгел, холкыңа да операция ясадылармы әллә?

— Нигә?

— Үзгәреп, һаваланып кайттың бит син!

— Үз фикереңгенәме бу? Әллә бүтәннәр дә шулай сөйлиме?

— Башкаларда минем эшем юк, үзем сизеп йөрим.

— Дөрес сизәсең бит син, кызый?

— Сизүен сизәм, сәбәбен һаман аңлый алмыйм. Әйт әле, Равил абый, нигә шулай битараф син? Миңа карата...

Сәбәбен аңлатмакчы булып, Равил тирә-ягына күз салган иде, исе китте: алар классташларыннан бик нык артта калганнар икән ләбаса! Равил тагын шунысын да абайлап алды: күпме генә тырышса да, тегеләр артыннан житү мөмкин булмаячак аңа. Рухия белән сөйләшеп барганга гына сизелми торган, кисек аягы тагын сызлый башлаган икән ич аның! Каткан кирза итегенең буш калган башына тутырылган һәм, эш барышында җайсызланып китеп, аягының кисек җирендәге яшь тиресен кыра башлаган чүпрәкләрен алып, яңадан рәтләп киеп куйса да, бераз

хәл булып китәр иде. Ләкин сөйгән кызы алдында ничек алай гарип аягын күрсәтеп торсын инде егет кеше?

— Дөресен әйтсәм үпкәләмисеңме? — диде Равил хәле кыен булса да, сиздермәскә тырышып.

— Честное комсомольское, үпкәләмим, Равил абый!

— Беләсеңме нәрсә, Рухия?..

— Белмим бит әле, иптәш Нәҗметдинов.

— Беләсеңме, мин... яратам бит мин сине...

Бүтән чакта бер нәрсәгә дә артык исе китми торган Рухия бу юлы кинәт каушап калды. Озын керфекләре аска сирпелде. Ул, бер сүз дә әйтә алмыйча, гел шулай аска караган килеш, Равил казыган чокырларга бәрәңге салып баруын дәвам итте.

— Ишеттеңме син мин әйткәнне? — диде Равил, кыз аңа ачуланмаганга куанып һәм йөрәксенеп китеп. — Яратам мин сине, Рухия!

Тик шуннан ары гына, анда да әле һаман шулай аска караган килеш кенә, кыз телгә килде:

— Яраткач, нигә шул тикле битараф соң син, Равил абый? Больницадан кайтканнан бирле юньләп сөйләшкәнең дә юк бит минем белән. Элек алай түгел идең бит син. Нигә шулай бик нык үзгәрдең?

— Син үзгәргәнгә үзгәрдем мин, кызый!

— Кызык: мин ничек үзгәрдем икән соң?

— Синме?.. Син... Килдеков белән хат алышасың ич!

Кыз кычкырып, элеккечә тирә-якны балкытып көлеп җибәрде:

— Алышам шул! Ләкин мин Килдековны түгел, сине якынрак күрәм, Равил абый!

— Ярар, кызый, күзгә карап көлеп торма әле кешедән!

— Ә мин көлмим. Минем өчен бик гади нәрсә ул, Равил абый: син артык горур булганга ачу итеп, сине көнләштерер өчен башланган эш ул. Теге чакта сине тикшергән бюро утырышыннан соң да Килдековка юри генә култыклатып чыккан идем. Ә ул, тиле, мин аны чын-чынлап якын итә дип уйлады булса кирәк: шул көннән башлап сагыз урынына ябышты бит. Дәрес саен икешәр-өчәр хат яза башлады. Аның шул беркатлылыгы минем үземә дә кызык булып китте дә мин дә, синең өчен үләргә дә әзер, Әнәскәем, дип, бер хатына уйнап кына җавап биргән идем. Шуннан бирле чатырдата гына мәхәббәт хатларын.

## 29

Кайгы килсә — йөге белән килә, диләр. Хак сүз икән бу. Моның шулай икәнлеген соңгы ике ел эчендә Равил үз җилкәсендә бик күп татыды. Әмма, бәхеткә каршы, кайгы гына түгел, кайчакта шатлык та тау хәтле булып килергә мөмкин икән бит!

Бәрәңге утырткannан соң аягы бик нык авырта башлап, авылларына кыенлык белән генә кайтырга туры килсә дә, ул көнне бу җир йөзендә Равилдән бәхетле кеше юк иде!

Юк иде, чөнки ул көнне Равил гомерендә беренче мәртәбә сөйгән кызына мәхәббәтен аңлатты!

Юк иде, чөнки шул көнне Рухия аңа, Килдековны түгел, сине якынрак күрәм, Равил абый, диде!

Ә өйләрендә аны тагын бер бик зур шатлык көтеп торган иде ул көнне. Ул кайтып кергәндә аларның өе тулы кеше һәм шул кешеләр арасында Равилнең Искәндәр абыйсы (әтисенең энесе) балкып утыра иде. Кырык өченче елда аккордеонын калдырып киткәннән соң бер тапкыр да Ташый елгага кайтып карамаган, җиде елга нибары ике хат һәм бер посылка гына (алары да сугыш чорында) салган һәм шунлыктан аеруча сагынылган абыйсы иде бу Равилнең!

Әллә ни үзгәрмәгән иде абыйсы. Күзләре дә нәкъ элеккечә зәңгәр һәм үткен, гәүдәсе дә гел шулай дәү һәм нык. Тик менә чәче... элеккечә бөдрә булса да, элеккечә кап-кара түгел, кырау төшкәндәй агарып-көмешләнеп калган иде. Аннары өстендәге киемнәре барысы да бүтән: солдат гимнастеркасы урынына хәзер ап-ак күлмәк, кап-кара костюм. Хәтта галстук та тагып җибәргән. Ә аягында ялык-йолык итеп тора торган лаклы ботинка. Абыйсының моңарчы Ташый елгада беркемдә булмаган ул затлы киемнәрен күргәч, Равил: «Их, бер генә тапкыр булса да, менә шушы киемнәрне киеп, Рухия янына барып кайтасы иде!» — дип кызыгып куйды.

Ә Равил үзе бик нык үзгәргән иде булса кирәк: янына барып, кул биреп күрешкәч тә Искәндәр абыйсы аны танымыйча торды. Өйләренә җыелган кешеләр:

— Энең Равил ич бу синең, Искәндәр! — дигәннән соң да:

— Булмаганны сөйләмәгез әле, җәмәгать, мин киткәндә бот буе гына малай иде бит, ул арада каян килеп шушылай үссен кеше? — дип ышанмыйча торды. Бары Хәбир бабай:

— Ә синең кайтканың юкка ничә ел соң инде, олан? Сигезенче киттеме? Яшьләр сигез елга сиксәнгә төрләнә алар! — дигәч кенә, ниһаять, ышанып һәм шаккатып:

— Каяле-каяле, кил әле монда! — дип, Равилне янына чакырып китереп, буйларын үлчәшеп карады. Гәүдәгә чандыр булса да, буйга Искәндәр абыйсыннан һич ким түгел, хәтта берәр сантиметрга озынрак та иде Равил.

— Вот этта да-а-а-а! — диде абыйсы, исе китеп. Равилнең аркасынан кагып куйды.— Болай булгач, нәкъ атаң буе икәнсең син, малай. Ул миннән нәкъ менә шушылай, чак кына озынрак иде. Молодец! Замана авыр дип тормагансың, сер бирмәгәнсең, молодец!

Кайтучының хәлен белергә җыелган авылдашлары таралышкач, абыйсы Равилне үз янына өстәл кырына дәшеп утыртты да:

— Я, энем, акардиун уйнарга өйрәндеңме? — диде. — Кая, апкил әле дә уйнап күрсәт әле абыеңа!

— Уйнавын уйный башлаганыем да...

Равил шунда төртелеп торган арада әнисе кече яктан:

— Менә, әйттемме мин сиңа, абыең кайткач ни дип җавап бирерсең дип! — диде. Аннары көрсенеп куйды да әйтте: — Ул әкәрдиун юк шул инде, наным Искәндәр, менә бу малай, укырга йөрергә кирәк дип, абый кайтса да ачуланмас әле дип, биләсәпиткә алмашты аны.

— Вот этта да-а-а! — диде абыйсы икенче тапкыр. Әйбәт эшләмәгәнсең бит син, энекәш, дигән сыман итеп, Равилгә карап алды. Ләкин Равилнең бик уңайсыз хәлдә калганын күреп булса кирәк, ул хакта бүтән сорашып тормады.— Ә укуың ничек бара соң? — дип, сүзне икенчегә борып җибәрде.

Равил әйбәт кенә укып килүен, эшләп укуын, шуңа аккордеонын да велосипедка алышырга мәҗбүр булганын сөйләп бирде. Үз нәүбәтендә, Равил дә абыйсының хәлләрен сорашып утырды. Гомере бетмәсә — яши икән адәм баласы. Сугышның иң соңгы көненә тикле фронтның гел алгы сызыгында булган Равилнең Искәндәр абыйсы. Ләкин пуля түгел, хәтта пуляның кыйпылчыгы да тимәгән үзенә.

— Үзең дә хәтерли торгансыңдыр, энекәш,— дип сөйләде ул Равилгә,— Нәсиха җиңгәңнең гүр иясе булганлыгын белгәч, мин ул чакта законный бирелгән ун көнлек отпускымны да тутырмыйча авылдан чыгып киттем. Чыгып киттем дә туп-туры фронтка, үзебезнең частька бардым. Бардым да, Нәсиха җиңгәң булмагач, бу дөньяның кызыгы калмады инде миңа, үлсәм дә үкенечле түгел, үлсәм дә дошманнарны күбрәк үтереп үлим, ичмаса, исән калган кешеләр рәхәтрәк яшәр, дип үзем

теләп, иң куркыныч җирләргә разведкага йөрдем. Кайвакытларда дошман сизенеп алып, шундый ут өермәсе күтәреп ата башлый — яртышар көн бер урында башны да калкытмыйча ятарга туры килә. Ләкин барыбер заданиене үтәмичә кайтмый торган идек...

Сугыш беткәч тә җиңел эш эзләп йөрмәгән Равилнең абыйсы. Ташый елгага кайтсам, һаман Нәсихәм күз алдымда торыр, читтә, ичмаса, җиңелрәк булыр дип, фронтташ иптәшенә ияреп, Кемерово якларына юл тоткан. Анда ул шахтада эшли башлаган. Ә иптәше, үземне-үзем тереләтә җир астына күмәр хәлем юк, анда ятарга теге дөньяга баргач та җитештерербез әле дип, өстә эшләргә урнашкан.

— Әмма шунысы гаҗәп булды,— диде Искәндәр абыйсы,— минем ул иптәш (Николай исемле рус егете иде) җир өстендә эшләсә дә, машинага тапталып, инде кырык җиденче елда ук вафат булды, ә мин менә, шөкер, җир астында булсам да, исән-сау әлегә.

Бик шәп эшли, ахры, ул анда. Шулайдыр, шулай булмаса берсеберсе яртышар метр озынлыгындагы «Казбек» папирослары гына тартмас һәм шул тикле бүләкләр алып кайтмас иде. Ә ул дөнья кадәр әйбер төяп кайткан лабаса! Атап әйткәндә, Равилнең энисенә Оренбур шәле, ике күлмәклек ситсы, бер бик һәйбәт көзге пальто алып кайткан иде.

Ләкин болары Равилгә алып кайткан әйберләр белән чагыштырганда пүчтәк кенә иде әле. Аңа алып кайткан бер костюм гына да мең дә сигез йөз тора булып чыкты. Мең дә си-гез йөз! Әйтергә генә ансат ул. Тагын бер мең табып кушсаң — әйбәт кенә тана, ә тагын шуңа әзрәк өсти алсаң — бура кадәрле һәм егермешәр литр сөт бирә торган сыер алырга була лабаса аңа. Менә нәрсә дигән сүз ул мең дә сигез йөз! Шул костюм-чалбар янына тагын ап-ак ефәк күлмәкне, капкара галстукны һәм көзге шикелле йалк-йолк итеп торган кап-кара ботинкаларны кушыгыз да үзегез исәпләп карагыз инде!..

Ләкин абыйсы биргән бүләкләрнең иң зурысы болар түгел, иң зурысы алдарак булган икән әле.

Район начальникларының да күбесенә тәтеми торган теге затлы киемнәрне киеп, Равил сөенеченнән ни эшләргә дә белмичә ишекле-түрле йөри башлаган иде, Искәндәр абыйсы, кинәт аптырап китеп:

— Карале, нигә болай бик нык аксыйсың әле син, егет? — дип сорап куйды.

— Пүчтәк кенә ул, абый! — дигән булды Равил, сер бирмичә. Шулай да абыйсы җентекли башлагач, сәбәбен аңлатып бирергә туры килде.

— Тәк! — дип куйды абыйсы һәм берәр минут чамасы уйланып утырды да: — Значит, эшең ни важный икән синең, парин! — дип өстәде.

Ул көнне шуннан башка бер сүз дә әйтмәде.

Икенче көнне Равил йокыдан уянганда Искәндәр абыйсының урыны инде җыеп куелган, ә ул үзе каядыр киткән иде. Әллә шыпырт кына кире китеп барды микән, дип куркып та куйды Равил. Әмма алай булып чыкмады. Төш авышуга ук әйләнеп кайтты абыйсы. Һәм ничек кенә кайтты әле! Равил моңарчы раймагта гына күргән һәм нужәли шушындый кыйбатлы әйберне сатып алырлык акчасы булган кешеләр бар икән бу дөньяда дип, шаккатып карап торган мотоциклга атланып кайтты аның абыйсы! Һәм әйтте Равилгә:

— Менә, энем, — диде, — сиңа апкайттым мин бу тырылдыкны! Башта сезгә сыер алып бирергә уйлаганыем. Ну, синең аягыңның бик нык эштән чыккан икәнен күргәч, шушыны алырга булдым. Моңарчы сыерсыз яшәгәнне, моннан соң да яшәп торырсыз әле. Ә менә ярты табан белән көн саен уналты чакрым җир йөрүләре, ай-һай!

— Укырга йөрергә бер генә ел калып бара бит инде, ничек тә түзәр идем әле,— диде Равил абыйсына.— Шушы мотоциклга түләгән ак-

чаны үзебезгә генә биргән булсаң, без аны, саклап кына тотып, үп елга житкерер идек. Мин укыган өчен түләргә дә, башкаларына да житәр иде!

Болай әйтүенең сәбәбе шул: мотоцикл тикле мотоцикл акчасын кызганмаганны вак-төягенә кызганып тормас, жае чыккан чагында исенә төшереп куйыйм, дип уйлаган иде ул. Дөрес чамалаган икән. Абыйсы шундук кесәсеннән калын гына бумажнигын тартып чыгарды да:

— Тәк! Әйт әле миңа, уны укып бетергәнче сиңа күпме акча кирәк булачак? — дип сорады.

— Сигезенче белән тугызынчыда укыган өчен мактап директоры түләп торган иде, анысы өч йөз сум. Ә алдагы елда йөз илле сум кирәк булачак.

— Значит, жәмгысы дүрт йөз дә илле тәңкә була инде ул! — диде абыйсы. Шул да булдымы акча, дигән сыман, бик эре генә әйтеп куйды. Шундук бумажнигыннан алты данә йөзәрлекне тартып чыгарды да: — Мә, энем, түләвеңне түләргә дә, уку эсбаплары алырга да житәргә тиеш бу сиңа! — дип, шуларның барысын да Равилгә сузды.

Кинәт килеп чыккан шатлыктан кешенең йөрәге ярылган очраклар була икән дип ишеткәне бар иде Равилнең. Әмма үз гомерендә гел кимсенеп, гел мохтажлыкта гына яшәгәнгә һәм зур шатлыкның нәрсә икәнен бөтенләй татып караганы булмагангадыр, ул сүзләргә бик үк ышанып житми иде. Ә менә бүген шулай булу мөмкин икәнлегенә тулысынча ышанды. Алдан бүләк иткән әйберләре өстенә абыйсы шытырдап торган алты йөз сум акча да чыгарып биргәч, үзенең дә йөрәге чак кына ярылмыйча калды аның. Һәм ул, сулуы кабынып, беркавым тәмам өнсезләнеп торды. Тик шуннан соң гына:

— Ну бәхетле дә кеше инде син, абый! — диде. — Кесә тутырып акча йөртәсең бит, ә?!

— Әй, энем-энем! — диде абыйсы, тирән итеп көрсенеп куеп. — Буең минеке хәтле булса да, бала шул әле син. Кулыңа уч тутырып акча кереп карамаганга гына шулай тоела ул сиңа. Ә мин менә, әгәр хәзер Нәсиха жиңгәңне терелтәбез дисәләр, бер тиен акчасыз калырга да биш куллап риза булыр идем. И бу жир шарында миннән дә бәхетле кеше булмас иде!

Шушыларны әйткән чагында абыйсының күңеле тулып китте.

— Жиңгине мәңге кайтарып булмаячак бит инде, абый. Нигә бүтән кешегә өйләнмисең соң син? — диде Равил. Абыйсын өйләндерәсе килүдән бигрәк, аның бу мәсьәләгә карата уй-фикерләрен белергә теләде.

— Әй, энекәш, — диде абыйсы, байтак дәшми торгач, — өйләнү белән генә эш бетә торган булса икән ул! Өйләнеп тә, аерылышып та карадым инде бу абыең. Мужыт тагын өйләнергә туры килер әле. Ну... Нәсиха жиңгәң юк инде ул, юк!

Равил аны авыр хисләреннән коткарырга теләп:

— Әйдәле, абый, мотоциклга утыртып, бер генә тапкыр булса да урам әйләндереп алып кайт әле мине? — диде.

## 30

Менә кайда икән ул дөньяның рәхәтлеге! Уң як рульдәге резина тотканы бару уңаена таба чак кына бора төштеңме, мотоцикл шундук алга ыргылып куя. Бернинди көч сарыф итәсе түгел! Ә жил Равилнең битләрен шул тикле йомшак итеп иркәли — тизлекне арттырганнан-арттырасы гына килеп тора. Күңелдә алга омтылу ләззәтеннән башка бернинди уй юк. Мотоцикл бер урында тик кенә тора, аның көпчәкләре астына жир үзе шуып кереп барадыр шикелле.

Абыйсы, күрсәтеп-өйрәтеп байтак йөргәч, Равилгә мотоциклны мөстәкыйль рәвештә йөртеп карарга кушты. Башта бернічә тапкыр моторы сүнеп киткәләсә дә, Равил мотоциклның рәтенә хәйран тиз төшенеп алды һәм, авыл эчендә борыла-сырыла йөргәнче, кырда иркенрәк булыр дип, басу капкасыннан чыгып китте. Кырга чыккач, тизлекне тагын да арттыра төшеп, ул инде Чүкәйгә бара торган юл өстендәге таныш урман буена килеп тә җиткән иде. Борылыргамы-юкмы дип икеләнеп барган арада ул урманны да үтеп китте. Җилпи генә мотоцикл җаный! Хәзер тавышы да баягы кебек ямьсез түгел, матур гына, гөрелдәп кенә бара! Рәхәт күрәселәре алда бит әле Равил абзагызның! Моннан ары көн дә шушы мотоцикл белән генә элдертәчәк иң ул, боерган булса! Әле ярый, абыйсы сыер алмаган. Сыерга атланып йөрер иденмени?.. «Туктале, кая барасың соң син болай? — диде Равил үз-үзенә, һаман Чүкәйгә таба баруына исе китеп. — Күптән борылырга вакыт иң инде сиңа! Басу капкасы төбендә абыең көтеп калды бит сине, малай актыгы!» һәм шул минуттан башлап ул икегә бүленде. «Чүкәй күренгәнче генә барыйм инде! — диде аңа икенче Равил. — Ә абыеңа берни дә булмас. Саф һава сулый торыр. Авыл һавасын сагынып кайттым ди бит».

Әнә шулай үз-үзе белән бәхәсләшә-бәхәсләшә, Чүкәйгә дә барып керде, мәктәп турына да җитте. Мәктәп тирәсендә Рухия очрамасмы дип өметләнгән иде Равил. Ләкин Рухияне түгел, гомумән, беркемне дә күрмәде ул анда.

«Ярый, исән булсак бер күрешербез әле без ул чибәр белән. Ике күзен дүрт итәрбез әле без аның!» дип, үзен-үзе юатып, Равил мотоциклын кайтыр якка борды. Ләкин мотоциклы «бик үҗәт нәрсә» булып чыкты аның: мәктәп турыннан үтеп, ике-өч метр китәргә дә өлгермәде, Равилне кирегә борып алды да, чатырдаттырып, мәктәп ихатасындагы интернат ишеге төбенә китереп тә куйды.

Интернат кызлары өйдә булганнар икән. Башта ачык тәрәзәдән башларын тыгып карадылар, аннары Равилне танып алып, ду кубып, кайсы ишектән, кайсы тәрәзәдән чыгып, кемнеке бу мотоцикл, нишләп йөрисең болай вакытсыз, нигә иртән дәрескә килмәдең? диешеп, төрлесе төрле яктан сорау яудырырга тотындылар. Равил аларга, бик тәҗел эш килеп чыкты, шуңа бүген укырга килә алмадым, ә иртәгә иртүк киләм, дип кыска гына җавап бирде дә, шаккатып карап торган Таняга мөрәҗәгать итеп:

— Нигәдер кайберләрегезне күрмим әле мин монда? — диде. Таня, хәйләкәр кыз, Равилнең тел төбен шундук аңлап алды һәм, бүтәннәр дә ишетсен өчен юри кычкырып:

— Сез, әлбәттә, Басыйрованы күз алдыгызда тотып сорыйсыз инде моны! Ул бүген, кызганычка каршы, Укмаска кайтып китте шул, Равил әфәнде. Әтисе килеп алды, — диде.

Равилгә хәзер мәктәп ишегалдын тавышка күмеп, әллә кемнәрнең игътибарын җәлеп итеп торудан мәгънә юк иде. Һәм ул мотоциклын шатырдаттырып, мәктәп ихатасыннан чыгып та китте. Очып кына Укмаска барып керергә дә, иртәгә биреп җибәрелгән өй эшләрен язып куярга онытканмын, шуларны гына әйтче, дигән булып Рухияне күреп кайтырга иде егетнең нияте. Әгәр җае чыкса, дәресләрен шунда Рухия белән бергәләп әзерләп кайтырга да исәбе юк түгел иде. Ләкин...

## 31

Ашыккан — ашка пешкән, дигәннәре дөрестер, ахрысы. Чүкәй күперенә килеп кергәч, күпер бүрәнәләре өстендә мотоциклның көпчәкләре бик каты дыңгырдаша башлады да Равилнең кулы рульдән ычкынып китте. Шунда, газ бирә алмыйча калып, моторы сүнде. «Чукынды болай

булгач! Кабызып кына булса ярар иде!» Һаман шул Рухия турында хыялланып килгәнлектән, күпергә кергәнен сизми дә калуына үзен-үзе орышып, Равил кабызу рычагына басарга тотынды. Биш басты, ун басты, егерме басты, әмма мотор кабынырга уйламады да. Тагын бик күп мәртәбәләр басып карап та эш чыкмагач, ватылган, ахрысы, дип, тәмам өметен өзеп, күпер буена барып ауды. Рәтләп йөртә белмәгән көе тинтәкләнеп шушы Чукәйгә тикле килгәне өчен, тагын үзен битәрләргә тотынды.

Тик аңа карап кына моторы барыбер кабынмады. Хәзер аны сөйрәп Чукәйгә илтеп берәрсендә калдырып торырга да соңыннан Искәндәр абыйсы белән бергәләп килеп, төзәтеп алып кайту чарасын күрергә кирәк иде.

Җансыз калгач иләмсез нык авыраеп киткән мотоциклын җитәкләп, Чукәйгә таба бара башлаган иде — артыннан бер атлы куып җитте. Равилгә таныш кеше — бу якларда төбәк милиционеры булып эшләүче, Баткаклы авылыныкы Сахип абый иде ул. Сахип абый Равилне узып китеп атын туктатты да, арбасыннан төшеп, каршына чыкты. Кул ишарәсе белән Равилгә туктарга кушып, иңенә аскан сумкасыннан кәгазь белән карандаш чыгарды.

— Яле, парин, исем-фамилияңне язып алыйк әле! Түлке, матри, дөресен генә әйт! Алдашсаң, үзеңә кыен булачак.

— Ә нигә язып куймакчы буласыз сез аны, Сахип абый?

Милиционерның йөзенә мыскыллы елмаю бәреп чыкты:

— Әһә! — диде ул, эчке бер канәгатьлек белән. — Син минем исемне дә беләсең икән инде? Кайда туры килгәнең бар соң синең миңа? Кайда танышканыек икән без синең белән? Мин нишләптер хәтерләмим!

— Хәтерләмәвегез бер дә гаҗәп түгел, Сахип абый: биш авылга бер генә кеше бит сез. Ә минем ишеләр сезнең төбәккә керә торган һәр авылда тулып ята.

— Карап-карап торам да, син, малай актыгы, артыгын күп сөйләргә өйрәнгәнсең бит! Син миңа, матри, экият сатма, сораганга җавап бир! Фамилияң ни мин сиңа?

— Фамилиям — Нәҗметдинов, исемем — Равил.

— Кайсы авылдан буласың?

— Ташый елганыкы.

Милиционер, әллә ялгыш күрәмме диптер, ахрысы, соры күзләрен ачыла алганча зур итеп ачып, Равилгә бөтенләй якын ук килеп карап торды да:

— Син, малай актыгы, кемне алдаганыңны беләсеңме? — диде. — Учаскавай милиционер, өлкән сержант Сахип Каюмычның үзе каршында басып торуыңны беләсеңме син?

— Белмәсәм, исемегезне әйтә алыр идеммени?

— Белеп ялганласаң — бик шәп! Ә хәзер, давай, машина йөртү праванны чыгар әле!

— Анысы нәрсә инде тагын, Сахип абый? — диде Равил, моңарчы шактый иркен сөйләшсә дә, хәзер куркуга төшеп.

— Әһә! — диде участковый, рәхәтләнеп көлеп җибәреп. — Әһә! Ул машина йөртү правасын да белми! Ә үзе мотоцикл сөйрәп йөргән була!

— Минем мотоцикл түгел бу, Сахип абый, — диде Равил, шушы тырылдыкны йөртер өчен дә укырга кирәк икәнлегенә аптырап.

— Ә мин аның синеке булмаганын әллә кайдан күреп торам! Шуңа туктаттым да инде. Син миңа туп-туры гына әйтеп бир: кайдан челдерден син моны? Номерын кайда ташлап калдырдың?

— Минем үземнеке бу, Сахип абый. Әле менә бүген генә абый районнан сатып алып кайтты.

— Ничек ул алай үзеңнеке? Әле генә минеке түгел дидең бит! Ә абыең кем синең? — диде теге, һаман Равилгә шикләнеп карап.

— Искәндәр исемле ул. Әле кичә генә Кемероводан кунакка кайтты.

Юк, бу мәгълүматлар гына да канәгатьләндермәде төбәк милиционерын. Искәндәр абыйсының да җиде бабасына хәтле тикшереп-сорашып чыкты. Һәм аның әнә шулай төпченүе ахыр чиктә Равил файдасына булды. Хикмәт шунда, Сахип абый үзе дә Равилнең Искәндәр абыйсы белән бер елгы һәм алар егет чакта бик дус булганнар икән.

— Аннары ул безнең авылның Нәсиха атлы кызга өйләнде, и мин аларның туйларында да булдым! — диде Сахип абый, кинәт ачылып китеп. — Каяле, энекәш, нигә кәҗәләнә икән синең бу нәмәстәкәең!? — дип, мотоциклның рулен үз кулына алды. Газны ачып, кабызу рычагына типте. Мотор кабынмады. Ул тагын бик каты типте һәм шундук кычкырып көлеп җибәрде:

— Ай-яй-яй, яй--яй-яй! Соң, алла бәндәсе, синең матациклың тизлеккә куйган килеш тора лабаса! Кара әле менә монда!

Равилгә аңлата-аңлата, тизлек алыштыру рычагын ычкындырды да:

— Ә хәзер син менә мине карап тор инде! — дип, кабызу рычагына бер генә типкән иде — мотор шундук кабынып, пырт-пырт-пырт-пырт итеп эшли дә башлады. — Мин бераз моторны җылытып килим, ә син атны карап тор, яме! — диде Сахип абый. Мотоциклга атланып, Чүкәйгә таба китеп тә барды.

— Мин фронтта матациклист идем бит. Шул заманнарны искә төшереп, бер җилләнеп килдем әле, — диде ул, шактый гомер йөреп килгәч. — Безнең анда мондый гына түгел, моннан да зурраклары — өч көпчәклеләр ие. Ничава, бер үзеңә бусы да бик җиткән. Сиңа монда фронттагы шикелле пулемет төяп, командирлар утыртып йөрисе түгел. Ни, карале, бер җаең белән минем янга килеп чыгарсың, права алып бирү мәсьәләсен дә, номер алу мәсьәләсен дә юллашырмын мин сиңа, яме! Автоинспекциядә минем күз күргән кешеләр анда. Тик берәр литрлык акча тыгып килергә генә онытма!

— Укырга кирәктер бит аңа башта.

Сахип абый кулын гына селекте:

— Кирәген кирәк инде ул, кәнишне. Киләчәктә дөньялар матурланып, тормышлар яхшырып, матацикларны күпләп ала башласалар, кәнишне, районда да курс ачарлар. Ну пока, елына бөтен районына биш-алты кеше генә матацикл алган дәвердә, укытып азапланмыйлар, әз-мәз мотор кабыза белгән кешеләргә права белән номерын да биреп җибәрәләр. Давай, энекәш, дуй инде хәзер үзеңнең Ташый елгаңа! Хәерле юл сиңа! — дип озатып калды.

## 32

Рухияне иртәгә Укмаска барып каршы алыргамы, әллә куыш имән төбендә көтеп торып, ялгыш кына шунда очраткан атлы булыргамы?

Иртәгә мәктәпкә яңа костюм-чалбарымны киеп барыргамы? Әллә бөтен яңалыкларны да берьюлы күрсәтеп, кызыгын бетермичә торыргамы? Дөбердәтеп мотоцикл белән каршына килеп чыгу да җитеп торыр микән әллә?

Кызык, Рухия ничегрәк кабул итәр икән бу шаккаттыргыч яңалыкларны?.. Моннан соң көн саен Равил белән мотоциклга утырып кайтакилә йөрергә риза булыр микән ул?

Төне буе үз-үзенә әнә шундый сораулар биреп һәм шуларга җавап эзләп баш ватты Равил. Ләкин барыбер Рухиясен кайда һәм ничек каршылау мәсьәләсен анык кына хәл итә алмаган иде әле.

Ә вакыты җиткәч, барысы да ансат кына булды да куйды. Каравылдан кайтып иртәнге ашны ашады да, сумкасын асып, мотоциклына утырып, туп-туры Укмаска элдертте Равил. Чөнки Рухиясе килеп җиткәнче мотоциклын күрсәтмичә торырлык түземе калмаган иде аның.

Аннары кызның кичә башкалар кайтмаганда нигә берүзе генә кайтып китүе дә билгеле түгел иде бит әле.

Ул Рухияләрнең капка төпләренә үк барып туктамакчы иде. Әмма таң тишегеннән бөтен авылны дер селкетеп йөрү килешмәс дип, Укмас басу капкасы төбендә тукталды да, мотоциклын читән буена, узган елдан калган коры куралар, әремнәр арасына ышыгайтып куеп, Рухияне шунда утырып кына көтеп торырга булды.

Сабыр төбе — сары алтын, ди. Кайчакта әнә шулай кыюсызрак, сабыррак булу да бик ярап куя икән! Әгәр Укмас авылының басу капкасы төбендә тукталып тормаган булса, үзе өчен бик мөһим бер очрашудан коры калачы икән.

Равил килеп туктаганга биш минут та үтмәгәндер, Рухиянең гадәтенчә искиткеч матур атлап, урам буйлап бирегә — басу капкасына таба килгәне күренде. Куанычыннан тыннары кысылып куйды Равилнең. Кыз якынайган саен йөрәге ешрак тибәргә тотынды. Менә хәзер ул капка төбенә килеп җитәчәк. Ә Равил йомылып кына каршына чыгып басып аны шаккаттырачак. Чү! Ни булды тагы? Шактый кызу килгән җиреннән урамдагы соңгы тыкрык буенда Рухия кинәт туктап калды. Тыкрык ягына карап, кемнедер көтә, ахрысы. Елмаеп та куйды булса кирәк — бик үк ачык күренмәсә дә, шулай шикелле сизелде Равилгә. «Таня белән Вәсимә кайтмаганнар иде бит, кемне көтә икән бу кызый?» Ул аптырап торган арада тыкрыктан велосипедка атланып... Я, рабби! Өченче ел кеше яллап Равилне тукматып җибәргән теге Эшләпә иде бу! Шуны күрүгә Равилнең күз аллары караңгыланып, ток бәргәндәй, тәннәре чымырдап китте.

Ә Эшләпә шатырдаттырып тормоз салып, Рухиянең алдына ук сикереп төште. Башта, авызын ерып, аңа нидер әйтте (исәнләшүе булгандыр инде). Аннары кызның сумкасын алып, велосипедының руленә элеп куйды. Велосипедын җитәкләп, Рухия белән рәттән басу капкасына таба килә башлады. Үзе туктаусыз нидер сөйләнә иде. Тегесе шул тикле мавыгып аны тыңлап бара — Равил читән буенда түгел, юл уртасында басып торса да күрмәс иде алар. Басу капкасыннан чыккач аз гына атладылар да, Эшләпә тукталып:

— Рәхим итегез, принцесса! — дип, Рухиягә велосипедына утырырга тәкъдим итте.

Рухия чытлыкланып көлеп җибәрде дә тегенең велосипедына менеп тә утырды. Һәм алар китеп тә бардылар.

Ә Равил, үз күзләре белән күреп торган шушы хәлгә әле һаман ышанып җитә алмыйча, берничә минут акылыннан язып торды. Шулай булмый хәле дә юк. Әле өченче көн бәрәңге утыртканда гына ничек итеп сөйләнеп йөргән булды бит шушы чәчбикә! Авызына сугып сөйләтмәде ич аңа Равил. Ә бүген шул кыз, әнә, уйлап та бирмичә, Эшләпәнең велосипедына утырды да китте!..

«Ярар, болай ылжырап утырып эш чыкмас. Мәсьәләгә якынрак килеп карыйк! Ул тәти егет белән минем алыш-биреш тә бар бит әле», — дип, үзалдына кычкырып сөйләнә-сөйләнә, Равил мотоциклын кабызды да, мотор тавышы белән иртәнге саф тынлыкны шатырдаттырып ярып, Эшләпә белән теге кыз артыннан атылды.

Ул аларны бик тиз куып җитте. Ләкин узарга теләмәде. Мотоциклын бар көченә кычкыртып, юри акрын бара башлады. Күрәсең, рәте шул чама гына булгандыр, Эшләпә велосипедын чалыш-чолыш китереп, педален бик авырлык белән генә әйләндереп бара иде. Башта ул читкәрәк тайпылып, Равилгә юл биреп кенә котылмакчы булды. Әмма Равил һаман кычкыртуын дәвам иткәч, тагын ни кирәк инде сиңа дигән сыманрак итеп, артына борылып карады. Әнә шул борылуы үз башына булды аның: велосипеды кинәт чайкалып куйды да, кыз да, Эшләпә үзе дә юл буендагы тузанга егылып төштеләр.

Равил аларны чак кына узып китеп, мотоциклын сүндереп куйды. Егылган җиреннән инде торып, өс-башларын кагып яткан Эшләпәгә һич тә игътибар итмичә, еларга да, көләргә дә белмичә шаккатып калган Рухия янына килеп, бер сүз дә әйтми генә аның өстендәге тузаннарны какты. Аннары Эшләпә янына барып, аны изүеннән тотты да ачу белән йөзенә текәлде. Эшләпә дә Равилне танып алды булса кирәк — секунд эчендә мәет шикелле агарынып китте.

— Әйдәле, агай-эне, әнә тегендәрәк барып сөйләшик әле без синең белән! — дип, Равил аны Рухия яныннан читкәрәк тартты. Шул тикле куркып-югалып калган иде Эшләпә — каршылык күрсәтү түгел, авыз ачып сүз дә әйтә алмады. Башка чакта бик батыр булган Рухия дә бу көтелмәгән хәлдән каушабрак киткән иде, ахрысы:

— Бәй, Равил абый, нишләвең бу?! — дип кенә куйды да баскан урынында тораташтай катып калды.

— Нишләтим инде мин сине? — диде Равил, тегене кыз яныннан читкәрәк алып киткәч.

Эшләпә бер сүз дә дәшмәде. Тиле кеше сыман күзләрен тәгәрәтеп, кымшанып та карамыйча тик тора бирде.

— Синнән сорыйм мин: нишләтим хәзер мин сине? — диде Равил, тагын да катырак дәшеп. Бары шуннан соң гына Эшләпә телгә килеп:

— Ни хакың бар синең тәк торганда кешегә бәйләнергә? Кая, җибәр әле күкрәкне! Кагылып кына кара! Беләсеңме сиңа шуның өчен нәрсә булачагын? — дип, хатын-кыздан да болайрак чәрелдәргә тотынды.

Равил аны, һаман шулай каптырып тоткан килеш, каты гына итеп селкеп куйды.

— Тынынны чыгарма, калай әтәч! Теге чакта кешеләр яллап мине тукматканда синең ни хакың бар иде соң? Яле, җавап бир әле шуңа?

Эшләпә янә телсез калды. Шуннан соң Равил:

— Кил әле, монда, кызый! — дип, Рухияне үзләре янына дәшеп китерде дә: — Бер дә боргаланмыйча гына, дөп-дөресен генә әйт әле менә хәзер: өченче ел мин сиңа үзебезнең ындыр табагында әйтеп җибәргән сүзләрне тапшырган идеңме син бу бәндәгә? — диде.

— Нинди сүзләр иде икән соң ул, Равил абый? — диде кыз, зур кара күзләрен еш-еш йомгалап.

— Менә шушы алла бәндәсенә әйт: әгәр минем янга килеп, Октябрь бәйрәме кичендәге хәлләре өчен гафу үтенмәсә — миннән яхшылык көтмәсен, — дип әйтергә кушкан идемме мин сиңа?

— Кушкан идең, Равил абый!

— Шул сүзләрне менә бу калай әтәчкә ирештергән идеңме?

Ирештергәнлеген бик яхшы белеп тора иде Равил. Рухия үзе сөйләгән иде аңа. «Мин син әйткәннәрне ирештергәч, үтенермен менә мин аннан гафу, шундый итеп үтенермен — ник туганына үкенер, дип әйтте», — дигән иде. Ләкин менә хәзер ул тотлыгып калды.

— Синнән җавап көтәм мин, Рухия! — диде Равил, түземе төкәнә башлап.

— Юк өчен тавышланып торма инде, Равил абый, — диде кыз, һаман әле кистереп кенә җавап бирмичә.

«Димәк, дөресен әйтергә теләми яки курка», — дип уйлап алды Равил һәм кызны кызганып куйды. Аннары Эшләпәгә мөрәҗәгать итеп:

— Ярый, менә бу кыз бала минем сүзләрне сиңа әйтергә оныткан да булсын, ди. Ләкин гел кеше әйткәнне генә көтеп тормыйлар аны! Гаебең бар икән, киләләр дә матур гына итеп гафу үтенәләр! — диде дә йодрыгын Эшләпәнең ияк астына тидереп алды. Тешләре-тешкә орынып, «шык» итеп китте тегенең. Арт ягына да берәрне тибәргә ниятләп тора иде Равил. Ләкин шул чак Рухия араларына килеп кереп:

— Юләрләнмә, Равил абый! Әгәр мине якын итсәң, зинһар тукта?! — дигәч, күңеле йомшап китте дә тыелып калды. Аннары сорады:

— Ә хәзер шуны әйтеп бир миңа: Укмас клубында сугышып йөрде, дип, өченче ел безнең мәктәп директорына һәм райкомолга минем өстән син язган идеңме?

Эшләпә җавап бирмәде.

— Син идеңме ул ялган хатны язучы? — диде Равил, тегене тибеп егудан авырлык белән генә тыелып торып.

Эшләпә һаман телсез иде.

— Ярый, үзең кабахәтлегеңне танырга йөрәгең җитмәсә дә, аны кире какмавың әйбәт анысы. Бөтенләй үк беткән кеше түгел, чак кына булса да ояла беләсең икән әле. Шуның өчен кичерәм мин сине бу юлга. Ну, икенче мәртәбә шундый эшеңне сизсәм — беттең. Ишеттеңме?

— Чукрак түгел лә мин! — диде Эшләпә, ниһаять, телгә килеп.

— Ишетсәң — бик шәп! Ә хәзер, давай, исән чакта ычкын моннан!

Шулай дип әйтүе булды, теге бичара, тиз генә велосипедына атланды да, артына да борылып карамыйча, авылларына сыпыртты.

Равил кызга борылды:

— Син дә колагыңа салып куй, кызый: әгәр тагын бер тапкыр шул Эшләпә белән сөйләшеп торганыңны күрсәм миңа үпкәләмә!

Рухия бер сүз дә дәшмәде: уйчан-борчулы кыяфәттә басып тора иде ул. Равилнең шулай усалланып китүенә аптырагандырмы, әллә Эшләпәнең куркак җан булып чыгуына исе китеп торгандырмы — Равилгә анысы мәгълүм түгел иде. Ләкин сөйгәненең шушындый хәлдә калуына Равил ин элек үзен гаепле дип тапты һәм кызның янына килеп, эссе, йомшак кулларыннан тотты да:

— Гафу ит, Рухия, мин сине үпкәләтергә һич тә теләмәгән идем! Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты инде, — диде.

Кыз күтәрелеп тә карамады.

— Әйт әле, Рухия,— диде Равил, бик нык борчылып,— Эшләпә белән мөнәсәбәтләрегез ничек сезнең? Ул үзе генә әрсезләнеп йөриме, әллә син үзең дә аны якын итәсеңме?

— Моны белү бик кирәкме, Равил абый?

— Бик кирәк, Рухия. Мәсәлән, минем өч нәрсәне беләсем килә. Бердән, ник сине озатырга килде әле ул бөҗәк? Икенчедән, Алабугадан ник кайткан ул һәм аның кайтканын син кичә кайдан белеп кайттың? Өченчедән, нигә син бүген аның үзе алдында мин килеп гафу үтенсен дип әйтеп җибәргәннән соң сиңа биргән җавабын кабатламадың? Аңа бер төрле, миңа икенче төрле сөйләп, нигә алдашып йөрисең? Беркатлы бу, моны ничек алдасам да ярый дип уйлыйсыңмыни?

Шушылай ук итеп «стенага китереп терәгәч», Рухия бөтенләй коелып төшәр дип уйлаган иде Равил. Ләкин кызыйның исе дә китмәде. Равил пыр тузынганда хәйләкәр елмаеп кына торды да, ул туктагач, беттеме, дип сорады.

— Хәзергә шулары да җитеп торыр дип уйлыйм, кирәк булса тагын өстәрмен! — диде Равил.

Шуннан ары гына Рухия сүзгә кереште:

— Беренчедән, — диде ул, — кеше үзе теләп, ярдәм итәргә дип таң тишегеннән торып килгән икән, син аңа, рәхмәт, мәшәкатьләнеп йөрмә, дип әйткәч тә кайтып китмичә, әгәр Ташый елга турына тикле генә булса да шушы велосипедка утырып минем белән барырга риза булмасаң, ул чакта мин бу велосипедны хәзер үк кайтам да күпердән суга ыргытам, дип «куркыткан» икән — ничек инде аңа каршы килеп, шул бердәнбер велосипедыннан да мәхрүм калдырмак кирәк? Аннары утырып барырга мөмкинлек булганда нигә ул мөмкинлектән ваз кичәргә тиеш ди әле мин? Аның белән утырып барганга карап кына дөнья харап булмыйдыр бит, Равил абый? Икенчедән, мин аның Алабугадан ник

кайтуын сорамадым. Кызыксынмадым чөнки. Үзем дә аның кайтканын белеп кайтмадым. Кичә әти МТС эше белән Чүкәйгә килде дә, әйдә, кайтып киләсеңме, дигәч, аның атына утырдым да кайттым да киттем.

— Ялганла инде, әйдә!

— Өченчедән, син гафу үтенергә кушканнан соң ул әйткән сүзләрне шуңа кабатламадым, чөнки син бик каты тотындың ич аңа. Шул чакта мин дә аның сүзләрен раслап торсам, бөтенләй йөгәнсезләнеп китеп, бер-бер хәл ясап ташларсың дип курыктым. Һәм тагын бер сәбәбе бар: Рәмзи абый бу ел институт тәмамлап, безнең мәктәпкә укытырга кайтырга йөри икән. Бүген, мәктәбегезне карап кайтыйм әле, дип чыгуы иде аның. Менә шулай, Равил абый! Син уйлаганча, алдашып, ике җирдә ике төрле сөйләшеп йөри торган гадәтем юк минем!

Менә шулай һич тә кире кагарга урын калдырмаган дәлилле туры сүзләре белән томалады да куйды кыз Равилнең авызын. Аннары, әле яңа гына күргәндәй исе китеп:

— Ә бу кем мотоциклы соң, Равил абый? — диде.

— Минеке.

— Кит аннан! Каян алдың?

— Абый алып кайтты.

— Теге сугыштан соң хаты да, хәбәре дә булмаган абыең мәллә?

— Әйе!

— Менә, ичмасам, кеше икән ул! Әйдә, Равил абый, кузгалыйк. Дәресләр башланганчы тарихтан биреп җибәрелгән теманы да кабатлап чыгасым бар әле минем! Укытучының бүген миннән соравы бик мөмкин! — диде дә мотоциклның арткы утыргычына барып тотынды.

Равил моторын кабызды да кызны очыртып Чүкәйгә алып китте.

## 33

Аннары алар тугызынчы классны тәмамлаганчы гел бергә, көн саен кайта-килә йөрделәр. Әлеге куыш имән төбендә утырып, имтиханнарга әзерләнделәр. Чынлап торып тырышса, адәм баласы булмастай тоелган нәрсәләрне дә булдыра ала икән. Равил белән бергәләп көннәр буе укый-өйрәнә торгач, Рухия физика законнарын да, математик формулаларны да ару гына үзләштерде һәм барлык имтиханнарны да үз көче белән тапшырып чыкты дияргә була. Равил аңа бик кыен чакларында гына ярдәм иткәләде. Дөрес, Рухиянең имтиханда алган билгеләре нигездә гел өчлеләрдән гыйбарәт булып, тик татар әдәбияты белән рус әдәбиятыннан гына бишле булды. Ләкин Рухия шуларга да бөтен фәннәрне гел бишкә биргән кешеләргә караганда йөз тапкыр ныграк куанды ул чакта. Хәләл көч белән башкарылган хезмәтнең нәтиҗәсе әнә шулай кадерле була икән!

Равил имтиханнар тапшырып йөргән арада авылларында да зур гына яңалыклар булды. Искәндәр абыйсы председатель Фәйрүзә апа белән әледән-әле очраша башлады. Моңарчы Равилләргә бик сирәк керә торган Фәйрүзә апа, әллә нинди йомышлар табып, көненә икешәр мәртәбә керә. Искәндәр абый да көндез, халык эштә чакта, председатель янына идарәгә барып утырырга гадәтләнеп китте. Шулай итеп атна-ун көн йөрделәр дә авыл Советына — Качкалакка барып, язылышып та кайттылар.

Аннары дөбердәтеп туй иттеләр. Күрәсең, шушы тантанага күптәннән әзерләнеп килгән булгандыр: Фәйрүзә апа туйга акчаны бер дә кызганмады. Ташый елгада алар туенда берәр кешесе катнашмаган бер генә йорт та калмады. Кайбер йортлардан хәтта өчәр-дүртәр кешене чакырдылар. Искәндәр абыйсы бүләк иткән аккордеонны Равил теге елны нужадан сатканлыгын да, шуңа Искәндәр абыйсы алдында бик

нык оялып-уңайсызланып йөрүен дә белә иде Фәйрүзә җиңгәсе. Үзләренең туенда Равилгә уйнату өчен махсус рәвештә аккордеон сатып алып кайтты.

Равил, болар кайда төпләнеп калырга ниятлиләр икән соң, дип кызыксынып, әмма үзләреннән сорарга читенсенеп йөргән арада тегеләр ул мәсьәләне дә ансат кына хәл итеп куйдылар: Искәндәр абыйсы Фәйрүзә җиңгәсен үзе белән Кемеровога алып китте.

Искәндәр абыйсы Нәсиха җиңгәсеннән соң ике тапкыр өйләнеп карап та алары белән яши алмагач, монысы белән ничек булыр икән инде дип, Равил башта Фәйрүзә җиңгәсе өчен шактый борчылып йөргән иде. Борчылырга урыны да бар иде. Авылларыннан киткән чакта җиңгәсе, Равилнең әнисе янына кече якка кереп:

— Китүен китәм инде, Мәгъсүмә апа, ну, башларымның ниләр күрәсен бер алла гына белә! Председатель булып йөреп, ирдәүкәгә әйләнеп бетә язганмын лабаса: хатын-кыз эшеннән кулларым бөтенләй бизгән! — дип, күз яше белән елап киткән иде.

Куанычка каршы, Равилнең дә, җиңгәсенең дә шикләнүләре бушка чыкты. Искәндәр абыйсы белән Фәйрүзә җиңгәсе әле хәзер дә, унҗиде яшьлек гашыйклардай, бер-берсенең күзләренә генә карашып торалар! Ике кызлары, бер малайлары бар. Кечесе, малайлары, киләсе елда унынчыны бетерергә тиеш. Ә бер кызлары техникум тәмамлап заводта эшли һәм үзе дә бала анасы инде. Уртанчылары Казан университетының биология факультетында укый...



### 34

Ә менә Равилнең бәхетле көннәре озакка бармады. Имтиханнарын тапшырып чыгу хөрмәтенә әнисе Рухияне башта Ленинградка алып китте дә шунда алар туганнарында айга якын торып кайттылар. Аннары, рәхәтләнеп, Агыйделдә су коенып, ял итеп, унынчыда укыр өчен көч җыеп кайтырсын дип, кызны Башкортстанның Илеш районындагы Аю авылына әбиләренә (кызның әниләренә) озаттылар. Менә шуннан соң Равилнең бөтен дөньясы бушап калды. Аны сагыш, моң басты. Күңеле гел нидер көтте, тынгысызланды. Җитмәсә тагын, Рухия Башкортстанга киткәндә, әйдә, үзебезнең түземлегебезне сынап, укулар башланганчы хат та язышмыйча, очрашмыйча да торып карыйк әле, дип сөйләшкәннәр иде. Сөйләшүе җиңел булса да, хәбәрләшмичә торулары бик читен булды аңа!

Ниһаять, Равил түземсезлек белән көткән сентябрь ае килеп җитте. Укулар башланды. Тик бу хәл дә Равилгә куаныч китермәде.

Унынчы класста үзеңне дә укытырга туры килмәсен әле, дип, теге чакта Эшләпә Рухиягә чынлап әйткән булган икән. Сигез-тугыз-унынчы классларны математикадан шул Эшләпә укыта башлады, ә Сөләйман Габдулловичны, институт белеме булмаганлыктан, биш-җиденче классларны укытырга калдырдылар. Равил хәзер тешен кысып булса да, Эшләпәгә Рәмзи Гарипович дип эндәшергә мәҗбүр иде. Узган язда булган хәлләр өчен миңа көн күрсәтәчәк түгел инде бу адәм, дип башта яхшы ук шиккә калган иде Равил. Ләкин Эшләпә Равил уйлаганга караганда акыллырак булып чыкты: аны күрәләтә рәнҗетеп интектермәде. Дөрес, килгән шапкә бер-ике мәртәбә һичнинди хатасыз эшләнгән контроль эшләренә «3»ле куеп, кимсетергә чамалап караган иде каравын. Әмма, бу гаделсезлеккә ачуы чыгып, Равил аннан нигә шундый түбән билгеләр куюының сәбәбен аңлатуны таләп итә башлагач, һәм тегенең әйтер сүзе булмагач, теләмәсә дә «5»ле куярга мәҗбүр була башлады.

Лəкин ул кеше Чүкəйгə килеп эшли башлаган сəгатьтəн алып Равилнең бəхетле, якты көннəрен кара болыт. баскан иде инде. Шуның өстенə тагын үзлəрен укыта башлагач, Рəмзи Гарипович та, Рəмзи Гарипович дип, Рухия дə аның тирəсендə кирəгеннəн артык сырпаланырга тотынды. Ə Равилгə карата, киресенчə, суыныбрак китте. Хəтта мотоциклына да утырмый башлады. Очрашырга кирəк һəм мөмкин булган чакларда да ничектер читлəшə, кемнəндер шиклəнгəн сыман итенə иде ул. Əйбəт кенə сөйлəшеп торган чакларында да, Рəмзи килеп чыкса, əллə нишлəп каушап кала иде.

Аның болай кылануы, əлбəттə, Равил файдасына түгел, киресенчə, Рəмзи тегермəненə су кою иде. «Рəмзи тинтəк кеше түгел, барысын да күреп тора. Берəр вакыт əйбəт кенə итеп мине дə каптырыр əле бу имансыз», дип шиклəнгəн иде Равил. Чыннан да каптырды ул аны. Һей, ничек оста итеп каптырды əле!

## 35

Башыннан ук рəте булмады ул көннең. Башта мотоциклы кабынмыйча интектерде. Аның рəтенə төшенгəлəгəнче тугызынчы ярты булды. Ə тугызда имтихан — математика буенча чыгарылыш имтиханы башланырга тиеш иде. Лəкин монысы əллə ни куркыныч түгел иде əле. Дəреслəр башланырга унбиш минут кала юлга чыгып та соңгармыйча барып житкəн чаклары була торган иде Равилнең. Əмма кисəк исə башлаган жил əллə кайдан гына кап-кара болытлар куып китерде дə, Равил басу капкаларыннан чыгуга, юл тузанын багана итеп бөтереп, бик шəп бер «пəри туе» ясап алды. Шуның артыннан ук коеп яңгыр яварга тотынды.

Ничек кенə ашыкса да, Равил мотоциклын артык куа алмый: салкын һəм эре яңгыр тамчылары битенə шул тикле нык килеп бəрелə — өтеп-өтеп алгандай авырттыра иде. Шул ук вакытта бик үк акрынларга да ярамый, юлны жебетеп өлгергəнче ничек тə мəктəпкə барып житəргə, ничек тə имтиханга элгəшергə кирəк иде аңа.

Равил барыбер вакытында барып житə алмады. Бөтен өс-башы манма су булып, мотоциклыннан чəчрəгəн пычракка буялып мəктəпкə килеп житкəндə имтиханнар башланган иде инде. Равил класслары ишеген ачып керергə рөхсəт сораганда, Рəмзи имтиханга килгəн мəсьəлə һəм мисалларның беренче вариантын кара тактага язып бетереп, икенче вариантын язарга керешкəн, ике имтихан комиссиясе члены парта араларында йөри, ə алыптай дəү гəүдəле бер ир — ронодан килгəн инспектор булса кирəк — классның бер тəрəзəсен бөтенлəй диярлек каплап, тəрəзə буенда басып тора иде.

Равил юеш костюмын салып класс стенасындагы элгечкə элеп куйды да, партасына барып утырып, беренче варианттагы мəсьəлəлəрне чишəргə тотынды. Бик ансат мəсьəлə булып чыкты ул. Рəмзи дəрескə кергəн саен искəртеп-өркетеп килгəн «безнең дəреслеклəрдəгегə караганда бик күпкə катлаулырак имтихан мəсьəлəлəре»нə һич тə охшамаган иде. Мисаллары да бик жиңел, унынчы класс дəреслеклəрендəге мисаллардан бернинди аермалары юк иде.

Буйга класстагы барлык укучылардан озынрак булганга, башкаларга да комачауламассын, үзенə дə иркенрəк булыр дип, Суфия апа көздəн үк Равилне иң арттагы партага ялгызын утырткан иде. Шунлыктан вариантлы контроль эшлəр эшлəгəндə аңа укытучы кайсы варианттагысын кушса, шунысын эшлəргə туры килə торган иде. Бу юлы Рəмзи əллə онытты, əллə исендə булып та берəр төрле мəкер белəн юри оныткатнга салышты — Равилгə кайсы вариантны алырга икəнен əйтмəде. Менə шуңа күрə Равил, туктале, нигə теге вариантны алмадың, дип бəйлəнə башласа, авыз ачып калмас өчен, монысын да эшлəп карыйм дип,

икенче варианттагы мәсьәлә һәм мисалларны да чишәргә кирәште. Алары беренче варианттагыларга караганда да җиңелрәк тоелды, тизрәк эшләнде. Хәзер инде куркыныч түгел, хәзер авыз тутырып сорау бирергә дә була иде. Ул, әйтәсе сүзе барын белдереп, кулын күтәрде.

— Нәрсә анда синең? — диде инспектор, Равилнең кулын Рәмзидән алда күреп алып.

— Мин кайсы вариантны эшләргә икән дип сорамакчы идем.

Инспектор, әле син һаман эшкә тотынмыйча утырасыңмыни, дигән сыман итеп, күзләрен зурайтып, иңбашларын сикертеп куйды да:

— Җаның теләгәнен сайла да җибеп утырмыйча гына эшкә тотын. Имтихан вакытының яртысы үтеп бара бит инде! — диде.

Ләкин Рәмзи, мөгаен, Рухия вариантын эләкмәсен диптер:

— Гафу итегез, Нәҗип Фазлыеч, ул икенче вариантны эшләргә тиеш! — диде.

— Пажалысты, анысы сезнең ихтыярда, — диде инспектор, берсүзсез риза булып. Аннары Равилне кисәтеп куйды: — Әй, син, бөдрә чәч, ишеттеңме анда укытучы абыең әйткәнне?

— Ишеттем! — диде Равил һәм эченнән генә уйлап куйды: «Иштегез инде ишәк чумарын. Миңа беренче вариант ни дә, икенчесе ни: икесен дә эшләп куйдым ич инде мин аларның!» һәм ул караламада эшләгән эшен акка күчерә башлады.

Рухия аннан бер парта аша алда утыра. Күрәсең, мәсьәләсен чишә алмыйчадыр, гел кыбырсый, артына әйләнеп, сорау тулы күзләрен мөлдерәтеп, Равилгә карангалый иде ул. Кызның ярдәм көтүен бик яхшы сизенә иде Равил. Ләкин соңгы вакытларда Рухия Рәмзи тирәсендә чамадан тыш куштанланып йөргәнгә, Равилнең аңа хәтере калган иде шул. Шуңа ул тегенең ялварулы карашын күрмәмешкә салышыбрак утыра иде. Менә шул чакта Рухия тагын бер тапкыр тиз генә Равилгә борылды да аның турына идәнгә түгәрәк итеп йомарланган кәгазь ташлады һәм, күзен кысып, шуны алырга кушты.

Хәзер инде күрмәмешкә салышып утыру килешми иде. Кешенең язмышы кыл өстендә торган чагында үпкә саклап тору егет кеше эше түгел бит инде!

Нәрсә язды икән, дип Равил Рухиянең кәгазен алмакчы булып иелгән генә иде, инспектор аны шундук күреп алды да:

— Әй, син, тик кенә утыр анда! — дип кычкырды.

Шулай да Равил язуны эләктереп өлгергән иде инде. Инспекторның азрак тынычланып, карашын бүтән укучыларга юнәлткәнен генә көтте дә укый башлады. «Равил абый! Миндә беренче вариант. Ә теге имансыз сиңа юри икенчене бирде. Миңа ярдәм итәрсең дип курыкты булса кирәк. Мин бу мәсьәләне мәңге чишә алачак түгел: башым бөтенләй эшләми бүген. Бөтен ышаныч синдә. Син коткармасаң — үләм! Рухия», — дип язылган иде анда.

Кыз бала шулай итеп ялынгач, аңа ярдәм итми буламы соң инде? Мәсьәләсе дә эшләп куелган бит аның. Тик менә ничек итеп, инспектор белән Рәмзигә сиздермичә генә, Рухиягә тапшырырга соң аны?..

Равил беренче вариант мәсьәләсен чишкән кәгазьне Рухиянең аягы янына барып төшәрлек итеп кенә ташлавы булды, инспектор тагын сизенеп алды һәм бу юлы аеруча каты итеп:

— Син нәрсә анда, күкәен сала алмаган тавык шикелле кыбырсып утырасың? Имтиханнан куып чыгарганны көтәсеңмени? — дип кычкырды.

Тапшырасы әйберсе инде тапшырылган, шулай булгач, Равилгә теге агайның кисәтүен һәм хаклы рәвештә кисәтүен, дәшми-тынмый гына үткәреп җибәрергә кирәк иде, әлбәттә. Һәрхәлдә, Равил менә хәзер, кырык яшьлек акылы белән шулай дип саный. Ләкин ул чакта Равил яшь иде, тәҗрибәсез иде һәм, барыннан да элек, башы-аягы белән гашыйк,

шуңа бик гарьчел иде. Ничек инде ул бөтен класс алдында, класстан да бигрәк сөйгән кызы һәм шул кызны үзенә каратырга тырышып йөри торган көндәше — Рәмзи каршында, мыскыл ителүгә түзеп торсын?!

— Ә сез шулай тавыклар йомырка салганны да тикшереп йөрисезмени әле, агай? — диде Равил, алдын-артын күп уйлап тормастан.

Бу юлы, мөгаен, инспектор агайга сабырлык күрсәтергә кирәк булгандыр. Әмма ул да тыелып кала алмады. Аның башта муены кызарып чыкты, аннары ул нервланып, ыжгырып Равил янына килде дә, таудай зур гәүдәсенә һич ятышмый торган нечкә тавыш белән:

— Нәрсә диден әле син, тәрбиясез? Яле-яле, кабатла әле бер шул сүзләреңне, безобразник! — дип җикеренергә тотынды.

Ә менә монысында инде Равилгә телен тешләп калырга кирәк иде. Бер әйткән — җиткән иде. Инспектор агайның кабатларга кушуы үзенүзе белештермичәрәк килеп чыгуын, яшь булса да, чамаларга тиеш иде Равил. Әмма, күрәчәге булгангадыр инде, тыелып кала алмады шул. Тотты да тагын бер кат, бу юлы аеруча нык итеп:

— «Сез соң мәктәпләрне генә түгел, тавыклар йомырка салганны да тикшереп йөрисезмени?» дип әйттем мин сезгә, Нәҗип Фазлыеч! — диде.

Барысы да бик тырышып мәсьәлә чишеп утырганлыктан, беренчесендә Равилнең сүзләренә классташлары бөтенләй игътибар итмәгән иде. Ә менә инспектор агай тузынып китеп, яңадан кабатлаттыргач, барысы да башларын калкыттылар һәм прых-прых көлешергә тотындылар.

Әнә шунда Равилнең уена да килмәгән коточкыч бер хәл булды: инспекторның башта күзләре калайланды, аннары бөтен гәүдәсе калтырана башлады. Һәм ул, бик хәтәр җикеренеп:

— Ах, син, идиот! — дип, Равилгә кизәнгән җиреннән кинәт кенә телсез калды да, бума хастасы тота башлап, идәнгә ауды.

Беркавым нишләргә дә белмичә торганнан ары Рәмзи Килдеков Әнәсне һәм тагын ике тазарак малайны дәшеп китерде дә инспекторны күтәреп укытучылар бүлмәсенә кертергә кушты. Тегеләрнең өчесенә генә авырга килүен күреп, Равил дә ярдәм итмәкче булган иде, ләкин Рәмзи рөхсәт бирмәде. Күзенең агын әйләндереп карады да:

— Марш класстан! Эзең дә булмасын монда бүтән! — дип кычкырды. Мондый хәлдә карышып торудан мәгънә юк иде, әлбәттә. Равил имтихан мәсьәләсенең караламасын укытучы өстәленә куйды да класстан чыгып китәргә мәҗбүр булды.

Имтихан комиссиясе членнары — география укытучысы белән инглиз теле укытучысы — Равилгә кызганулы караш ташлап калсалар да, аны яклап бер сүз дә әйтмәделәр.

## 36

Хәнифә Вәлиулловна мәктәптә булган булса, Равил бу мәсьәләне болай гына калдырмас иде, әлбәттә. Ләкин ул көнне Хәнифә Вәлиулловна юк иде шул. Имтихан комиссиясе члены итеп бүтән мәктәпкә җибәргәннәр иде аны. Ә укыту бүлеге мөдире Наталья Георгиевна белән сөйләшүнең файдасы булмасын алдан ук белеп тора иде ул. Үзе искиткеч гадел, кешелекле булса да, йомшак холыклы ул Наталья Георгиевна. Мондый зур мәсьәләләрне түгел, бик кечкенәләрен дә үзе генә хәл итәргә тәвәккәллеге җитми аның. Аннары тагын ул көнне Наталья Георгиевна үзе дә унынчы «а»да имтиханда утыра иде. Шуңа күрә Равил аның белән бөтенләй сөйләшеп тормады. Пычракка батып беткән мотоциклын сөйрәп, авылларына кайтырга чыкты.

Яңгыр инде туктаган. Кинәт кенә килгән җәйге болытлар кинәт кенә үтеп тә киткән һәм ялтырап кояш чыккан иде. Юллар инде сирки

башласа да, әле тайгак, мотоциклга утырып кайтырга мөмкин түгел иде. Чүкәй күперен чыгып, әрәмәлек буеннан бара башлагач, Равилнең күңеленә, туктале, бу мотоциклны сөйрәп йөргәнче, юллар кибеп җиткәнне көтеп торсам, үзе мине утыртып алып кайтачак бит, дигән фикер килде. Һәм ул инде чабып алырлык булып килә торган хуш исле, чәчәкле үләннәр арасына керде дә сузылып ятты.

Күк йөзе нәкъ кырык тугызынчы елның октябрендә Равил Чүкәй урманы буенда яткан вакыттагыча биек һәм чиста иде. Аерма тик шунда гына: ул чакта көз иде, өрәңге һәм әлмә яфракларына алтын йөгертелгән, кырлар бушап калган, үләннәр чабып алынган, кыскасы, табигатьнең кышкы йокыга әзерләнә башлаган чоры иде. Ә хәзер игеннәрнең шаулап үсеп утырган, үләннәрнең шау чәчәккә күмелгән, бал кортларының шул чәчәкләрдән бал җыя торган чагы. Табигатьнең иң хозур, иң ямьле вакыты. Тереклек ияләренең яшәү һәм үсү чоры. Башка елларда мондый көннәрдә Равилнең дә күңеле шат, хыяллары якты була, ул да дәртләнеп, дөньяның матурлыгына куанып йөри торган иде. Ә менә бүген, киресенчә, дөньяның шушылай матурлыгы аның болай да моңлы, болай да борлыккан күңелен тагын да моңландырып җибәрде. Һәм ул, теге елгы сентябрь көнен исенә төшереп, шул көнне сагынып:

— Их, яңадан кайтарып булса икән шуны! — дип, йодрыкларын кысып, уфтанып куйды.

Ләкин шул уфтанудан башка берни дә эшләп булмый, — үткәнне кире кайтару мөмкин түгел иде. Шуңлыктан ул сабыр гына юл кипкәнне көтеп утырырга мәҗбүр иде... Хәер, юлның юеш булуы аңа бер сылтау гына иде ул чакта. Рухияне көтү өчен уйлап чыгарылган бер сәбәп кенә иде ул. Ә Рухия ул көнне, һичшиксез, Укмаска кайтырга тиеш иде. Имтихан тапшырган көнне ул һәр вакыт кайта торган иде. Нигә безне ташлап йөрисең, дип, Таня белән Вәсимә үпкәлиләр дигән булып, быел Рухия нигәдер Равилнең мотоциклына утырмый, иптәш кызлары белән җәяүләп кенә йөри башлаган иде.

Таня белән Вәсимә ул көнне икәү генә кайтырга чыкканнар иде. Кызлар, Равилне күреп, йөгерешеп килеп җиттеләр дә, иишләдең син, Нәҗметдинов, нигә инспекторга каршы әйттең, дип сорашырга тотындылар. Бу минутларда Равилнең кайгысы аларда түгел иде.

— Бүтән хәсрәтегез булмаса, минем өчен кайгырмагыз, яме! — дип кырт кисте дә: — Басыйрова ник калды? Әллә кайтмыймы ул бүген? — дип сорады.

Мәсьәләне Таня аңлатып бирде:

— Нәҗметдиновны имтиханнан дөрес куып чыгармадылар, инспектор йөрәк авырулы булганга ул гаепле түгел бит, дип сезне яклап Хәнифә Вәлиулловна белән сөйләшеп кcallарга калды ул, Равил әфәнде!

— Кырыр инде кырчыйнныкын! — диде Равил, директорның бөтенләй башка авылда икәнлеген исенә төшереп.

— Аныисын Басыйрованың үзенә әйтерсез инде, Равил әфәнде! — диде Таня. — Ә хәзер, әйдәгез, кайсыбызны булса да беребезне мотоциклыгызга утыртып алып кайтыгыз әле?

— Кайтырлык булса, күптән кайтып киткән булыр идем инде мин, шул кайтып булмаганга ятам да инде — пычрак бит! — дигән булды Равил. Юллар кибеп өлгергән, рәхәтләнеп кайтырга мөмкин булса да, Рухияне көтеп калды.

Рухия кояш баер алдыннан гына күренде. Ләкин ул ялгыз гына түгел, әлеге кипкән балык — Рәмзи белән кайтып килә иде. Әһә, менә эшләр кая таба бара икән, туктале, ни сөйләшеп киләләр икән, тыңлап карыйк әле, дип, Равил мотоциклын куаклар арасынарак шыгайтып куйды да, тал арасына посып, тегеләрнең якынаюын көтә башлады. Алар, әлбәттә, Равил турында сөйләшәләр инде.

— Шул юләр Нәҗметдиновны яклап бүтән берәр укучы Хәнифә Вәлиулловнаны эзләп йөргән булса, ул тикле үк гаҗәпләнмәс тә идем,— дип сөйләп килә иде Рәмзи кызга. — Беркатлы авыл балалары чыннан да яраталар аны. Алар арасында дәрәҗәсе бар ул малайның. Ләкин менә шул авыл балалары да дәшми калганда синең өтәләнеп йөрүең просто аңлашылмый миңа, Рухия!

— Юк, бу очракта мин һич тә килешә алмыйм синең белән, Рәмзи Гарипович! — диде кыз аңа. — Сез бүген Нәҗметдиновны дөрес куып чыгармадыгыз. Аның гаебе юк иде бит! Инспекторга җавап кына биргән иде бит ул. Анда да әле усаллык белән түгел, ялгышлык белән генә каршы әйтеп ычкындырган иде ул аңа.

— Ә син аның ялгыш булганын кайдан беләсең әле?

— Өч ел бергә укыйбыз ич инде без Нәҗметдинов белән. Өч елда түгел, өч айда да кемнең кем икәнен чамаларга була. Юк, Нәҗметдинов инспектор тикле инспекторны түгел, үз иптәшләрен дә урынсызга кимсетә торган укучы түгел ул!

— Син әле дөньяны аңламыйсың, Рухия, яшьлегеңә барасың! Ә дөнья да, кешеләр дә син уйлаганнан күп мәртәбә катлаулырак!

— Анысына мин каршы түгел, Рәмзи Гарипович. Әмма менә бу конкрет очракта мин сезне һич тә хаклы дип саный алмыйм!

— Син һаман балалыгыңа барасың, Рухия.

— Ярый, анысы шулай да булсын, ди. Ә Нәҗметдиновка мәсьәләсенең караламасы буенча билге куярга мөмкиндер бит.

— Булмый шул алай. Аның караламасының очына шайтан үзе дә чыгарлык түгел!

— Ә мин чыктым бит әле!

— Ничек инде ул «мин чыктым?»

— Дөресен әйтсәм, ачуланмассызмы, Рәмзи Гарипович?

— Ачулана ала торган булсам, әллә кайчан ачуланырга тиеш идем инде мин сиңа, Рухия. Ачулана алмыйм шул. Яратам мин сине, Рухия! Син шуны үзең дә бик яхшы беләсең һәм, һаман уенга алган булып, минем өстән көлеп йөрисең. Мин бит сине...

— Кирәкми, Рәмзи Гарипович! Бүтән ул турыда сөйләшмәскә вәгъдә биргән идегез бит инде! — диде Рухия, тегенең сүзен бүлеп.— Беләсезме, бүгенге мәсьәләләрне Нәҗметдинов чишеп бирде бит миңа, Рәмзи Гарипович! Мин үзем үлсәм дә чишә алмый идем аларны.

— Ах, менә нәрсә өчен яклап киләсең икән әле син аны! Менә ни өчен директорга кадәр барып җиткәнсең икән! Кая әле, шуның өчен...

Шулай диде дә Рәмзи Рухияне кочаклап, чупылдатып үбеп тә алды. Шунысы бик гаҗәп тоелды Равилгә: Рәмзи үпкәч, Рухия бөтенләй диярлек үпкәләмәде. (Алар инде Равил качып торган куаклар янынннан үтеп киткән һәм Равил башын сузып карап тора иде.) Тегенең ябык яңагына берне чалтыратып җибәрәсе урында «что сез, Рәмзи Гарипович, үпкәләтәсез бит инде» генә диде дә, шуның белән вәссәлам. Анысын да үпкәләп түгел, чытлыкланып кына әйтте бугай әле. Ә Равил, юләр, кайчаннан бирле бергә йөреп тә үбәргә батырчылык итмәгән иде. Әгәр шушы Озын толымны үбеп алса, дөньялар яктырып китәр, кошлар адәмчә сөйләшә башлар төсле тоела иде аңа. Әнә Рәмзи үпте. Ләкин дөнья да үзгәрмәде. Кошлар да элеккечә, үзләренчә сайрауларын дәвам итә. Рухиягә дә берни булмады...

Моннан соң да карап торуның хаҗәте юк, мәсьәлә болай да бик ачык иде инде. Равил мотоциклын ачу белән, бер тибүдә кабызып кайтып китте. Тегеләр, котлары алынып, икесе юлның ике ягына тайпылып калдылар.

Шул хәлләрдән соң ул мәктәпкә бөтенләй аяк басмаска карар кылды: хәзер аңа укуның бернинди дә кызыгы калмаган иде. Аннары барсам да барыбер файдасы булмас, алдагы имтиханнарга кертмәсләр

инде, дип тә уйлаган иде ул. Шуңа чираттагы имтиханга барып та йөрмәгән иде. Әммә, бәхетенә каршы, әнә шул имтиханына бармый калган көнне үк мәктәп директоры Хәнифә Вәлиулловна кичке якта үзе Ташый елгага килеп:

— Ну, энекәш, мәшәкатьле дә укучы булдың син! Әй, борчыдың да инде Хәнифә апаңны! Тагын ни булды, нигә бүген химиядән имтиханга килми калдың? — дип, башта шактый гына Равилне кыздырып алды. Аннары барысын да энәсеннән җебенә кадәр сорашты-белеште дә, гадәтенчә йомшак итеп: — Әгәр мин ул көнне өйдә булган булсам, бәлки берәр чарасын тапкан булыр идек тә, хәзер соң шул инде,— диде.— Математика белән химияне көз көне тапшырырсың. Ә нәүбәттәге имтиханнарыңны обязательно вакытында тапшырып калырга кирәк!

Менә шуннан соң гына барды Равил мәктәпкә. Язгы имтиханнарын да, көзгә калганнарын да, аумакай һәм ялагай Рухия белән мәкерле Рәмзи Гарипович үч итеп, аеруча зур үҗәтлек белән тырышып, гел «бишле»гә генә тапшырып чыкты.

Ләкин Равил ул елны өнендә генә түгел, хәтта төшләрендә дә күреп хыялланган Казан университетына керә алмады: көзге имтиханнарын тапшырып йөреп соңга калды.

Рәмзи Гарипович әнә шулай тагын бер тапкыр тез астына типте Равилнең! Ләкин бу соңгы тибүе түгел иде әле. Соңгысында ул Равилне миңгерәтеп үк китте. Шул миңгерәвеннән бүгенгәчә айнытканы юк Равилнең. Ник алай килеп чыкканын ул һаман ахырынача төшенеп житә алмый әле.

### 37

Хәнифә Вәлиулловна килеп киткәннән соң чираттагы имтиханга баргач, Равил янына иң әлек Рухия җилкенеп килеп җитте.

— Нигә химиядән имтиханыңны калдырдың син, Равил абый? — диде ул. — Нишләп алай юләрләнеп йөрисең?

— Аның каравы, син бик акыллы бит! — диде Равил, гомерендә беренче тапкыр аңа чын-чынлап ачуланып. — Нишләп теге көнне директорны эзләп йөрдең син?

— Эзләүдән ни мәгънә, барыбер минемчә булмады бит! —диде кыз. Аннары кинәт кенә сорап куйды: — Ә кайдан белдең әле син минем аның белән сөйләшеп карарга йөргәнне?

— Теге көнне Рәмзигә үзең сөйләдең бит!

— Безнең ни сөйләшкәнне тыңлап, шымчылык итеп йөрдеңмени, Равил абый?

— Бер дә тыңлыйсы түгел идем дә, ләкин колакка тыгарга мамыгым юк иде шул.

— Тукта, нигә болай усалландың әле син, Равил абый?

Равил аның соравын ишетмәгәнгә сабышты.

— Ә нигә син ул көнне кызлар белән кайтмадың?

— Башта Хәнифә Вәлиулловнаны көтеп тордым. Аннары ул кайтмагач кайтып китмәкче идем дә, Рәмзи Гарипович көтеп торырга кушты.

— Шу-у-улай-мы-ни-и? Ә аның белән үбешергә кем кушкан иде соң сиңа?

Рухия бурлат төсле кызарып чыкты.

— Анысын да күрдеңмени, Равил абый? — Ул бермәлгә аптырап торганнан соң кисәк кенә батыраеп китте: — Әй, ярар ла инде, бер үбүдән дөнья харап булмагандыр бит инде, Равил абый!

Үзе изтегә санап йөргән шушындый зур мәсьәләгә, житди мәсьәләгә кызның бер дә алай шаккатмыйча каравы Равил өчен аяз көнне яшен суккандай булды. Һәм ул, телсез-өнсез калып, кыз яныннан кырт борылып класска кереп китте.

Кыз аның артыннан кереп:

— Үпкәләмә инде, Равил абый? Ну, ярар, гаеп миндә булды инде. Рәмзи Гарипович белән мин болай гына, физика белән математикадан имтихан биргәнче генә сөйләшкәләп йөргән идем, — дип аңлашырга тырышып караса да, Равил, бөтенләй ишетмәгәнгә салышып, аңа актан да, карадан да җавап бирмәде.

Шуннан ары Рухия танымаслык булып үзгәреп китте. Равил күреп торган чакларда бүтән малайлар янында юри чытлыклана башлады. Бер дә хаҗәте булмаганда да Рәмзи тирәсендә иркә песи шикелле бөтерелә торган булды. Ә чыгарылыш кичәсендә (Суфия апа да, класс-ташлары да бик кыстагач, көзге имтиханга калдырылган булса да, ул кичәгә барырга туры килгән иде Равилгә) тәмам хәттин ашып кыланды. Бүтән кызлар рюмкаларына салынган кызыл шәрабка да иреннәрен генә тидереп куйганда, бу салган берен эчеп бетерә барды. Бүтәннәргә караганда биш тапкыр күбрәк җырлады, ун тапкыр күбрәк биеде. Аннары Равил янына килеп:

— Әйдә, гел боегып кына торма, Нәҗметдинов, бер рәхәтләнеп вальс әйләник әле! — дип, аны тинтерәтергә тотынды.

Равил вальс әйләнә белмәвен әйткәч, әйдә, болай гына, әйләнмичә генә танцевать итик, алайса, дип аптыратырга кереште. Ләкин Равил аны бөтенләй ишетмәгәндәй, кымшанмыйча да бер почмакта басып тора бирде. Менә шуннан соң Рухия түзмәде:

— Ну, егет, болай булгач миңа үпкәләмә инде, яме! — диде дә, Таня белән танцевать итеп йөргән җиреннән Рәмзине аерып алып, шуның белән әйләнергә тотынды...

Ә икенче көнне Рухиянең Рәмзигә кияүгә чыкканлыгы билгеле булды.

Аннары Рәмзи Рухия белән Ферганәгә киткәннәр, шунда калачаклар икән, Рәмзие шунда укытучы булып урнашкан, имеш, дип сөйләделәр...

Дөрес сөйләгәннәр инде болай булгач. Һаман шунда яшәп яталар икән ич әле: котлау хаты Ферганәдән килгән.

## 38

Менә шул.

Менә шушындый хәлләр булган иде безнең Равил белән әлеге котлау хатын язган Рухия арасында.

Аннан соң инде егерме ел вакыт үткән. Ләкин онытылмаган бит шулар. Берсе дә онытылмаган. Ә Рухия менә хәзер дә әле аермачык тере булып, нечкә билле, озын толымлы булып, җитез һәм чибәр булып Равилнең күз алдында басып тора. Күрәсең, беренче мәхәббәт шулай гомер буена саклана торгандыр инде ул. Һәм гомумән мәхәббәтне «беренче» дип атарга кирәк түгелдер. Икенчесе, өченчесе булмый бит аның. Мәхәббәт бер генә, тик бер генә була икән ләбаса! Нигә аны кимсетеп, «беренче» дип тәртип саны белән атадылар икән?.. Әгәр мәхәббәтнең икенчесе яки өченчесе була торган булса, бер Равилне генә читләтеп үтмәс, аңа да килгән булыр иде инде ул. Икенчесе килмәсә дә, өченчесе килгән булыр иде. Ләкин килгәне юк шул әле һаман. Эзләп тә карамады түгел инде кана. Хәтта берсендә тапкан да шикелле булган иде.

...Рухиянең Рәмзигә ияреп Үзбәкстанга ук китеп барганын белеп торса да, Равилнең өмете бөтенләй үк өзелмәгән иде. Рухия Рәмзи белән озак тора алмас, соң булса да ялгышын аңлар да әйләнеп кайтыр шикелле тоела иде аңа. Сөйләшербез, аңлашырбыз, дип өметләнә иде Равил. Шуңа күрә ул көзге имтиханнарын тапшырып йөреп университетка керә алмый калган елны авылларында да, аннары Казанда уни-

версиtetta укыган елларында да бер кызга да күз салмады. Ул турыда хәтта башына да китермәде. Бар белгәне шул уку, шул физика белән математика булды. Гел шул Рухия белән хыялланып яшәде.

Вакыт үтә торды, әмма Равилнең өметләре акланмыйча кала килде. Ә Мәскәүдә аспирантурада укый башлагач, аның хыялларының чынга әверелү мөмкинлеге тагын да ераклашты. Менә шул чакта бер мишәр кызы очрады аңа. Метрода очрады һәм үзе башлап сүз кушты. Зөлфия исемле иде ул. Ләкин үзен Зоя дип атаганны ярата, шулай дәшергә куша иде. Рухиягә охшаганрак иде ул Зоя. Толымнары Рухиянеке кебек озын булмаса да, буй-сынында, күз карашында һәм аяк атлауларында Рухия чалымнары бар иде. Аннары бик ачык, Рухия шикелле үк тере һәм телгә бик оста иде. Бик инсафлы да шикелле тоелган иде. Ләкин асылда алай инсафлы булмаган, Равилнең башын-күзен әйләндерер өчен генә шулай әүлияланып йөргән икән ул. Язылышып кайтканнан соң ук аждаһага әйләнде. Сатучы иде анысы. Равилгә кадәр дә язылышмыйча гына берничә тапкыр иргә чыгып караган нәрсә булган икән. Бу хакта Равил өйләнешкәннән соң гына белде. Ярый, анысына гына түзәр дә иде әле. Безнең заманда андый гына хәлләр очраштыргалый инде ул. Ләкин иң яманы шул булды: бергә тора башлауларына ай да тулмас борын Зоя үзенең элекке «дуслары» белән бәйләнешеп китте. Хәтта бер төнне кунарга да кайтмады. Шуннан соң да аның белән бергә яшәү, әлбәттә, мөмкин түгел иде инде. Һәм Равил, йортка кергәнче утка кер, дигән мәкальнең искиткеч дөрес әйтелгәнлеген үз җилкәсендә татып, Зояга әти-әнисе бүләк итеп алып биргән квартирадан үзенең гомуми торагына кайтты да, дөнья хәлләрен бөтенләй онытып, үҗәтләнеп үзенең фәнни эшенә тотынды.

Менә шул хәлләрдән соң хатын-кыздан гайрәте чигеп, Равил байтак гомер кызлар тирәсенә якын да бармады. Аспирантурасын тәмамлады. Кандидатлык диссертациясен яклады. Ике ел фәнни институтта эшләде. Аннары аны үзенең фәнни шефы — атаклы академикларыбызның берсе:

— Ярый, егет, булды, тырышып эшләдең. Ләкин эшли белгән кеше вакытында ял да итә белергә тиеш! — дип, ирексезләп диярлек, көньяк курортларның берсенә ялга җибәрде.

Анда баргач эш мәшәкатьләре бетте һәм Равил үзеннән-үзе курорттагы гомуми шартларга килеп керде. Ул әле яшь иде. Утызга яңа чыккан гына иде. Шунда бер Казан кызы белән танышып китте. Дөресрәге, кыз аңа үзе гашыйк булды. Казан авиация институтын тәмамлап, вертолет заводында нибары бер ел эшләгән, тупырдап торган егерме биш яшьлек кыз артыннан йөрүчеләр байтак булса да, кыз аларга әйләнеп тә карамады. Ә Равилне үзе дәшеп тауларга алып менде, диңгезгә коенырга һәм кызынырга алып йөрде. Төсе-бите дә чибәр генә, сүзгә-телгә дә ягымлы иде ул. Аның белән сөйләшеп йөрү шактый күңелле иде Равилгә. Ләкин ул аңа гашыйк түгел иде. Ул аны ошаткан гына иде. Курорт срогын тутырып, кыз иртәгесен кайтып китәргә тиешле кичтә дә Равил аңа:

— Тагын өч көн көтсәң, мин сине, ихтимал, үзем белән Мәскәүгә дә алып кайтып китәр идем, Нәзирә, — дип тә шаяртыбрак кына әйткән иде. Ләкин кыз аның шаяртуын чынга алып:

— Ә сез, Равил Нуриәхмәтович, минем өчен өч көнегезне корбан итә алмыйсызмыни? — дип, мәсьәләне кабыргасы белән китереп куйды.

Кыз шулай төрттереп куйгач, Равилнең җене чыкты. Ахыры ни булып бетәрен һич уйлап тормастан, шул ук көнне ул Мәскәүгә очачак самолетка ике билет алды...

Бик инсафлы, турылыклы хатын иде ул Нәзирә. Тора-бара Равил аны ярата да башлаган иде. Нәзирә үзе Равил өчен үлеп тора иде. Шул тикле нык ярата — гел үз янында, гел үзенең күзенә генә каратып торырга тели иде. Ә Равилгә гел аның янында гына тору һич мөмкин

түгел. Кай көннәрдә лабораториядә ярты төнгә тикле тоткарланырга туры килә иде аңа. Нәзирә менә шул хәл белән берничек тә килешергә теләмәде. Сукранып, елап, Равилне «нормальный кешеләр кебек» булырга, эшенә «тугызга барып алтыда кайтырга» өндәп азапланды-азапланды да, теләгенә ирешә алырына өметен өзгәч:

— Миңа көн-төн гел шул үзенең фәнен кайгыртып йөрүче фанатик кына кирәк түгел, миңа үзен сөйгән хатынын иркәли, сөя белә торган ир дә кирәк! — диде һәм кавышуларына ике ел тулганда Казанга кайтып ук китте.

Киткәндә әйткән сүзләре әле дә колагында яңгырап тора әле Равилнең:

— Бел аны: әле хәзер дә син туң йөрәкне яратып китәм мин! Син шул яратуымның кадерен белмәгәнгә китәм. Һәм шуны телим: моннан соң синең күзең төшкән хатын-кызларның берсе дә сиңа әйләнеп тә карамасын да, син дә, минем шикелле, үкенечле сөю утында янып яшәсәң иде дөньяда! — диде ул елап...

...Равил кулына кәгазь-каләм алды да хәрефләрен Чүкәй мәктәбендә укыган еллардагыча итәргә тырышып, җавап язарга тотынды:

«Рухия, бик күп итеп сәлам сиңа, кызый!

Әйе, минем өчен һаман да шулай озын толымлы кызый әле син. Мөгаен, син инде ул толымнарыңны күптән кистергәнсеңдер дә. Ләкин мин сине башкача итеп күз алдыма китерә алмыйм.

Котлавың өчен рәхмәт. Әйе, миңа бүтән кешеләрдән дә котлаулар байтак килде. Ләкин синеке — иң кадерлесе булды. Син дөрес язгансың, әйе, бер төркем хезмәттәшләрем белән бергә миңа да бирелгән бүләктә синең дә өлешең бар, Рухия. Теге чакта мин чикләвектән кайтып килешли син очрап туктатмаган булсаң, мин, мөгаен, шул үзебезнең Ташый елгадан әллә ни ерак китә алмыйча калган булыр идем. Әнә шул чакта очравың өчен рәхмәт, Рухия!

Син миннән тормышым, семья хәлләрем турында язуны үтенгәнсең икән. Гафу ит, кызый, мин синең шикелле матур итеп язарга һаман өйрәнә алганым юк әле. Булмый, фикерләремне язып аңлата алмам мин. Әйдә, без менә болай килешик әле синең белән. Минем шушы ай ахырында Ташкентка бер фәнни киңәшмәгә барасым бар. Шунда барганда Ферганәгә дә сугылыйм да очрашып, кара-каршы утырып бер сөйләшик әле, ярыймы? Бер дә гөнаһсы булмас дип уйлыйм. Ни әйтсәң дә классташлар бит без. Һәм нинди генә классташлар идек әле!

Егерме бишләреннән соң почтага ешрак кергәләп йөр: кайчан Ферганәгә киләсемне һәм кая тукталасымны әйтеп телеграмма сугармын.

Кабат сәлам белән Равил.»

1970—1973.

# ИМАДЕТДИН НӘСИМИ ГАЗӘЛЛӘРЕ

ӘХМӘТ ИСХАК тәрҗемәсендә

*Узган елның сентябрь аенда бөек әзербәйҗан шагыйре һәм философы Имадетдин Нәсиминең туына 600 ел тулды. Шагыйрьнең әсәрләре безнең илебездә һәм дөньяда төрле телләрдә яңгырады.*

●

Гаҗәп, сиңа кавышуның җан икән бәһасе,
Йөзеңнән шундый нур чәчә күзеңнең кояшы.

Рәхимле ходай сыйфаты юк, дисә, төсеңдә,
Ул кеше — бәхетсез кеше, юк аның ходасы.

Кем тапса синең йөзеңдә Җәмшиднең касәсен [1],
Шул булыр җиһан Җәмшиде, әй, айның яңасы.

Синең назлы карашыңнан шашты бөтен галәм,
Шаштырды аны күзеңнең агы һәм карасы.

Күзләреңә ходай язган үнике аятен,
Коръәне дә, китабы да күзеңнең карашы.

Күз салу синең йөзеңә гөнаһ, диде суфи,
Бу аның иң зур ялгышы, бу иң зур хатасы.

Туры идем һәм төз идем сәрби агачыдай,
Бөкте мине хәсрәтеңнән буеңның зифасы.

Теләде сине Нәсими һәм шуңа иреште,
Кабул булды хак алдында, димәк, бар догасы.

●

Әй, күңел һәм күз нурым, бер күрергә сусадым,
Һай, фәрештәдәй хурым, бер күрергә сусадым.

Әй, айдай йөзле ярым, әй, йөрәгем һәм җаным,
Һай, иреннәре балым, бер күрергә сусадым.

---

[1] Җәмшид — борынгы Иран шаһы, Җәмшид касәсе — дөньяда нәрсә барлыгын күрсәтүче касә.

Әй, рәхмәте ходаның, йөзең сурәте аның,
Һай, шаһы матурларның, бер күрергә сусадым.

Әй, тугыз галәм җаны, гашыйкларның иманы,
Һай, гәүһәр чыганагы, бер күрергә сусадым.

Әй, тәхет-таҗ хуҗасы, җаннарның сөйгән ашы,
Биеклеккә юл башы, бер күрергә сусадым.

...Әй, мәңгелек гүзәл йөз, рәхмәтең иксез-чиксез,
Валлаһи, мин тәкатьсез, бер күрергә сусадым.

Әй, ак тәнле гүзәлем, син — җан, Нәсими — тәнең,
Һай, көндәше гөлләрнең, бер күрергә сусадым.

●

Әй, гүзәл, синең битеңдә укыдым корьәнне мин,
Чәчләреңнең арасында җуйдым ич иманны мин.

Мәңгелек нурны йөзеңә бүләк иткән бер ходай,
Шуның өчен бүген сиңа багышладым җанны мин.

Сурәтең — изге китап ул, нурлы йөзең — тулган ай,
Син кояштан алдым ай күк, йөздәге нурларны мин.

Син миңа сигез җәннәтне вәгъдә итәсең, суфи,
Гүзәлем йөзендә таптым шәбрәк гөлестанны мин.

Җәберенә сөйгән ярның мин сабыр иттем, чыдап,
Һәм таптым шушы сабырда дәртемә дәрманны мин.

Әй, Нәсими, тәңренең зур рәхмәте аның йөзе,
Күз салып шул йөзгә, таптым илаһи илһамны мин.

●

Яшермә йөзеңне, сәҗдә кылган ташым [1] шул ич,
Күземне алмыйм, син — күктән, ай-кояшым шул ич.

Атылдым йөзең шәменә мин күбәләк сыман,
Нур күрдем караңгыда, якты юл башым шул ич.

Гыйшыктан баш тартмас гашыйк, әй, гыйшык дошманы,
Баш тарт, дисең, сөйгәнеңнән, шаһиншаһым шул ич.

Кашларың һәм керфекләрең булды исме әгъзам, [2]
Шайтаннан мине саклаучы чын юлдашым шул ич.

---

[1] Сәҗдә кылган ташым — Кәгъбәдәге изге кара таш күздә тотыла.
[2] Исме әгъзам — бөек исем, ягъни алла исеме.

Табынамсың тәңрегә, дип, шәһадәт сорыйлар,
Мин таптым тәңремне, минем табынасым шул ич.

Әй, хуҗасы бу дөньяның, мине фәкыйрьсетмә,
Дәрәҗәм, байлыгым, тиңсез асыл ташым шул ич.

...Аерылдым мин, Нәсими, йөзеңнең гөлеңнән,
Бакчадагы былбылдай, аһым, күз яшем шул ич.

●

Мин тереклек чишмәсе, миндә тереклек суы,
Ятма караңгылыкта, тор йокыдан, эч шуны.

Җәннәт тә, хуры да мин, Кәүсәр[1] дә, Туби[2] да мин,
Нур да һәм ялкын да мин, чүл дә, күл суы да мин.

Күкнең гөмбәзе дә мин, хаклы да һәм хак та мин,
Барсын тудырган да мин, коръән дә, аять тә мин.

Бакча да, түтәл дә мин, җиләс гөлестан да мин,
Динлегә Нух көймәсе, динсезгә туфан да мин.

Тәңренең йөзе дә мин, кыйбла да, иман да мин,
Руза да намаз да мин, саф битле коръән дә мин.

...Җиткезгән, җиткән дә мин, бар да мин, барлы да мин,
Үстергән, үскән дә мин, җиһан да ярлы да мин.

Серле хәзинә дә мин, һәр ике дөньям да мин,
Мөмкинлек, зарурлык та, бар тәндәге җан да дин.

Диңгез дә, энҗе дә мин, күбәләк тә, ут та мин,
Мәйханә дә, мәчет тә, чиркәү дә һәм пот та мин.

Бай да мин, юксыл да мин, юлчы да һәм юл да мин,
Кем моңа каршы, аңа бирәмен мат шунда мин.

●

Аңламыйм һич, бу түгәрәкне сызучы[3] — нәрсә ул?
Нәрсә ул күк һәм аның әйләнү көче нәрсә ул?

Әйләнүче бу тугыз кат күк ясалган ни өчен?
Күктә ай, йолдыз булып күчеп йөрүче нәрсә ул?

Муса[4] һәм Тур[5] нәрсә ул, Шәбли[6] вә Мансур[7] нәрсә ул?
Аждаһага охшаган дар һәм бау очы нәрсә ул?

---

[1] Кәүсәр — җәннәттәге чишмә.
[2] Туби — җәннәттәге агач.
[3] Түгәрәкне сызучы — дәвернең әйләнешен сызучы.
[4] Муса — пәйгамбәр.
[5] Тур — хода белән сөйләшкән тауның исеме.
[6] Шәбли — IX йөздәге атаклы суфи.
[7] Мансур — IX—X йөздәге суфилык мәзһәбен оештырган атаклы суфи.

Кукнең аслы нәрсә ул, фәрештә нәсле нәрсә ул?
Кешегә шул чаклы таләпләр куючы нәрсә ул?

Кәгъбә һәм пот нәрсә ул, чит-ят белән үз нәрсә ул?
Нәрсә чиркәү һәм мәчет, хирка [1] киюче нәрсә ул?

Нәрсә коръәнне өйрәнү, нәрсә хәдис [2] һәм вәгазь?
Шул бер үк фикерне гел тәкрарь кылучы нәрсә ул?

Син кара бал кортына: балы нидән, агу нидән?
Бик гаҗәп, шуның барын бергә җыючы нәрсә ул?

Ут вә су, туфрак вә җил [3] — адәм, диләр. Шул нәрсәгә
Нигә сәҗдә? һәм шуны инкарь итүче нәрсә ул?

Ник сибә җиргә нурын күктән түгәрәк бу кояш?
Утны һәм нурны аңа берләштерүче нәрсә ул?

Кем дә кем белми үзен, ул белми картларның сүзен,
Нинди эш ниндилеген белмәүче кеше нәрсә ул?

Кил, дусым, ятма күзең йомган килеш, кил каршыма,
Аңлатыйм: сиңа кыенлыклар өюче нәрсә ул?

Кит фани йорттан, Нәсими, шундый көн килер сиңа,
Син белерсең: җөббә [4] һәм чалма киюче нәрсә ул?

●

Кая антында торган тугры дуслар?
Кая сүзендә торган чын гүзәл яр?

Кая хаклык сөюче шундый бер ир,
Ки һәр адымда шул хаклыкны яклар?

Кая чын сүз сөйләүче саф күңелләр?
Кая акча сөймәүче зур акыллар?

Кая икърәр итүче шундый бер җан,
Күңелдә юк минем, дип, хакны инкарь?

Кая бу дөньяда саф шундый сәдәф,
Эчендә кайсының мең энҗесе бар?

Кая Мансур кебек хакка гашыйк ир,
Ки муйнын кайсының буды явыз дар?

...Сөйгән ярына кавышты Нәсими,
Ни кайгы, тулса бу галәмгә ятлар?

---

[1] Хирка — дәрвишләр киеме.
[2] Хәдис — пәйгамбәр сүзе.
[3] Ут вә су, туфрак вә җил — ягъни кеше шулардан яратылган, имеш. Хода фәрештәләргә шул кешегә сәҗдә кыларга куша. Шайтан моны инкарь итә һәм сәҗдә кылудан баш тарта. Нәсими бу юлларда шуны күздә тота.
[4] Җөббә — жиңел чапан. Бу юлда Нәсими мулланы күз алда тота.

●

Ураза ае, сакый [1], булды тәмам,
Кил дә бире, бир шәраб һәм — вәссәләм!

Гашыйкыңның бәйрәме — йөзең ае,
Әй, чәчең — мәхшәр [2], рухың — Бәйтелхәрәм! [3]

Иренең юешлеге — җәннәт мәе,
Шундый мәй белән сыйлауда ит дәвам.

Назлы карашың исерткәнгә күрә,
Мәй хәлал булды, ә суфилык — хәрам.

Тәүбәдән баш тарт, суфи, мәй шундый саф,
Килде көн безгә тотарга кулга җам.

...Аералмыйм кәгъбәдән потханәне,
Тәңрене күргәнгә бар җирдә һаман.

Энҗедән кыйммәт Нәсиминең сүзе,
Чөнки хак сүзне сөйли ул һәр заман.

---

[1] Сакый — мәйханәдә мәй бирүче.
[2] Мәхшәр — кыямәт көнендә кешеләр җыела торган урын.
[3] Бәйтелхәрәм — Мәккә шәһәре янындагы изге урын.

# ОЧЕРКЛАР

## КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**МАРТ, 1973**

«Түбән Камада соңгы елларда бер-бер артлы зур предприятиеләр калкып чыга. Шундый зур промышленность комплексларының берсе — Түбән Кама шәһәрендә төзелә торган шиналар заводы. Ул завод Тольятти, Кама автозаводларын һәм авто-хуҗалык машиналарын камералар, покрышкалар белән тәэмин итәчәк.

Производство процессларын машинага көйләү һәм автоматлаштыру, шундый ук профильдәге башка заводлар белән чагыштырганда, хезмәт җитештерүчәнлеген ике мәртәбә, ә производство мәйданының һәр квадрат метрыннан производство продукциясен алуны өч-дүрт мәртәбә арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Быелгы ел — иң җаваплы ел: заводның беренче чираты сафка басарга тиеш!»

«Правда». Мәскәү.

«Безнең шәһәр урамнарында әрҗәләренә «МАЗ-КамАЗ» дип язылган машиналар колоннасын еш очратырга мөмкин. Алар Минск автомобиль төзүчеләренең Чаллыга җибәрелгән продукцияләре.

Минск автомобиль төзүчеләре, илебезнең башка уннарча коллективлары кебек үк, машина төзелеше гигантына кадрлар әзерләргә теләк белдерделәр. 1972 елның сентябрендә Чаллыдан Минскига 700 эшче килгән иде. Аларның барысы да төрлесе төрле һөнәр үзләштерде. Укыту программалары алты айга исәпләнгән һәм ике өлештән тора: теория һәм практика. КамАЗ эшчеләренә тәҗрибәле мастер-инструкторлар беркетелде. Алар шәкертләренә яңа һөнәр үзләштерергә, квалификацияләрен күтәрергә ярдәм итәләр.

Быел Белоруссия башкаласы предприятиеләрендә биш йөзгә якын Чаллы эшчеләре укый һәм эшли. Аларның күбесе автозаводта һөнәр үзләштерә».

«Вечерний Минск». Минск.

«Бишьеллыкның ике елында КамАЗ төзелеше киң колач алды. Моны исбатлау өчен эшләнгән эшләр күләмен характерлаучы бик күп саннар китерергә булыр иде: күпме җир казылган, күпме бетон коелган, күпме металл конструкция монтажланган һ. б. лар. Әмма ул саннар гына барлык эшләнгән эшләрне күз алдына китереп бастырмый әле. Мөгаен, узган елда иң мөһим вакыйга — Чаллыда үзенә кирәкле барлык техника белән тәэмин ителгән куәтле төзелеш оешмасы эшли башлау булгандыр.

Шунысы да әһәмиятле: моторлар ясау һәм коюю производствосы технологиясе француз фирмасы «Рено» һәм АКШ фирмасы «Свинделл-Фресслер» белән техник хезмәттәшлектә эшкәртелә.

Ике арада төзелгән контрактлар нигезендә бу фирмалар технологик җиһазларны КамАЗдагы производство өчен кирәклеләрен генә сайлап җибәрәләр.

Чаллы зур тизлек белән хәзерге заман социалистик шәһәренә әверелә, киң урамнар, проспектлар барлыкка килә, сәүдә үзәкләре, культура учреждениеләре, спорт корылмалары, административ биналар үсеп чыга...

КамАЗның һәм бу комплекс белән бәйле барлык корылмаларның зур темп белән төзелүе — алдан күрелгән әзерлек һәм, икенче яктан, төзелештә эшләүчеләрнең даими инициативасы һәм эшкә иҗади карашы нәтиҗәсе».

«Экономическая газета». Мәскәү.

«Без зур төзелешләргә күнеккән инде. Алар һәркемгә газеталардагы фотолар, кинохроника буенча таныш. Әмма КамАЗдагы эшләр масштабын һәм колачын беренинди фотография дә күз алдына бастыра алмый. Дөресен әйткәндә, бу гигант

төзелеш кенә түгел, бик зур территориягә җәелгән бик күп гигант төзелешләр җыелмасы.

Яңәшә генә яңа шәһәр салына. Анда инде йөз егерме мең халык яши. Шәһәр белән бергә кала өчен кирәкле барлык предприятиеләр — йортлар төзү комбинаты, ит комбинаты, сөт һәм икмәк заводлары, халыкка хезмәт күрсәтү, транспорт предприятиеләре төзелә.

Яңа шәһәрләр салуда мондый темпның дөньяда әлегә кадәр булганы юк иде, диләр белгечләр. Әмма эш бер темпта гына түгел. Эш шунда: бу үсеш алдан планлаштырылганча, уйланганча алып барыла, анда стихиялелекнең һичнинди элементына урын юк. Үсешнең генераль планы һичшиксез үтәлергә тиешле закон булып тора. Хәер, төзелеш көчләренең һәм средстволарының шундый тупланышы нигезендә, шәһәрнең промышленность һәм торак зоналарының комплекслы тиз үсеше башкача булырга да тиеш түгел.

Биредә хезмәтнең темпы һәм ритмы чын-чынлап гаҗәпкә калырлык.

Шоферлар биредә булган шундый бер хәл турында сөйли.

Чаллыга Себердән олы яшьтәге, күпне күргән бер шофер килеп төшә. Аңа әр-яңа үзбушаткыч машина бирәләр. Автобазадан чыга да ул трасса буйлап уза торган машиналар агымына кушылырга җай көтә башлый. Биш минут көтә, ун минут, ярты сәгать — аның машинасына һич урын юк, гаҗәпләнүдән күзләре маңгаена менә моның. Аннан ул газ бирә дә машинаны артка чигендерә.

— Китәм мин сездән,— ди автобаза начальнигына.— Ничә ел рульдә утырып, мондый тамашаны күргәнем юк. Мондый шартларда мин эшли алмыйм.

Бу хәл ничек беткәндер, билгесез. Мөгаен, начальник тәҗрибәле шоферны калырга үгетләп күндергәндер. Әмма бу вакыйга шактый гыйбрәтле.

Эш киеменең җиңенә «КамАЗ төзүче» дигән горур эмблема беркетелгән энтузиастларның күп меңле коллективы төзелеш эшләренең график буенча баруы өчен бар көчен сала. Әлбәттә, биредә аларның үз проблемалары, үз кыенлыклары да бар. Әмма Камадагы бөтен Союз удар төзелешнең характерын алар түгел, ә социалистик ярышның югары рухы билгели».

«Рабочая газета». Киев.

«Казандагы сынлы сәнгать музеенда «Татарстан художниклары — КамАЗга» дигән күргәзмә зур уңыш казанды. Музей залларында йөргәндә бу грандиоз төзелешнең сулышын тоясың, аның геройлары белән танышасың.

Казан һәм Чаллы шәһәрләре художникларының рәсем һәм скульптура әсәрләрендә Кама буендагы яңа, яшь шәһәр шактый тулы сурәтләнә. Унике катлы хәзерге заман йортлары, гаять зур завод корпуслары, йөзләрчә краннар күңелдә горурлык уята.

Безнең сәнгать осталары, диде РСФСРның халык художнигы, Татарстан художниклары союзы идарәсе председателе Х. Якупов, зур төзелешнең яшь эшчесе образын тудырырга омтылалар».

«Комсомольская правда». Мәскәү.

«Мин КамАЗда булып кайткан кино артистларының беренчеләреннән.

Иң кызыклысы нәрсә соң анда? Шул кадәр кешеләрне нәрсә гаҗәпләндерә? Иң элек, әлбәттә, тын Кама елгасы буендагы төзелешнең масштабы. Монда төзелеш барлык нәрсәне уяткан. Шәһәр инде яши, сулыш ала.

Бу гигант төзелеш ничектер миңа космосны күз алдына китерде. Колач чын-чынлап шаккатарлык. Бу Гулливер патшалыгында йөрүчеләр үзләре дә буйлары белән аңа тиң кебек. Туып килә торган шәһәрнең ак кар түшәмдә силуэты күктә йөзгән диңгез корабларының җилкәннәрен хәтерләтә. Һәм боларның барысын да безнең кешеләр, гади совет кешеләре булдырган.

...Һәр грандиоз төзелеш кебек, КамАЗ да — техник күренеш кенә түгел, ул әхлакый, мораль нормаларга да туп-туры бәйле. Чөнки төзелешне кешеләр башкарган кебек, төзелеш үзе дә кешеләрне тәрбияли, аларда корыч ихтыяр тудыра.

Әйе, КамАЗ ул — кешеләр. Үз хезмәтләренең нәтиҗәсен кайгыртучы кешеләр. Бер көнлек өчен генә түгел, киләчәк буыннар өчен эшләүче кешеләр.

Биредә һәркем художник. Биредә һәркем хезмәт хакы өчен генә түгел, ә үз хезмәтенең җимешен күрү өчен эшли.

Үз хезмәтеңнең җимеше...

Кешеләрнең Олы тулай торагы — КамАЗ дип исемләнгән гигант төзелеш уртасында басып торганда, аның турында уйланасың. Аның турында хыялланасың.

Ә тирә-ягында — күз күреме җирдә — биниһая күркәм пейзаж. Әлбәттә, каһарманлыкка монда өйрәнмичә, кайда өйрәнәсең: биредә кешеләр гүзәл татулыкта яшиләр, менә дигән итеп эшлиләр һәм хезмәт җимешләре дә аларның матур».

**Николай Крючков, СССРның халык артисты.**
**«Советская культура». Мәскәү.**

«Бөтен илебез төзи торган Кама автомобиль комплексы Казан кинохроника студиясе хезмәткәрләрен яңа фильм иҗат итүгә рухландырды. Ул «Югары нота» дип исемләнгән һәм анда биеклектә эшләүче монтажчылар бригадасы кешеләре сурәтләнә. Картина геройларының берсе — Сергей Елистратов.

Оператор камерасы аның эшен өйрәнчек вакытыннан ук игътибар белән күзәтә, шул ук вакытта тәҗрибәле осталарның эшен дә күрсәтә. Иң мөһиме шунда: картинада эшче коллективында кеше характерының ныгуы, гомуми эш өчен шәхси җаваплылыкның үсүе гәүдәләндерелә».

ТАСС.

«КамАЗ. Бу сүз әлегә сүзлекләрдә дә, белешмәләрдә дә юк. Әмма аның турында газеталарда һәм журналларда языла, киноларда, телевизион тапшыруларда күрсәтелә. «Камадагы Батыр» дигән китап та Кама автомобиль заводына һәм аның төзүчеләренә багышланган. Бу китап Татарстан китап нәшрияты чыгарырга планлаштырган бөтен бер серия китапларның беренчесе.

Җыентыкка Кама автомобиль комплексы турында үзәк һәм республика газеталарында, журналларында басылып чыккан очерклар, мәкаләләр, интервьюлар, репортажлар, статистик материаллар, фотодокументлар кертелгән.

Шунысы әһәмиятле: аларда сурәтләнгән кешеләр дә, вакыйгалар да — барысы да реаль тормыштан алынган...»

«Книжное обозрение». Мәскәү.

«Сәнгать осталары бөтен Союз удар төзелешендә еш кунак булалар. «Чулпан» кинотеатрында бер атна эчендә генә дә Дагстанның атказанган «Лезгинка» бию ансамбле, Дәүләт академия рус хор капелласы, Ленинград вокаль инструменталь ансамбле — «Алые паруса» һ. б. коллективлар чыгыш ясады. Бу зур төзелеш эшчеләре белән җиңел промышленность әйберләре ассортименты һәм кием культурасы бөтен Союз институты вәкилләре дә очрашты. Баш сәнгать белгече И. Андреева тыңлаучыларга быелгы сезондагы төп юнәлешләр турында сөйләде. Манекенщицалар яңа киемнәр белән таныштырдылар».

«Советская культура». Мәскәү.

«Ата-аналарын, туган йортларын, уңай квартираларын ташлап яшь егетләр, яшь кызлар нигә соң чит-ят җирләргә китәләр? Алар бит белеп торалар: төзелешләрдә күнегелгән уңайлыклар да, торыр, ял итәр урыннар да, бакча-парклар да юк.

Бу сорауга берәүләр бик гадиләштереп җавап бирәләр: янәсе, яшьләргә романтика хас, алар учак ягып палаткаларда яшәүгә тансык. Юк, романтика анда гына түгел. Революцион романтика, батырлыкка рухландыра торган романтика хезмәтнең, эшләгән эшеңнең биеклегендә, әһәмиятендә. Нәкъ менә революцион романтика яшьләрне Чаллыга, төзелешкә чакыра. Әлбәттә, әлегә кыенлыклар күп. Әмма беркем дә куркып калмый, кыенсынмый, киресенчә, һәркем зур, үзбаш эшкә омтыла.

КамАЗ — бетон, цемент, пыяла һәм металл гына түгел. Ул, иң беренче, тормыш мәктәбе. Ярославль кызларының Чаллыдагы тормышы һәм эше турында Зина Лебедева болай диде: «Ярнефтехимстрой трестының комсомол оешмасына без КамАЗ төзелешенә тәкъдим итүе өчен чын күңелдән рәхмәтебезне белдерәбез. Ышанычны намус белән акларга тырышабыз, белемебезне һәм тәҗрибәбезне тулырак файдаланырга тырышабыз».

«Юность». Ярославль.

«Язучыларның һәм журналистларның көндәлек, даими игътибары,— ди партиянең Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Р. Беляев «Литературная газета» хәбәрчесе белән әңгәмәсендә,— безгә материаль-техник җиһазлар кебек үк бик кирәк. Безнең алда торган чын-чынлап бөек бурычларны хәл итү өчен КамАЗ төзүчеләренә — ул кайсы тармакта гына эшләмәсен — әхлакый, идея потенциалы гаять әһәмиятле. Кешеләр максатны тирәнтен аңласыннар, үзләренең нинди зур эш башкаруларын исләреннән чыгармасыннар, гомуми эш өчен тырышсыннар. Язучының ялкынлы сүзендәге төп максатны мин шунда күрәм».

«Литературная газета». Мәскәү.

Тугызынчы бишьеллыкның удар төзелеше — КамАЗның корыла башлавына өч ел тулды. Узган елның төп нәтиҗәсе шунда: Чаллы промышленность үзәгендә уннарча нык производство коллективлары барлыкка килде. Аларның һәрберсе алларында торган иң катлаулы бурычларны гамәлгә ашырырга сәләтле. Ике ел ярым эчендә 679 миллион сум капиталь салым үзләштерелде.

1972 елның сентябрендә үк инде төзүчеләр коллективы көнгә бер миллион сумнан артык капиталь салымнар үзләштерде. Моңа кадәр илебез төзелеше тарихында мондый хәлнең булганы юк иде әле».

«Строительная газета». Мәскәү.

# Игорь Алексеев

# ОЛЫ ЮЛГА ЧЫККАНДА

*Татарстанның кино тарихы турында язмалар*

Совет киносы — күп милләтле кино. Инде егерменче елларның уртасында ук Советлар Союзының күп кенә республикалары һәм өлкәләре илебез экраннарына үз фильмнарын чыгардылар. Ләкин шуны да әйтергә кирәк: милли кинематографияләрнең һәркайсы — революциягә кадәр бу эштә азмы-күпме тәҗрибәле булганнары да, революциядән соң оешканнары да, кагыйдә буларак, эшне хроникадан башладылар.

В. И. Ленинның хроникага нинди зур игътибар биргәнлеге күпләргә мәгълүм. Мәсәлән, беренче Мәгариф наркомы А. В. Луначарский үзенең истәлекләрендә болай яза: «Владимир Ильич миңа, коммунистик идеяләр белән сугарылган һәм совет чынбарлыгын чагылдырган яңа фильмнар эшләүне хроникадан башларга кирәк, диган иде...»

Әлбәттә, тавышсыз кинолардан хәзерге (киң экранлы, төсле) документаль фильмнарга кадәр кинематография чиксез озын юл узды. Тик 20—30 елларда кинохроника өлкәсендә эшләүчеләр тарихи вакыйгаларны олы теләк, зур энтузиазм белән җанландыруларын, кыска метражлы фильмнарга илебез тормышыннан иң әһәмиятле вакыйгаларны гына төшерүләрен басым ясап әйтеп китмичә булмый.

Кино, аерым алганда, хроника шикелле оператив жанрның үсүе һәм камилләшүе — Советлар иле кинематографистларының партиябез җитәкчелегендә бер максатка юнәлтелгән планлы эш алып баруы нәтиҗәсе ул.

Бу җәһәттән, кинохроника тарихына, аерым алганда, Татарстан кинематографиясе тарихына тукталып китү кызыклы булыр.

* * *

Революциягә кадәр киноны төшерү дә, күрсәтү дә шәхси фирмалар, аерым кешеләр кулында иде. Революциядән соң Россиядә яшәүче барлык милләтләрнең рухи тормышы төрле яктан, шул исәптән, сәнгатьнең кино кебек интернациональ һәм тиз тарала торган төре белән дә баеды.

1918 елда Мәскәү (үзәк) кинокомитетының карары белән Казанда, Мәгариф Комиссариаты каршында, театр һәм музыка бүлекчәләре белән беррәттән, кино бүлекчәсе дә оештырылды. Ә инде 1919 елда кинокомитет Мәгариф Комиссариатының аерым бүлегенә әверелде.

Революция еллары, гражданнар сугышы, җимереклек, ачлык — болар, әлбәттә, барысы да совет кинематографистларына бик нык комачауладылар. Мондый шартларда Татарстан кинокомитеты каршында торган төп бурыч — агитация һәм культура эше турындагы фильмнар чыгара торган киноательелар оештырудан һәм барлык шәхси кинематографияләрне хисапка алудан гыйбарәт иде.

Шулай да, революциядән соңгы авыр еллар булуга карамастан, кинога, аерым алганда, кинохроникага һәм тәрбияви әһәмияте булган документаль фильмнарга игътибар бик тиз үсте. 1919 елның 25—26 январенда кинокомитет тарафыннан «Электра» дигән документаль фильм чыгарылды. Бу фильмда Смоленск губернасының Вонляев имениесендә оештырылган коммунаның эше һәм тормышы яктыртылган иде. «Җирне күмәкләп эшкәртү идеясен нинди генә сүзләргә караганда да үтемлерәк пропагандалый торган» бу

фильмны тамашачылар зур кызыксыну белән карадылар һәм аңа югары бәя бирделәр. 1921 елда Казанны азат итүгә 3 ел тулу уңае белән үткәрелгән хәрбифәнни җәмгыять утырышына катнашучыларның: «Казанны алу» дигән кино бар икән — шуны карыйсыбыз килә»,— дигән сүзләре мәгълүм.

Революцион рухлы, агитацион характерлы картиналарга беренче конкурслар үткәрү дә шул чорга карый. «Сценарийлар бер генә кисәктән торырга тиеш, ә кинолентала 300—400 метрдан артмасын» диелә ул конкурсларның шартларында.

Ләкин әле болар барысы да кино өлкәсендә беренче адымнар гына булып, әлегә бу эшне үз кулына алырлык махсус оешма да, кирәкле материаль база да, өзерлекле кадрлар да юк иде. Ул чактагы ситуацияне истә тотып, «Известия ТАТЦИК» болай язып чыкты: «...Бу мәсьәләне тәртипкә салырга вакыт. Хезмәт ияләрен тәрбияләүнең шундый мөһим чарасын игътибарсыз калдыру — дәүләт мәнфәгатеннән чыгып караганда, түзеп тормаслык хәл».

Татарстанда кино эшенең алга китүе һәм үсүе 1923 елга туры килә. Шушы елның башында Мәскәүдә ВЦСПС, Мәскәү шәһәр Советы профсоюзлары, политидарә һәм башка оешмалар инициативасы белән «Пролетарское кино» («Пролеткино») җәмгыяте оештырыла. 1923 елның 14 июнендә «Пролеткино» вәкиле З. Островский Казанга килә. Ә икенче көнне Татпрофсоветның культура бүлегендә партия, совет, профсоюз һәм хуҗалык оешмалары вәкилләренең «Пролеткино»ның максаты һәм бурычлары мәсьәләсенә багышланган киңәшмәсе була. Киңәшмә «Пролеткино»ның Татарстан республикасы белән бәйләнешына киң тукталу, бу бәйләнешның төрле формалары барлыгын ачыклау белән бергә, «Пролеткино» оешмасына пайчылар да билгели; Татарстан кинематографиясен юлга салу, аны җанландыру өчен махсус комиссия дә шушы киңәшмәдә төзелә.

«Таткино»ның рәсми рәвештә эшли башлавын 1924 елның 13 февраленнән санарга мөмкин. Чөнки нәкъ шул көнне Татарстан Мәгариф Комиссариаты үз системасыннан дәүләт фотокиноидарәсенең Татарстан бүлеген аерып чыгара.

Оешуының беренче ике елында ук «Таткино» пропаганда өлкәсендә дә, хроникаль ленталар җитештерү буенча да зур эшләр башкара. 1924 елда «Таткино» бүлеге төньяк-көнбатыш өлкә кино идарәсе белән берлектә Казан тамашачылары өчен «Энштейн теориясе», «Авыл хуҗалыгы күргәзмәсе», «Октябрь революциясенең 6 еллыгы», «Советлар власте өчен» кебек документаль фильмнар карау оештыра. «Таткино» керткән тагын бер яңалыкны — нәфис фильмнар алдыннан хроникаль кадрлар күрсәтүне дә җәмәгатьчелек хуплап каршы ала. «Соңгы вакытта,— дип яза ул чагында «Красная Татария» газетасы,— сеанслар программасына еш кына кыска метражлы кинохроникалар да кертелә. Һәм бу, һичшиксез, сеансларның кыйммәтен арттыра».

Бу елларда кино төшерү өлкәсендә беренче тәҗрибәләр ясала. Бүлекнең махсус белгечләре документаль һәм нәфис фильмнарның титрларын тәрҗемә итә башлыйлар. В. И. Ленинның йөрәге тибүдән туктаган көннәрдә төшерелгән матәм демонстрациясе татарча текстлар белән күрсәтелә; октябрь аенда шәһәрнең татарлар яши торган өлешендә ачылган «Чаткы» кинотеатрында Шәрык тормышын чагылдыручы «Мөселман кызы» дигән нәфис фильм да «Таткино» лабораториясендә татарчалаштырылган текстлар белән бара.

1924 елда Татарстанның яшь кинематографистлары үз көчләре белән дә, Самара белгечләренең дусларча ярдәме белән дә берничә хроникаль лента чыгаралар. Октябрь аенда ук инде Казан кино хезмәткәрләренең актив катнашында Самара «Пролеткино»сы төшергән «Казанда өченче Идел буе олимпиадасы» дигән кыска метражлы фильм Мәскәүгә җибәрелеп, яхшы бәя ала. Моның артыннан ук «Унион» кинотеатрында Казан кинематографистларының үз фильмнары — «Луначарский Казанда» күрсәтелә башлый. Һава шартларының начар булуына карамастан, фильм уңышлы төшерелә. Бу уңайдан газеталар да: «Таткино» техник сынауны яхшы узды»,— дип язып чыгалар.

Татарстан кинохроникасының үсүенә «Пролеткино»ның Самара бүлеге кинематографистлары да зур йогынты ясый. Алар хуҗалык эшләрен яктырта торган һәм агитацион, реклама характерындагы кинолар төшерәләр. Ул чагында Татсовнарком, Комклуб, Татпрофсовет һәм башка бик күп оешмалар, пайчылар рәтенә басып, Татарстан киносын үстерүгә материаль ярдәм күрсәтәләр.

1925 елның 9 мартында «Таткино» оештырылуга ел тулу уңае белән кино хезмәткәрләренең һәм партия, совет, проф-

союз оешмалары вәкилләренең тантаналы җыелышы була. Җыелыш киноны хезмәт ияләре массаларына якынайту буенча «Таткино»ның байтак кына эшләр башкарганлыгын билгеләп үтә. Бу вакыт эчендә Татарстанда биш хроника төшерелә, дүрт зур картина татарчага тәрҗемә ителә, кино белгечләре хәзерләү максаты белән өч кеше кинематография институтына укырга җибәрелә.

Идеология эшенең иң мөһим бер тармагы буларак, кино эшенә республикабызның партия органнары да игътибарларын көчәйтәләр. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты (Агитпропы) каршындагы кино комиссиясе утырышларында «Таткино» һәм «Совкино» эшчәнлеге Совет киносы дуслары җәмгыятен оештыру, картиналарны татарчалаштыру мәсьәләләре тикшерелә. Фикер алышулар вакытында кинохроникалар төшерү һәм аларны пропагандалау буенча да, республикабыз тормышыннан нәфис фильмнар төшерү буенча да эшлекле тәкъдимнәр әйтелә.

Комиссиянең бер утырышында Татарстан тормышын чагылдыра торган нәфис фильм өчен сценарийга конкурс шартлары проекты тикшереп раслана. Бу фильмны үзәктәге кино оешмалары ярдәмендә төшерү күздә тотыла.

1927 елның апрелендә Октябрь революциясенең ун еллыгына багышлап язылган сценарий буенча (авторы А. Шакиров) «Булат батыр» дигән нәфис фильм эшләү өчен «Совкино» белән килешү төзелә.

Бу фильмдагы вакыйгалар Пугачев хәрәкәтенә караган елларны эченә ала. Фильмның тарихи материалларга нигезләнүе баш күтәргән ярлы халыкның патша хөкүмәтенә һәм патша яклы татар байларына каршы героик көрәшен дөрес чагылдырырга мөмкинлек бирә.

Крестьяннар хәрәкәте фонында качкыннар башлыгы Булат батырның шәхси драмасы ачыла. Һәм бу картинаның төп сюжет сызыгын тәшкил итә.

Баш күтәрүчеләр җитәкчесенең ике улы капма-каршы ике лагерьда көрәшәләр. Җәза отрядлары экспедициясенә катнашкан Асфан, хөкүмәт гаскәрләренең коткочкыч ролен аңлаганнан соң, восстаниечеләр ягына чыга. Ә Тимер, киресенчә, сәүдәгәр булу хыялыннан айный алмыйча, крестьяннар хәрәкәте мәнфәгатьләренә хыянәт итә һәм Екатерина гаскәрләре сафында сугыша башлый. Хыянәтчегә кырыс хөкемне әтисе чыгара. Картина Емельян Пугачев һәм Булат батыр гаскәрләренең Казанны алуы белән тәмамлана.

1927 елны Казанның барлык кинематографистлары һәм кино һәвәскәрләре бөтен көчләрен нәфис фильм төшерү эшенә бирәләр. Май аенда «Совкино»дан Казанга кинематографистлар килә. Киноның режиссеры итеп Ю. В. Тарич, операторы итеп инде ул чагында ук В. И. Ленин турындагы кинохроникалары белән танылып өлгергән Г. В. Гибер билгеләнә. Кинематографистлар моннан өч гасыр булып узган вакыйгаларны төшергәндә, мөмкин кадәр тарихи һәм документаль төгәллек сакларга тырышалар. Мамадыш тракты, Арча кырындагы кирпеч сарайлар, шәһәрнең татарлар яши торган өлеше һәм Кремль чыннан да картинага шул еллар рухын бирә. Казанка белән Кремль арасына берничә агач йорт салып куялар. Бу йортларга кино төшерү барышында ут төртелә. Шәһәрне штурмлау манзарасын төшергәндә 15 меңнән артык кеше, шул исәптән, Казан хәрби гарнизоны сугышчылары да тартыла. Бу киноны төшерү эшләре Казаннан тыш Камада һәм Вяткада алып барыла.

Кинематографистларның Татарстанда беренче тарихи нәфис фильм төшерүләре ничек бәяләнүен белергә теләсәк, газеталарга күз салыйк. Бу хакта «Красная Татария» газетасы менә нәрсә яза: «Булат батыр» без моңа кадәр караган Шәрык картиналарыннан күп өстен. Картина татар халкының тарихын, көнкүрешен берниндикүпертүләрсез, купшы бизәкләрсез, хәтта романтик буяуларны артык куертмыйча дөрес итеп, реаль җирлектә чагылдыра. Фильмда политик хаталар юк — күренә ки, сценарист һәм режиссер бу җаваплы темага җитди караганнар һәм зур әзерлек белән керешкәннәр».

Техник яктан да фильмга тел-теш тидерерлек булмый. Шәһәрне тупка тоту эпизоды, Пугачев гаскәрләренең Булат батыр отряды белән очрашуы, Идел буе урманнары, Кама таулары, Вятка буе әрәмәлекләре аеруча уңышлы чыга.

«Булат батыр» кинофильмын төшерү, бер яктан, Татарстанда социалистик культураның үсешен күрсәткән зур вакыйга булса, икенче яктан, сәнгатьнең бу яңа өлкәсендәге эшләрнең камилләшүен раслый торган бер дәлил була. Шуңа күрә дә инде Октябрь революциясенең ун еллыгы уңае белән культура-тәрбия эшләренең нәтиҗәләре турындагы докладта «Булат

батыр» — Татарстанның үз фильмы» дип телгә алына.

Бу еллар Татарстанда кинохрониканың тагын да ныграк үсүе белән характерлы. Казан кинематографистлары төшергән һәрбер яңа кинохрониканы тамашачылар яратып кабул итә, республикабыз хезмәт ияләренең тормышын чагылдырган документаль кадрларны кызыксынып күзәтә.

1927 елда республикабыз кинематографиясе тагын да ныграк үсә, кинохроника даимиләшеп җитә. Идарә директорының урынбасары Гринберг (профессиясе буенча оператор) үзе Казан тирәсе күренешләрен һәм хроникаль кадрлар төшерә башлый. Бу чорда төрле тантаналы утырышлар, иске һәм яңа Казан күренешләре, эшче һәм крестьян хатын-кызлары съезды, «Красная Татария» типографиясендәге эш процесслары кинога төшерелә.

Октябрь революциясенең ун еллыгына «Наданлыкны бетерү» җәмгыяте заказы буенча республикабызда махсус фильм эшләнә. Татарстанның «Наданлыкны бетерү» җәмгыяте советы каршындагы мәктәпләр тормышыннан төрле эпизодлар, олылар өчен оештырылган авыл һәм шәһәр мәктәпләренең эше турында сөйләүче кадрлар, әлбәттә, тамашачыларның һәркайсына якын һәм аңлаешлы була. Шуңа күрә дә бу лента Татарстанның гомуми кинохроникасына кертелә һәм Октябрь бәйрәме алдыннан экраннарда күрсәтелә.

* * *

Татарстанда кино эшенең үсүендә илебезнең көньяк республикаларында яшәүче эшче-крестьяннарның аң-белем дәрәҗәсен күтәрү максаты белән төзелгән «Восток-кино» милли оешмасы зур роль уйный. Чөнки «Восток-кино» составына Татарстан да керә.

1929 елда ук инде «Восток-кино» Татарстанда ике кинолента эшләүне планлаштыра. Аларның берсе «Койрыклы йолдыз» исемле нәфис фильм, икенчесе «Татарстанның ун еллыгы» дигән документаль кино була.

Республикабызда совет власте елларындагы үзгәрешләрне мөмкин кадәр тулырак чагылдырырга тиеш булган документаль кино 1929 елның мартында эшләнеп бетә һәм прокатка чыгарыла.

Соңгы варианты «Татарстан» («Дүрт елга иле») дип исемләнгән юбилей фильмы беренче мәртәбә Мәскәүдә, «Красный богатырь» заводында күрсәтелә. (Бу коллективта татар эшчеләре дә күп иде.)

Тагын бер айдан бу фильмны Казан тамашачылары да карый башлыйлар.

«Татарстан» фильмы — безнең республика турында беренче зур документаль фильм — тамашачыларга аеруча нык тәэсир итә. Әгәр дә казанлылар «Булат батыр» киносының кайбер җитешсезлекләрен моннан күп еллар элек барган вакыйгалар бәрабәренә кичерсәләр, хәзер, ун ел эчендә үзләре төзегән яңа тормышны экранда бөтен тулылыгы белән күрергә теләгәнлектән, «Татарстан» фильмына карата бөтенләй үзгә фикердә булалар, кинематографистларга олы таләпләр куялар.

«Восток-кино» эшләгән лентаны язучы Г. Кутуй тәнкыйтьләп чыга. Татар хезмәт ияләренең революциягә кадәрге тормышы картинада уңышлы күрсәтелүенә тукталу белән бергә Г. Кутуй «фильмның иң җитди хатасы — пролетариатның, аерым алганда, татар эшчеләренең Октябрь көннәрендәге революцион ролен чагылдыра алмауда икәнлеген әйтә. «Картинада,— дип яза ул,— эшчеләр белән ярлы һәм урта хәлле крестьяннар массасын берләштерүче җитәкче көчләр юк...» Г. Кутуйның бу фикерен С. Галиев, А. Шәрәфетдинов, Л. Соколов һәм башкалар үстерәләр. Алар фильмда Казанның В. И. Ленин исеменә бәйле урыннары күрсәтелмәвен, Я. Шейнкман, Я. Чанышев, К. Якубов кебек ялкынлы көрәшчеләрнең игътибар үзеннән төшеп калуын, Совет Татарстанының культурасына һәм сәнгатенә кагылышлы кадрлар булмавын ачынып язалар.

Ун ел эчендә Татарстанда булган вакыйгаларның барысын да бер лентага сыйдыру, әлбәттә, мөмкин түгел иде. Шулай да, «Восток-кино» кинобригадасы адресына әйтелгән тәнкыйть сүзләренең хак булуын танырга кирәк. Әлеге хаталар кино оешмалары белән республикадагы культура көчләре арасында бәйләныш булмавын, кино төшерүчеләрнең җирле материалны, милли республикаларның үсеш тенденцияләрен белмәвен күрсәтте.

«Койрыклы йолдыз» исемле нәфис фильм авторлары үз алларына ялган экзотикадан тулысы белән арынган милли кинофильм төшерүне максат итеп куялар. Төп вакыйга күпчелек татарлар яши торган шәһәрчектә барырга, шушы фонда муллаларның, реакцион татар сәүдәгәрләренең сыйнфый йөзе фаш ителергә тиеш. Ләкин, кызганычка каршы, экранга чыккач,

әлеге фикернең хыялда гына калганлыгы ачыклана. Вакытлы матбугат бу фильмга бик хаклы рәвештә «кинохалтура» дип бәя бирә. Революциягә кадәрге татар халкы тормышын сурәтләгәндә тарихи дәреслекне бозып күрсәтү, этнографияне һәм крайның үсү үзенчәлекләрен белмәү — бу сәбәпләр барысы да фильмның бик йомшак булуына китерә.

Әлеге уңышсызлыклар җирле кино базасы булдыру һәм милли кадрлар тәрбияләүгә игътибарны көчәйтү кирәклеге турында сөйлиләр. Шуңа күрә 1930 елның апрелендә Казанда «Восток-кино»ның Татарстан бүлеге ачыла. Озакламый бу бүлек каршындагы җитештерү базасы Идел буе республикаларындагы социалистик төзелеш турында хроникаль фильмнар чыгара башлый. Кинофильмнарга төрле текстлар язу өчен махсус лаборатория җиһазландырыла, яңа аппаратлар алына.

Бу чараларның барысы да кино эшенең үсеген, ныгуын тизләтәләр. Нәтиҗәдә «Татарстанның 10 еллык юбилее» дигән фильм бөтен Союз экранына чыга. Тиздән Казан шәһәре предприятиеләрендәге социалистик ярышны һәм ударниклар хәрәкәтен чагылдыра торган фильм — «Чакыру» төшерелә. Аннан соң «Тугызынчы», «Ижминвод», «Икмәк өчен көрәш», Казан укчы дивизиясе турында документаль фильм һәм башка бик күп картиналар дөньяга чыга.

Ләкин әле бу вакытта Казан кинохроникасы махсус оешма булып яшәми. Кино төшерү планы рәсми рәвештә расланмаган була. «Союзкинохроника»ның Татарстан бүлеге бары тик 1932 елның 1 апрелендә генә оештырыла.

1931—1932 елларда республикабыз кинохроникасы даимиләшеп, тәмам ныгып җитә. Казанда оешкан төстә һәм системалы рәвештә хроникалар төшерелә башланганнан бирле иллегә якын кыска метражлы документаль фильм эшләнә, йөзгә якын сюжет бөтен союз экранына чыгарыла. Бу елларда «Союзхроника»ның Казан бүлеге башка Идел буе республикаларына да хезмәт күрсәтә.

1932 елдан «Татарстан» киножурналы даими рәвештә чыгарыла башлый.

Татарстанның бай һәм күп яклы тормышы, хезмәт геройлары, алдынгы колхозлары һәм предприятиеләре журналның ике-өч ел эчендә чыгарылган 30 санында тулы чагылыш таба.

Бу елларда кинематографистлар арасында да, матбугат битләрендә дә «беренче» сүзе еш яңгырый. «Союзкинохроника»ның Татарстан бүлеге беренче тапкыр К. Тинчуринның «Булат батыр» һәм «Зәңгәр шәл» спектакльләрен пленкага язып алды. Беренче мәртәбә оператор К. Мотков гармунчы Тунишев белән, аның уйнавын тавышлы кинога төшерү өчен Мәскәүгә китте. Татарстан АССРның 15 еллыгына багышлап чыгарылган «Татарстан» киножурналының бер саны беренче тапкыр тавышлы итеп эшләнде. Беренче кат 1939 елны «Кинопленка» тәҗрибә-экспериментал станциясе тарафыннан эшләнгән пленка уңышлы сынау узды...

Кинохроника, «җанлы тарихның аерылгысыз кисәге буларак», тамашачылар арасында көннән-көн киңрәк популярлаша. Хезмәт ияләре җирле һәм союз күләмендәге киножурналларны зур кызыксыну белән карыйлар. Әгәр дә нинди дә булса нәфис фильм алдыннан документаль картина күрсәтелмәсә, кинотеатрны тәнкыйть итәләр. Мәсәлән, «Красная Татария» газетасында без: «Халык журнал сорый... Киножурналлар һәм кыска метражлы фильмнар өчен махсус сеанслар оештырырга кирәк» дигән юлларны укыйбыз.

1939 елның февраленнән Идел буендагы барлык автономияле республикалар өчен дә уртак киножурнал чыга башлый. Соңга таба аны «Халыклар дуслыгы» дип атыйлар. Бу журналның беренче саннарында ук тамашачылар «Спартак» берләшмәсе стахановчылары белән беррәттән Ижевск мотоцикл заводы эшчеләрен, «Кызыл яшьләр» артеле колхозчылары белән беррәттән Мари АССР студентларын да күрәләр. Әнә шулай итеп, Идел буенда яшәүче тугандаш халыкларның зур киноелъязмасы башлана. Автономияле республикаларда милли политиканың тантана итүе, промышленность һәм авыл хуҗалыгы, сәнгать һәм культура өлкәсендәге уңышлар турында сөйләүче кадрлар экраннарда көннән-көн киңрәк урын ала.

1939 елны Казанда зур киностудия төзү турында проект раслана. Ләкин бу проект тормышка ашмый кала — Бөек Ватан сугышы башланып китә. 1942 елда кинохрониканың Казан бүлеге Куйбышев киностудиясенең хәбәрчеләр пункты итеп үзгәртеп корыла. һәм егерме ел буе шул сыйфатында эшләп килә. Фәкать 1961 елда гына, махсус бина салынып, Казан кинохроника студиясе бүгенге хәленә китерелә.

Габдрахман Минский

# ДУСТЫМ ТУРЫНДА

„Достум»...

Бу сүзне тырнаклар эченә алып язуымның бердәнбер сәбәбе шунда, мондый җылы сүз белән миңа беренче тапкыр күренекле әзербайҗан язучысы Мәһди Хөсәен эндәште, мине дус итеп, якын күреп, үз телендә «достум» дип эндәште. Шуннан соң, бик тиз вакыт эчендә, бу достум сүзе бер-беребезгә ихлас якынлык тудырган уртак исемгә, хәтта, мин әйтер идем, мулла кушкан исемем белән беррәттән, Мәһди «кушкан» икенче исемемә әйләнеп китте. Һәм институтта бергә укыган әзербайҗан язучылары Рәсүл Рза, Сабит Рәһман, Әнвәр Мәммәдханлы иптәшләр дә, Мәһдигә ияреп, миңа достум дип эндәшә башладылар. Шул рәвешчә, рәхмәт яугыры Мәһди Хөсәеннең кешелеклеге аркасында, минем кебек шул елларның кайбер вакыйгалары шаукымы белән иҗат ялгызлыгы кичергән берәүнең болытлы көндәй боек күңелен ачып, яктыртып җибәргән дуслары ишәеп китте... Институтны тәмамлап, 1938 елның көзендә Баку киностудиясенә эшкә килгәч, дуслар тагы күбәйде. Ә инде Ватан сугышы елларыннан соң ТАССның әзербайҗан бүлеге (АзТаг) редакциясендә эшләп, журналист буларак, күп кенә әзербайҗан авылларында, шәһәрләрендә, аеруча, күңелемдә якты истәлек калдырган автономияле Нахичиван республикасы районнарында, аның Неһрәм, Ордубад, Карабаглар, Бөек дөз, Шаһбуз кебек ямьле почмакларында гизеп, Араз елгасы буендагы бу яшь республиканың хезмәт кешеләре белән очрашкан саен дуслар саны артканнан-артты.

Әле бүген дә, ул истәлекле көннәргә 30—35 ел вакыт узуга карамастан, исемнәре күңелем түрендә сакланган әзербайҗанлы дусларны хәтерләгән саен, миңа мондый рухи байлык — дуслык хәзинәсенә юл ачкан газиз дустым Мәһди Хөсәен каберенә рәхмәтләремне чәчәкләр урынына сибәрдәй булам...

Югарыда әйтеп узганымча, шул чорның кайбер хәлләре аркасында, әдәби күгемне беркадәр болыт каплаган көннәрдә башланган бу дуслык алгы язмышым өчен шул хәтле якты, шул хәтле бай сәхифәләр ачты, ул сәхифәләрдә үз күзем белән күреп, тавышларын ишетеп калган һәм иҗатларына баш игән мәшһүр композитор, драматург Үзеир Гаджибеков, атаклы романист Мәммәд Сәед Ордубады, зур шагыйрь Сәмәд Вургун исемнәре язылган. Бу бөек шәхесләрнең берсе — Сәмәд Вургун белән истәлекле очрашуларым, зур шагыйрьнең миндәй бер татар баласына күрсәткән игътибар вә хөрмәте турында шагыйрьнең алтмыш еллыгы уңаеннан «Социалистик Татарстан» газетасында басылган «Бөек гашыйк» исемле истәлегемдә язып чыккан идем инде. Аннары шагыйрьнең туганнарыннан берсенең соравы буенча махсус истәлек язып биргән идем.

Бара торгач, еллар узып яшьлегебез бакчасына кырау төшә башлагач, бу дуслык, чал Идел елгасы буендагы Казан белән зәңгәр Хәзәр диңгезе ярындагы Баку арасының ераклыгына да карамастан, безне якынайтканнан-якынайта барып, туганлык дәрәҗәсенә җитеп үсте. Шуңадыр инде, 1958 елның декабрендә, Татарстан кунагы сыйфатында әзербәйҗан язучылары съездына Бакуга килгәч, Мәһди үзенең «Сәһәр» романын миңа «Гардашым Рәһмана, ядикар олараг»[1] дигән автограф белән бүләк итте.

Бер безнең шәхси дуслыгыбыз гына булмыйча, гомумән, әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы көченнән илһамланып язылган шушы юллардан соң, еллар артында калган яшьлегебезгә әйләнеп кайту кирәк булды...

1936 елның көзе.

Без — Украинадан, Белоруссиядән, Әзербәйҗаннан, Грузиядән, Үзбәкстаннан, Татарстаннан килгән бер төркем яшь язучылар — Мәскәүнең иң гүзәл һәм тарихи биналарының берсендә урнашкан Бөтен Союз кинематография институтының яңа кабул ителгән студентлары — бер-беребез белән күрешәбез, танышабыз, тулай торак бүлмәләренә урнашабыз. Әнә шундый күңелле дә, шатлыклы да ыгызыгы вакытында безнең белорус язучысы Михась Блистинов белән урнашкан бүлмәбезгә яшь кенә, мөлаем гына бер егет килеп керде. Урта буйлы, өсте-башы бик пөхтә, тыйнаклыгы, нур өстенә нурдай, көләч мөлаемлылыгын тагы да көчәйтеп-ямьләндереп җибәргән, беркадәр тырпаебрак торган шомырт чәчле, уктай сызылган кыйгач кара кашлы, күз карасында елмаюы балкыган егет иде бу.

— Сәлам! — диде ул керә-керешкә һәм, иске танышны күргәндәй, елмаеп миңа карады:

— Сез Татарстаннанмы?

Егетнең минем каян булуым белән кызыксынуының сере шул минутында ук чишелде: татар әдәбиятының бөек шәхесләре Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов иҗатларына гашыйк икән. Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр», «Казакъ кызы», «Кызыл чәчәкләр» әсәрләренә карата фикерләре белән уртаклашты. Мин исә аңа татар әдәбияты һәм театры сәнгате дөньясында Мирза Фәтәли Ахундов, Җәлал Мәммәд Кули-Задә, Нариман Нариманов, Үзеир Гаджибеков, Җаббар Җаббарлы исемнәренең популярлыгы турында сөйләдем. Ике халыкның бөек сәхнә реформаторларыннан Араблинский белән Габдулла Кариев труппалары арасындагы иҗади дуслык турында сөйләгән тарихи документларны телгә алдым.

Табигый, халыклар дуслыгы нигезендә корылган социалистик культурабызның рухи хәзинәсендәге мондый якты фактлар без ике яшьне, һичшиксез, үз тәэсиренә алырга тиеш иде һәм бу шулай булып чыкты да. Озак та узмады, без — украинлы Микита Шумило, грузин Григол Чиковани, белорус Илларион Барашко, үзбәк Сабир Мөхәммәтов һәм югарыда исемнәрен атаган әзербәйҗанлы иптәшләр — бер-беребезгә «достум!» дип эндәшә башлап, чын мәгънәсендә дуслашып киттек.

Татар халкының бер әйбәт мәкале бар: «дус дуска авызыннан өзеп бирер», ягъни кабасы ризыгын үзе капмыйча дустына бирер... Мәһди Хөсәен шундый дусларның берсе иде.

1938 елның язында Ватаныбыз башкаласы Мәскәү шәһәрендә әзербәйҗан әдәбияты һәм сәнгате ункөнлеге үткәрелде. Бу зур бәйрәмгә М. Ф. Ахундов исемендәге әзербәйҗан дәүләт опера һәм балет театры үзенең яңа хезмәтен — либреттосын М. С. Ордубады, музы-

[1] Гардашым Рәһмана, ядикар олараг — кардәшем Габдрахманга, истәлек итеп.

касын Үзеир Гаджибеков язган «Кероглы» операсын алып килгән иде. Мин бу спектакльгә эләгергә теләп, билет эзли-эзли, кассадан кассага күпме генә чапсам да, тырышлыгым бушка чыкты. Мондый үкенечле хәлне Мәһдигә сөйләгәч, ул мине юатырга теләп:

— Кыен булыр, достум, кыен булыр эләгүе. Бакуда булса бер хәл иде... Әмма монда билет табу кыен булыр. Зарары юк, күрерсең әле,— диде.

Нишләмәк кирәк, башка чара калмагач, аның белән килешергә туры килде, әлбәттә. Әмма бу «килешү» кыска гомерле булып чыкты. Икенче көнне иртән Мәһди мине институтта очратып, сере бар кешедәй, бераз елмаеп торгач:

— Достум, «Кероглы»ны бик карыйсың киләме? — дип сорады.

Мондый сүзләрнең төбендә нинди мәгънә ятуын шунда ук абайлап, мин елмаеп җибәрдем.

— Менә сиңа билет,— диде ул, бик пөхтә эшләнгән чакыру билетын сузып,— өчебезгә бер билет биргәннәр иде, без аны сиңа бүләк итәргә булдык.

Аның бу тәкъдиме шул хәтле ихлас, шул хәтле дустанә һәм җылы булып чыкты ки, мин, «рәхмәт, дустым!» диюдән башка, әйтер сүз дә таба алмадым.

Үз гомеремдә онытылмас тәэсир калдырган «Кармэн», «Аида» операларыннан соң караган гаҗәеп матур опера «Кероглы» булды дисәм, һич арттырып әйткән булмамын. Соңыннан инде бу операны мин Бакуда яшәгән елларымда берничә тапкыр карадым һәм бүгенге көнгә кадәр Кероглы (мәшһүр әзербәйҗан җырчысы Былбыл), Нигяр (Кнарык Григорян) арияләре, искитмәле моңга бай агышлы музыкасы белән, күңелемдә саклана...

Институтта уку елларында миңа Мәһди белән совет кинематографиясе һәм театрның атаклы осталарыннан С. М. Эйзенштейн, Вл. Вольненштейн, В. Шкловский, А. Кулешов, Г. Александров лекцияләрен тыңлаудан, Мәскәүнең МХАТ, Вахтангов, Мейрхольд театрларында Качалов, Москвин, Хмелев, Тарасова, Бабанова кебек сәхнә йолдызлары катнашындагы спектакльләрне караудан туган фикерләребез турында кызыклы әңгәмәләр, күңелле бәхәсләр алып барырга, бу бәхәсләрдә Мәһдинең эрудицияле һәм таләпчән художник булуын күреп, яхшы мәгънәдә аңа сокланырга туры килә иде. 1938 елда институтны, аның академия тибындагы сценарий факультетын тәмамладык.

Укулар тәмамлангач, төрлебез төрле якка, һәркем үз республикасына эшкә билгеләнде. Бакуга кайтып китәр алдыннан, Мәһди минем киләчәгем, алган белемем буенча кайда эшләргә чамалавым белән кызыксынды. Чөнки Татарстанда нәфис фильмнар студиясенең булмавын ул да белә иде. Әлбәттә, миңа Казан кинохроника бүлегенә кайтып та булачак иде, әмма академия тәмамлаган берәү өчен мондый тар профильдә эшләүне үзем дә, Мәһди дә кулай тапмадык.

— Әйдә, теләсәң, алып кайтабыз Бакуга,— диде Мәһди һәм бу тәкъдимнең җитди әйтелүен аңлаткан сыман сөйли башлады,— мин дә, Әнвәр дә Баку киностудиясе өчен сценарийлар язсак та, әмма аның штатында торып эшләячәк кешеләр түгел. Ә аларга синең кебек кино буенча махсус югары белемле кадрлар бик кирәк, син студия штатында эшләрсең, ә без сиңа булышырбыз... Кызыктыргыч тәкъдим иде бу.

Озак та узмады, миңа Баку киностудиясе директоры Бәһрат Григорьевич Асриевтан студиядә эшләргә чакырып рәсми телеграмма килде. Моның дустым Мәһди инициативасы белән эшләнүен аңлавы артык кыен түгел иде.

Телеграмманы алып, барыргамы-юкмы дип икеләнеп йөргән көннәремдә Мәһдидән хат килде. Дусның гаять җылы язылган хатында:

«...Килегез, мотлак килегез, Каспий дулкыннары сезне сәламләп каршылаячак!» — кебек юлларны укыгач, бердән канат үсте һәм без хатыным Сәлимә белән Баку сәфәренә хәзерләнә башладык...

Баку киностудиясендә хезмәт итү еллары минем өчен гаять әһтәмиятле һәм иҗади бай үтте. Студиягә эшкә килгән көннәремдә Әзербайҗан кинематографиясенең күренекле остасы, кинорежиссер Сәмәд Мардановның «Кәндләләр» фильмын тәмамлаган чагы иде. Студия өчен Мәһди Хөсәен, Әнвәр Мәмәдханлы, Сабит Рәһман, Микаэль Рәфили иптәшләр яңа сценарийлар язарга керештеләр. Кинорежиссер Ага Рза Кулиев талантлы һәм сәләтле яшь кинодраматург Имран Касумовның «Яңа горизонт» сценариесе буенча фильм төшерүгә хәзерлек башлап җибәрде. Кыскасы, Баку киностудиясендә иҗади атмосфера көчәеп китте. Шул көннәрнең истәлекле вакыйгаларыннан берсе булып студия худсоветы утырышында мәшһүр композитор Үзеир Гаджибековнең «Аршин мал алан» комедиясе буенча Сабит Рәһман язган киносценарийның тикшерелүе күңелдә калган.

Әрмәнстан кино сәнгатенең күренекле вәкиле Амо Бекназаровның М. Рәфили сценариясы буенча «Сабухи» фильмын куюы да истәлекле вакыйгаларның берсе булды. Аеруча сценарийның худсовет утырышында, язучылар җәмәгатьчелеге катнашында, кат-кат укылуы, бу укуларда Микаэль Рәфилинең искитмәле бер эмоциональ көч белән нәфис укуның югары осталыгын күрсәтүе ул чагында бер мине генә түгел, бик күпләрне сокландырган иде. Ә инде соңыннан, сценарий укылып фикер алышулар башлангач, кызып киткән кайнар бәхәсләрдә Сәмәд Вургун, Рәсүл Рза, Мәһди Хөсәеннәрнең булачак фильм герое — әзербайҗан халкының данлы улы, мәгърифәтче, әдип Мирза Фәтәли Ахундов образы турында, бу бөек шәхеснең Пушкинга, аның поэзиясенә булган мәхәббәте турындагы фикерләрен ишетеп утыру минем өчен М. Ф. Ахундов иҗатын өйрәнүдә бай һәм практик мәктәп тә була алды.

Гомумән, шул еллар әдәби хәрәкәтендә Мәһди Хөсәеннең, бу хәрәкәтнең үзәгендә торып, принципиаль таләпчәнлек, партиялелек белән, коммунист язучы буларак зур активлык күрсәтүе каләмдәш дусларына яхшы мәгълүм. Әгәр дә инде мин бу мәгълүм хакыйкатьне кабатлап язам икән, моны бары мәрхүмнең күп кырлы эшчәнлеге үз язмышыма да уңай йогынты ясавын күрсәтү өчен, иҗат утымның суынып, сүнеп калмавына тибәргеч үрнәк булуын аңлату өчен язам. Мәсәлән, Баку киностудиясендә эшли башлавыма дүрт-биш ай вакыт узгач, Мәһди миңа үз иҗатым турында онытмаска киңәш бирә, хәтта бу турыда студия җитәкчеләре белән дә сөйләшә. Шуннан соң студия җитәкчеләре миңа Бакудан 100 километрлар читтә, диңгез эчендә утырган Артем атавы турында фильм-очерк төшерү өчен сценарий язуны тәкъдим итәләр. Минем өчен бу бик күңелле факт иде һәм мин атна-ун көн буе диңгез уртасында, җил-давыллар эчендә утырган бу атауда булып, диңгез төбеннән нефть алу кебек, ул чагында әле яңалык саналган һәм шул яңалыкның Аникин кебек пионерлары турында сценарий яздым.

Ике-өч ай узгач, студия минем сценарий буенча «Остров Артема» исемле документаль фильм чыгарды. Бу фильм Мәскәүдә кинематография комитетында югары бәя белән кабул ителде. Мондый иҗади уңыш бер минем өчен генә түгел, бөтен студия коллективы өчен дә шатлык китерде. Мондый шатлык исә «Долина новый жизни» («Яңа тормыш үзәнлеге») исемле икенче фильм сценариесын язарга дәртләндерде.

Иң истәлекле вакыйгалар Ватан сугышы башланган көннәргә бәйләнгән. Ватаныбыз чикләрен бозып, хаиннәрчә һөҗүм иткән фашизм көчләре илебезгә зур хәвеф тудырган көннәрдә, әзербәйҗанлы Кемал Касумов Прут елгасы буенда батырлык күрсәтеп, дошман танклары чыгып килгән күперне шартлатып, дошманның мәкерле хәйләсен өзә. Бу турыда «Известия» газетасында зур мәкалә басыла. Баку киностудиясе бу кыю сугышчы турында фильм чыгару теләге белән сценарийлар язуга ашыгыч конкурс игълан итә. Конкурс срогы бик кыска, ялгышмасам — 10 көн. Конкурста мин дә катнашам һәм язган эпизодларымны Мәһдигә укыйм, аның киңәшләрен тыңлыйм. Мәһдинең ярдәме зур була. Нәтиҗәдә, конкурста мин язган сценарий яхшы дип табыла.

Шулай итеп, студия коллективы фильм төшерүгә керешә, ә мин, военкомат повесткасында күрсәтелгән срогым җитеп, фронтка китеп барам. Тылда калган дуслар, чын мәгънәсендә фидакарь хезмәт үрнәкләре күрсәтеп, ике ай эчендә минем сценарий буенча «Сын Родины» («Ватан оглы») исемле нәфис фильм чыгаралар. Соңыннан, хәрби частьның сәяси бүлеге инициативасы белән, бу фильм мин хезмәт иткән полкка китереп күрсәтелә.

Мәһди белән булган иҗади дуслык Ватан сугышы тәмамланып, мин фронттан кайткач тагы да көчлерәк дәвам итте. Ул үзе редактор булган әдәби журналда минем «Еракта... еракта» исемле новелламны, «Шәрык капусында» исемле очеркымны татарчадан әзербәйҗан теленә тәрҗемә иттереп басты. Миндә тагы да теләк-дәрт уянды. Үз ана телемдәге әдәби журнал — Татарстан язучыларының «Совет әдәбияты» (бүгенге «Казан утлары») битләрендә «Остаз», «Эзләр», «Батырлыкта матурлык», «Лейтенант Хәсәнев» кебек хикәяләремне язып бастырдым, Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Бакудан язып җибәргән «Гөлчәчәк» исемле комедиям уйналды. Шул рәвешчә, әзербәйҗан әдипләре, аеруча дустым Мәһди Хөсәеннең иҗади дуслыгы аркасында, мин, иҗатта яңадан туган кешедәй дәртләнеп, канатланып йөри торгач, туган Казаныма кайтып яңа көч, якты теләкләр белән әдәби хәрәкәткә кушылдым.

Әзербәйҗан әдипләренең, аеруча дустым Мәһдинең, миңа карата мондый эчкерсез дуслык мөнәсәбәтләренә бурычлы калмау теләге миндә әле Бакуда яшәгән чагымда ук бөреләнә башлаган иде. Казанга кайтып эшли башлавыма, бу теләгемне үтәүгә киң юл ачылды һәм мин Мәһди Хөсәеннең совет әдәбиятында күренекле урын алган, Дәүләт премиясе белән бүләкләнгән «Апшерон» романын татарчага тәрҗемә итеп бастырдым. Романны татар укучыларының яратып каршылавы минем өчен дә шатлыклы булды. Шулай ук Җаббар Җаббарлының «Айдын» драмасын һәм бүгенге замандаш язучыларның хикәя-пьесаларын тәрҗемә итүем дә минем өчен иҗат ләззәтен кичерү булды...

Казанга кайтканнан соң Мәһди Хөсәен белән элемтәбез өзелмәде, киресенчә, көчәйде генә.

1963 елда булса кирәк, «Социалистик Татарстан» газетасының редактор урынбасары Флорид Әгъзамов белән, газетада «Дуслык сәхифәсе» оештыру максатын күздә тотып, Бакуга килдек. Сәхифәне оештыруда Мәһдинең ярдәме зур булды. Безнең үтенечебез буенча язган мәкаләсе газетабызны бизәгән парчаларның берсе булды. Мәһди Хөсәен бу мәкаләсендә дә татар әдәбиятына, аның классигы Галимҗан Ибраһимов иҗатына дан җырлады.

Дустым Мәһди белән 1964 елның август аенда Ялтада, язучыларның Иҗат йортында көтмәгәндә-уйламаганда очраштык. Бу чагында биредә революцион төрек шагыйре Назыйм Хикмәтнең хатыны Мөнәввәр ханым улы Мәммәд белән, СССР Язучылар союзы-

ның кунагы сыйфатында, ял итә иде. Мәһди исә Ялтага Мөнәввәр ханымны Бакуга кунакка алып китәргә дип килгән иде. Кызганычка каршы, ул килгәндә минем ял срогым тәмамланып, кайтасы көннәр җиткәнгә, туйганчы сөйләшә дә алмадык. Әмма очрашуыбыз кыска вакытлы булса да, күп кенә истәлекле вакыйгаларны сагынып телгә алдык, бер-беребезнең иҗат планнары белән уртаклаштык. Бер аянычлы хәл истә калган, шуны хәтерләгән саен йөрәгем әрнеп-әрнеп китә: кайтасы көнем иртәсендә озатучылар арасында Мәһдине күрмәгәч, тиз генә үзем аның өченче каттагы бүлмәсенә килдем. Ул бик күңелсез хәлдә караватында утырып уйга чумган иде. Мин керүгә, ул йөзендәге кайгысын елмаюы артына яшерде һәм хәлен сорашкач:

— Дустум, син гафу ит, зинһар, озатып чыга алмамдыр, нишләптер йөрәгем чәнчешә, — диде.

Мин моны аның самолетта очып килүеннән булган вакытлы кичерешe дип уйлап, дустыма борчылмаска, ял итәргә кушып, саубуллашып чыгып киттем... Бу соңгы очрашуыбыз, соңгы саубуллашуыбыз булган икән...

1965 елның март аенда РСФСР язучыларының чираттагы съезды булды. Съезд тәмамланып, Казанга кайтыр сәгатьләрем иде. Мин яшәгән «Москва» гостиницасындагы бүлмәнең телефоны шалтырады. Трубканы алсам, Мәскәүдә яшәүче дусларның берсе шагыйрь Әхмәт Ерикәй икән. Ул миңа тетрәткеч хәбәр — Бакуда Мәһди Хөсәеннең вафаты турында ишетүен әйтте...

Мондый зур кайгыны ишетү хәтсез авыр булды. Икенче көн иртәсендә «Татарстан» поездында ничаклы ялгыш эшләвемне абайлап әрнүемнән нишләргә белмәдем, яраса, шунда ук поездан сикереп төшеп, киредән Мәскәүгә әйләнеп кайтырдай булдым... Миңа, кичә Ерикәй хәбәр иткәч, кичке поезд белән Казанга кайтып китмәскә, ә Мәскәүдә калып мәрхүмнең җеназасына баручы делегациягә кушылырга һәм алар белән бергә Бакуга очарга кирәк булган лабаса!.. Нишләмәк кирәк, кешенең зур кайгыга дучар минутларында, әзербәйҗанлылар әйткәнчә, башы карыша, күрәсең...

1969 елның май ае азакларында, Казанда булачак әзербәйҗан сәнгате көннәре уңаеннан, мин өлкә газетасы редакциясе тапшыруы буенча махсус материаллар оештыру өчен, Бакуга килдем. Үтисе йомышларны үтәгәч, Әзербәйҗан язучылар союзы идарәсенә, иске дусларның берсе Имран Касумовны күрергә ашыктым. Аңа Мәһди Хөсәен күмелгән зиратка барып кайту теләгемне белдергәч, Имран Ашумович шул ук сәгатендә миңа машина һәм юлдашка кеше билгеләп, мәрхүм дустымның каберен тәваф кылу мөмкинлеген тудырды...

* * *

Мәһди Хөсәен гаҗәп сәләтле, ташып торган энергияле, тынгысыз, принципиаль, таләпчән коммунист язучы, драматург, ялкынлы публицист, әдәбиятчы, киң диапазонлы редактор, ару-талуны белмәс җәмәгать эшлеклесе иде. Мәһди Хөсәен барыннан да элек үз Ватанының кайнар йөрәкле патриот гражданины иде.

Бу истәлегемне мәрхүм дустымның миңа язган хатларындагы сүзләре белән түгәрәкләр идем:

«Онытма, без иҗади дуслык белән бәйләнгәнбез, ә бу, минемчә, иң ихлас дуслык»...

Әйе, ихлас дуслык онытылмый да, сүнми дә ул...

*Казан, сентябрь, 1973 ел.*

Габдрахман Әпсәләмов

# КОЯШ ТОТЫЛГАНДА ТАБЫЛГАН ХӘЗИНӘ

Шифаханә көннәре дәвам итә. Күз докторы килгән. Күзләрне карый. Йөрәк белән авыручыларның күзләре зәгыйфьләнә икән. Николай Иванович үзалдына мыгырдана: «Минем әчем кипкән, запордан җәфа чигәм. Ә сез күз дисез. Минем пыяла күземә чуртым да булмый». (Николай Ивановичның бер күзе пыяла икән!)

— Иҗат бөек нәрсә! — дип кычкырып куя Якушенко. — Иҗат кешесе үлгәндә дә иҗат белән әвәрә килә. О, хо-хо!

Мин хикәя өчен бер уемны язып куям:

«— Аһ, Кәрим, нигә әйттең шул сүзләреңне! Дөнья миңа бөтенләй башкача күренә иде, яшәве күңелле иде, кошлар сайравына шатлана, кояш нурларына иркәләнә, яфраклар лепердәвенә назлана, чәчәкләр исенә сөенә идем. Хәзер бар да бетте». (Мин бу юлларны бер хикәямдә дә файдалана алмадым шикелле. Әллә бу үзе өч-дүрт юллык тәмамланган хикәя булдымы? Булса була икән!)

Ачык ишектән сестра Данияиең коридорда җил-җил йөрүен карап ятам. Ул, дежуркага бер генә минутка кереп, пыяла шкафтан яки холодильниктан дарулар ала да тагын каядыр чыгып китә. Көне буе шулай йөри инде. Безнең палата ишеге төбендә ак халаты, ак бүреге генә яшендәй сызылып кала.

Безнең эрага хәтле ике мең ел элек Көнчыгышның борынгы медицинасы табибның өч даими коралы бар дип әйткән: берсе — сүз, икенчесе — үсемлек, өченчесе — пычак. Сүзне беренче урынга куйганнар. Хәзерге врачлар кайчак шул хакыйкатьне оныталар, авыру белән рәтләп сөйләшмиләр дә. Врач никадәр тәҗрибәлерәк булса, сүзгә шул кадәр күбрәк әһәмият бирә.

Бүген профессор килде. Озын буйлы, күзлеге алтын кысалы, чәче маңгай турында коелган, чигәләрендә көмешләнгән, ә җилкә чокырында — кап-кара. Барыбызны да караганнан, барыбыз белән дә сөйләшкәннән соң, ул безгә болай диде:

— Менә сез, солдатлар, окопта утырасыз, һөҗүмгә кузгалырга приказ көтәсез, ди. Берегезнең йөрәге окоптан чыкканчы ук ярыла яза. Ул солдатта өмет юк. Икенчегез, кабаланып, сигнал булганчы ук окоптан сикереп чыга. Аны шунда ук атып егалар. Димәк, аңарда да өмет юк. Ә күпне күргән солдат көтәргә кирәк чакта сабыр гы-

Дәвамы. Башы журналыбызның 2 нче санында.

на кетә, сугыш кырын күзәтә, башта кая кадәр, аннары кая кадәр йөгерәчәген чамалый. Мондый сугышчыда өмет бар. Ул дошманны да җиңә, исән дә кала. Йөрәк белән авырганда да тәҗрибәле солдат булырга кирәк. Дошман рәхимсез. Ләкин аны җиңеп була. Тынычлык, түземлек һәм тагын бер тапкыр түземлек. Барыгызның да хәле рәтләнүгә таба бара.

Уйлап табучыбыз Григорий Иванович йоклаганда кулларны ике яктан да караватка беркетеп куяр өчен (инфарктлы авырулар гел чалкан ятарга тиеш) махсус каптырмалар уйлап чыгарды. Моңарчы ул, авиатор буларак, очу турында гына уйлаган, хәзер нәкъ киресен эшли. Һай, бу язмыш!..

Көн болытлы, палатада күңелсез. Николай Иванович, яшелле-зәңгәрле тавышлар чыгарып, гырылдап йоклый. Григорий Иванович яткан җиреннән сызымнар сыза. Ул ком белән туфрактан дача салырга хыяллана. Мин түшәмгә карап тик ятам. Тышта самолет гүли.

А. Гомәр килде, съезд хәлләрен сөйләде, минем хатны укыганлыкларын әйтте, съездның миңа җибәргән хатын бирде. Иптәшләрнең игътибары бик дулкынландырды.

Йөрәкнең күкрәкне ертырдай булып әрнүләре, бугаздан алып буулары басылгач, шатланган идем, иртәрәк булган, ахрысы. Тагын башланды. Гаҗәп ул йөрәк авыруы. Сәламәт чакта син йөрәгеңнең кайда икәнен дә сизмисең. Авырта башлагач, күз аллары караңгылана, баш әйләнә, суларга һава җитешми. Күкрәгеңнең сул ягына әйтерсең авыр тәпие белән аю баскан. Кайчак йөрәк йомарланган йодрыкны хәтерләтә. Син аның сөякчел буыннарын тоясың. Ихтыярсыз валидол суыра башлыйсың.

Төн булды исә товар йөртүче вагоннар дөбердәргә тотына — якыннан гына тимер юл тармагы үтә.

— Ө-хо-хо! — дип ыңгыраша Николай Иванович. — Ә йөрәк һаман сызлый, тамыр тибеше югалып-югалып тора. Әнә тагын тибә. Бер, ике, өч, — дип саный ул, — дүрт, биш, алты... Менә тагын туктады. Беттемме? Актык сулышыммы? Юк, яңадан тибә. Да-а! Шуннан соң нәрсә? Җавап юк. Юләр кебек ята бирәм. Әй, язучы, ишетәсеңме, бер кыз исемә төште. Күзләре төпсез күл шикелле, батуың мөмкин. Матур күзләр! — Николай Иванович беркадәр вакыт түшәмгә карап сүзсез ята, аннары тагын сөйли башлый. — Их, хәзер Сочига барасы иде. Безнең театр быел җәйгә гастрольгә Сочига китә бит. Эш беткәч — диңгезгә. Инфарктны бар дип тә белмисең. Беренче сентябрьдә Казанга кайтып төшәсең — йөзең алсу шафталу!

Тагын бер көн мәңгелеккә китеп барды.

Әле күптән түгел генә Николай Ивановичның юбилее булган. Өч йөз котлау хаты килгән. Барысы да озын гомер, нык сәламәтлек теләгән. Менә ул авырып ята.

— Барлык котлауларын кире алсыннар иде дә сәламәтлегемне кайтарсыннар иде, — дип шаярта артист.

Өендә Николай Ивановичның ике эте, ике мәчесе һәм аквариумда балыклары бар икән. Этләренең берсе карт, әлсерәгән, икенчесе чукрак, ди. Хуҗаларын күрсәләр, шатлыкларыннан сикерешергә тотыналар икән.

Кич. Яшен яшьни, күк күкри. Бөркү. Мондый төннәр бик тә интектерә. Бөтен шифаханә ыңгыраша. Яшен яктысында дежурдагы сестра Таня күренеп кала.

Кичә карт большевик Курманаев, яныма килеп, сөйләшеп утырды. Ул үзе аяклары белән җәфалана икән. Курманаев заманында бик мәһабәт ир булган булса кирәк. Хәзер дә әле кыяфәте мәгърур, түгәрәк башы матур, чәчен такыр итеп алдырган, мыек чылгыйла-

рын бөтереп тора. Элек лейб-гвардиядә, драгуннар полкында хезмәт иткән. Мулланур Вахитовны яхшы белә. Казанны ак чехлардан саклаганда революцион батальонның командиры булган.

Хәзер безнең дүртенче караватыбыз да буш түгел. Анда ятучы авыруга хатыны һәр вакыт компот китерә. Николай Иванович һаман шаярта:

— Тагын тәмле компот китердегезме? Ирегез бик бәхетле кеше сезнең,— ди.

Бүген Николай Иванович яңалык ачты. Бөтен палатага кычкырып:

— Наз белмәгән хатын — хуш иссез чәчәк ул! — диде. Аннары кемнең ничек яшәве турында сөйләп китте. Минем, ди, бер танышым бар. Шул, өендәге барлы-юклы әйберен сатып, автомобиль алды. Автомобиль аңа шайтаныма да кирәкми. Иртә саен хатынын базарга алып бара, ә базарга бездән җәяү дә биш минутлык юл. Хатыны ике сәгать базарда йөри, бу — машинасын саклап утыра. Кайткач, караңгы төшкәнче, машинасын чистарта, гаражына әллә нинди әкәмәт бикләр ясап куйган.

Бер көнне бу миңа: шәһәр советыннан участок алырга булыш әле, дача салам, диде.

— Нинди акчага, машинаңны сатасыңмы әллә? — дим моңа.

— Юк, машинамны сатмыйм. Өйдә аз-маз иске-москы бар, шуларны сатам, аннан дәүләт бераз ссуда бирер, — ди.

Аның квартирасы ярыйсы гына. Дача аңа әллә ни кирәк түгел. Ләкин аның һәр вакыт нидер эшлисе килә. Татарлар юкка гына: тик торганчы тун итәген ямый тор, димәгәннәр ич. Кеше әгәр бер нәрсә белән дә кызыксынмый икән, аңа иң күңелле урында да күңелсез була, — дип нәтиҗә ясый Николай Иванович.

Кузгалмый ята-ята барыбыз да аз гына юләрләндек бугай. Йөрәк инде сызламый, ләкин син ятасың, димәк, авырыйсың. Кай төшең авырта! Уйлый торгач табыла бит: калак сөяге чәнчи!

Зифа буйлы, кара чәчле яшь врач Диләрәне Николай Иванович «утешительница души» ди. Мин бу сүзнең фарсыча «күңелне бизәүче» дигән мәгънә белдерүен әйтәм.

— Шулаймыни! — ди артист, мине үчекләп.

Карчыгы аңа астралар китергән. Ул ире янына утырмый, кулларын күкрәгенә кушырып, каршында моңаеп басып тора. Николай Ивановичка бу да ошамый:

— Син, карчык, моңайма, мин үлмим әле. Минем комнан дача салдырасым бар. Проектын әнә Григорий Иванович бушлай бирәм, ди.

21. 6. 1958 ел. Американың хәрби министры гарәп илләрен атом бомбасы белән куркыта. Шундый дәһшәтле корал шундый министрлар кулында булгач, кешелек дөньясы тыныч яши аламы? Англия Кипрга гаскәр күчерә. Монысы да азатлыкка сусаган гарәп халкын куркытыр өчен инде. Империализмның коточкыч бер ваба икәне шундый тынгысыз заманда күренә дә инде.

Григорий Иванович кич буе туфрактан яки комнан дача салу турында илһамланып сөйләде. Без ышанмаган саен ул үз фикерен тырышыбрак яклады. Николай Иванович тыңлап ятты-ятты да:

— Григорий Иванович, җаным, синең бу уйларың, бәлки, чыннан да комга корылгандыр, әмма үлем түшәгендә ятканда тормышны яратуың белән син минем күңелдәге актыкка төшенкелекне дә себереп түктең. Мең рәхмәт сиңа! — диде.

Кеше, хәле аз гына яхшыру белән, ил тормышыннан аерым яши алмый. Радио тыңлый, газеталар караштыра. Соңгы көннәрдә американлылар хыянәтче Имри Надька чыгарылган гадел хөкем карары

уңае белән бөтен дөньяга дау-шу күтәрәләр. Имеш, бу вәхшилек, Имри Надь герой булган. Шул ук вакытта үзләре Алжирда, Кипрда, Ливанда һичбер гаепсез меңнәрчә кешеләрне кыралар...

Тормыш! Радио тыңлыйм. Заһид Хәбибуллин скрипкада «Аккош» көен уйный. Аңа ду килеп кул чабалар. Ә монда, күрше палатада, Хәснул Вәлиуллин җан өзгеч тавыш белән ыңгырашып ята. Аның бавыры авырта. Ул бернәрсә күрми, ишетми. Ул да композитор. Ләкин аңа кул чабу юк. Ул сестраның тизрәк укол кадауларын гына көтә.

Палатада кузгатыла торган проблемалар гаҗәп күп төрле. Ни өчен ирләр хатыннарыннан бик тиз туялар? Бүген безнең палата шул мәсьәләне тикшерә. Белдекле Николай Иванович кистереп әйтеп куя:

— Яшь хатыннар үзләрен карый белмиләр. Яшь хатын матур итеп киенә, бизәнә, назлана һәм назлый белергә тиеш. Ул чагында ире аны йөз ел яратачак. Менә шул!

Монысын кем әйткәндер белмим:

— Сез ул явызга нинди җәза кирәк дисезме? Аны ату да, асу да аз. Аңа дөнья әле күрмәгән җәза кирәк.

— Сезнеңчә, ул нинди җәза тагы?

— Улмы? — Аның бөтен йөзе бөрешеп, ирennәре калтырый, күзләре ялтырый башлый, — мин... мин... аны... үз хатыныма өйләндерер идем! Ул чагында... ул чагында мин ул ләгыйньнең нинди җәзага эләккәнен белер идем! Белер идем!!.

Юк, ни генә булмасын, дөнья матур. Баш очымдагы тәрәзә ачык. Көн кояшлы. Читкәрәк борылсам, койма буе күренә. Койма артында бакча булса кирәк. Кемнеңдер көлүе ишетелә. Кайдадыр әтәч кычкыра. Кичкә таба каргалар карылдый башлый. Мөгаен, яңгыр явадыр...

— Бервакытны У-2 самолетына утырып Ярославльгә очтым, — дип башлый Николай Иванович, — кич театрда премьера. Һавага күтәрелгән генә идек, чайкарга тотынды. Минем беренче утыруым ул самолет дигән нәрсәгә. Бетте, мин әйтәм, баш. Ходай таш белән орсын иде шуны уйлап тапкан кешене. Самолеттан төшкәч, аягымда чак басып торам. Каршы алучылар булмаса ярар иде, дим эчемнән, бер кулым белән чалбарымны тотам... Я, алла, бер көтү артист-артисткалар, чәчәкләр күтәреп, миңа таба киләләр инде!.. Авиация өлкәсендә беренче чыныгу үтүем менә шулай булды минем. Ул У-2 ләрне менә шушы,— кулы белән артка күрсәтә,— Григорий Иванович ясый икән. Сез аңарга инфаркт каян килгән дип уйлыйсызмы? Шул У-2 ләре өчен аны шүрәле каргаган!

Шифаханә көннәре озын, күңелсез, төннәре тагын да газаплырак. Бөтен җирдә ыңгырашалар, саташалар, гырылдыйлар...

Тагын кич. Күкнең тәрәзәдән күренгән кисәге кып-кызыл, аз гына миләүшә төсе дә бар. Ара-тирә кара-кучкыл болытлар да күренгәли. Әллә, югыйсә, бу кара төтенме? Караңгылана. Табигать тә, авырулар да тып-тын калган. Шомлы караңгылык, күңелдә яшерен борчу, тын алуы кыен. Җил купты. Тышта нәрсәдер бөтерелә, дулый, үкерә. Авыруларның йөзләре озайган сыман. Ләкин торып тышка карый алмыйлар. Алар караватка кадакланган кешеләр!

Чиләкләп яңгыр коя. Яңгыр басыла төшкәч, сестра тәрәзәне ачты. Палатага дымсу һава тула башлады, сулыш алулары җиңеләйде. Кайдадыр еракта әле һаман ялт-йолт килеп яшен яшьни, күк күкри.

— Их, җан кисәкләрем, — дип тавыш бирә Николай Иванович, — тере мәет булып ятуның нәрсә икәнен белсә идегез! Аннары җырлый башлый:

Эх, ухнем...
Айда да, айда...

Күңел әллә нишләп китә.

Палаталарда утлар сүндерелгән, караңгы. Тавыш-тынсыз ятабыз. Няня, идән щеткасының сабына таянып, Николай Ивановичның баш очында утыра. Николай Иванович аңа әкрен генә Пушкинның «Суга баткан кеше»сен укый. Няняның исе киткән...

Азат Аббасов радиода Мозаффаровның «Гөлкәем» җырын җырлый. Йөрәккә ярып керә торган җыр. Мин Мансур абый өчен шатланам, соңгы елларда аның таланты яңа күтәрелеш кичерә.

Безнең палатадагы дүртенче караватта кешеләр гел алмашынып тора. Хәзер анда айгыр кебек таза бер ир ята. Авыруы нидер тагы, әмма няняларның теңкәләренә тиеп бетә. Кайчак яхшы атлы да була, тик... дәүләт исәбенә.

24. 6. 1958 ел. Ун сәгать ун минут. Өстә Домрачев Мелузниковка операция ясый. Барлык врачлар шунда китте. Без борчылабыз. Әле кичә генә Мелузников безнең палатада утырып торды. Сер бирергә теләмәде, ләкин күзләрен моң баскан иде. Көлгән чакларында да күзләреннән курку китмәде. Хәерлегә булсын.

Шул ук минутларда Мәскәүдән Непал короле Махендра туган иленә кайтып китә. Миндәр астындагы радиодан аларны озаткан тавышлар ишетелә.

Григорий Ивановичның аякларын юалар. Аяклары ап-ак, нечкәреп калган. Николай Иванович, түшәмгә карап, моңлы романс көйли. Мин, дәфтәремне күкрәгемә куеп, ишеткән бер нәрсәне сызгалыйм.

Без дә дөньяда яшибез, имеш!

— Эх, Махендра! — дип кычкырып куя Николай Иванович. Әйтегез әле, мин чыннан да авырумы? Няня, нинди гөнаһ шомлыгым өчен миңа бу җәза? Нюра, ник дәшмисең, бу юләрләр йортымы, шифаханәме?

Безне профессор Әбүбәкер Терегулов карап китте.

Медицина дөньясының үз законнары бар. Ул җирәнәм, оялам, хурланам, кимсенәм һәм башка шуның кебек сүзләрне белми. Көндәлек тормышта бик зур әдәпсезлек дип саналган нәрсәләргә монда алай каралмый. Бу тупаслыктан килми, медицина хезмәткәрләре, гади санитаркадан алып профессорга кадәр, иң югары, иң нечкә зәвыклы кешеләр. Врачлар кулында бер ятып чыккан кеше гомере буе аларга рәхмәт әйтеп йөри (билгеле, күңеле мүкләнмәгән кеше). Врачлар турындагы төрле уйдырмалар — усаллар гайбәте генә. Сирәк кенә очрый торган, булдыксыз,илтифатсыз һәм шәфкатьсез врачлар — ак халатларны ялгыш кигән кешеләр, алар шифаханә йортларыннан сөрелергә тиеш.

25.6. 1958 ел. Язылмаган әсәремне болайрак тәмамлаганда ничегрәк булыр икән:

Сәламәтләнгән авырулар берсе артыннан берсе зур, матур, ямьле дөньяга чыгып китә торалар. Алар үлем уйнаган җирдән, газап һәм ыңгырашулар белән тулы җирдән китүләренә шат. Ә ак халатлы кешеләр һаман шунда калалар. Алар инде яңа авыруларны каршыларга ашыга. Аларның күңелләрен бүтәннәр аңламый торган шатлык биләгән. Кешене үлемнән аралап калудан да зуррак шатлык бармы соң!

Еллар үтәр, врач Мансура ханымның гына түгел, бүген әле бөтенләй яп-яшь булган Лена, Дания, Нәҗияләрнең дә чәчләренә чал төшәр. Әмма алар, бүгенгедәй, ярдәмгә мохтаҗ авырулар янына барырлар. Нинди ак сүзләр, йөрәкнең иң тирән җиреннән күтәрелгән нинди кадерле теләкләр белән аларга рәхмәт әйтергә?!

Уйларга, уйларга кирәк.

Бик бөркү булганга, Григорий Иванович үзе эшләгән заводта өстәл вентиляторы ясатты. Николай Иванович шул уңай белән дә шаяртып алды:

— Без гаҗәп нәрсәләр уйлап чыгардык: атом бозваткычлары, атом электр станцияләре, җир иярченнәре дисезме, Григорий Иванович хәтта өстәл вентиляторлары уйлап тапты, ә юк кына нәрсәгә башыбыз җитми. Миңа дүрт мәртәбә клизма куйдылар, барыбер файдасы юк!

26. 6. 1958. Мелузниковның хәле авыр диләр. Сестра Галя аның янында гына тора. Бу коточкычтыр. Болай Галя гади генә бер кыз кебек. Дөрес шул, хатын-кыз күңелендәге шәфкатьлелекне һич аңлап бетереп булмый.

— Дөнья гаҗәп, — ди Николай Иванович, — кайчандыр мин У-2 дә очтым һәм үземне аллага исәпләдем. Хәзер нинди дер Махендра ТУ-114 тә бөтен Советлар Союзы буйлап оча, моңа берәүнең дә исе китми. Нинди заманнарда яшибез, ә! Үләсе дә килми. Анысы ни, менә без түшәктә ятабыз, ә палатабызда әле Мәскәү, әле Ленинград, әле Пекин сөйли. Тиздән шифаханәләрдә телевизорлар да булыр. Аннары һәр юләр шифаханәдә ятарга теләр. Могҗиза, дуслар, могҗиза. Ахыр заман җитә булса кирәк! Беләсезме, беренче репродукторлар чыккач, минем бабам, белемле кеше, нинди булса юләр түгел, ә статский чиновник, бүреген салды да елап җибәрде.

Төн буе яшен яшьнәп, күк күкрәп торды. Мин иптәшләрнең ап-ак йөзләрен күреп калам. Соңгы тапкыр уянганда таң сызыла башлаган иде. Палатаның да, дежурканың да ишеге ачык. Тәрәзә пыялалары аксылланып килә.

Мин сәламәт чакта да чалкан йоклый алмый идем. Шифаханәдә гел чалкан ятарга туры килгәч, үләм дип торам. Миңа калса, хәзер бөтен гәүдәм яссыланып бетте, күкрәккә нинди дер авыр таш бастырып куйганнар сыман. Ян белән ятарга рөхсәт ителгән кешеләргә кызыгам, алар дөньяда иң бәхетле кешеләр сыман тоела миңа. Бер заман үземә дә башта уң якка, аннары, бер атна үткәч, сул якка ятарга рөхсәт иттеләр. Гаҗәп, мин күбрәк чалкан ятарга тырышам. Хәзер инде мин торып утырырга рөхсәт ителгән кешеләргә кызыгам. Ниһаять, бүген, миндәргә терәлеп, ун минут утыртып торгыздылар. Чак кына баш әйләнеп китте. Беренче тапкыр кешечә як-ягыма каранып алдым. Бөтенләй яңа палатага килеп кергән кебек булдым. Григорий Иванович, яткан җиреннән генә, ике кулын кушырып, мине тәбрик итте. Аңа әле ян белән борылырга да рөхсәт юк.

27. 6. 1958. Бүген көн болытлы булса да, Афзал абый Шамов белән Гариф Гобәй килеп киткәч, көн яктыргандай булды.

Иртәнге биштә уянып киттем. Тук-тук таяк тавышы ишетелә. Бу — ул, фамилиясен беләм, ләкин язмыйм. Арыслан ялы кебек озын чәчле, гәүдәсе юан, борыны озын. Таягын идәнгә гаҗәп каты төртә. Тора алсам, кулыннан таягын гына тартып алыр идем! Бу кеше Хөснуллалар палатасында ята. Үткәндәге революцион эше белән мактанырга ярата, ди. Мин ышанып җитмим, уннарча авыруларның тынычлыгы белән исәпләшмәүче кеше чын революционер була алдымы икән?

Хәзер инде яшермиләр. Мелузниковның чире теге ташка үлчим зәхмәт икән. Эчен ярып караганнар да яңадан тегеп куйганнар.

— Выходит дело, эшләр яхшы түгел,— диде Антипкин. Болай аның белән бер сөйләшсәң, җаннарың рәхәтләнеп китә. Эреләнү, үзен

зурга кую, мактану юк, аерым игътибар таләп итми, кешенең хәленә керә, врачларның һәм сестраларның эшенә хөрмәт белән карый. Бүген ул төне буе йокламаган. Күршесе бик каты сызланган.

— Выходит дело, дежур тордым, — ди ул аз гына да зарланмыйча. — Әле физкультура ясап кердем. Картларга кирәк нәрсә ул.

2. 7. 1958. Әле күптәнме соң Муса Җәлил исемендәге театрда без Николай Иванович белән тынычлык турында чыгышлар ясадык. Күпмедер вакыттан соң икебезнең дә бер палатада ятачагыбызны кем уйлаган ул чакта.

Шифаханәдә бер кеше пәйда булды, ул бер нәрсәдән дә канәгать түгел: анысы да ярамый, монысы да. Әле врачлар, сестралар, нянялар аңа ошамый, әле мондагы тәртипләр. Чак кына бер нәрсә булдымы, хәзер телефон шалтырата, зарлана, ниндидер аерым шартлар таләп итә, янәсе, ул шундый зур кеше. Авыруларны да туйдырып бетерде һәм алар аны үз палаталарыннан күчерүне таләп итә башладылар.

Профессор Голиков карады һәм... юатты! Шифаханәдән чыккач та ярты ел, бер ел авырып йөрерсез әле, диде. Көненә ике сәгатьтән артык эшләмәскә, борчылмаска, дулкынланмаска, берәү белән дә сүзгә килешмәскә. Шулай ук ашыкмаска. Ун минут алдан, ун минут соң булды ни, барыбер дөньяны үзгәртә алмыйм, дип фәлсәфә сат... Боларны тыңлаганда гына да чәчләр үрә тора.

Бер хикәя уйлап ятам. Төн. Пароход Уфага бара. Красные Ключи пристанендa ул каютадан чыга. Палуба буйлап йөренә. Яр буенда, уңдарак, гармун уйныйлар. Кызлар җырлый. (Монда ял йорты.) Пароход янында гына ике кеше саубаллаша. Урта яшьләрдәге кешеләр.

— Менә аерылышабыз, — ди ир кеше. Хатын дәшми.

— Булмаса, хат яз.

Хатын һаман эндәшми. Аннары: «Кая?» дип сорый. Бу юлы ир кеше эндәшми...

(Шул нигездә 1961 елда «Айзирәк» хикәясен язганмын.)

Нянялар арасында да төрле кеше бар. Иң яше һәм иң шаяны — Вера. Бер көн эшкә бик күңелсез килде. Кичә баш врач, кабинетына чакырып, күп көләсең, авырулар белән шаярып сөйләшәсең, дип ачуланган. Моны ишеткәч, без ни әйтергә белмәдек. Аның көлүе, берике шаян сүз әйтүе кемгә зыян китерде икән?

Тагын бер хикәя борынлый. Берсут. Сугыштан кайтучылар пароходтан төшәләр. Бер читтә, яр башында, бер хатын елап утыра. Аның ире сугышта хәбәрсез югалган...

(Бу сюжетка «Күңел сөйгәч» хикәясен язганмын. 1968.)

— Ир кеше матур хатын-кызга соклана алган чакта, ул әле яшь, соклланудан туктадымы — эше хана, — дип фәлсәфә сата Николай Иванович.

Хөснул да, Иван Федорович та шифаханәдән терелеп чыгып киттеләр. Хәзер безгә башка палаталардан килеп йөрүче дә юк. Күңелсез. Хәрәкәтсез ята-ята аякларның җегәре бетә. Кайберәүләр, яңадан аякка баскач, йөри дә алмыйлар икән. Инфаркт белән авырган бер авыруны, яңадан шифаханәгә салып, йөрергә өйрәтүләре турында врачлар да, сестралар да сөйләделәр. Аякларның җегәрен бетермәсен өчен, Григорий Иванович белән Николай Ивановичка массажистка килеп йөри.

Массажистка аксыл йөзле, йокымсырабрак торган бер хатын. Тел бистәсе Николай Иванович аны һәр көн чәнечкеле сүзләр белән каршы ала:

— Кичә нишләдегез, бүген иртән ни булды? Массажистка елмая, ләкин кызармый. Беренче килгәндә ул күкрәгенә сары чәчәк кадаган иде. Николай Иванович бу хыянәт билгесе дигәч, яңадан сары чәчәк белән килмәде. Үз эшен ул ничектер дәртсез эшли, дөресрәге, куллары эшли, ә уйлары кайдадыр еракта.

Күп сөйләшүе, кычкырып җырлап җибәрүләре өчен, дәвалаучы врачыбыз Мансура апа артистка шелтә ясады. Хәзер Николай Иванович, чыбык белән суктырылган малай кебек, тып-тын ята. Гарьләнгән, үпкәләгән булса кирәк.

Безнең палатага Горизонтов дигән кешене күчерделәр. Ак чәчле, эре сөякле. Агач хәзерләү конторасының җитәкчесе диләр. Үзеннән алда нянялар җиләк-җимеш тутырган пыяла савытларын ташыдылар.

— Коллеганың ни белән авыруы ачык, — диде Николай Иванович, Горизонтовны үзен күрмәс борын ук.

5. 7. 1958. Иртәгә Мәскәүдән поезд белән авыру шагыйрь Әхмәт Фәйзине Казанга алып кайталар. Аны безнең шифаханәгә салачаклар икән, беренче палатада урын хәзерлиләр. Иртәгә, ял көне булуга карамастан, Мансура апа эшкә чыга, шагыйрьне үзем каршы алам, ди. Димәк, язучылардан өчәү булабыз. Мелузниковның терелү өмете юк. Әхмәт Фәйзи терелсә ярар иде. Үзем турында уйлыйсым килми.

Тырыша торгач, Григорий Иванович ком дачасы проектын тәмамлый бугай. Бу кешенең түземлелегенә, эшкә йотлыга белүенә исем китә. Хәзер ул күпме цемент, кирпеч, ком, агач, калай кирәк буласын исәпли.

Мин дә тик ятмыйм, тик киләчәктә «йорт салганда», ягъни әсәр язганда, мин әзерләгән, «материалларның» күпмесе эшкә ярар? Әйтеп булмый. Язучы эшенә сметалар төзелми.

Григорий Иванович көн аралаш электробритва белән башын кыра.
— Җиту чәч уйларга комачаулый, — ди.

Горизонтов үзен бик эре тота. Безнең белән сөйләшми, хәтта артистны да санга сукмый. Санигаркаларны, сестраларны шулай ук. Шифаханәдә оят юк югын да, оятсыз булырга димәгән ләбаса!

Безнең палатага художник Ратницкий кергәли башлады. Аның сукыр эчәгесе авырта, операция булырга тиеш. Бик курка.

— Менә шул художник инде мине исерек баш итеп ясаган иде. Бу йортка эләккәнбез икән, димәк, гаеп икебездә дә булган. Шулай да аныкы күбрәк, чөнки ул пычак астына ятачак! — диде Николай Иванович.

6. 7. 1958. Мансура апа вокзалдан берүзе кайтты. Әхмәт Фәйзи шифаханәгә ятарга теләмәгән, сеңелесенә төшкән. Тиздән Аккош күленә, язучылар дачасына алып китәләр икән. Хәле начар ди. Мансура апа әйтми, әмма күзләреннән күреп торам: Әхмәт абыйның да хәле өметсез бугай. Төзәлердәй булса, аны Мәскәүдә дә дәвалаарлар иде шул. Картлардан «туфрагы тарта» дигән сүзләрне ишеткәнем бар. Шулай да ышанасы килми. Ул бит зур әдип, зур художник. Соңгы елларда аның таланты ничек чәчәк атты, инде коелырга да тиешме?

Тәрәзә төбендә төне буе песи баласы елады. Ачуы килгән сестра, таң алдыннан тышка чыгып, песи баласын коймa аръягына ташлаган. Коридорда төн буе авыру ыңгырашты. Ләкин кешене коймa артына ташлап булмый. Сестра төне буе аның яныннан китмәгән.

Бүген Горизонтов янына хатыны белән алты яшәр баласы килде. Хатыны карт күренә, кибеп беткән. Горизонтов аңа карамый да, ә улын коча, үбә. Малай аңа үзе ясаган рәсемен китергән: зәңгәр дулкыннарда җилкәнле кораб йөзеп бара. Әтисе бу рәсемне стенага беркетте һәм күңеле нечкәреп карап тора башлады. «Бу кешенең дә җаны бар икән! — дип уйладым.— Ләкин ни өчен ул башкаларга карата шундый тупас».

— Менә таныш булыгыз, иптәш доктор, — диде Николай Иванович беренче тапкыр кергән врачка, — минем баш очымда Григорий Иванович ята, тегенди-мондый вак-төяк кеше түгел, авиаконструктор. Сәламәт чагында ул У-2 ләрне, тагын әллә нинди самолетларны уйлап чыгара торган булган, ә хәзер... комнан йорт иҗат итә. Бу, сезнеңчә, ничек, алга китешме?

Көн болытлы, аз гына яңгыр сибәли, сестра Дания алсу күлмәк киеп килгән. Ак халат, алсу күлмәк аны алма чәчәгенә охшата.

— Дөньяда шундый матур кызлар үскәндә, мин ни пычагыма картайганмын! — ди Николай Иванович.

Хөснул яңадан больницага кайтты. Чир бер бәйләнсә, тиз генә китми ул. Авыру килә потлап, китә мыскаллап, дип, тикмәгә әйтмәгән борынгылар.

Сәгать унберләрдә кояш күзен ачты. Җил тәрәзә төбендәге яфракларны тибрәтә. Юеш яфракларга көмеш су йөгерткәннәр кебек, җем-җем итәләр. Авырулар тәрәзәгә карап тора. Күз карашлары моңсу, ә уйлары?

Горизонтовка биш-алты төрле дару китереп бирәләр. Ул аларга ачуланып карап тора да барысын берьюлы эчеп җибәрә.

Күр, таягын идәнгә шак-шок бәреп йөри торган теге бәндә тагын шифаханәдә. Аны һәр елның алты аен монда үткәрә диләр. Дүрт бүлмәле квартирасында яшь хатын бер үзе кала. Бу телефоннан гел тикшереп тора: өйдәме, юкмы? Сестралар аңардан ничек качарга белмиләр. Менә хәзер дә дежурка янына ук килгән, дару сорый.

— Врач сезгә андый дару язмаган, мин бирә алмыйм,— ди Дания һәм, гафу үтенеп, авырулар янына ашыга.

— Мин авыру түгелмени? Белеп торыгыз, мин зарланачакмын. Сез игътибарлы түгел. Сестра, имеш... Менә бер сәгать була инде әлеге таяклы карт — Гөлдери дип әйтик — бер дежуркага, бер безнең ишеккә карый, әйтерсең бер-бер яшерен эш сизгән, таягын торган саен идәнгә катырак төртә.

7. 8. 1958. Бүген аякны салындырып караватта утырырга рөхсәт иттеләр. Тиздән мин өстәл янына утырачакмын.

Икенче көнне кич белән радиодан Маһинур Шәрипова «Дустым мәхәббәте»ннән өзек укыды. Башкаларга комачауламас өчен, наушникларымны мендәр астына куеп тыңлап яттым. Әзрәк дулкынландым, ахрысы. Йөрәк көчлерәк тибә башлады.

Николай Иванович төннәрен йоклый алмый. Ут яндырып укый. Берсүз әйтмибез.

Бүген шифаханәдә «кыен» көн: өч кешегә операция ясадылар. Берсе художник Ратницкий, икесе хатын-кыз. Мондый көннәрдә шифаханә әйтерсең кайгы киеме кия; йөзләр сүрән, тып-тын. Врачлар, сестралар операция ясалган кешеләр янында.

Николай Ивановичның хәле бераз яхшырса, теле сөйләүдән туктамый, җитмәсә, сәхнәдәгечә кычкырып сөйли, кычкырып көлә.

Палатага няня Маруся килеп керде. Күрше палатадагы хатын-кызлар, аптырагач:

— Шул артистыгының телене, ичмасам, сөлек салдырсыннар иде,— дигәннәр. Моны ишеткәч, Николай Иванович бик кимсенде. Хәзер дә мышный-мышный ята.

Горизонтов янына, кулына укол инәсе тотып, шаян Лена килде. Горизонтов йоклый иде. Лена Николай Ивановичка дәште:

— Николай Иванович, стенадагы корабны сез ясап биргәнсездер инде?

— Николай Иванович моны булдыра алмый, бу минем малайның иҗаты, — диде Горизонтов, күзен ачып.

— Шундый яхшы ата булган өчен менә сезгә укол!

Безнең палатага Плеханов дигән кешене салдылар. Горизонтов терелеп чыгып китте. Буе-сыны белән Плеханов Тарас Бульбаны хәтерләтә. Кара кашлы, кара чәче маңгаена каерылып төшкән. Беләкләре юан, йөнтәс. Ул үзенең ничек авырый башлавын сөйләде, әйтергә кирәк, бик җитди сөйләде. Тик без, кызганудан битәр, көлемсерәп яттык. Приступ башлангач, ул, тик кенә ятасы урында, торып, квартирасының барлык тәрәзәләрен ача, — суларга һава җитми. Тәмәке тарта. Шул турыда соңыннан врачларга сөйләгәч, тегеләр ышанмыйлар.

11. 8. 1958. Бүген беренче тапкыр аякка басарга рөхсәт иттеләр. Нибары бер минутка! Тамыр тибешен Мансура апа үзе тикшереп торды. Тез буыннары калтырый, баш чак кына әйләнә. Мансура апа шатлана, тәки аякка бастырдым үзеңне, ди.

Николай Иванович карчыгын сагынып ята. Күңеле нечкәргән бичараның, карчыгының ничек итеп табын әзерләүләрен, һәр вакыт ашыгуы өчен яратып бетермәүләрен сөйли, аннары бер генә көнгә булса да карчыгы янына барасы килгәнен әйтә:

— Мансура бар, ул булмаса күптән качып китәр идем, Мансураны күңелсезләндерәсем килми. Ул бит без абыйларның дәү әнкәсе! — ди.

Көннән-көн дөнья иркенәя бара. Хәзер инде, утырып, туйганчы тәрәзәдән карый алам. Тәрәзә янында юкә агачы, арырак утын әрдәнәләре, аннары җимеш бакчасы. Көн бер аяза, бер болытлый. Электр чыбыкларына чыпчыклар тезелгән. Кайчакта җирдән күк күгәрченнәр күтәрелә. Очкан чакта аларның эчке ак күлмәкләре күренә.

12. 8. 1958. Мелузниковның хәле начарланганнан-начарлана бара. Ябь-яшь кешенең шулай сүнә баруы бик аяныч. Аның тирәсендә йөрүче сау-таза кешеләрнең аңа берничек тә ярдәм итә алмаулары тагын да аянычрак. Аны инде юатырга да, дәртләндерергә дә мөмкин түгел, ул белә булса кирәк. Кызгану исә авыруның газабын гына арттыра.

Әхмәт Фәйзи дә шул хәлдә ята диләр. Мин Мансура ападан һаман сорашып торам, ул аңа барып йөри.

Бик каршылыклы бу дөнья. Берәүләр үлеп ята, ә берәүләр... Безнең кечкенә генә палатага исә еш кына бөтен планета кереп утыра. Без үз илебез турында гына түгел, бөтен дөнья хакында сөйләшәбез. Авыру иң элек үзе турында гына уйлый диләр дә, юк, алай ук түгел шул, җан бугазга килгәндә дә кеше кеше булып кала.

— Ни шайтаныма кирәк миңа ком дачасы, — дип сөйләнә тынгысыз артист, — бер инфарктым инде бар, икенчесе бер атнадан була диләр.

Иртәнге алты сәгать 30 минут. Сызланулар, ыңгырашулар белән тулы төн үтеп бара. Авырулар һушларын җуйганнармы, әллә булмаса хәлдән тайганнармы — тып-тын яталар. Вера Григорьевна, авыр гына атлап, узып китә; зур күзле, шәфкатьле няня Нюра (Николай Иванович аны богомолка дип йөртә), ябык гәүдәле, күзлек киеп йөрүче врач Маргарита Кузьминична — барысы да чиксез арыганнар. Кайдадыр чиләк чылтыравы, краннан су акканы ишетелә. Сестра пыяла шкафтан дарулар ала. Хәзер ул безнең палатага керәчәк. Кемдер «а-а-а» дип, әрнеп кычкырып җибәрә. Хатын-кыз тавышы бу. Бөтен шифаханә сискәнеп киткәндәй була...

Бүген беренче тапкыр ишеккә кадәр атлап бардым. Сестра Таня култыктан тоткан иде. Моңарчы, урындык артына тотынып, ике-өч атларга гына рөхсәт итәләр иде. Ике-өч адым. Вәссәләм! Ишеккә кадәр баргач, беренче тапкыр озын һәм иркен коридорны, дежурканы тулысынча күрдем. Моңарчы пыяла шкаф, холодильник кына күренә һәм алар биек сыман тоелалар иде. Коридорда, тәрәзә буенда, ак өстәлләр, йөри алган авырулар шунда ашыйлар икән. Безнең палата чыннан да «Сахалин» икән — иң кырыйда.

Кичтән Николай Иванович белән Плеханов, мыдыр-мыдыр сөйләшеп, йокларга бирмәделәр. Плеханов көлә башласа, стеналар дерелди. Йоклаганда ул йөзтүбән ятып йоклый, кул-аякларын як-якка ташлаган, юрганы идәнгә очкан була.

Кайберәүләр миңа күп эшләдең, үзеңне сакламадың диләр. Әгәр алар минем күңелдәге уйларны белсәләр, болай әйтмәсләр иде. Мин уйлаганнарымның чиреген дә эшләмәдем әле. Терелеп, тизрәк эшкә тотынасы килә.

Соңгы тапкыр уянганда тәрәзә пыялалары яктыра башлаган иде. Сәгатькә карадым. Өч тулып килә. Шуннан соң йокы тәмам качты. Тукта, нәрсәдән уяндым соң, бик әйбәт йоклый идем бит. Ә-ә, хәтерләдем, теге Гөлдери таягын идәнгә тәртә-тәртә узды. Таяк тавышы иртәнге тынлыкта шул хәтле көчле ишетелә, башка әйтерсең кадак кагалар.

Күрше бүлмәдә бер хатын үләргә ята. Вакыт-вакыт бик каты әрнешә, сестра Галя аның янында китми. Шунда да Николай Иванович аны шаяртып алырга җай таба.

— Галочка, син бүген чәчәк аткан гөлгә охшыйсың, — ди. — Кичә кайларда булдың, аның белән очраштыңмы? Үткән дежурда матур түгел идең, күз төпләрең каралган иде.

— Йокламаган булганмын, Николай Иванович.

— Юк, Галочка, бу йокламаганныкы гына түгел. Менә бүген синең күңелеңдә тантана. Мөгаен, үпкәндер. Шулаймы?

Әй, тормыш! Бер-берсенә ярашмаган нинди коточкыч очракларың бар синең. Менә әле дә син безнең палатадан чыгып теге үлеп ята торган хатын янына кереп киттең бит!

Николай Иванович һәм Григорий Иванович янына Даима Шакирҗанова (министр урынбасары) һәм партиянең шәһәр комитеты хезмәткәре Замова килде. Чәчәкләр китерделәр. Хәлләрен сораштылар, юаттылар.

— Шундый зур кунаклар килгәч, җитмәсә, алар хатын-кыз да булгач, безгә, егет кешеләргә, авырып ятарга ярыймы соң, иртәгә үк аякка басабыз, — диде Николай Иванович.

Шакирҗанова минем белән дә әзрәк сөйләште. Рәхмәт.

Алар киткәч, Николай Иванович тагын сайрарга тотынды:

— Яшь һәм матур хатын-кызларны күрсәм, күңелем ташый. Менә миңа алтмыш яшь икән. Я, мәрхәмәтле ходай, ташла шуның яртысын чигереп. Сиңа ни тора!

Язылачак әсәрем турында уйланам. Күз алдымнан аның аерым күренешләре, эпизодлары, кайбер кешеләре үтә. Алар әле томанлы, ерактагы төсмерләр генә. Бер заман чынлап шытып китәрләрме?

Яшәү һәм үлем. Әсәрнең үзәгендә шул мәңгелек конфликт булырга тиеш. Шифаханә тормышы моңа турыдан-туры бәйләнгән. Чир (ахыр килеп үлем) һәм бөтен бер медицина персоналы шундый кискен бәрелешкә керәләр ки, бу хакта тыныч кына уйлап та булмый. Язмаларымда шуны ачыкларга телим, ләкин бу алай җиңел генә бирелми. Әле бик күп уйланырга, бик күп өйрәнергә кирәк. Язучыга хәзинәне бирәү дә алдан ачып, хәзерләп куймый. Күп вакытта язучыдан тегс-бу әсәреңне ничек яздың, дип кенә сорыйлар. Язу кадәресе, минемчә, шулай да җиңелрәк, ә менә материал җыю, аны тәртипкә салу — инә белән кое казу. Менә медицина кешеләре (авырулар һәм врачлар) турында мең вә мең төрле әсәр язарга мөмкин. Ләкин син хәзергә аны күреп җиткермисең: кайдан тотынырга, кайдан башларга, нәрсәгә басым ясарга? Энҗе эзләүчеләр диңгез төбенә чумалар ди. Язучыга да диңгез төбенә чумарга кирәк. Ләкин тормыш диңгезе чын диңгезләрдән дә тирәнрәк бит.

Авыру кеше чагыштырмача пассив булса (ул егылган, физик яктан көчсез, аның бары тик яшәү теләге, ышанычы, ниһаять, рухы бар), ә врач актив көрәшче. Аның өчен урталык юк, чөнки врач аз гына сүлпәнләндеме, үлем ялт итеп үз эшен эшли. Аннары инде барысы да беткән була, кайту юк. Гомумән, үлемнән ары берни юк!

Врач ашыгырга тиеш түгел, әмма соңга калу да ярамый. Кирәк чакта ул иң кыю, иң тәвәккәл кеше. Авыруны үз җаваплыгыннан читкә этәреп, башкаларга тондыручы футболист врачлар, кызганычка каршы, аз булса да бар һәм алар — медицинаның сәламәт тәнендә иң яман шеш.

Билгеле, болар фрагментлар гына. Моны мин бик яхшы аңлыйм, әмма шуннан артыгы хәзергә минем башыма килми. Шифаханәне өйрәнгәндә анда яту да файда итә, әмма язганда сәламәт булырга кирәк. Әгәр күргәннәрең, ишеткәннәрең практика белән ныгытылмаса, син үз палатаңны гына белсәң, боларның барысы да аерым очрак булып кына калуы мөмкин. Сәнгать әсәре өчен исә гомумиләштерү кирәк. Мин уйларымның очына чыга алмыйм.

— Кара әле, Дмитрий Федорович, — ди Якушенко Плехановка, — бәхетлеләр шушы минутта Мәскәүнең Тверской бульварында саф һава сулап йөриләр бит.

— Хәзергесе сәгатьтә, Николай Иванович, бәхетлеләр Идел буенда балык шулпасы пешерә. Учакларыннан сыек кына төтен күтәрелә, коры-сары ягалар. Корымлы чиләктә шулпа быгырдый. Аңа беләсеңме нәрсә тәм бирә — төтен! — ди Плеханов. Күрәсең, ул нинди-дер Тверской бульварны бар дип тә белми.

18. 8. 1958. Төшемдә кемнеңдер минем хикәямә язган рецензиясен укыйм, имеш: «Автор үзенең хикәясен тикмәгә генә «Кызыл сызык» дип атамаган. Иң җаваплы чорда хикәянең геройлары үз язмышларын ил язмышы белән бәйлиләр... Бары тик усал ниятле бик аз кешеләр генә кызыл сызыкның теге ягында калалар».

Минем мондый хикәям юк, әллә язып карагамы?

— Беләсезме, дуслар, театрда эшләүчеләр өчен 37,8 температура температурага саналмый, — дип фәлсәфә сата башлый Николай Иванович. — Билетлар сатылган, афишалар эленгән икән, артист үлсә дә уйнарга тиеш. Әгәр авырыйсың икән, башта директор бер өч тапкыр өеңә килеп китә. Аннары баш режиссер. Хәлеңне белә киләләр

дип уйлый күрмәгез, синең саулыгында аларның эше юк, шимбә һәм якшәмбе көннәрдә уйнаячагыңны исеңә төшерергә килгән алар. Театр эше, дуслар, җәһәннәм эше белән бер. Минем хатын, актриса булмаса да, үзенең иң зур дошманы итеп юкка гына театр директорын санамый шул.

21. 8. 1958. Бүген профессор Әбүбәкер абзый Терегулов карады. Елмаеп йомшак кына сөйләшә. Ак мыек, ак чәч. Халаты да ап-ак. Кардиограмманы бик җентекләп күздән кичерде. Аның белән бергә дәвалаучы врачлар Мансура апа һәм Маргарита Кузьминична бар иде.

— Сезнең кебек яшьләргә бу инфаркт кайдан килә тагы,— диде профессор миңа. — Бу бит картлар авыруы.

— Монда баш ватасы юк, — диде кич белән безнең палатага кергән һәм Николай Ивановичның аңлатмаларын тыңлаган бер авыру.— Ирләрнең барлык авырулары хатыннарыннан. Минеке кебек аждаһа белән егерме ел торсаң, акылдан язар идең.

— Язмагансыз ич.

— Шул гына җитмәгән иде.

Минем караватта кайчандыр бер авыру яткан булган. Аңарда җиңелчә паралич икән, авызы белән борыны кәкрәйгән, бер күзе йомылмый башлаган. Профессор аңа гел сызгырып йөрергә кушкан. Сызгыра башласаң, инде сәламәтләндем дип уйла, дигән. Шуннан бу авыру гел сызгырырга итә икән. Башта һич булдыра алмаган. Күпмедер вакыттан соң эшләре җайга киткән — сайрый башлаган. Сестралар аңа Кара бүрек (снегирь) дип кушамат такканнар.

— Раильме, раиль зур нәрсә ул, — диде бер авыру коридорда. Ул роэны үзенчә раиль ди.— Монда гына утыра,— ул кулы белән җилкә чокырын күрсәтте. — Раильләрең шәп булса, чиргә бирешмисең. Раильләрең яхшы булсын дисәң, яхшы ашарга кирәк. Бөтен медицина шунда. Ышан, белеп әйтәм.

Әле яңа гына белдем, безнең шифаханәдә атаклы җырчы Гөлсем апа Сөләйманова ята икән. Хәзер коридорга чыккан саен мин карашым белән аны эзлим. Ул стенага тотынып кына йөри. Хәле әйбәтрәк көннәрдә диванга утырып сөйләшәбез. Мин аның сүзләрен соңыннан дәфтәремә теркәргә тырышам. Бер көнне ул:

— Нинди сөйкемле сөякләре бардыр шуның, яңа йорт салган саен квартира бирәләр үзенә,— диде.

Икенче бер көнне инде миңа карап:

— Шушы пәри алмаштырган хәрефләр белән язган китапларыгызны бер дә укый алмыйм. Телем сынгандай була,— диде.

Авыруы турында:

— Әҗәл башыдыр инде бу,— диде.

Ул миңа «Габдулла абзый радиода» дигән хикәя сыман бер нәрсә сөйләде. Мөгаен, үз башыннан үткән нәрсәләр дә бардыр монда. (Бу турыда «Азат хатын» журналында «Иделкәем» дигән бер нәрсә язган идем. 1969 ел. 1 сан.)

Николай Иванович бик хикмәтле сүз әйтеп куйды:

— Артистлар һәм язучылар инә-төймә белән сату итмиләр, алар җаннарын һәм йөрәкләрен саталар. Тик боларны тиеннәргә сатып алып булмый. Алтынның да бәясе җитми!

30. 8. 1958 ел. Ниһаять, иртәгә чыгам! Гаҗәп, палатага шул хәтле күнегелгән, аны калдыруы кызганыч тоела.

Төнлә гаҗәп бер төш күрдем: койрыгы киселгән, авызы ямьшәйгән эт кемнәрнедер һау-һаулап куып йөри, имеш. Муенында бау кисәге бар. Мин бу явыз этне элек тә күргәнем бар, имеш. Кайда — хәтерли алмыйм. Соңыннан исемә төште: бу теге ролик астына яшеренеп торган үлем ләбаса. Бер заман әлеге этме, урман мәчесеме, минем яныма йөгереп килде, ырылдарга тотынды. Мин качмадым, үз юлымнан бара бирдем. Ул ырылдаудан туктады һәм, иң гади юаш көчеккә әверелеп, койрыгын салындырып, минем арттан иярде.

31. 8. 1958 ел. Шифаханәдәге соңгы төн дә үтеп китте. Уйландым, нәрсәләрнедер тәртипкә китерергә тырыштым, булмады, бер уемның да очына чыга алмадым.

* * *

Шунда беренче шифаханә язулары өзелә. Әйе, бетми, тәмамланмый, ә өзелә. Дөрес, калын дәфтәрнең калган битләрендә медицинага кагылышлы язулар байтак әле. Аларны мин больницадан чыккач, поликлиникаларда йөргәндә язганмын. Ләкин алар шифаханә язуларына нинди булса да яңа нәрсә өстәми.

Иҗат лабораториясе дигәч, сез бәлки нинди дә булса яхшы җиһазландырылган бүлмә көткәнсездер. Тормышта сезнең фәнни-тикшерену лабораторияләренә, һич югында, колхоз яки завод-фабрика лабораторияләренә кергәнегез бар. Язучының иҗат лабораториясе бер ягы белән дә аларга охшамаган. Түбәсе дә яхшылап ябылмаган, стеналары да рәтләп торгызылмаган. Ләкин ни генә юк анда! Кызыклы сыман күренгән яки аз гына ялтыраган нәрсәләрнең барысын да җыйган язучы, авыл агае кебек, хәтта тузан эчендә аунап яткан ташландык тимер кисәген дә, күтәреп, чорма кыегына кыстырган. Нәрсәгә ярар, ул аны үзе дә әлегә белми. Бәлки тора торгач бер-бер нәрсәгә ярап куяр, ярамаса да ашарга сорамый, кыстырган җирендә ята бирсен.

Берүк нинди булса нәтиҗә ясарга, бигрәк тә язучыга әрлән икән бу дип әйтергә ашыкмагыз. Менә күз алдына китерегез: умарта корты болында оча, күз явын алырлык нинди генә чәчәкләр юк анда! Әмма бал корты аларның теләсә кайсына кунмый, үзенә кирәклесен эзли һәм таба. Локаторы бармы аның, — сез теләсә нәрсә фараз итегез, — ул инде юкә чәчәкләре арасында, ап-ак яки алсу карабодай кырында, шунда рәхәтләнеп бал җыя. Язучы да, ниндидер күләмдә, шул искиткеч хезмәтчел умарта кортына охшый. Ул бер әсәрен яза, икенчесенә, өченчесенә, хәрбиләрчә әйтсәк, разведка ясый, чөнки бу эшкә билгеләнгән аерым солдатлары юк аның, ул берүзе. Ахрысы, шуңа күрәдер, язучы берьюлы күп нәрсәне күрергә тиеш. Кайчагында ул унынчы яки егерменче әсәренә генә ярарлык чәчәкләргә очрап куя. Умарта кортыннан аермалы буларак, ул аларны да игътибарсыз калдырмый, алар яныннан гамьсез үтми. Тормыш кайбер нәрсәләрне чиратсыз да сорый. Теге яки бу язучы көн сорауларына кирәкле нәрсәләрне вакытында яза белә, дигән сүзләрне күп укыгансыз, әлбәттә. Публицистны шуннан башка гомумән күз алдына китереп булмый. Әмма кечкенә генә әсәргә дә — мәкаләме ул, хикәяме, анысы барыбер — материал кирәк. Алдан хәзерлеге булмаса, язучы аны кайдан ала? Әҗәткә биреп торучы юк бит. Дөрес, әдәбият тарихында теге яки бу әсәрнең идеясен фәлән язучыга фәлән шагыйрь биргән дигән фактлар бар. Мондый очракта беренче чиратта Пушкин белән

Гоголь фамилияләрен атыйлар. Ләкин анысы башка нәрсә, монда сүз ул турыда бармый.

Мин инде медицина эшчеләре турында әсәр язарга хыялым барлыгын әйткән идем. Хыял да юктан гына тумый. Әгәр фронтта яраланып, госпитальгә — врачлар кулына эләкмәгән, аларның кешене сәламәтләндерү өчен никадәр көч куюларын үз күзем белән күрмәгән булсам, бу хыял башыма, белмим, килер идеме? Ләкин бу уй ул чакта бөтенләй икенче булган. «Җил капканы ачканда» исемле әсәрдә минем фронт көндәлекләрем бар. Кызыксынган кешеләр шул көндәлекләрнең госпиталь өлешен карый ала. Җыеп әйткәндә, ул заманда барлык совет кешеләрен билгәгән төп уй — газиз Ватанны фашистлардан саклау — хәрби врачлар эшендә дә нигез булган. Хәтерләгез «Алтын йолдыз»дагы Мөнирә Ильдарскаяны яки Һаҗәр Шәмсиеваны, «Газинур»дагы Катя Бушуеваны. Алар медиклар булсалар да, беренче чиратта, солдатлар. Кайберләре, солдат кебек, окопта башларын да салалар.

Хәзер инде медицина кешеләрен беренче планга куясым килә иде минем. Моңа алар һәр яктан лаеклы. Ләкин минем бу язуларым, ягъни көндәлекләрем бер-бер нәрсәгә ярармы-юкмы, яхшылап кына белмим әле. Әгерҗе хәленә калмасам ярар иде. Шуңа күрә, шифаханәдән чыккач, анда-монда ташланганмын, вак-төяк мәкаләләр, хикәяләр язганмын. Үзем яхшылап белмәгәнмен, әмма кайдадыр уй артында кызу эш барган. Моны мин хәзер генә әйтә алам. Чыннан да, әгәр шулай булмаса, шифаханә язуларын мин болай яза алыр идемме? Анда бит кемнәр генә булмагандыр, нинди генә сүзләр сөйләнмәгәндер? Ләкин мин аларның медицинага һәм авыруларның рухи халәтләренә кагылышлыларын гына язганмын. Моны хәл кыенлыгы белән генә аңлатып булмый, әлбәттә. Николай Иванович Якушенко — хикмәт иясе — «иҗат кешесе үлгәндә дә иҗат итә», дип, юкка гына әйтмәгәндер. Аннары көндәлекләр үзләре... Алар никадәр тәртипсез, эшкәртелмәгән, иләнмәгән булсалар да, аларда төп уй торган саен ачыграк төс ала бара. Николай Ивановичның сафсаталары вакыт-вакыт туйдырып бетергәләсә дә, мин аларны ташламаганмын. Күрәсең, Николай Ивановичның булачак әсәремдәге геройларның берсенең прообразы буласын төсмерли башлаганмын. Шулай ук Мансура ханым, Дания һәм башкалар минем игътибарымны тарткан. Григорий Иванович Бакшаевка сокланганмын. (Алга йөгереп булса да әйтим, 1961 елда «Яшен суккан имән» дигән хикәя язганмын һәм бастырганмын. Анда сүз шул Григорий Иванович Бакшаев һәм Николай Иванович Якушенко турында бара. Бу үзенә күрә бер этюдтыр инде. Художниклар гына түгел, язучылар да этюдлар ясый икән!)

«Ак чәчәкләр» романын укыган кешеләр көндәлекләрдәге тагын күп нәрсәләрне анда күргәннәрдер. Ләкин романның төп образларыннан берсе — Әбүзәр абзый әле юк. Ул күренеп кенә китә. Ә аңардан башка роман да юк. Шулай ук Гөлшәһидә, Мансур образлары да әле төсмерләнми. Ахрысы, шуңа күрәдер, романга тиз генә тотына алмаганмын.

1959—1960 еллар нигездә «Мәңгелек кеше» романын иҗат итү белән үтте. Аны мин сугыш елларында ук уйлый башлаган идем. Төп герой Баки Назимовның реаль прообразы Баки Назиров белән очрашу эшне бик тизләтте. Аннары бу романны мин икенче бер әсәргә тотыныр алдыннан көч сынау дип карый идем. Хәзер инде ачык итеп язсаң да була — үтелгән этап һәм иҗат планнарыннан төшеп калган нәрсә. Эш шунда, бервакыт мин Муса Җәлил һәм җәлилчеләр белән бик дәртләнеп йөрдем. Ул арада бу зур эшкә өлкән шагыйребез Шәйхи Маннур тотынды. Ул Мусаны миннән күбрәк һәм

яхшырак белә, аның белән җитәрлек аралашкан да, иҗатлары да бер үк чорда диярлек башланган. Кыскасы, Муса турында роман язарга Шәйхи Маннур миннән мең кат хаклырак дип уйладым. Шулай ул әсәр минем тарафтан язылмый калды.

1960 елның ахырында һәм 1961 елның башында яңадан шифаханәдә ятып чыгарга туры килде. Тагын көндәлек сыман нәрсәләр, күзәтүләр китте. Монысын иҗат лабораториясенең икенче бүлмәсе дип атасаң да ярый торгандыр. Аңа шулай ук тәртипсезлек һәм чуалчыклык хас. Сиңа кирәк нәрсәне бераү дә алдан, тәртип белән хәзерләп куймый бит. Бүген кызыклы материалга юлыккансың икән, бүген язып кал, иртәгә инде ул эзләсәң дә булмас.

Түземлеге һәм сабырлыгы җиткән кешеләр, әйдәгез, рәхим итегез, ишекләр ачык. Билгеле, үзем сизеп торам, безнең татар укучылары мондый язуларны укырга бик үк күнекмәгән, алар бездә әллә ни юк та. Мин матбугатта игълан ителгән кадәресен әйтәм. Академия бүлмәләрендә әллә нәрсәләр бардыр да, без аларны белмибез.

Әлеге язмаларны караганда, миңа да әйткәләделәр: юк белән шөгыльләнәсең, картая башлагач, юк акылыңны җуйгансың. Бу — галимнәр эше. Мин бәхәсләшмим, галимнәр өлешенә керәсем юк, ләкин минем өстәл тартмасында ниләр барын галимнәр белми бит. Рус әдәбиятында һәм көнбатыш әдәбиятларда язучыларның көндәлекләрен дә, бүтән язуларын да, хәтта караламаларын һәм вариантларын да чыгара торалар, алар турында зур-зур тикшеренүләр язалар. Күрәсең, әдәбиятны аңлау өчен болар барысы да кирәк. Без дә кайчан булса шуңа барып җитәрбездер. Хәзергә материалларны туплау кадәрлесе мөһим. Менә Галимҗан Ибраһимовның архивындагы кыйммәтле материалларның юкка чыгуына бик әрнибез дә, соң инде, эш узгач, терсәкне тешләп булмый. Бардан исә теләсә кайчан файдаланып була. Мин менә шул турыда гына кайгыртам.

Ярый, икенче дәфтәрне, кыскартып, күчерә башлыйм.

*Ахыры бар.*

# АНКЕТА БИТЛӘРЕННӘН

Революциянең беренче көннәреннән үк большевиклар партиясе һәм совет хөкүмәте марксистик-ленинчыл матбугатны үстерү эшенә җитди игътибар биреп килделәр. Партиянең VIII һәм XI съездларында совет матбугатының эшен юлга салуга бәйләнешле күп төрле мәсьәләләр каралды, вакытлы матбугатның сыйфатын һәм авторитетын күтәрү буенча конкрет чаралар билгеләнде.

Партиянең Татарстан өлкә комитеты да матбугат эшләре турында даими кайгыртып торды, марксистик-ленинчыл матбугатны яңа тормыш төзү, революция эшенә туплау буенча бик күп чаралар күрде.

Партия өлкә комитеты членнары җитәкче партия-совет газеталарының редакторлары итеп расланды. Партия өлкә комитетының агитация-пропаганда бүлеге каршында вакытлы матбугат белән идарә итү буенча махсус совет оештырылды, агитация-пропаганда бүлегенең әдәбият-нәшрият бүлекчәсе матбугат бүлекчәсе итеп үзгәртелде. Татарстан Халык Комиссарлары Советы каршындагы матбугат эшләре буенча вакытлы комиссия матбугатка ярдәм итү буенча даими комиссиягә әйләндерелде һәм аның функцияләре шактый киңәйтелде. Газета-журналларны тарату эшен яхшыртуга юнәлдерелгән эшлекле чаралар күрелде.

Моңардан тыш, республика партия оешмасы редакцияләрне тәҗрибәле һәм сәләтле кадрлар белән ныгытуга игътибарны көчәйтте. Партия өлкә комитеты танылган татар язучыларын һәм журналистларны газета-журналларда актив катнашырга чакырды, партия поручениесы тәртибендә, кайбер иптәшләрне аерым газеталарга беркетте. Мәсәлән, «Татарстан» һәм «Кызыл яшьләр» газеталарына Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Шамил Усманов, Фәтхи Бурнаш, Салах Атнагулов һәм башкалар беркетелделәр. Моңардан тыш, җитәкче партия-совет работниклары, комсомол, профсоюз һәм хуҗалык оешмаларының җитәкчеләре газеталарга актив язышып торырга мәҗбүр ителделәр.

Бу чаралар газеталарның эчтәлеген баетырга, аларның идея-политик дәрәҗәләрен күтәрергә ярдәм итте. Газеталарның массалар белән элемтәләре ныгыды, акрынлап тиражлары күтәрелде, дәүләт һәм хуҗалык оешмаларының даими ярдәм итүләре нәтиҗәсендә материаль хәлләре сизелерлек ныгыды. Шулай итеп, вакытлы матбугат акрынлап тиешле югарылыкка күтәрелде.

Архив материалларыннан күренгәнчә, партиянең Татарстан өлкә комитеты 1921 елның декабрендә һәм 1922 елның май аенда республикадагы партияле журналистларны исәпкә алуны уздырган. Бу уңай белән журналистлар махсус анкеталар тутырганнар. Бу анкеталар матбугат тарихын һәм күренекле татар журналистларының, язучыларының биографияләрен өйрәнүдә файдалы материаллар була алырлар, дип уйлыйбыз. Түбәндә 1922 елның май аенда тутырылган анкеталарның кайберләрен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.

Анкеталарның сораулары махсус бланкаларга машинкада басылган. Сорауларга җаваплар исә кулдан тутырылган. Аларның төп нөсхәләре Татарстан өлкә комитетының партия архивында саклана. (15 фонд. 2 тасвирлама. 450 эш.)

Урынны күп алмас өчен, анкетаның сораулары беренчесендә генә китерелә, калганнарында сорауларның тәртип номерлары һәм җаваплар гына бирелә. Анкеталарны татарчага әлеге мәкаләнең авторы тәрҗемә итте. Кыскартылган сүзләр тулы итеп бирелде.

**К. ФӘСӘХОВ,**
**Казан финанс-экономика институты укытучысы.**

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ АНКЕТАСЫ

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме:[1] Ибраһимов Галимҗан Гыйрфан улы.

2. Яше: 34[2].

3. Партия стажы: 1917 елның 15 апреленнән.

4. Өй һәм хезмәт урыны адресы: 2 нче Совет йорты, номер 21.

5. Социаль чыгышы: Крестьян.

6. Белеме: Югары — көнчыгыш мөселман уку йорты.

7. Журналистлык эшен нинди телдә алып бара ала: Татар телендә.

8. Февраль революциясенә кадәр нинди газета һәм журналларда һәм кем булып эшләгән: 1908 елдан революцион татар яшьләре органы «Әльислах» газетасында эшләдем. Аннан соң төрле-төрле бүтән газеталарда һәм журналларда тәнкыйтьче-фельетончы һәм библиограф, ара-тирә җәмәгать публицисты сыйфатында катнаштым[3].

9. Әктябрь революциясенә кадәр һәм бүгенге көнгәчә: 1917 елның март ахырыннан Уфада «Ирек» исемле социалистик газетаның редакторы булдым. Октябрьдан соң Милләтләр Халык Комиссариаты каршындагы Үзәк мөселман комиссариаты органы «Чулпан» газетасының фактик редакторы.

10. Хәзерге вакытта нинди матбугат органнарында һәм кем булып эшли: Аннары «Эшче», «Кызыл Армия» газеталарында һәм «Кызыл шәрык» журналында һәм башка коммунистик органнарда тәнкыйтьче һәм марксист-теоретик булып эшләдем. Хәзерге көндә РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты органы «Безнең юл»да редакция коллегиясе члены һәм редактор урынбасары булып торам.

11. Әгәр дә эшләмәсә, ни өчен: —

12. Журналистикадан башка эш белән шөгыльләнәме, кем булып һәм кайчаннан бирле: Газетада эшләүдән башка, даими һәм системалы рәвештә үземнең әдәби революцион һәм фәнни-марксистик хезмәтләрем өстендә эшлим[4].

13. Тулысынча журналистлык эшенә күчәргә телиме: —[5].

Имза: Г. Ибраһимов.
6 май, 1922 ел.

Искәрмәләр:

[1] Анкетаның сораулары разбивкада бирелгән.

[2] 1921 елның 4 декабрендә тутырган анкетасында «Туган елым — 1887» дип язган.

[3] 1921 елдагы анкетасында: «Вакытлы матбугатта 1908 елдан бирле туктаусыз, революцион яшьләр органы «Әльислах», «Йолдыз», «Вакыт», «Аң» газеталарында һәм журналларында күбесенчә тәнкыйтьче-фельетончы булып эшләдем», — диелгән.

[4] 1921 ел анкетасында: «РКП(б) теориясе буенча лектор булып эшлим», — диелгән.

[5] РКП(б)ның өлкә комитеты төзегән коммунист-журналистлар исемлегендә бу сорауга «әйе» дип җавап бирелгән.

# ФАТЫЙХ СӘЙФИ АНКЕТАСЫ

1. Сәйфи Камалетдин улы Фатыйх.

2. 33 яшь.

3. 1920 ел, декабрь.

4. Өченче Аркылы Тукай урамы, 12 нче йорт, 3 нче квартира. Жуковский урамы, 4 нче йорт (Мәгариф Халык Комиссариаты).

5. Крестьян.
6. Урта, Көнчыгыш-мөселманча — югары.
7. Татар телендә.
8. 1906 елда татар газетасы «Таң йолдызы»нда, 1910—1914 елларда «Йолдыз»да вакытлы хезмәткәр сыйфатында эшләдем. Юморист-журналист буларак яздым.
9. Уфада «Ирек»нең җаваплы секретаре, «Безнең юл»ның редакторы.
10. «Чулпан» (Мәскәү), «Эш», «Эшче» газеталарында даими сотрудник, «Кызыл шәрык» журналының җаваплы секретаре, «Мәгариф» журналының һәм «Татарстан»ның редколлегия члены. Хәзерге вакытта Социаль тәрбия баш идарәсенең начальнигы.
11. Өлкә комитеты билгеләве буенча, Халык Мәгариф Комиссариаты коллегиясе члены булып торам.
12. Мәктәптә укытучы сыйфатында эшлим, Социаль тәрбия баш идарәсе начальнигы булып торам.
13. Бик телим.

Имза: Ф Сәйфи.

## ШӘҺИТ ӘХМӘДИЕВ АНКЕТАСЫ

1. Әхмәдиев Шәһит Гыймадетдин улы.
2. 31 яшь.
3. 1919 елдан.
4. Икенче Совет йорты. Жуковский урамы, 4 нче йорт. Халык Мәгариф Комиссариаты.
5. Крестьян.
6. Урта.
7. Татар, үзбәк телләрендә.
8. «Ак юл», «Аң», «Хокук-хаят», «Ялт-йолт», «Сөембикә», «Йолдыз»ларда тәрҗемәче, сотрудник булып эшләдем.
9. «Аваз» газетасының редакторы булып.
10. Аз эшләдем [1].
11. —
12. Җаваплы совет эшләрендә эшлим [2].
13. Совет эшен, партия эшләрен журналистлык эше белән бергә алып барырга телим.

Искәрмәләр:

[1] 1921 елның 7 декабрендә тутырылган анкетасында: 4 газетаның: «Аваз», «Эш», «Кызыл Армия», «Кызыл шәрык»ләрнең редакторы булдым»,— диелгән.

[2] 1921 елдагы анкетасында: «Хәзерге вакытта Татарстан республикасының Халык Мәгариф Комиссары булып эшлим»,— диелгән.

## ВӘЛИ ШӘФИГУЛЛИН АНКЕТАСЫ

1. Шәфигуллин Вәли Сәлим улы.
2. 1894 елда тудым.
3. 1917 елның апреленнән.
4. 1) Элеккеге Щетинкин номерлары, 21 нче йорт (яки Казан өлкә авыл хуҗалыгы тәҗрибә станциясе — элеккеге Архиерей дачасы, телефон номеры 3-27 (һәм 2) авыл хуҗалыгы тәҗрибә эше буенча өлкә идарәсе.
5. Элеккеге крестьян.
6. Урта.
7. Башлыча, татар телендә.

8. 1911—1915 елларда үзбәк телендә чыга торган «Төркстан тавышы» («Садаи Төркстан») газетасында сотрудник булып эшләдем.

9. Казанда Мөселман коммунистлар һәм социалистлар органы «Кызыл Байрак» газетасында сотрудник.

10. 1918 елдан 1919 елның октябрена кадәр Казанда «Эш» газетасының редакторы булдым. 1920 елдан 1921 елга кадәр бер үк вакытта ике газетаның — «Татарстан»ның һәм «Эшче»нең редакторы булдым. 1921—1922 елларда «Мәгариф» журналының редакторы булып тордым.

11. Хәзерге вакытта 1922 ел башыннан бирле, үз гаебем булмаган сәбәпләр аркасында, журналистлык эше белән шөгыльләнмим.

12. Хәзерге вакытта авыл хуҗалыгы өлкәсендә авыл хуҗалыгы тәҗрибә эшләре буенча өлкә идарәсендә эшлим.

13. Әйе.

Имза: 5 май, 1922 ел.

# САЛАХ АТНАГУЛОВ АНКЕТАСЫ

1. Атнагулов Салах Садри улы.

2. 29 яшь.

3. 1919 елның гыйнвареннан.

4 Икенче Аркылы Тукай урамы, 7 нче йорт, 1 нче квартира. Эш урыны: Татпрофсовет. «Хезмәт йорты».

5. Профсоюз хезмәткәре-интеллигент.

6. Урта (татарча).

7. Татар телендә.

8. Февраль революциясенә кадәр юмористик журналларга, һәвәскәр сыйфатында, татарча кечкенә-кечкенә мәкаләләр яздым.

9. Октябрьга кадәр — юк. Революциядән соң социалистик газеталарга языша башладым һәм төрле вакытта партия, совет һәм хәрби оешмалар тарафыннан нәшир ителә торган 7 газетада редактор булып эшләдем.

10. «Татарстан» газетасында «Эшче сәхифәсе»нең мөдире һәм «Коммунистический путь» журналында ирекле сотрудник сыйфатында.

11. —

12. Әйе, ТСПС члены һәм ТСПСның оештыру бүлеге инструкторы һәм лектор булып.

13. Юк.

Имза: 9 май, 1922 ел.

# НУР СӘЙФИ АНКЕТАСЫ

1. Сәйфи Нур Сибгатулла улы.

2. 23 яшь.

3. 1922 елдан, 1919 елның 15 июненнән РКСМ члены.

4. Аркылы Верлен урамы, «Гранд-отель» номерлары. 28 нче бүлмә. ГПУның Татарстан политбүлеге.

5. Крестьян.

6. Урта.

7. Татар телендә.

8. —

9. Чистай кантонында башкарма комитет органы «Берлек» газетасында эшләдем.

10. «Кызыл шәрык яшьләре» журналының һәм «Кызыл яшьләр» газетасының җаваплы секретаре булып эшләдем.

11. Хәзерге вакытта бүтән эшләрдә мәшгуль (совет органнарында).

12. Матбугатта политик һәм хәрби цензор.

13. Юк.

6 май, 1922 ел.

# ИСХАК РӘХМӘТУЛЛИН АНКЕТАСЫ

1. Рәхмәтуллин Исхак Шиһабетдин улы.

2. 25 яшь. 1897 елның июлендә тудым.

3. 1921 елның 25 мартыннан (икенче тапкыр керүем, беренче керү буенча стажым 1918 елның 20 июненнән).

4. Лобачевский урамы, 24 нче йорт. Коммунистик университет. 7 нче бүлмә.

5. Крестьян.

6. Урта.

7. Татар телендә.

8. Юк.

9. Октябрь революциясеннән соң: 1917 елның декабреннан 1918 елның августына кадәр «Кызыл Байрак» газетасының редакторы: 1918 елның сентябреннән декабрена кадәр — Мөселман коммунистлар үзәк комитеты органы «Эшче» газетасының редакторы; 1919 елның сентябреннән 1920 елның июненә кадәр «Башкортстан хәбәрләре» газетасы редакторы.

10. «Татарстан» газетасында һәм «Безнең юл» журналында «Коммунистик мәгариф» мәсьәләсен яктыртуда катнашам.

11. —

12. 1921 елның октябреннан Көнчыгыш халыкларының югары өлкә партия мәктәбе лекторы, 1922 елның мартыннан Татарстан коммунистик университетының уку-укыту эшләре бүлеге мөдире булып эшлим.

13. Коммунистик университет хезмәткәре булып тору белән бергә, татар газеталарына һәм журналларына язышып торачакмын, мәкаләләр язудан туктамаячакмын.

6 май, 1922 ел.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ VIII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

**Зәки Нури,**

Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе

# ЯШЬЛӘРГӘ— ЯШЕЛ УРАМ

Әдәби алмашны сан һәм сыйфат ягыннан ничек һәм нинди чаралар белән үстерү турындагы мәсьәлә иҗат оешмасы өчен һәр вакытта да гаять дәрәҗәдә мөһим мәсьәләләрнең берсе булды һәм ул һәр чакта да шулай булачак. Безнең сафларыбызга яңа көчләрнең өзлексез килеп торуы — елганың туктаусыз агарга, диңгезгә коярга тиешлеге кебек үк зарури нәрсә ул. Башакларын бөртекле итәр өчен игеннәр, ябалдашлары куе һәм орлыклары мул булсын өчен агачлар, җимешләре татлы булсын өчен бакчалар бөтенесе кояшка үрелеп үсә. Әдәбиятта яңа, яшь каләм осталары да нәкъ шундый ук табигый закончалык нигезендә яралырга, еллар үткәч кирәгенчә орлыклы-җимешле булып җитлегергә тиешләр.

Әдәби алмашны тәрбияләүнең зур һәм мактаулы бурычы турында сөйләгәндә барча очракта да ике яклы җаваплылыкны күздә тотып аңлашырга кирәк. Аның беренчесе — иҗатка сәләтле яшьләрне таба яки «ача» белергә, аларның иҗатына тирән кызыксыну белән карарга тиешле остазлар җаваплылыгы. Чөнки теге яки бу шәкертнең кайчан да булса нинди дер кимчелеге яки хатасы «ачылса», аның өчен беренче җавап сүзен заман һәм халык нинди дер бер остаздан да таләп итәчәк бит. Ләкин бу хакыйкать яшьләрнең үз өсләренә төшә торган җаваплылыкны һич тә киметми. Иҗатлары, әхлакый сыйфатлары һәм иҗат йөзләре нинди булуы өчен заман һәм халык алдында алар иң зур җавапны бирергә тиеш булачак. Чөнки үзенә укытучы итеп нинди остазны сайлау, кемгә охшарга тырышу яшь әдипнең үз ихтыярында бит. Бу очракта, мәгълүм халык әйтемен бераз үзгәртеп, «өйрәтүчеңнең кем икәнен әйтсәң, мин сиңа үзеңнең кем икәнлегеңне әйтеп бирермен» дип искәртеп китәсе килә. Һәр ике як та мәсьәләгә менә шулай бик җитди, җаваплы караганда гына безнең сугышчан сафыбыз ышанычлы, сәләтле яңа яшь көчләр хисабына тулыланырга мөмкин.

Сүзебез предметлы булсын һәм кайбер гомумиҗат һәм гомумпрактик мәсьәләләр турында фикер йөртергә уңайрак булсын өчен, республикабызның Язучылар союзы тормышындагы кайбер мисал һәм фактларга тукталып үтик.

Соңгы өч елда без үз сафларыбызга 29 яшь әдипне кабул иттек. (Хәзер Татарстан язучылар союзында 142 СССР Язучылар союзы члены бар.) Бу, әлбәттә, куанычлы хәл. Ләкин без киләчәктә ниндирәк юнәлештә эш алып барачагыбызны ачыклау өчен, мәсьәләнең сан ягына гына түгел, сыйфат ягына да бик нык игътибар итәргә тиешбез. Әнә шул җәһәттән карaганда эшләр ничек тора соң? Әлеге 29 яшь әдипнең тугызы проза әсәрләре яза, унбере — шагыйрь, өчесе — тәрҗемәче, дүртесе — тәнкыйтьче һәм әдәбият белгечләре. Ә менә драматургларыбыз исемлегенә тик ике кеше — Сәет Шәкүров белән Диас Вәлиев кенә өстәлде. Драматургларыбызның болай да аз, бармак белән санарлык кына булуын да искә алсак, бу

мәсьәләдә борчылырлык урын булуы һәм безгә Культура министрлыгы һәм театрлар коллективлары белән бергәләп бик җитди кайгыртучанлык күрсәтергә кирәк икәнлеге хакында сүз озайтып торуның хаҗәте калмый.

Соңгы өч ел эчендә безнең коллективка 18 коммунист өстәлүе аеруча күңелле факт.

Язучылар союзына кабул ителгән яңа членнарның дүртесе фән кандидатлары, егерме өче югары белемле. Ә менә икесе югары уку йортын тәмамламаган килеш хәзергә беркайда да укымыйлар. Без ул иптәшләр хакында бик җитди борчылып уйланабыз һәм алар үзләре дә уйланырлар, укуларын дәвам итеп, югары белем алырлар дип ышанабыз.

Союзга яңа кабул ителгән кешеләрнең яшьләре дә шактый уйландыра торган. Әлеге 29 иптәшнең тик икәве утызның бу ягында булып, бишесе утыз белән утыз биш, унысы утыз биш белән кырык арасындагы, җидесе кырык белән кырык биш арасындагы кешеләр. Хәтта иллене тутырып, алтмышны башлап җибәргәннәре дә бар. Димәк, безгә киләчәктә тимерне кызу чакта сугып калу мәсьәләсенә дә игътибарны көчәйтергә кирәк.

Яңа иҗат итә башлаган яшьләр гадәттә үзләре яраткан өлкән әдипләргә ияреп, шуларга охшатырга тырышыбрак язучан булалар. Ә безнең оешмада һәм тормыш, һәм иҗат тәҗрибәләре ягыннан яшьләргә үрнәк булырлык өлкән әдипләребез, бәхеткә каршы, шактый күп. Яшьләребез алардан югары сәнгать осталыгына өйрәнсеннәр һәм, эстафета итеп, алардан халыкка, язучылык эшенә тугрылыклы булуны кабул итсеннәр иде.

Безнең аксакалларыбыз — яшьләре өлкән булганга гына чаларган кешеләр түгел. Алар чын мәгънәсендә хезмәт сөючән, чын мәгънәсендә тырыш, чын мәгънәсендә партия солдатлары. Аларның биографиясе совет дәүләте биографиясе белән аерылгысыз бәйләнгән. Алар идея ягыннан чыныккан, югары квалификацияле профессионаллар.

Гомәр Бәширов һәм Афзал Шамовның тормыш дөреслеген чагылдырган проза әсәрләре, күп яклы иҗатчы-энциклопедияче Нәкый Исәнбәт һәм ару-талу белмичә театрга хезмәт итүче Риза Ишморат пьесалары, Хәсән Туфанның эшчеләр тормышын сурәтләүгә багышланган шигырьләре, Сибгат Хәкимнең пафос һәм лиризм белән тулы әсәрләре республикабыз һәм илебез укучыларына киң билгеле. Шушы исемлеккә җырлап тора торган проза остасы Фатих Хөсни, кабатланмас характерлар тудыручы Мирсәй Әмир, Тихон Журавлев, Әмирхан Еники, күп планлы романнар язучы Габдрахман Әпсәләмов, әдәби иҗат активлыгын вакытлы матбугатта даими катнашу белән бәйләп алып баручы Габдрахман Минский һәм Мөхәммәт Садри, шагыйрь һәм тәрҗемәче Нури Арсланов әсәрләрен дә өстәсәк, өлкән буын әдипләребездән үрнәк алырлык кешеләр исемлеге тагын да тулылана төшә. Күп еллардан бирле тырышып эшләп килә торган тәнкыйтьче һәм әдәбият белгечләре Мөхәммәт Гайнуллин, Хатип Госман, Хәсән Хәйри, Гази Кашшаф, Гали Халит та тәнкыйть өлкәсендә эшләргә килгән яшьләребезгә күп яктан үрнәк булырлык остазлар.

Бөек Ватан сугышы фронтларыннан кайтып, соңыннан әдәбиятта «хәрби буын» буларак танылып киткән Әдип Маликов, Юныс Әминов, Рафаил Төхфәтуллин һәм башкалар — барысы да үзләренең беренче китапларын әнә шундый аксакалларыбызның ярдәме белән дөньяга чыгарган әдипләр. Ә хәзер бу иптәшләр инде әдәбиятыбызда ныгып урнашкан, үз урыннарын тапкан һәм үзләре яшь буынга ярдәм итә алырлык, үрнәк булырлык авторлар.

Мин үзем дә «хәрби буын» вәкиле һәм өлкәннәребезнең аталарча кайгыртулы, эчкерсез ярдәмен күреп үскән кеше. Шагыйрь Әхмәт Исхак 1949 елда партизаннар турындагы шигъри китабымны («Дан юлы») редакцияләгәндә атна буе мине үзе белән янәшә утыртып эшләтте һәм ярдәм итте. Аның әнә шулай шагыйрь буларак та, редактор буларак та таләпчәнлеге һәм чын күңеленнән булышуы миңа бик зур гыйбрәт булды һәм әдәбиятка кыюрак атлап килергә ярдәм итте. Соңыннан республикабызның комсомол газетасының редактор урынбасары булып эшләгәндә дә, китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире вазифасын башкарганда да һәм «Казан утлары» журналының баш редакторы булган чагымда да миңа шулай өйрәнү, шул тәҗрибәнең файдасы зур булды. Шуңа күрә мин Әхмәт агайга күңелемдә һәрчак рәхмәт хисе йөртәм. Бүтән иптәшләр дә үз остазларына карата шундый мөнәсәбәттәдер дип ышанам.

«Хәрби буын»нан соң әдәбиятыбызга

сугыштан соңгы буын яшьләре килде. Сугыш елларында яшьләре җитмәү сәбәпле фронтка алынмаган, әмма тылда эшләп фашизмны җиңүгә хәл кадәренчә булышкан, ә сугыштан соң исә югары уку йортларында белем алган яшь язучылар иде болар. Гариф Ахунов, Нурихан Фәттах, Илдар Юзеев, Әхсән Баянов, Аяз Гыйләҗев, Барлас Камалов, Эдуард Касыймов, Шамил Рәкыйпов, Рафаэль Мостафин... Болар барысы да үзләренең яңа почерклары, әсәрләрендә замандашларыбызның эчке дөньяларына үтеп керүләре һәм берберләренә охшамаулары белән аерылып тора торган һәм бүгенге укучыларга инде яхшы таныш исемнәр. Аларның бөтенесенә дә хәзер бер гомуми сыйфат — әдәбиятка җаваплы караш һәм яшьләр турында кайгырта белү хас.

Безнең әдәби алмашыбызның сугыштан соңгы икенче буыны исемлеге тагын да киңрәк. Аларның кайберләре, әйтик, Туфан Миңнуллин, Марс Шабаев, Рәдиф Гатауллин, Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Гәрәй Рәхим һәм башкалар укучылар игътибарын хаклы рәвештә җәлеп иткән яшь әдипләр. Бу уңышлары өчен алар нәкъ менә әлеге сүзләре һәм эшләре белән яшьләргә ярдәм итеп килә торган аксакалларыбыз мәктәбенә һәм гомумән безнең эшлекле, изге теләкле язучылар коллективына бурычлылар.

Хәзер кыскача гына шул мәктәпнең программасын һәм бурычларын күздән кичереп китик.

Бу өлкәдәге иң мөһим бурыч — әдип иҗатын җәмгыять тормышын, чорыбызга хас күренешләрне мөмкин кадәр тулырак, калкурак итеп сурәтләүгә юнәлтү. Л. И. Брежневның КПССның XXIV съездында сөйләгән докладында әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре идеологик көрәшнең иң кискен участогында торганлыклары һәм совет кешесенең дөньяга карашын, рухи культурасын формалаштыруда әдәбиятның һәм сәнгатьнең роле һаман үсә барганлыгы бик ачык итеп әйтелгән. Совет әдәбияты үсешенең төп юнәлешен тәшкил иткән әсәрләр, диелә ул документта, «игътибарны коммунистик тәрбия һәм төзелеш проблемаларының чыннан да мөһим булган проблемаларына юнәлтәләр» һәм «алар: совет халкының күп яклы тормышы белән художникның элемтәсе никадәр ныграк булса, иҗади казанышларга һәм уңышларга юл шул кадәр ышанычлырак икәнлеген тагын бер кат раслыйлар».

Партия безне әнә шулай тормышта актив катнашырга, замандашларыбызның хезмәт һәм рухи активлыгын тулырак яктыртырга, яңалыкны, алдынгыны калкурак күрсәтергә, тискәре күренешләрне кыюрак фаш итәргә чакыра. Тормышны төшенү һәм андагы күренешләргә партияле һәм сыйнфый позициядән торып дөрес бәя бирү өчен һәр әдипнең шул күренешләргә карата үз позициясе, үзенең җитлеккән карашы һәм фикере булырга тиеш. Мондый карашка бары тик тормышны тирәнтен өйрәнгәндә, язачак әйберенең инәсеннән җебенә тикле бик яхшы белгәндә һәм булачак геройларың белән якыннан аралашканда гына ирешергә мөмкин. Язачак китапларының персонажларын тизрәк тапсыннар һәм аларны һәр яктан өйрәнеп-белеп кайтсыннар өчен без яшь язучыларны төрле командировкаларга җибәрәбез. Ә кайберләренә эшчеләр, колхозчылар арасында тагын да озаграк яшәп кайтырга да киңәш итәбез. Чөнки шунысын беләбез: үзенең булачак геройлары арасында яшәп һәм эшләп язган әдипнең әсәре һәр вакыт диярлек уңышлы чыга, укучылар күңеленә хуш килә. Мисалга ерак барасы юк. Республикабызның нефть районнарында яшәүче тугыз язучыбыз тормышны һәм кешеләрне ныклап өйрәнеп язулары нәтиҗәсендә шактый әйбәт әсәрләр иҗат иттеләр. Ул әсәрләрнең байтагы русчага тәрҗемә ителеп бөтен Союз укучыларына да ирешерелде инде. Хәзер КамАЗ башкаласы Чаллыда яшәүче һәм эшләүче Эдуард Касыймов, Мәхмүт Газизов һәм башка иптәшләр дә әнә шундый уңышлы әсәрләр иҗат итәрләр дип ышанырга кирәк.

Яшьләр — җитез, яңалыкны тиз эләктереп алучан халык. Аларның тормышның алгы сызыгындагы яңалыкларны, замандашларыбызның героик хезмәтен чагылдырган очерк һәм публицистик мәкаләләр язулары бик кирәк. Ләкин, кызганычка каршы, безнең күп кенә яшьләребез менә шушы мөһим нәрсәгә тиешенчә әһәмият биреп җиткермиләр әле. Зур булмаса да, күп нәрсә турында уйланырга мәҗбүр итә торган бер белешмә-анализга мөрәҗәгать итик. Узган дүрт елда Татарстан китап нәшрияты без хәзер укыта-өйрәтә һәм киләчәктә шуларның иң сәләтлеләре безнең сафларыбызны тулыландырырлык булып өлгерсеннәр өчен төрле эшләр кушып сынап карый торган 38 яшь авторның беренче, өлешчә икенче һәм хәтта өченче

китапларын бастырып чыгарды. Шул китапларны күздән кичергәч нинди нәтиҗә килеп чыга соң? Беренчедән, прозаиклар аз — нибары тугыз гына кеше. Ә драматурглардан берәү дә юк. Икенчедән, проза китапларының Илдар Низамов, Миргалим Харисов, Мәгъсум Хуҗин, Кави Латыйповныкылардан башкалары барысы да диярлек авыл темасына багышланган. Шуның өстенә ул китапларның байтагында инде әдәбиятыбызда шактый тулы яктыртылган сугыш авырлыклары сурәтләнгән. Зур художестволы һәм социаль гомумиләштерелүләр ясауга ирешелмәгән. Авторлар сугышка шул еллардагы балаларча һәм яшүсмерләрчә тар карашларыннан ары китә алмаганнар. Бу яктан өстенлекләре белән бары тик Хәниф Хәйруллинның «Канатлар талмасын» повесте белән «Чишмәләр Иделгә коя» исемле коллектив җыентык кына аерылып торалар.

Ә күп кенә шигырь җыентыкларында заман сулышы тиешенчә сизелми, авторларның үзләренең интим хисләре белән генә мавыгулары, үзләренең «мин»нәрен генә алгы планга куеп эш итүләре күзгә күбрәк ташлана. Сюжетлы шигырьләр, характерлар бәрелешенә корылган поэмалар бөтенләй диярлек күренми. Димәк, бу яшь иптәшләр завод һәм фабрикаларда, тәзелеш мәйданнарында, иген үстерүчеләр арасында, химиклар һәм нефтехимиклар янында, галимнәребезнең лабораторияләрендә аз булалар, кешеләрнең акыл һәм хис дөньясын, аларның дөньяга һәм тормышка карашларын тамырдан үзгәртә торган техник прогрессны тиешенчә күрмиләр, кирәгенчә төшенмиләр, шунлыктан әсәрләрендә дә тирәнтен чагылдыра алмыйлар.

Кайбер яшь язучыларда бик иртә профессионаллашуга омтылу тенденциясе дә юк түгел. Бу — бик зыянлы нәрсә. Яшь кенә көенчә беркайда да эшләмичә гел үз өендә утырып иҗат итү белән генә мавыккан әдипнең тора-бара тормыштан бөтенләй аерылуы, иҗади уңышсызлыкка дучар булуы бик мөмкин.

Заман темасына язу — язучының изге бурычы, дидек. Ләкин тема яңалыгы гына мәсьәләне һич тә хәл итми әле. Яңа теманы яңа сурәтләү чаралары белән ачып бирә белергә дә кирәк. Монысы, әлбәттә, зур тырышлык һәм осталык таләп итә торган катлаулы, авыр эш. Ләкин ул изге эш, мактаулы эш. Шушы таләпләргә җавап бирә торган әсәр язганда гына әдип уңышка ирешә ала. Ә салкын кан белән һәм кәсепчелек максатыннан чыгып кына язылган әсәрләр безнең әдәбиятка бернинди дә яңалык алып килмәячәк. Андый әсәрләр, авторның үзенә дә, укучыларга да куаныч китермичә, бик тиз онытылалар.

Безнең яшьләрнең күбесе әдәбиятка килгәнче башта мәктәпләрдәге әдәби түгәрәкләрдә катнашып, стена газеталарында, кульъязма альманахларда беренче әсәрләрен чыгаралар. Аннары «Яшь ленинчы» газетасында һәм «Ялкын» журналында басыла башлыйлар. Сүз уңаенда бу редакцияләрдә эшләүче иптәшләргә бик зур рәхмәт әйтеп китәргә кирәк. Алар башлап язучылар иҗатына игътибар белән карыйлар, яшьләр әсәрләренә киң урын бирәләр. Китап нәшриятыбызга шулай ук зур рәхмәт: ул соңгы елларда балаларның «Яшь ленинчы» газетасында һәм «Ялкын» журналында басылып чыккан хикәя һәм шигырьләреннән иң яхшыларын сайлап алып, китап итеп бастырып чыгаруны гамәлгә кертте һәм «Тамчылар», «Нинди иркен минем туган илем», «һәр вакыт хәзер!» исемле өч җыентыкны чыгарып та өлгерде инде. «Тамчылар» җыентыгында гына да 40 укучының әсәренә урын бирелгән. Менә шушы яшь һәм сәләтле укучы балалар киләчәктә безнең әдипләр сафын тулыландырырга тиешләр дә бит.

Ә хәзергә алар әле укыйлар, өйрәнәләр, район газеталары каршында оештырылган әдәби түгәрәкләргә йөриләр. Бүгенге көндә республикабызда егерме биштән артык әдәби берләшмә эшләп килә. Ул берләшмәләр белән түгәрәкләрдә иҗат өлкәсендә азмы-күпме тәҗрибәләре булган иптәшләр җитәкчелек итә. Еш кына, Казаннан барып, күренекле әдипләребез һәм союзның консультантлары да районнардагы әдәби түгәрәк членнарының әсәрләрен тикшереп, аларга практик ярдәм күрсәтеп кайталар. Зуррак күләмле һәм аеруча игътибарга лаеклы әсәрләр язган яшь авторларның үзләрен Язучылар союзына китереп, индивидуаль семинарлар үткәрү дә инде күп еллардан бирле гамәлдә. «Казан утлары» редакциясе каршында оештырылган яшь тәнкыйтьчеләр семинарына да без әдәби иҗатның серләренә төшенергә ярдәм итә торган чараларның берсе итеп карыйбыз.

Союз идарәсе һәм партия оешмабызның эш планнарын төзегәндә без яшьләрне тәрбияләү чараларына аеруча зур игътибар бирәбез. Узган бер ел эчендә

генә дә бу мәсьәлә ике тапкыр партия җыелышында каралды. Язучылар союзы каршындагы иҗат секцияләрендә 37 яңа авторның әсәрләре тикшерелеп, шуларның яхшы дип табылганнары матбугат битләрендә бастырып чыгару өчен тәкъдим ителде. Казан университеты, Чаллы, Зеленодольск әдәби берләшмәләрендә семинар-занятиеләр үткәрелде. Язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында планлы рәвештә яшьләрнең иҗат отчетлы кичәләре, шулай ук радио һәм телевидениедә чыгышлар үткәрелеп килә.

Яңа әсәрләрнең кульъязмаларын һәм Союзга кабул ителә торган яшь авторларның китапларын Союзга кабул итү комиссиясе һәм Союз идарәсе утырышларында җентекләп тикшерү дә күптән инде гамәлгә кертелгән. Ә Союзга керергә теләүче яшь язучыларга рекомендацияләрне тәҗрибәле, күренекле әдипләребез бирә. Ул иптәшләр яшь язучыны Союзга тәкъдим итү белән генә чикләнмичә, аның иҗатындагы уңышлы һәм кимчелекле якларны да күрсәтеп, һәр яктан анализлап бирәләр. Шулай итеп, әдәбиятка яңа килүче яшь кешегә иҗат эшенең гаять җаваплы, гаять кыен һәм зур түземлелек, тырышлык таләп итә торган эш икәнлеген тагын бер тапкыр искәртеп үтәләр, киләчәктә ниндирәк юнәлештә эш итү өчен файдалы киңәшләрен бирәләр.

Язучылар союзы чыгара башлаган «Идел» альманахы — шулай ук яшьләр өчен. Аның редакторы да, җиде кешедән торган редколлегиясе дә — барысы да Язучылар союзы членнары. Һәммәсе тәҗрибәле, яшьләргә дустанә карашлы һәм шул ук вакытта таләпчән дә иптәшләр. Дүртенче саныннан башлап бу альманахта әдәби осталыкка өйрәтүне күздә тоткан «Осталык мәктәбе» дигән даими бүлек ачылды. Республикабызда чыга торган партия һәм комсомол газеталары да яшьләр иҗатына бик теләп урын биреп киләләр.

Кайбер күренекле язучыларыбызның иҗатын өйрәнүгә багышланган монографияләрне татар китап нәшрияты китап итеп чыгарды, ә кайбер өлкән әдипләребез үзләренең иҗат лабораторияләре турында сөйли торган китапларны үзләре язып бастырдылар. Моннан егерме еллар элек егермеләп авторның, шул исәптән Горький һәм Галимҗан Ибраһимов, Тукай, Маяковский кебек гигантларның да әдәби иҗат турында әйткән сүзләрен һәм мәкаләләрен туплап, «Язучылык хезмәте турында» дип аталган бер китап та чыгарылган иде. Мондый китапларны киләчәктә дә күбрәк һәм регуляр төстә бастырып барырга, язучылык хезмәте турындагы китапны тулыландырып, яңадан чыгарырга кирәк. Мондый кулланмалар әдәбиятыбыз мәйданына килергә әзерләнүче яшьләргә зур ярдәм итәчәк.

Соңгы бер-ике ел эчендә безнең нәширләребез үзләре чыгарган китапны рецензияләгән кешеләрнең фамилияләрен дә күрсәтеп бара башладылар. Шулай итеп, рецензентның да җәмәгатьчелек алдында җаваплылыгын бик нык арттырдылар. Бу яңалыкны хупларга һәм яшь авторларның беренче китапларын бары тик танылган әдипләребез генә рецензияләвен, тик зур тәҗрибәле редакторлар гына редакцияләвен системага кертергә кирәк.

КПССның XXIV съездында һәм соңыннан КПСС Үзәк Комитетының әдәби тәнкыйть турындагы махсус карарында билгеләп үтелгәнчә, әдәбият һәм сәнгатьнең уңышы тәнкыйтьчеләрнең ни дәрәҗәдә актив эшләүләренә, художникларга карата игътибарлы булу белән бергә, бер үк вакытта принципиаль һәм таләпчән булуларына да бик нык бәйләнгән. Яшьләр иҗатына бәя биргәндә тәнкыйть аеруча зур кайгыртучанлык белән һәм авторларны дөрес юлга юнәлтүне күздә тотып эш итәргә тиеш. Безнең шактый зур тәнкыйтьчеләр отрядыбыз бар. Әмма, шулай булуга да карамастан, яңа чыккан китапларның күбесе, шул исәптән яшь язучыларныкы да, нигәдер тәнкыйтьчеләребез игътибарыннан читтә кала килә. Тәнкыйть секциясе һәр чыккан китапка аның уңышлы һәм уңышсыз якларын күрсәтеп бәя бирә барырга дигән карарны тормышка ашыруга җитди әһәмият бирми, секция членнарына конкрет бурычлар кушып эшләтми. Ә кайбер тәнкыйтьченең бары тик ул сайлап алган авторга гына карата, бары тик дус-ишлек, әшнәлек мөнәсәбәте нигезендә генә сайлап алынган әсәрләрне бәяләү сүзе еш кына язучы файдасына булмыйча, тик аны мактауга гына кайтып кала. Күп санлы яшьләр иҗатын проблемалы гомумиләштерүләргә нигезләнгән, аларның әдәби осталыгына тирән анализ ясый торган тәнкыйть мәкаләләре, тематик күзәтүләр юк дәрәҗәсендә аз.

Әдип кешегә сүз белән оста эш итү, телнең бөтен нечкәлекләрен белү аеруча мөһим. Билгеле булганча, тел ул — куль-

тура коралы, әдәбиятның беренчел элементы, әдип хезмәтенең иң кирәкле инструменты. Бөек рус тәнкыйтьчесе Белинский әдип сүзен (димәк, телен) кеше акылын шигърияткә якынайту чарасы дип санаган. Хәер, бу хакта безнең халык та, бик мәгънәле итеп, колакка кергән салкын сүз йөрәккә җитеп боз була, дип әйтә бит! Бу акыллы сүзләрне без, язучылар, һәрчак исебездә тотарга тиешбез.

Телне өйрәнү язучыларга гына түгел, тәнкыйтьчеләргә дә фарыз. Әдип теле дә, тәнкыйтьче теле дә тирән мәгънәле, образлы һәм чишмә суыдай саф-чиста булырга, укучының йөрәгенә үтеп керергә тиеш. Тел белән аннан-моннан гына эш итүчеләр юлына ныклы киртәләр куярга кирәк. Әдәбиятка яңа килүче яшьләр теленә таләпчәнлекне арттыруча нык көчәйтәсе бар.

Әдип булган кешегә тормышны, кешеләрнең характерларын һәм телне яхшы үзләштерү генә җитми, аңа политик яктан зур мәгълүматка да ия булырга кирәк. Ә моңа бары тик марксизм-ленинизмны һәм чорыбыз проблемаларына карата коммунистлар партиясе ясаган теоретик нәтиҗәләрне ныклап өйрәнгәндә генә ирешергә була. Бары тик шул вакытта гына художник халык тормышы һәм заман белән тыгыз бәйләнештә тора ала. Марксистик-ленинчыл теорияне практик куллану әдипнең иҗатын тирәнәйтергә һәм баетырга ярдәм итә. Димәк, ул әдип әсәрен укучыны коммунизм идеаллары рухында нәтиҗәлерәк тәрбияләү өчен кирәк.

Даими һәм ныклы политик белем алу өчен бездә мөмкинлекләр күп. Язучылар союзында марксизм-ленинизм эстетикасы мәсьәләләре буенча инде менә берничә ел рәттән теоретик семинар эшләп килә. Ул семинарларда өлкән әдипләр белән бер рәттән яшь язучылар да актив катнашып, докладлар, рефератлар белән чыгышлар ясыйлар. Ә кайберләре, аксакалларыбыз белән бергәләп, КПСС өлкә комитеты тарафыннан шәһәребезнең иҗат интеллигенциясе өчен оештырылган семинарга йөри. КПССның шәһәр комитеты семинарлары да еш кына булгалап тора. Ә унлап яшь язучыбыз кичке марксизм-ленинизм институтында белем ала.

Язучылардан гомуми теоретик уку да бөтен җитдилеге белән таләп ителә. Яшьтәшләре конструкторлык бюроларында искиткеч катлаулы машиналар иҗат итү белән мәшгуль булган һәм шул катлаулы машиналар белән идарә иткән, фән өлкәсендә гаять зур ачышлар ясаган хәзерге заманда яшь каләм иясе үзенең укучысына караганда күп мәртәбә белемлерәк булырга тиеш. Чөнки китап ул — тормыш дәреслеге, дигән хакыйкать бар. Кешеләр китапка фикер байлыгы һәм дөньяны киңрәк танырга өйрәнү чыганагы итеп карыйлар һәм бу дөрестән дә шулай.

Шушы бәхәссез дөреслекне истә тотып, Союз идарәсе яшь каләм ияләренең белемен күтәрүгә арттыруча зур әһәмият бирә. Район газеталарында һәм күп тиражлы газеталарда үзләренең мәкаләләре белән актив катнашып килә торган яшьләрне Союз югары уку йортларының филология бүлекләренә укырга тәкъдим итә. Безнең оешмадан ел саен бер-ике кеше Мәскәүдәге әдәбият институтына укырга китеп тора. Ә өченче ел шул ук институтта тәрҗемә буенча татар бүлеге оештырылып, сигез кеше шунда укырга җибәрелде. Алар татар теленнән рус теленә, рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү серләрен өйрәнеп, югары квалификацияле белгечләр булып кайтачаклар. Узган ел Диас Вәлиев белән Николай Беляев Мәскәүдәге ике еллык Югары әдәби курсларга кабул ителделәр.

Шушындый куанычлы хәбәрләрдән соң яшь һәм сәләтле шагыйрь Мәдәррис Әгъләмовның укуга тиешле игътибар бирмәвен зур борчылу белән искәртеп китмичә мөмкин түгел. Ул, университетның икенче курсыннан укуын ташлап, Чаллыга киткән иде. Хәзер, КамАЗ төзелешенең иң кызган чагында, ул Чаллыдан Казанга килде. Ә иң аянычлысы шул, нибары егерме алты яшьтә генә булуына карамастан, укуын дәвам итми генә түгел, хәтта беркайда да эшләми дә. Кызганычка каршы, Мәдәррис бу юлда ялгызак кына түгел.

Өлкән әдипләребездә дә, яшь буын язучыларда да заман таләп иткән, язучылар коллективы күрергә теләгән сыйфатлар әйтеп үтелгәннәрдән тыш та байтак әле. Мәсәлән, бөек Чехов бик хаклы рәвештә талант күрсәткече дип атаган нәрсәгә — иҗат ителгән әйберләрнең санына игътибар итик. Ә талант җәмгыять байлыгы итеп санала бит. Талант иясе һәр вакыт зур иҗади ритм белән эш итәргә, һәрчак чын мәгънәдә киеренке иҗади халәттә булырга, яңадан-яңа сурәтләү

чараларын табу өчен туктаусыз эзләнергә тиеш. Әдип иҗаты тырыш хезмәткә, туктаусыз иҗат итәрлек нык ихтыяр көченә тапкырланган талант ул. Менә шушы сыйфатларны үзендә булдырган вакытта гына яшь әдипләребез әсәрләренең сан ягыннан да күп булуына, сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан да тиешле югарылыкта торуына ирешерләр.

Әдәбиятны пропагандалау һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашу өлкәләрендә дә эшлисе эшләребез күп әле безнең. Халык һәм художник дуслыгы дигән төшенчәгә язучының төрле аудиторияләрдә укучылар белән очрашулары да керә. Әдипләребезгә еш кына күп милләтле илебезнең бүтән халыклары алдында да үзебезнең бөтен бер әдәбият исеменнән чыгышлар ясарга туры килә. Алга таба мондый хәлләр тагын да ешаячак. Менә шуңа күрә дә без язучыларның әсәрләрен русчага тәрҗемә иттерү өчен зур көч куябыз, алардан ышанычлы һәм яхшы тәрҗемәчеләр белән тыгыз мөнәсәбәт урнаштыруны таләп итәбез. Әле Союзга член итеп алганчы ук Союз идарәсе яшь язучыларның коллективта үзләрен ничек тотулары, республикабызда һәм ил күләмендә мөһим булган вакыйгаларда ни дәрәҗәдә катнашулары белән якыннан кызыксынып тора. Яшьләрнең басылып чыккан әсәрләрен зур игътибар белән күзәтеп барудан тыш, аларның халык алдында ничек чыгыш ясауларын да күз уңында тота. Шулай итеп, аларның кешеләргә, тормышка мөнәсәбәтләрен, холык-фигыльләрен ачыклый. Дөньяга үзенең китабыннан алда чыгарга омтылган, әдәбиятны түгел, бәлки әдәбиятта үзен ярата торган, буш сүз сөйләп, минутлык уңыш артыннан куып, шул уңыштан масаеп йөрүчеләргә Язучылар союзы сафларында моңарчы да урын булмады һәм киләчәктә дә булмастыр дип беләбез. Без, язучылар, үз-үзебезгә карата да, бер-беребезгә карата да таләпчәнлекне һаман саен арттыра барганда гына яңадан-яңа уңышларга ирешә алачакбыз. Тик шул чакта гына яшьләребез кешегә кирәк булган иң мөһим сыйфатларга — хезмәтчеллеккә, дөреслеккә һәм гаделлеккә ия булып үсәрләр.

Халыкара хәлләрне яхшырту өчен конкрет чаралар күреп, партиябез һәм хөкүмәтебез безгә чит илләр кешеләре белән һәртөрле очрашуларга да мөмкинлек тудыралар. Мәсәлән, соңгы өч ел эчендә генә дә безнең язучылар мексикалылар, французлар, японнар, болгарлар, поляклар һәм Ямәннән килгән вәкилләр белән Казанда очраштылар, ә кайбер әдипләребез исә үзләре Кубага, Төркиягә, Сүриягә, Польшага, Италиягә һәм башка илләргә барып кайтты. Мондый җаваплы очрашуларда югалып, аптырап калмау өчен әдип кеше һәр яктан зур әзерлекле булырга, үзен совет халкының лаеклы вәкиле итеп күрсәтә белергә тиеш. Бүгенге яшь язучыларыбыз киләчәктә әнә шундый җаваплы миссияләрдә дә, әлбәттә, катнашачак. Алар моңа хәзердән үк әзерләнә башласыннар иде.

Әдәбиятыбызга соңгы елларда яшьләр байтак килә дидек. Бу чыннан да шулай. Аларның һәркайсы, хәл кадәренчә, әлбәттә, заманыбызның җитлеккән проблемаларын сәнгатьчә анализларга, кешеләр арасындагы яңа мөнәсәбәтләрне сәнгать чаралары белән расларга омтыла. Аларда үзләренчә фәлсәфә кылу, яңа образлар белән фикер йөртү чалымнары да юк түгел. КамАЗда геодезист булып эшләүче Мәхмүт Газизов шигырьләрендә, мәсәлән, шул бөек төзелеш кешесенең почеркы күзгә бәрелеп тора. Университетны тәмамлаганнан соң Равил Вәлиев гади эшче булып КамАЗга киткән иде. Ул анда гади ташчы булып эшләү белән беррәттән, кирпечне кирпечкә ябыштырган шикелле, сүзләрне сүзләргә тезеп, көндәлекләр дә язып барган. Һәм менә шул тырышлыкның нәтиҗәсе хәзер барыбызның да күз алдында: аның «Чаллы эскизлары» дип аталган очеркы «Казан утлары» журналының иң яхшы очеркларга бирелә торган еллык бүләгенә лаек булды һәм ул тиздән китап булып та чыкты.

Яшьләребезнең иҗат мөмкинлекләре шактый икәнлеген «Идел» альманахындагы әсәрләрдән дә күрергә мөмкин. Аның инде дөньяга чыккан дүрт санында сиксәнгә якын авторның беренче әсәрләре басылган. Җырчыларга карата әйтелә торган «тавыш куюы» дигән сүзне яшь язучыларга карата да кулланырга була шикелле. Шул җәһәттән караганда яшь авторларның тавышлары әлегә куелмаган була, алар бер үк әсәрләрендә төрле тавышларга кереп-кереп китәләр. Аларның әле нык-лап, тир түгеп эшлисеrange, тавышларын кую өчен күп көч куясылары бар. Аларга өлкәннәрнең дә киңәше һәм ярдәме кирәк. Тәнкыйтьчеләребез бу мөһим эштән шулай ук читтә калмаска, ә әйдәп

баручылар булырга тиешләр. Шул чакта альманахта басыла торган әсәрләргә таләпчәнлек артыр һәм аның дәрәҗәсе тагын да күтәрелә төшәр иде.

Бу урында «Идел» альманахының — яшьләребезнең иҗади үсүе өчен һава белән су шикелле кирәк булган басманың кечкенә күләмле булуын һәм елга нибары бер генә тапкыр чыгуын да борчылып әйтеп китмичә булмый. Татарстан китап нәшрияты бу альманахны тик резерв хисабына гына чыгара. Елына ике сан итәргә мөмкинлек юк. «Идел»нең тагын ике саны — бишенче, алтынчы саннары да әзерләнеп бетте инде. Ләкин аларны кайда бастырырга соң? Альманахны республика газета-журналлар нәшриятында чыгара башлау мәсьәләсен мөмкин кадәр тизрәк хәл итәсе иде.

Кыскасы, яшьләр белән эшләү, аларны һәм иҗади яктан, һәм идея-политик яктан тиешле югарылыкта тәрбияләү буенча алда торган бурычлар зур икәне аңлашыла. Хәзер Язучылар союзы яшь язучылар белән эшләүнең ике еллык планын тормышка ашыра башлады. Ул план буенча 1974—1975 елларда «Идел» альманахының барлык чыккан саннарында басылган әсәрләрне тикшерү, яшьләрнең иҗат отчеты белән радио һәм телевизион тапшырулар оештыру, рус һәм чуваш телләрендә яшьләрнең коллектив җыентыкларын бастырып чыгару, газета-журналларда студентлар тормышын сурәтләп язылган шигырьләргә, поэмаларга һәм хикәяләргә конкурслар оештыру күздә тотыла. Хәзер СССР Язучылар союзында шушы елда яшь язучыларның VI бөтен Союз киңәшмәсен үткәрүгә әзерлек алып барыла. Ул киңәшмәдә безнең яшьләрнең дә иң яхшыларын күрсәтергә кирәк. Моны без комсомол белән бергәләп эшлибез. Гомумән республика комсомолының өлкә комитеты белән безнең Союз инде күп еллардан бирле тыгыз элемтәдә тора. Узган елларда бергәләп яшь язучылар семинары үткәргәнебез, бергәләп Казанда төрле республикалар яшь язучылары — комсомол премиясе лауреатларының фестивален үткәргәнебез бар. Шәһәребездәге яшь иҗат интеллигенциясе берләшмәсен шулай ук комсомол өлкә комитеты белән бергәләп оештырдык.

Әйе, яшь язучыларны иҗади осталыкка өйрәтү буенча да, аларны чын совет кешеләре, коммунизм төзүче кешеләр итеп тәрбияләү буенча да язучылар коллективы шактый актив эшләп килә. Ләкин шунысын аермачык итеп әйтеп китәргә кирәк, бу эшләрнең берсе дә каләм тибрәтә башлаган һәр яшь автордан язучы ясауны күздә тотып эшләнми. Әлеге шул күп санлы яшьләр арасыннан талантлыларын эзләп табу һәм сайлап алу өчен эшләнә бу эшләр. Каләм осталарын үстерүне, шуларга ярдәм итүне күздә тотып эшләнә. «Яңа талантның чак кына талпына башлавын күреп алдыммы, ул үзенең биеклегенә җиңел, артык көч түкмичә генә күтәрелсен өчен, минем шундук аның аяк астына келәм булып ятасым килә». Бу сүзләрне атаклы Максим Горький әйткән. Һәм яшьләр белән эш иткәндә шуны без һәр вакыт истә тотарга тиешбез.

РСФСР язучылар союзы секретариаты утырышларының берсендә, әлеге шул әдәби алмаш хакында сүз барганда, яшьләрнең язучылар оешмасындагы оештыру-иҗат эшләрендә башта кыюсыз гына катнашулары, тора-бара шактый активлашып китүләренә игътибар ителгән иде. Фикерләрнең менә болайрак итеп әйтелгәне хәтердә: «Зур агачлардан торган шаулы урманда яшь куаклар да күп була. Алар еллар үткән саен ныгый, үсә баралар һәм бер вакыт аларның да башлары теге зур агачлар биеклегенә менеп җитә. Ләкин бу яшь куаклар теге агачны каплап китмиләр, бәлки аның тирә-якка киң таралган ябалдаш ботакларының шавын тыңлап, аны үзләренең саф яшеллекләре белән матурландырып кына торалар».

Аңлагансыздыр, бу символ төрле буын язучыларының бер-берләренә һич тә комачауламавы, бәлки үзара аңлашып, дус булып яшәүләренә ишарә буларак бик урынлы китерелә.

Урманчы һөнәренә турыдан-туры мөнәсәбәтем булганга, шушыларга өстәп мин тагын менә болай дип тә әйтер идем: яшь куаклар зур һәм шаулы агачны урап, аның тирәсен ямьләндереп тору өчен генә түгел, ә шул зур агачның тормышы, үсеше өчен дә кирәк. Чөнки табигать законнары шундый. «Имән агачы тун киеп, ләкин ялан баш үсәргә ярата». Урман белгечләре яшь куакларның әһәмиятен әнә шулай дип аңлаталар.

Яшьләр белән нәтиҗәле эшләү өчен без менә шушы мөһим нәрсәне дә һәрчак хәтердә тотарга тиешбез. Монысын инде тормыш законнары белән иҗади үсеш процессы законнары таләп итә.

# КЫСКАЛЫК— ӘДӘБИ ОСТАЛЫКНЫҢ БЕР ШАРТЫ

Мәгълүм ки, әдәби осталык турында предметсыз сөйләп булмый, шуңа күрә мин сүземнең предметы итеп өлкән язучыбыз Мирсәй Әмирнең «Җан көеге» повестен алдым. «Социалистик Татарстан»да чыккан беренче бүлеген исәпләмәгәндә, бу повесть беренче кабат «Исәндәме...» дигән китапта дөнья күрде[1]. Аның турында, гомумән, чыкканчы да, чыккач та, төрле фикер булды, мәгәр матбугатта повесть уңай бәя алды. Бигрәк тә аның оста каләм тарафыннан язылган әсәр икәнлеге икърар ителде[2].

«Җан көеге» — чынлап та оста язылган әсәр. Ләкин болай дип катгый әйтү никадәр җиңел булса, «ни өчен?» дигән әллә күпме сорауга төпле җавап бирү шул кадәр авырдыр. Әсәр ничек укыла? Укып чыккач, хисләребез нишли? Күзебез ачылып, күңелләргә тәгәрәп нур төшәме? Автор идеясе образларга сеңеп, бер бөтен хасил иткәнме? Моңа әсәрнең теле, сюжеты, композициясе ни дәрәҗә ярдәм иткән? Гомумән, әсәр ышандырамы?.. Кыскасы, сорау бик күп. Әлбәттә, бу кечкенә мәкаләдә һәммәсенә җавап биреп чыгу мөмкин түгел, шулай да кайберсенә тукталуны кирәк таптым.

...Кайчан бетә инде дип йөрәкләргә кан савылып төшкән сугыш беткәнгә дә тиздән утыз ел тула. Сугыштан соң туган балаларның инде үзләренең балалары бар. Ләкин **сугыш** дигән шомлы сүзнең күңелләрдән җуелганы юк. Ул — Ватаныбыз өчен шәһид киткән 20 миллион кешенең безгә мирас булып җир өстендә калган бөек рухында. Ул — тәннәрендә кургаш кисәге йөргән исән солдатлар хәтерендә. Ул — изге җир куенына улларын биргән аналар бәгырендә. Ул әле озак еллар күңелдән китмәячәк — икенче, өченче, дүртенче... буын кешеләрен дә ата-бабалар әйдәгән батырлыкка, ватан сөючәнлеккә өндәп торачак. Ул хакта әле зиһенне генә түгел, гражданлык хисләрен дә уйнатырлык яңадан-яңа әсәрләр язылачак. Шуңа күрә заманында сугыш чорына бәйле байтак әсәр язган Мирсәй Әмир яңадан да бу темага әйләнеп кайткан икән — бу бик табигый хәл.

Ләкин, алдан ук әйтергә кирәк, «Җан көеге» повестеның материалы безнең татар әдәбиятында күз күнеккән түгел: аның үзәгендә — дезертир образы!.. Дөрес, моңа тикле Эдуард Касыймовның «Көмеш язулы кылыч» дигән повестенда Хисам атлы бер дезертир күзгә чагылып киткән иде китүен. Инде тагы берәү! Сагаймас җирдән сагаясың: безнең халыкка хасмы соң бу? Хәтергә шундук Тукай сүзләре килеп төшә: «Без сугышта юлбарыстан көчлебез, без тынычта аттан артык эшлибез». Без шуңа күнеккән. Бөек Ватан сугышын гына искә төшерик — күпме герой чыкты безнең халыктан!

Һәм менә шул батырлыкка күмелгән данлы юл өстендә бер дезертир тора! Каян чыккан ул?.. Повестьның язылу тарихына тукталып, автор үзе болай ди:

«Ватаныбыз авыр еллар кичергән чакта, баласы ямьсез хурлыкка төшкән бер бәхетсез ана авызыннан ишетелгән гыйбрәтле сүз күңелемдә гомергә бетмәс яра шикелле авыр эз калдырды: «Уллары сугышта үлгән авылдашларым турында ишеткән чакларда,— диде ул ана,— күңе-

[1] М. Әмир. Исәндәме... Повесть һәм хикәяләр. Татарстан китап нәшрияты. 1972.

[2] Г. Рамазанов. Өлкән әдипнең яңа китабы. «Кызыл таң», 21 февраль. 1973; А. Расих. Художник осталыгы. «Социалистик Татарстан», 24 июнь. 1973.

лемнән, бар бит бәхетле аналар дип уфтана торган идем». Шул вакытта ук миндә бу ананың фаҗигасе турында, гражданлык хисен югалткан түбән җанлы бәндәләргә нәфрәт һәм нәгъләт сыйфатында бер әсәр язу теләге туган иде. Ямьсез факт булганга, язарга ашыкмадым. Күп еллар үтеп китте, ләкин ул гыйбрәтле хәл онытылмады. Онытылмады гына түгел, үзе турында язуны таләп итеп, җаныма тынгы бирмәде. Ниһаять, мин аны язмый булдыра алмадым. Нәтиҗәдә «Җан көеге» дигән повесть барлыкка килде»....

Димәк, материалы бар, мотивы бар, идеясе ачык. Ләкин боларның чишелеше һәр вакыт, математик тел белән әйткәндә, язучының политик, әдәби-эстетик карашлары ныклыгына һәм, ниһаять, осталык дәрәҗәсенә туры пропорциональ бәйләнештә тора. Партияле карашы, принциплары булып та, осталыгы булмаса, әдәби әсәр дип авыз ачуның мәгънәсе юк: көтүдән алда тузан туздыру гына була.

Инде повестьның эченә күз салып карыйк.

1941 елның җилле-яңгырлы көзге кара төннәренең берсендә, шомлы җилдәй тәрәзә кагып, фронтка киткән җиреннән качкан Камәретдин кайтып төшә. Әсәрнең беренче җөмләсеннән үк сискәндереп башлаган ямьсез төн картинасына кеше сурәтле «ниндидер салкын юешлек» килеп кушыла. Үз вөҗданын көзге юл пычрагына салып изгән Камәретдингә булган мөнәсәбәт шушы өч сүздән башлана да инде: «ниндидер салкын юешлек». Ул хәтта сөйгән хатыны белән әнисенә кул да биреп күрешә алмый; тизрәк толып белән берике телем ипи алып, печәнлеккә чыгып яту юлын карый.

Шул караңгы төннән алып, «бу өйгә яңадан мәңге әйләнеп кайтмаска ант иткәндәй», килен белән кайнанага әз булса да ял бирә торган тәмле йокы юкка чыга. Ил белән килгән, ләкин рухны сындыра алмаган сугыш авырлыгы өстенә, бу икәүнең генә башына төшкән олы хәсрәт — хурлык өстәлә. Моңардан, әлбәттә, бик авыр булса да, бер селтәүдә кырт өзеп, котылып та булыр иде. Ләкин беренә бала, икенчесенә ир булган якын кешеләрен, күрәләтә, җитәкләп чыгарып сата алмыйлар: кан бер, гаилә бер!.. Шулай итеп, алар, ихтыярсыз, хыянәткә катнашучы булып китәләр.

Шулай да алар беренче көннән үк бик ныклык белән Камәретдинне бу түбәнлек юлыннан коткарырга тырышып карыйлар. Тик Камәретдиннең ишетәсе дә килми. Ул поездлары туктап торган бер станциядә бик «мәгънәле» сөйләшкән ике кешедән: «Да, купка бармас. Мәскәү киткәч инде, калганы... күп булса бер айдан бары да бетәр... Хәзер бөтен хикмәт — исән кала белүдә» дигән сүзләр ишетеп кайта. Камәретдиннең мескен йөрәгенә бу сүзләр көч бирә. Әлбәттә, исән кайтасың дигән ышаныч булса, ул да сугышта нинди кыенлыкка да түзәр иде. Ләкин аңа кем андый гарантия бирә? Шуңа күрә ул «бер айга да бармас» сугыштан исән калырга уйлый.

Хәтирәнең дә күңеленә иблис коткысы төшеп ала. Тик ул аны минут эчендә йолкып ыргыта. «Барыбер дошманга баш ия торган түгел безнең ил»,— ди ул. Сугыш Татарстанга җиткән хәлдә дә Хәтирә үзен фәкать партизан итеп кенә үенә китерә ала. Бу — аның иманы. Язмаячак ул бу иманнан.

Камәретдин белән сөйләшкәннән соң Хәтирә дә, Сабира да тәмам гаҗизлеккә төшәләр. Кайнанасы «Хәтирәнең шундый авыр тойгылар кичергән чагында да гүзәллеген, зифалыгын югалтмаган гәүдәсенә, бетмәс яшьлек, карап туймас яшәү матурлыгы бөркеп торган иңбашларына, күкрәкләренә, хәсрәт күләгәсе астында да алсу нурын саклаган моңсу йөзенә карап авыр уйга талган иде. Аның улы янында фәрештә бит бу изге җан!..» Бу уйлар фәкать килененә карап уйланса да, нигездә улына юнәлтелгән; хурлыклы, түбән юлга аяк баскан улына карата әрнүле мөнәсәбәт ап-ачык булып ярылып ята, һәм шушы моменттан башлап килене аңа үз баласыннан якын бер кешегә әйләнә. Икесе өчен дә газиз булган Камәретдиннең йомшак җиргә чыгып, сызлата-сызлата үсә барган чуанга әйләнә.

Шулай да әле өметләре тәмам киселмәгән: алар әле һаман Камәретдиннең бөтенләй үк намусы бетмәгәндер, үз гаебен үзе танып, үзенә генә түгел, әнисе белән хатынына, үз халкына, ниһаять, Туган иленә төшергән кара тапны үз каны белән юар дип көтәләр. Инде аларны Камәретдиннең бу газават юлында исән калу-калмавы да борчымый — ил алдында вөҗданы саф булып калырга тиешлеге генә борчый. Идән аша туры да, кинаяләп тә әйткән күпме сүз, күпме акыл исраф ителә! Ләкин Камәретдин бирелергә уйламый: аның көчсез зиһене белән кур-

как йөрәгеп, сөремдәй, җан саклап калу инстинкты томалаган; шул инстинкт белән ул тиздән хөкем алмашынуын көтә. Әмма көннәр уза, атналар уза, ә тыны белән суырып алырдай көткән көне килми дә килми. Алай гына түгел, киресенчә китә бара — безнекеләр Мәскәү янында фашист сурәтенә кергән тевтон токымының мөгезен сындыралар.

Бу шатлыклы хәбәрне ишеткәч, «Сабира үзалдына сөйләнү тәртибендә генә әйтеп куйды:

— Болай булгач, ходайга шөкер икән әле,— диде.— Батыр йөрәкле ирләр дә җитәрлек икән...

Юри кычкырып әйтә, юри бәгыреңә пычак кадый... бердәнбер улы артык микәнни?..»

Монысы әле баласы гына! Бер көн аларга, хәсрәтеннән үзен-үзе кая куярга белмичә, бердәнбер улының үлем хәбәре килгән Шәргыя карчык керә. Сабира белән икәүләп елаша-елаша сөйләшеп утыралар. «Камәретдиннең әнисе авыр хәсрәткә тарыган күршесен юатырга теләп әйтте:

— Командиры бик дөрес әйткән, күрше,— диде.— Сабыр бул. Улыңның әнә шулай ил рәхмәтен алырлык батыр булып үлүе ул кайгы гына түгел, аның юанычы да зур. Моңардан начаррак хәсрәтләр дә була бу дөньяда».

Шәргыя карчыкны озатып кергәч, Сабира апа тирән көрсенеп: «Бәхетле ана!» дип куя. Бу сүздән тәннәр чымырдап китә. Чыннан да Камәретдин ише баланың тере булуыннан ни бәхет! Әлбәттә, өстә сөйләнгән һәр сүзне Камәретдин үзе дә базда ишетеп ята. Ләкин суга баткан саламга ябышыр диләр, ул өметсезлек, дучарлык белән талпынып-бәргәләнеп, көннәр җылытуын көтәргә була. «Җәйгә чыккач ни булыр бит әле?» — менә аның бик тә әйле-шәйле өмете.

Ә ул арада әнисе белән хатыны күңелендәге аңа булган өмет, әрнеп-авырттырып, сүнгән йолдыз шикелле, сызылып кына юкка чыга; якынлык хисләре битараф ераклыкка китеп, таштай каткан бәгырь генә торып кала. Бәгырь ите шулай киселә. Моннан соңгы вакыйгаларда Камәретдиннең барлыгы-юклыгы үзенең әһәмиятен җуя.

Хәтирәнең дә иренә булган мөнәсәбәте кульминация ноктасына җитә. Казаннан урман кисәргә җибәрелгән ике кыз боларда торган чакны була бу хәл. Бер кичне ярыктан ялгыш төшеп киткән фоторәсемне алырга дип Хәтирә базга төшә.

«Әллә нишләде шунда Камәретдин. Карточканы тыныч кына ычкындырасы урында, нишләгәнен үзе дә аңламастан, ихтыярсыз, Хәтирәне шул сокландыргыч матур беләгеннән тотып алды.

Әйтерсең елан чакты Хәтирәне. Йөрәк яргыч тавыш белән, бөтен өйне яңгыратып, чарылдап кычкырып җибәрде:

— Кеш, ләгънәт! Кеш!

Ул атылып баздан чыкты. Шундук идәнне ябып, өстенә тибеп куйды... Куркынган кызлар:

— Нәрсә булды, Хәтирә апа? — диештөләр.

Хәтирә һаман тынычлана алмый, аларга рәтләп җавап та бирми иде.

— Паразит! — дип дәвам итте ул.— Әрәмтамак! Каян иләшкән безгә шундый хәшәрәт! Бөтен өйнең ямен җибәрә, шакшы!»

Моннан да ачык әйтү мөмкин дә түгелдер. Шулай итеп, Камәретдин Хәтирә өчен ир буларак кына түгел, гомумән, кеше буларак та бетә — Хәтирә күңеленнән язгы ташкын юып алып киткән чүптертирестер шикелле юылып кына төшә. Хәтта кулы да, башы-күзе дә гарип Каһәрман да аңа Камәретдиннән ягымлырак күренә башлый. Тик йөрәгендә, «хәтта аның турында уйламаганда да бетми торган чир шикелле» булып, юшкын утырып кала.

Ләкин мондый киеренке хәлнең бер өй эчендә озакка китүе мөмкин түгел. Чуан җитлегеп сытылырга тиеш. Һәм сытыла да: язның шөлдерәп ерганаклар аккан, шашып сыерчыклар сайраган бер көнендә үзе дә инде артык түзә алмаган Камәретдин караңгы баздан якты көнгә чыгарга була.

Хәтирә «каршысында базда үскән бәрәңге кебек төссез ак чырайлы, мыегы белән тоташып, чәбәләнеп, укмашып беткән кара сакаллы, килбәтсез озын һәм пычрак чәчле, кабердән чыккан төсле арык, хәлсез ят кеше басып тора иде...

— Менә чыктым,— диде Камәретдин.— Хәзер әзрәк өс-башымны рәтлим дә сельсоветка барам. Теләсәләр нишләтсеннәр...

Ниһаять, Хәтирә дә сүз әйтерлек хәлгә килде:

— Соңга калдың, Камәретдин.

Аның тавышында Камәретдинне кызгану да, үкенү дә юк иде».

Нәфрәт тойгысын әйтәсе дә юк, чөнки нәфрәт өчен дә бу бәндә артык түбән. Аңа карата фәкать кыргаякны изгәндәге җирәнү генә булуы мөмкин. Чөнки аның Кеше һәм Гражданин дип аталырлык йөзе калмаган, ә кылган гамәле, дөресрәге, гамәлсезлеге безнең совет чынбарлыгында җирлек таба алмый. Безнең чынбарлык Хәтирәләр, Майбәдәрләр, Корбангалиләр, Камалиләрнең таза кулында; идея шуларның уй-холкы, гамәлләренә әверелгән. Димәк, уңай образлар никадәр көчле булса, никадәр ышандырса, кире тенденцияләргә мәйдан шул кадәр бетә барачак.

Бу җәһәттән Камали (тулы исеме — Камалетдин) образын әйтеп узасым килә. Унбиш яшендә авылдан качып чыгып китеп — бер шаулый. Читтән акыл утыртып, чаяланып кайта. Төннәрен колхоз атына атланып, күрше авыл кызлары янына йөри. Аннары армиягә алалар. Армиядән туры Уралга китә. Салган баштан ярамаган эш эшләп, төрмәгә утыра. Аннан котылгач, яңадан үз авылына кайта. Читтә өйләнгән хатыны ул төрмәдә чакны кияүгә чыгып куйган: Камали күп уйлап тормый, бер баласы белән ирдән кайткан Майбәдәргә өйләнә. Эчеп алса, бер дулап та ала.

Сугышка тикле менә шундый була Камали. Шуңа күрә, улы качып кайткач, Сабираның шиге шундук аңа төшә: «Мәгаен, шул Камали этлеге бу! Югыйсә, мондый бала идеме соң безнең Камәретдин?!»

Сугышка алар бергә китәләр. Бер авылдан булулары өстенә фамилияләре дә бер: Абдуллин. Җитмәсә, барлау вакытларында Камәретдинне һаман Камалетдин белән бутыйлар. Инде шул бутауның бәласе булып, бер төнне Майбәдәрләргә тенту керә.

«— Мин аны әллә кайларда газап чигә дип, сугыш кырларында җәфалана дип кызганып йөрим. Көне-төне дигәндәй ходайга ялварып, исән-сау булуын сорыйм, җиңүче булып әйләнеп кайтуын көтәм. Ә ул... Минем янда чакта аңардан батыр кеше юк иде. Куян йөрәк икән, адәм хурлыгы!» — дип, Майбәдәр бар ачуын, ярсуын Хәтирәләргә түгеп чыга.

Ә базда яткан чын дезертир моны үз файдасына бора — Камали турындагы бу яман хәбәр аның өчен яхшы гына түгелме соң? Димәк, аларны һаман бутап йөртүдә дәвам итәләр. «Димәк, Камәретдин урынына Камалетдинне эзлиләр. Эзли бирсеннәр. Камәретдингә тынычрак булыр». Ә Камали — аларның ут күршесе.

Ләкин, һич көтмәгәндә, «тагын берәр ярамаган эш эшләп ташлавы бик мөмкин» булган дуамал Камалетдин чын батыр булып чыга. Ул хат язышырга ярамый торган җиргә барып эләккән дә шунда яраланып госпитальгә кергән икән. Хаты килеп күп тә үтмәстән, аның исемен газетадан укыйлар: сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән. Ә тагын бер-ике атнадан, юл буйларында гөрләвекләр аккан бер матур көнне, үзе дә отпускыга кайтып төшә.

Хәтирәләргә күрешә кергәч, автор аны ничек аяк атлавына кадәр тасвир итә: «Таза итекләре белән идәнне сыгарлык басып атлаулары өй эчен тулыландырып, ямьләндереп җибәрде», ди. Бу деталь бик мәгънәле — Камали чыннан да өй эчен генә түгел, ә бөтен әсәрне ямьләндереп җибәрә: бу образга язучы аерым идея — батырлыкның җиңүе идеясен йөкләгән.

Әсәрдәге конфликт, көрәш психологиясе дә бик катлаулы — чаптың-өздең белән генә хәл ителә алмый: гаилә, туганлык җепләренә уралып беткән. Камәретдин «мондый яман акылсызлык эшләве белән ана күңелен бик каты рәнҗетсә дә», әнисе аңа рәхимсез була алмый: «Бала бит!» Хәтирә дә башта, Камәретдин үзе теләмәгәч, сельсоветка барып әйтми: «Үз иреңне үзең чагу? Юк, Хәтирә анысын булдыра алмый. Күңеле тартмый, күңеле тартса да, аягы атламас ул юлга, аягы атласа, теле әйләнмәс! Әби-бабайлар йоласын тотар».

Менә шушындый, җан тартмаса да кан тарткан, акыл җитсә дә, йөрәк җитмәгән ситуациядә кемнең кем икәнлеге, ягъни характерлар сынала да инде. Бу психологик көрәштә үз язмышын ил язмышына бәйләгән, үз намусын ил намусы итә алган кешеләр генә ут-су барьерын янмасбатмастан җиңеп чыга ала. Камәретдин баскан юл әнисе белән хатынын да, сиздерми генә, битләренә халык төкерәчәк хурлыкка җитәкләп алып керәчәк иде. Бу җитәккә иярмәү өчен күңел тартмау гына җитми — югары дәрәҗә гражданлык хисе, гражданлык аңы да кирәк. Сабира белән Хәтирә менә шушы бөек хиснең ныклыгыннан сынау үтәләр. Әлбәттә, әгәр әйләнә-тирәләрендә Майбәдәрләр, Зәкияләр, Мәрьямнәр, Корбангалиләр булмаса; әгәр бөтен авыл халкы бөтен ил язмышы өчен яшәмәсә, бу баткак юл, кем белә, бәлки аларны да суырып ала алыр иде. Ләкин

социаль җирлек башка, мохит башка! Нинди авырлык, мохтаҗлыклар кичереп тә, җиңеп чыгуыбызның чишмә башы менә шул мохиттә — стройда инде! Бу фикер повестьның бөтен әдәби җирлегенә аркавы-буе итеп тукылган.

Мирсәй Әмирнең хатын-кызларга булган хөрмәте, инсафлы яратуы бу повестендә дә бетмәс көч белән бәреп тора. Хатирәнең һәр сүзе, хәрәкәте, мөгамәләсе, портретына игътибар итегез. Никадәр фидакарьлек, никадәр сафлык һәм мөлаемлек! Яки берничә генә биттә күренеп тә, күңелгә ярылып төшкән Казан кызлары нинди! Яки чәчрәп торган зәңгәр күзләре, уйнаклап торган кайнар күкрәкләре белән оешкан каннарга да ут җибәрә торган Майбәдәр дә күз алдыннан китәсе түгел. Янә Сабира апа белән Хатирә арасындагы мөнәсәбәт **ышандыргыч** ситуацияләр аша сокландыргыч итеп сурәтләнгән — йөрәккә кадала торган бер шырпысы юк. Бу — кайнана белән килен арасындагы традицион «яратышудан» бик нык аерылып тора. Бу ике образны язучының аеруча уңышы дип әйтергә кирәк. Болар бик нык уйланылган: идеянең авыр башы шул ике хатын өстенә төшә дә инде. Кыскасы, үзенең бәрәкәтле иҗат дәверендә Мирсәй Әмир каләме яраткан хатын-кызлар галереясына — Артыкбикәләр, Миңлекамаллар, Фатыймалар, Санияләр янына Хатирә өстәлде.

Гомумән, образларның төгәл эшләнүе, һәммәсенең ышандыруы җәһәтеннән «Җан көеге» повесте күпләргә үрнәк була ала. Анда — кереп тә, сүз әйтергә оныткан, яки сүз әйтеп тә, чыга алмый буталып йөргән бер генә персонаж да юк. Роберттан Рәшиткә әйләнгән иң эпизодик персонаж белән Каһәрманның ун гына сүз каткан тилемсә хатынына кадәр төгәлләнеп бетә.

Әгәр без повестьның күләме нибары биш кенә табак икәнлеген искә алсак, уйланыр, үрнәк алыр нәрсә бик бар. Күл-күл су җыелып торган калын романнар белән чагыштырганда бу кечкенә повесть бик тыгыз. Ул — Мирсәй Әмирнең өзлексез камилләшә килгән осталыгы нәтиҗәсе. Монда ул «Саф күңел»ендәге озынлык чирен җиңеп, сюжетның җегәрле агышына, композицион бөтенлеккә ирешкән. Су тула торган арыклар ябылган — повестьта бер артык эпизод, бер артык деталь җебеп-бүртеп ятмый.

Сүзләр тукымасы да һәр төрле тәти нәкыш, бизәктән арчылган, ничек бар шул мәгънәсе белән дөрес кулланылган. Өстән карaганда, образлы итеп язарга омтылганлык һич күренми сыман, ләкин язган һәр сүзе төбәлгән ноктасына тиеп кенә тора. Менә Хатирә портретындагы кечкенә бер штрих-билге. Фонарь тотып, бер генә минутка базга төшеп менгән Хатирәне автор болай тасвирлый: «Камәретдин аны хәзер тагын да тулырак күрә. Алсу нур балкытып торган ялангач беләкләренең, юка күлмәк изүе аша әйтеп бетергесез нәфис булып күренгән ап-ак күкрәкләренең баш әйләндергеч җылылыгын тоя». Биредә портрет турыдан-туры түгел, ә Камәретдин күргәнчә — көзгедәге сыман чагылдырып бирелгән. Әмма, шулай булуына карамастан, Хатирә тере булып күз алдына килеп баса. Чөнки ул, иң үзгә бер билгесен тотып алу өстенә, Камәретдиннең ямьсез, кара язмышы аркылы чагылдырыла. Портрет деталенең эчке динамикасы, җегәре бар. Ул символик та: караңгыда ялангач беләкләрнең алсу нур балкытуы бөтен әсәр өчен кирәк.

«Җан көеге»ндә катлаулы чагыштырулар, метафоралар юк дәрәҗәсендә. Язучы образлау йөген төгәл мәгънәле һәр сүзнең үзенә йөкләгән. Мисаллар: «Яңгыр да, төне буе **тырышып ява-ява хәлсезләнеп калгандай,** юашланган, туктар-туктамас кына сибәли» (чагыштыруның иң гади формасы); «Коштабакка сөт салып, кулына күкәй алгач, кире уйлады: **таба исе бөтен урамга таралачак бит**» (өлешенә карап бөтенне аңлаткан сәбәпле бәйләнеш); «**Тарала алмый йөргән сөякләрен** таратып бирермен!» (метонимиягә сүзнең кабатлануы өстәлеп көчәйтелгән); «Инде тынычланып җитәм дигәндә, яңадан **иреннәре йомшарып** китте» (метафора); «Йөрәккә үткәреп карый ала торган зәңгәр күз» (эпитетка әйләнгән чагыштыру) һ. б.

Мисаллардагы сын яки хәрәкәт безнең күз алдында торган яки эшләнгән кебек. Сүзләр тук башактагы бодай бөртекләре сыман шыплап тезелгән. Күрәсез, болар һәркем әйтә ала торган гап-гади сүзләр. Ләкин язучы аларны, сәйләндәй сайлап кына, берсен-берсенә ялгап куйгач, пластик образ барлыкка килә — шул «йөрәккә үткәреп карый ала торган зәңгәр күз»ләргә күз тутырып үзең карап торган төсле.

Җыеп әйткәндә, «Җан көеге» повесте — йодрыктай йомарланган, пружинадай кысылган, кирәкмәгән бар детальдән арчылган, бер сулыш белән укыла торган әсәр ул.

**ХӘСӘН САРЬЯН.**

# ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР ӨЛГЕРГӘНЧЕ

Татарстан китап нәшрияты бер-бер артлы ике китап чыгарды. Икесе дә шигырь китабы. Беренчесе — Илдар Юзеевның «Карурман»ы, икенчесе — Равил Фәйзуллинның «Наз»ы.

Тәнкыйтьчеләребез бу китапларны алганнардыр, укып, уйланып йөриләрдер, үзләренең авторитетлы сүзләрен бер заман әйтерләр. Минем максат — алар кузгалып өлгергәнче берничә сүз әйтеп калу, китапларны укыгач туган фикерләрем белән уртаклашу. Фикер — артык зур сүз, хисләрем белән уртаклашу дисәм, дөресрәк булыр.

Тәнкыйтьчеләр шагыйрьләрне буыннарга бүлеп өйрәнәләр. Өлкән буын, урта буын, яшь буын. Хәтерем ялгышмаса, Илдар Юзеев урта буынның бер вәкиле булып йөри, Равил Фәйзуллин исеме яшь буыннар тутырылган тартмадан алынып өлгермәгән. Ләкин Илдар Юзеев белән Равил Фәйзуллинның тирән фәлсәфәле, киң колачлы шигырь һәм поэмаларын укыгач, үзеңне берни дә белмәгән бала-чага итеп тоясың, дөньяны яңа ачасың, ә әлеге шагыйрьләрнең икесе дә тормышның бөтен сикәлтәләрен үткән ыру башлыклары — аксакаллар, өлкән буын булып күренәләр.

Сүзне Илдар Юзеев китабыннан башлыйм. Бу китапта шагыйрьнең соңгы елларда язган шигырьләре һәм поэмалары. Шигырьләр турында сөйләп тормыйм: Илдар шигырьләре матбугатта беренче тапкыр күренгәннән алып хәзерге көнгәчә өлкәннәрнең дә, яшь-җилкенчәкнең дә күңелләрен били килгән, аларны һаман яттан сөйлиләр, җырга салып җырлыйлар. Хәер, шагыйрьнең хискә, моңга тулы поэмаларын да яхшы беләләр.

Шулай да «Карурман»га кергән ике поэманың һәркайсына аерым-аерым тукталып, аларга үз мөнәсәбәтемне белдереп китәсе килә. Кайбер кешеләрдән ишеткәнем бар: имештер, Илдар Юзеев изге эш эшләгән, бүгенге көннең актуаль проблемасын күтәреп табигатьне саклау турында «Карурман» исемле поэма язган. Мондый бәя белән мин килешеп бетмәс идем. Үзебезнең мохитебезне пычранудан, тапталудан саклау, әлбәттә, гаҗәеп актуаль проблема: ул мәсьәләдә илләр белән илләр сөйләшә, һәртөрле килешүләр төзелә. Ләкин Илдар поэмасының фәлсәфәсе тагын да тирәндәрәк ята түгелме? Чорлар агышында, еллар калейдоскобында, дөнья ашкынып алга чапканда кешеләрнең, халыкларның язмышы-тормышы турында сөйләмиме поэма?

Кыләчәгем шиңа нәрсә әйтер
Бабам васыятен онытсам,
Кан юлларым буйлап челтерәгән
Чишмә агышларын корытсам?

Шуның белән сүзем бетте, «Карурман»ны кичтем. Әйтергә теләгәнем — поэманы укыганда дикъкатьлерәк булуны үтену.

Инде килеп «Таш диварлар авазы». Поэманың «Казан утлары»нда дөнья күрүенә күпме вакыт узды, матбугатта бер кәлимә сүз булганы юк шикелле. Форма яңалыгын, әсәрнең катлаулылыгын читкә куеп торып, поэманың эчтәлегенә — фикеренә күз салыйк. Шагыйрь «хәйләкәр йөреш» ясый, парадокс әйтә — кешегә төрмә кирәк түгел, ди. Чыннан да дөньяның нинди акыл ияләрен, нинди каһарманнарын ничәмә гасырлар буе төрмә үз кочагына алып изгән, сыткан, үтергән. Әйе, төрмә кирәк түгел. Ә ул чакта чын мәгънәсендәге җинаятьчеләрне, кешелек палачларын һәм башка вак җаннарны нишләтергә? Иректә йөртергәме? Шагыйрь ялган гуманлылыкка бирелмиме? Ялгышмыймы? Юк, ялгышмый, минемчә. Килер бер көн, ди шагыйрь, кеше үзенең асылын аңлар, үсүенең иң биек камиллегенә ирешер — төрмәнең кирәге калмас. Үзе уйлап тап-

кан тормөне Көше үзе җимерер. «Таш диварлар авазы»нда мин шушы бөек килөчөкне күрөм. Һөм мондый поэманы бары тик олы шагыйрь генә яза ала дип уйлыйм.

Равил Фәйзуллин шигырьләренә минем әллә ни исем китми иде. Хәтта, кемнәргәдер ияреп, аның нюансларын Матбугат йорты коридорында сүгеп тә йөрдем. Минем исем китмәгәнгә Равилнең дә исе китмәде: яза торды, китаплар чыгара торды. Һәм менә тагын берсе. «Наз» дип атаган, һәм мин сүгеп йөргән «Нюанслар»ының да байтагын шушы китабына керткән. Миңа иң ошаганы шул булды. Юк, нюанслар үзләре түгел, мин әле дә аларны әллә ни аңлап бетермим. Миңа шагыйрьнең үзе ышанып язган әйберен төрле тиргәү, хәтта мыскыллауларга карамастан, яклый белүе ошады. Бу — кирелек, үҗәтлек түгел. Шагыйрь үз сүзен яклый белергә тиеш. Заманында кайберәүләр, Равилнең аерым шигырьләрен укыгач, әрәм була бу бала, мөгез чыгарып азапланыр да мөгезе сынгач, мүкләк кәҗәгә әйләнер дип курыкканнар иде. Менә «әрәм булган бала»ның шигырьләре.

Мөхәммәт Мәһдиев китапка язган кереш сүзендә Равилнең шигырьләрен җентекләп анализлый да, шагыйрьне мактап туйгач: «Соңгы сүз — укучыныкы»,— ди. Мин — меңләгән укучыларның берсе — үз сүземне әйтергә ашыгам. Шәп, шайтан.

Шигырьләрендә әллә ниләр «кыландыра» Равил. Форма турында әйтмим. Шагыйрьне «акылга утырттылар», шигырьләрнең бөтенесе диярлек традицион формада язылган. Мине шаккатырганы, Мөхәммәт Мәһдиевне кабатлыйм, бәләкәй генә, вак кына, гади күз белән күрә алмаслык тормыш детален алып шуны көчәнмичә, интекмичә, фәлсәфи югарылыкка күтәреп, теләсә кемне уйландырырлык шигырь яза алуында.

> Һәр тамыр, һәр бөре — һәрбере
> Бер шауда, бер сүздә: яз! Яз! Яз!

Нәрсә инде бу? Яз көне агачларның бөреләнгәнен шагыйрь әйтмәсә дә беләбез ләбаса. Ләкин — чү!..

> Чү! Өстә — каенның тузыннан
> ишетелә кызганыч бер аваз?!
>
> Шыгырдый, сыкрый яшь юкә,
> каенның иңенә ауган да...
> Шулайрак егыла кеше дә
> җиңәм дия, җитәм дип барганда,

Миңа бәлки каршы төшәрләр, шигырьнең бик үк уңышлысын сайламагансың диярләр. Бәлки, бәлки... Ләкин бу юллар мине уйландыра. Язларын урманга чыксам, теләсәм-теләмәсәм дә, бу юллар кылт итеп исемә төшәчәк. Язгы урманның матурлыгына тилеләрчә сокланып кына йөреп булмас, ахры.

Яки менә мәхәббәт турындагы шигырьдән бер өзек:

> Яшьлегеңне, гомереңне
> миңа багышладың да,
> хәзер инде гел әзер тор
> яңа сагышларыңа.

Өстән карaганда, шагыйрь кылана кебек, нидәндер акланырга тырышып, ваклана сыман. Шигырьне китапка кертмәскә дә кирәк булгандыр кебек. Андыйларга альбом шигыре дигән тамга сугылган. Бактың исә, шигырьдә тагын фәлсәфә: гыйшкыбыз ташыганда уйламыйчанитмичә антлар итешәбез дә, тормыш белән очрашкач еш кына суд ишеген шакыйбыз.

Мәхәббәт дигәннән, соңгы елларда Равил адресына гаепләү сыманрак бер сүз әйтелә башлады. Янәсе, Равил интим лирика белән артык мавыга, шуңа иҗаты тарая. Имеш, Р. Фәйзуллин гражданлык пафосы белән сугарылган шигырьләр күбрәк язарга тиеш. Бүтәннәргә ничектер, мин, мәсәлән, «Наз» китабында Равил иҗатының тараюын түгел, тирәнәюен күрәм. Гражданлык пафосы белән сугарылган шигырьләр бик күп китапта. Тик алар күзгә бәрелеп тормыйлар, декларатив яңгырамыйлар, алар җылылар, шуңа күрә йөрәккә тиз үтеп керәләр.

Әгәр Равил ара-тирә интим лирика белән мавыга икән, начармыни ул? Мәхәббәтсез поэзия поэзиямени ул?! Кызларның чибәр, сылу, акыллы булуларына карап кына гашыйк булмыйбыз, картлар әйтмешли, мәхәббәте дә булсын. Кыскасы, Равил «Нюанслар»ын язганда ук чын шагыйрь булган, бүген мин шуңа инандым.

Ике китап. Ике шагыйрь. Кайсы буынга кертергә аларны? Хәер, андамыни мәсьәлә. Иң яхшысы, поэзиябездә шатланырлык-мактанырлык шагыйрьләребез җитәрлек. Бүген мин аларның икесен мактадым. Беләм, алар мактауга мохтаҗ түгел. Һәм бу рәвештә мәдхия укуны тәнкыйтьчеләр дә әллә ни өнәп бетермиләр, шагыйрьләрнең «бозылуыннан» өркәләр. Ләкин без «бозганга» карап кына «бозылган» шагыйрьнең бозылуы хәерлерәк.

Туфан **МИҢНУЛЛИН.**

## Шәүкәт Галиев

### Бакчада бәхәс

**1. Кояш нинди!**

Кызыл кашкарый
Кояшка карый:
— Минем төсле! — дип,
Күзләрен алмый.

Бишни кашкарый
Кояшка карый:
— Юк, юк, бишни! — дип,
Үзенчә саный.

Зәңгәр кашкарый
Кояшка карый:
— Минем төсле! — ди,
Килешә алмый.

Күк кашкарый да
Кояшка карый:
— Күк ул, күк, күк! — дип,
Кабатлап арый.

Яшел яфраклар
Кояшка карый:
— Безнең төсле! — дип,
Үзләрен таный.

Көнбагыш бигрәк
Текәлеп карый:
— Минем төсле! — ди, —
Сары ул, сары!

Өстәл өстеннән
Әфлисун карый:
— Кояш нәкъ минем
Төсле ул, җаный!

Шунда салават
Күпере калкып:
— Минем төсле!!! — дип
Елмайды балкып.

2. **Җир тәмлеме!**

Кура җиләк:
— Җир — шикәрле,
Тәмле, — диде.
Торма әйтте:
— Ялганлама,
Яме! — диде.

Кайсына да
Кушылырга
Белми суган:
— Җиләк, син дә,
Торма, син дә
Хаклы сыман...

— Икеләнмә,
Сөйләшсәң син
Өзеп сөйләш —
Җәен — әче,
Көзен — баллы, —
Диде миләш.

Алма әйтте:
— Мин дә шулай
Дөрес күрәм.
— Юк, юк, җир ул
Һәрчак әче! —
Диде керән.

Кеше әйтте:
— Һәркайсыгыз
Хаклы, — диде. —
Тирем — әче,
Ә хезмәтем —
Татлы! — диде.

## Тиктормас

Җирдә, әнә, туп тора,
Сезнеңчә, ул тик тора.
Кәлине үртәп тора:
— Тип! Тип, әйдә! — дип тора.

Юлда шома таш тора,
Тупны да оныттыра,
Үчларны кычыттыра —
Алдырта, ыргыттыра!

Карт юкә өстән карый:
— Берни күрмисең, дия,
Ничек менмисең, дия,
Әллә шүрлимсең?! — дия.

Машиналар кычкыра:
— Исәнме, таныш, диеп,
Әйдәле, ярыш, диеп,
Җитәлсәң, ябыш! — диеп.

Күрделәр, кисәттеләр,
Йодрык та күрсәттеләр.
— Йөрмә әле син анда
Теләсәң нишләп, — диләр, —

Өйдә утырып кара!
Утырса, исе китә!
Утырыр иде бик тә —
Диван аны сикертә!

Буфеттагы конфет та:
— Мине табып кара, ди,
Менеп алып кара, ди,
Берне кабып кара! — ди...

Торыр иде тик кенә,
Котырталар бит менә!
...Сүзләре күп, дәшмиләр
Китаплары ник менә?

## Бугай...

Басуга чыкты бабай,
Кулына алды курай,
Кушылды аңа тургай.
Уйнап торгачтын шулай
Тургайга уңай бугай...

Вәли сөйләде болай:
— Басуга чыктым, малай,
Алдым кулыма тургай,
Кушылды аңа курай.
Ник көләсең? Нәкъ шулай!
Нәкъ шулай иде бугай...

## Маймун

Җитмәгән җире
Аның бар микән,
Агачка менгән —
Урам тар микән?

Маймун ботакка
Асылып тора,
Чи-чи кычкырып
Атынып тора.

Үчекләп ала,
Мыскыллап кала,
Кеше көлдерсә,
Шул җиткән аңа...

Кыланмышыннан
Тәмам арыйлар:
— Маймылланма! — дип,
Бармак яныйлар.

Ахрысы, шундый
«Эшләр»дән арып,
Зоопаркта
Ял иткән барып.

Монда да шул ук
Иске гадәте —
Маймылга малай
Биргән тәмәке...

Тегесе дә бит
Кызыгын тапкан,
Төтен пошкыртып
Тәмәке тарткан.

Бер абый моны
Күзәтеп торган:
— Маймүнләнмә! — дип,
Колагын борган.

## Сөзгәк

Сөзмичә бәти
Ничек чыдасын —
Маңгай кычыта,
Мөгез чыгасы!

Сөзә мине дә,
Сөзә диванны,
Үпкәләмим дә,
Аңлыйм мин аны.

Ә Мәгазь исә,
Мәгазь ул бүтән,
Мәгазь ул усал,
Усал ул күптән.

Исәп-хисапны
Өзеп йөри ул,

Кем юлыкса да,
Сөзеп йөри ул.

Усал тәкәдәй
Килә каршыңа,
Тик шул уй гына
Аның башында.

Яшь үгез, очрап,
Үз ишен сизгән,
Маңгай кычыткач,
Мәгазьне сөзгән!

Ахры, сөзгәккә
Шактый ук тигән —
Өркә ул хәзер
Хәтта бәтидән!

## «Әлләкем»

Шәвәли рәсем ясый,
Сакаллы... мәче ясый!
— Бигрәк әкәмәт икән!
Мыегы кая киткән?
— Кәҗәгә бүләк иткән.
Үзара аңлашканнар,
Кызык дип алмашканнар.
Кәҗә әйткән: «Мә»! — дигән,
Мөгезләрен дә биргән.
Мәче бик тә шатланган,
Дусларына мактанган:
— Менә мин, күрдегезме, —
Мин берүзем мөгезле!
Мин-мин, дигән, сакаллы,
Мин-мин, дигән, акыллы!
Акыллырак та бәлкем,
Мин бит хәзер — Әлләкем!

Акбай килгән тавышка:
— Һау-һау, иске танышлар!

Мәчеләр пыр тузганнар,
Кайсы кая сызганнар.
Әлләкем дә китмәкче,
Рәшәткәдән үтмәкче.
Сыймыенча мөгезе,
Торып калган берүзе...
— Мин-мин-мин белмим сезне,
Мин-мин, дигән, мөгезле,
Мин-мин, дигән, сакаллы,
Мин-мин, дигән, акыллы.
Акыллырак та бәлкем —
Мин бит, мин бит — Әлләкем!

Акбай исеннән сизгән —
Мәче койрыгын өзгән.
Кыскаргачтын койрыгы,
Искә төшкән мыегы:
Мыегы сыйган җирдән
Ул бит бик иркен йөргән!

Мәчеләр читтән күргән,
Мәчеләр ятып көлгән!
— Мәчеләр ничек көлгән?
— Мияу-мияу, дип көлгән,
Эчләрен тотып көлгән!
Кыска койрык — Әлләкем!
Озын мөгез — Әлләкем!
Әлләкем дә Әлләкем —
Түгелсендер дә, бәлкем?
Ник берәрсе жәлләсен...
Әйткәннәр, бүтән бер дә
Мөгез чыгарып йөрмә!

...Шәвәли рәсем ясый,
Тагын ул нәрсә ясый?

## Чит җирләр күргән карга

Үзе әле яшь карга,
Тулган тик бер яшь аңа,
Ә инде күпне күргән,
Чит илләрдә дә йөргән!
Быел очасыларга
Сөйләр нәрсәсе бар ла!
Сөйли яшьләргә карга,
Томшык ачып тыңлыйлар,
Чит җирләрне сорыйлар:
— Гаҗәптер, диләр, анда,
Рәхәттер, диләр, анда!

Дәшми тора да карга,
Болай дия аларга:
— Безнең туган якларда
Җиңелрәк канатларга!

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Татарстан язучылары партия оешмасының январь аенда үткәрелгән ачык партия җыелышында «КПСС Үзәк Комитетының партиягә һәм совет халкына мөрәҗәгате» уңае белән язучылар партия оешмасының бурычлары» дигән көн тәртибе куеп тикшерелде.

Җыелышта С. Хаким, А. Хәсәнова, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, З. Нури чыгыш ясадылар. Язучыларның хезмәт коллективлары белән бәйләнешен тагын да ныгыту, Әлмәт нефтьчеләре, КамАЗ төзүчеләр, Буа районы хезмәт ияләре белән дуслык, хезмәттәшлек элемтәләре урнаштыру турында карар кабул ителде.

## СССР ХУДОЖЕСТВО АКАДЕМИЯСЕНДӘ

СССР Художество академиясе президиумы татар рәссамы — СССР Верховный Советы депутаты, РСФСР художниклары союзы идарәсе секретаре, ТАССР художниклары союзы идарәсе председателе Харис Габдрахман улы Якуповны Академиянең член-корреспонденты итеп сайлады.

Харис Якуповның иҗаты Татарстанда гына түгел, ил күләмендә билгеле. 1947 елдан башлап аның әсәрләре республика, зона, бөтен Россия, бөтен Союз күргәзмәләрендә күрсәтелә. Аның әсәрләрен тугандаш социалистик илләрдә дә беләләр — алар Монголиядә, Польшада, Югославиядә һ. б. чит ил күргәзмәләренә куелды.

## МУСА ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯ

СССР журналистлары союзының Оренбург өлкә оешмасы идарәсе Оренбург комсомол оешмасында тәрбияләнгән Советлар Союзы Герое, шагыйрь һәм журналист Муса Җәлил исемендәге премия булдырды. Бу премия белән шәһәр һәм авыл хезмәт ияләренең социалистик ярышын оештыруда һәм яктыртуда актив катнашкан авыл һәм эшче хәбәрчеләре, күп тиражлы, шәһәр, район һәм өлкә газеталары, телевидение һәм радио журналистлары бүләкләнәчәк.

1974 елдан башлап ел саен матбугат көнендә дүрт премия тапшырылачак.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Татарстан язучылары союзы идарәсе каршындагы проза секциясенең чираттагы утырышында Әнәс Галиевнең «Койрыклы кеше» романы тикшерелде. Фикер алышуларга катнашкан А. Расих, Н. Фәттах, Б. Камалов, К. Тимбикова, М. Насыйбуллин һ. б.лар әсәрнең уңай һәм кимчелекле якларын күрсәттеләр, авторга файдалы киңәшләрен әйттеләр. кабат эшкәрткәннән соң, бастырып чыгару өчен Татарстан китап нәшриятына тәкъдим итәргә мөмкин дигән карарга килделәр.

## ПОЧЕТЛЫ ДИПЛОМ

СССР оештырылуга 50 ел тулу уңае белән иң яхшы җырларга бөтен Союз конкурсы үткәрелгән иде. Жюри комиссиясе председателе А. Пахмутова, членнары: К. Хачатурян, Л. Ошанин, С. Туликов һ.б.лар Нури Арсланов сүзләренә Рөстәм Яхин язган «Бөек якташыбыз» дигән җырны Почетлы диплом белән бүләкләнергә лаек дип таптылар.

## КАЗАКЪ ТЕЛЕНДӘ

Казагыстан ССРның «Жазусы» китап нәшрияты бөек татар шагыйре Габдулла Тукай әсәрләре җыентыгын казакъ телендә бастыру өчен әзерләде. Китапка шагыйрьнең халык яратып укый торган барлык шигырьләре һәм поэмалары кертелгән.

## КамАЗ ТУРЫНДА КҮРГӘЗМӘ

Мәскәүдә, Журналистлар йортының күргәзмә залында рәссам-репортерларның яңа әсәрләре күргәзмәсе ачылды. Экспозициянең зур өлешен СССР журналистлары союзы премиясе лауреаты Игорь Пчелконың «КамАЗ төзүчеләр» дигән әсәрләре алып тора. Анда төзелеш алдынгылары, завод күренешләре, Кама пейзажлары сурәтләнә.

## ЯЗУЧЫЛАР ЭШЧЕЛӘР ЯНЫНДА

М. Вахитов исемендәге химия комбинатында өч буын вәкилләре очрашты. Бу очрашуга комбинатның элекке слесаре шагыйрь Мөхәммәт Садри, элекке техникы РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы Венера Шәрипова, элекке монтеры композитор Мәсгут Латыйпов, шагыйрьләрдән Галимҗан Латыйп, Мәхмүт Хөсәен һәм Мөнип Шәймөхәммәтов катнаштылар. Очрашуга катнашучы эшчеләр, инженертехник хезмәткәрләр шагыйрьләрнең бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинга багышланган әсәрләрен зур кызыксыну белән тыңладылар.

## ИҖАТ КИЧӘСЕ

Актерлар йортында Татарстанның атказанган артисткасы Зифа Басыйрованың иҗат кичәсе булды. Бөтен Россия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге һәм сәхнә ветераннары Советы оештырган бу кичәдә Зифа Басыйрова татар халык җырларын, композиторларыбыз әсәрләрен башкарды.

## ГАЛИМНЕҢ ИӨЗ ЕЛЛЫГЫ

Республиканың фән, мәгариф һәм культура җәмәгатьчелеге күренекле мәгърифәтче, галим һәм педагог, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, профессор Мөхетдин Корбангалиевнең тууына 100 ел тулуны киң итеп билгеләп үтте. Шул уңай белән Казан дәүләт университетының Актлар залында СССР Фәннәр академиясе Казан

филиалы тел, әдәбият һәм тарих институты, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты, Казан дәүләт педагогия институтының татар теле кафедраларының берләштерелгән утырышы булды. Утырышта филология фәннәре докторы, профессор В. Хаков «Профессор Корбангалиевнең тормышы һәм эшчәнлеге», филология фәннәре кандидаты Ш. Ханбикова «М. Корбангалиев — тел галиме», педагогика фәннәре кандидаты Ф. Вәлиева «М. Корбангалиев — методист һәм педагог» дигән темаларга доклад ясадылар.

## ГАДЕЛ КУТУЙНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Республикабыз җәмәгатьчелеге күренекле драматург, шагыйрь һәм прозаик Гадел Кутуйның туууына житмеш ел тулу көнен киң итеп билгеләп үтте, мәктәпләрдә, югары уку йортларында, китапханәләрдә бу уңай белән әдәби кичәләр үткәрелде, китап күргәзмәләре оештырылды.

Татарстан язучылары союзы, ТАССР Культура министрлыгы һәм Бөтен Россия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Г. Кутуйга багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрде. Кичәне кереш сүз белән Гази Кашшаф ачты. Филология фәннәре кандидаты Баян Гыйззәт язучының тормышы, иҗади-иҗтимагый эшчәнлеге турында доклад ясады. Соңыннан республикабыз сәнгать осталары Г. Кутуй әсәрләрен башкардылар.

* * *

Түбән Камада «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе, шәһәрнең культура бүлеге белән берлектә, Г. Кутуйның туууына 70 ел тулу юбилеена багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрде.

Язучының тормышы һәм иҗаты турында докладны әдәби берләшмә члены яшь шагыйрә Альбина Мортазина сөйләде.

Р. Имаев, С. Фәнзаман, Р. Хисмәтуллин, Ф. Абдуллин, А. Мортазина, М. Шәйхи һәм Чаллыдан килгән кунаклар, «Лэйсэн» әдәби берләшмәсе членнары Х. Хөснуллин, Р. Хисамиевлар үзләренең әсәрләрен укыдылар. Соңыннан шәһәрнең үзешчән сәнгать көчләре катнашында зур концерт булды.

* * *

Оренбург шәһәренең Хөсәен Ямашев исемендәге китапханә бинасында да күренекле язучы Гадел Кутуйның туууына 70 ел тулу уңае белән әдәби кичә үткәрелде.

Гадел Кутуйның тормыш һәм иҗат юлы турында китапханә каршындагы әдәбиҗат түгәрәге җитәкчесе инженер Зиннур Шакиров доклад ясады. Китапханә уку залы мөдире Лия Рафикова язучының күп тармаклы әдәби мирасы һәм китапханәдәге әсәрләре белән таныштырып чыкты.

РСФСРның атказанган артисты В. Фатыхов Гадел Кутуй белән Казанда очрашуы һәм язучының нинди драма әсәрләре Оренбург театры сәхнәләрендә куелуы турында сөйләде.

Персональ пенсионер Тәүфыйк Сабитов әле Кутуевлар гаиләсе Самарада (Куйбышев) яшәгән вакытта яшь Гаделша белән кызыклы очрашуы турындагы истәлеген уртаклашты.

Оренбург татар драма театры артистлары язучының «Тапшырылмаган хатлар» повесте буенча инсценировка куйдылар.

Китапханә залында «Кайнар көннәр жырчысы» дигән баш астында Г. Кутуй иҗатына багышланган әдәби күргәзмә оештырылган иде.

## РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИНГА 50 ЯШЬ

Татарстан җәмәгатьчелеге күренекле каләм остасы Рафаил Төхфәтуллинга 50 яшь тулу юбилеен билгеләп үтте. Нефть якларындагы мәктәпләрдә, китапханәләрдә аның иҗади эшчәнлегенә багышланган күргәзмәләр, әдәби кичәләр үткәрелде.

Әлмәт шәһәренең Техника йортында юбилей кичәсе булды. Р. Төхфәтуллинның иҗат юлы турында Шамил Бикчурин доклад белән чыкты. ТАССР Верховный Советы Президиумы члены, Татарстан язучылары союзы идарәсе председателе шагыйрь Зәки Нури СССР Верховный Советы Президиумы исеменнән язучы Рафаил Төхфәтуллинга «Почет билгесе» ордены тапшырды.

Татарстан язучылары союзы һәм «Казан утлары» журналы исеменнән Г. Ахунов, «Татнефть» берләшмәсе начальнигы урынбасары Ү. Саттаров, башкорт язучысы Гали Ибраһимов, КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре Р. Галиев, Татарстан язучыларының Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Ә. Маликов, 8 нче трест парткомы секретаре Ф. Закиров, шагыйрә һәм укытучы Э. Мөэминова, Азнакай нефтьчеләре исеменнән язучы Мәхмүт Хәсәнов, шагыйрь Мәхмүт Хөсәен, Әлмәт театрының баш режиссеры Ленар Садриев һәм башкалар юбилярны кайнар котладылар, аңа адрес папкалары, кыйммәтле бүләкләр тапшырдылар. Шагыйрә С. Сөләйманова Советлар Союзының төрле почмакларыннан юбиляр исеменә килгән телеграммаларны укыды. Җәмәгать эшендә актив катнашуы һәм нефтьчеләр турында яхшы әсәрләр иҗат иткәне өчен КПССның Әлмәт шәһәр комитеты һәм хезмәт ияләре дпеутатларының шәһәр башкарма комитеты язучы Рафаил Төхфәтуллинны Мактау грамотасы белән бүләкләде. Соңыннан район үзешчән сәнгать коллективы кичәдә катнашучылар өчен зур концерт бирде.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Сарман районында татар әдәбияты атналыгы үткәрелде. Атналыкта нефть якларында яшәүче язучылардан Юныс Әминов, Мәхмүт Хәсәнов, Сәет Кальметов, яшь язучы Хәниф Хәйруллин һәм Казаннан шагыйрь Рөстәм Мингалимов катнашты. Язучылар район үзәгендәге культура йортында, Нөркәй совхозы, «1 Май», «Урнәк», Серго һәм Муса Җәлил исемендәге

колхоз клубларында игенчеләр, механизаторлар белән очраштылар, әсәрләрен укыдылар. Драматург Юныс Әминов тыңлаучыларны бүгенге татар әдәбиятының торышы белән таныштырды.

Алар шулай ук Азалак, Сарман, Нөркәй, Мортамак, Каташ-Каран, Ләшәү-Тамак һәм Ләке авыл мәктәпләре коллективлары алдында чыгышлар ясадылар, укучыларны кызыксындырган күп төрле сорауларга җаваплар бирделәр.

* * *

Әлмәт татар дәүләт күчмә театры артистлары һәм Әлмәттә яшәүче язучылар иҗади очрашу, фикер алышу үткәрделәр. Анда театрның быелгы премьералары турында сүз барды. Башкорт драматургы Ә. Атнабаевның «Игезәкләр», Н. Исәнбәтнең «Рәйхан», чех драматургы И. Букочанның «Таң атәче кычкырганчы» (Р. Төхфәтуллин тәрҗемәсе) дигән әсәрләре буенча куелган спектакльләр турында язучылар Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, Г. Афзал, С. Сөләйманова үзләренең фикерләрен, киңәшләрен әйттеләр.

* * *

Әлмәттәге 9 номерлы урта мәктәптә үткәрелгән поэзия сөючеләр клубының чираттагы утырышында шагыйрь Әдип Маликов чыгыш ясады. Яшь әдәбиятчыларны ул нефть якларында яшәүче язучыларның иҗатлары белән таныштырды. Укучылар Әлмәт шагыйрьләренең шигырьләрен сөйләделәр, поэмалардан өзекләр башкардылар.

* * *

Баулыдагы 5 нче трестның 31 номерлы төзү-монтаж идарәсе төзүчеләре алдында драматург Юныс Әминов һәм әдәби берләшмә членнары чыгыш ясадылар.

## «ӘЛЛҮКИ» ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕНДӘ

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты каршындагы «Әллүки» әдәби берләшмәсенең чираттагы утырышында яшь каләмнәрдән Р. Исламшин хикәяләре һәм Н. Акмалов шигырьләре тикшерелде.

Утырышта татар әдәбияты кафедрасы укытучыларыннан профессор И. Нуруллин белән доцент З. Мәҗитов катнашты.

* * *

Иҗат көчләрен барлау максаты белән, «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсендә «Шигъри сабан туй» дип аталган ачык конкурс үткәрелде. Декабрь башында булып узган бу кичәдә унбишләп яшь автор үзләренең шигырьләрен укыдылар. Жюри беренче урынны журналистика бүлегенең II курс студенты Фәйрүзә Мөслимовага бирде.

Жюри составына шагыйрьләрдән С. Хәким, И. Юзеев, Р. Гатауллин, берләшмә җитәкчесе доцент З. Мәҗитов һәм Татарстан радиокомитетыннан Г. Әхмәтҗановлар бар.

Соңыннан С. Хәким студентларга яңа поэмасын укыды.

## КАЗАКЪ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНДӘ ТАТАР ӘДИПЛӘРЕ

Казагыстан ССР Фәннәр академиясе Казакъ совет энциклопедиясенең II томын бастырып чыгарды. Бу томда татар әдәбияты һәм сәнгате вәкилләре турында да шактый гына материаллар кертелгән. Мәсәлән, укучылар бу энциклопедиядән Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Ф. Әмирхан, Г. Бәширов, РСФСРның халык артисткасы М. Булатова, драматург Ф. Бурнаш һ. б.ларның тормышы, иҗади эшчәнлеге белән таныша алалар.

Алар турындагы мәкаләләрне филология фәннәре докторы, профессор Б. Кенжебаев, филология фәннәре докторы, профессор Т. Нуртазин, филология фәннәре кандидаты Б. Исхаков, танылган казакъ шагыйрьләреннән Ж. Сыздыков, С. Машаков, журналист Б. Мәжитов һ. б.лар язган.

## «ЮМАРТ ЖИР»

Шул исем астында «Кыргызстан» нәшрияты Татарстан язучыларының хикәяләр җыентыгын кыргыз телендә бастырып чыгарды. Җыентыкка кертелгән Г. Әпсәләмов, Г. Ахунов, В. Байдерин, Г. Бәширов, Я. Винецкий, Д. Зөбәерова, Р. Ишморатова, Э. Касыймов, Р. Кутуй, М. Маликова, Г. Минский, Я. Мостафин, С. Сабиров, Х. Сарьян, М. Хәбибуллин, Ф. Хөсни, Ә. Шамин хикәяләрен М. Ормонбеков, С. Сыдыгалиев, О. Жекгиенов, Б. Сиксәнбаев, А. Разеева, Ж. Алыкулов, Т. Байзаков, К. Кадыркулова һәм Т. Тургуналиев тәрҗемә иткән.

Җыентыкны Ш. Абдылдаев төзегән. 312 бит, бәясе 45 тиен.

## КОМПОЗИТОРЛАР СОЮЗЫ ПЛЕНУМЫ

Татарстан композиторлары союзының XII пленумы иҗади ел йомгакларына һәм КПССның XXIV съезды карарларын һәм КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарын үтәү актуальлыгында музыкаль тәнкыйть мәсьәләләренә багышланды.

Пленумны кереш сүз белән ТАССР композиторлары союзы идарәсе председателе Н. Җиһанов ачты.


Пленум утырышында сәнгать фәннәре кандидаты Г. Касаткина «Татарстан композиторларының симфоник һәм камера-инструменталь иҗатлары», композитор Р. Яхин «Татарстан композиторлары иҗатында вокаль жанры», сәнгать фәннәре кандидаты Ч. Бәхтиярова «КПССның XXIV съезды карарларын һәм КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарын үтәү яктылыгында музыкаль тәнкыйтьнең торышы һәм алдагы бурычлары» дигән докладлар белән чыктылар. Аннары тикшерелә торган мәсьәләләр буенча фикер алышулар булды.


Пленум утырышында КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев, ТАССР Культура министры Ә. Миндубаев катнашты.

# ӨЗЕЛГӘНСЕҢ СИРЕНЬНӘН

**НӘҖИП ҖИҺАНОВ** музыкасы

**СИБГАТ ХӘКИМ** сүзләре






Яулыкларың
әллә синең,
әллә синең
чигелгән. (2)

Юлларыңа
әллә сирень,
әллә сирень
сибелгән.

Сине күреп
һәммәсе дә,
һәммәсе дә
сөенгән. (2)

Шатлыкларын
әле дә сөйли,
әле дә сөйли
сиреньнәр.

Яшь миндә
синең тавыш,
синең сагыш,
синең сүз. (2)

Мөмкин түгел:
ничек таныш,
ничек кавыш
сиреньсез.

Балкый хәтта
үзеңнән соң,
үзеңнән соң
синең ямь. (2)

Әллә инде
өзелгәнсең,
өзелгәнсең
сиреньнән.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210